Татарстан Фәннәр академиясенең
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты

# ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ ТАРИХЫ

Казан – 2017

УДК 37.013/017
ББК 74.03
Т 23

**Фәнни редактор:** тарих фәннәре докторы *Р.С.Хәкимов*

**Җаваплы редакторлар:**

педагогика фәннәре кандидаты *М.М.Гибатдинов*,
педагогика фәннәре кандидаты *Л.Р.Мортазина*

**Рецензентлар:**

*Р.Х.Шәймәрданов*, педагогика фәннәре докторы (Сургут)
*Г.Т.Хәйруллин*, педагогика фәннәре докторы (Алматы)
*И.Э.Ярмәкәев*, педагогика фәннәре докторы (Казан)

**Авторлар:**

*Мортазина Л.Р.*, пед. фән. кандидаты (кереш мәкалә, V.1.1; V.1.5; VI.1)
*Абызова Р.Р.*, филол. фән. кандидаты (I; II)
*Сафина А.М.*, филол. фән. кандидаты (III)
*Лотфуллин М.В.*, физ.-мат. фән. кандидаты (VI.2)
*Зиннәтуллина А.Ә.* (IV; V (кереш); V.1.2; V.1.3; V.1.4; V.2)
*Әхтәмова А.В.*, тарих фән. кандидаты (V.3)
*Гибатдинов М.М.*, пед. фән. кандидаты (тарих укыту –
IV; V.1.3; V.3; VI.1.3; VI.2)
*Садыйков Ш.Ф.*, пед. фән. кандидаты (җәмгыять белемен укыту –
V.1.3; V.2; V.3; VI.1.3; VI.2)
*Мөхәммәтҗанова Д.С.* (VI.1.6)
Шулай ук тарих фән. кандидаты *Измайлов Б.И.* материаллары кулланылды

**Татар педагогик фикере тарихы.** – Казан: ТФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017. – 308 б.

ISBN 978-5-94981-258-7

Әлеге китапта татар педагогик фикере тарихының төп этаплары һәм аларга хас булган үзенчәлекләр чагылыш тапты. Шулай ук халкыбызның укыту-тәрбиягә караган карашлары һәм татар педагогларының милли тәрбиягә багышланган хезмәтләренә анализ бирелде, аларны хәзерге заман шартларында куллану юллары күрсәтелде. Хезмәт укытучыларга, тәрбиячеләргә, ата-аналарга һәм татар мәгарифе тарихы белән кызыксынучы киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим ителә.

© Авторлар, 2017
© ТФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институты, 2017

# ЭЧТӘЛЕК


УКУЧЫЛАРГА ........ 4

ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ
МЕТОДОЛОГИК НИГЕЗЛӘРЕ ........ 5

I. БОРЫНГЫ ТӨРКИ ЧОРДА ПЕДАГОГИК ФИКЕР ........ 13

II. УРТА ГАСЫРЛАРДА ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ ........ 16

III. XVI–XVIII ГАСЫРЛАРДА ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ ........ 30

IV. XVIII ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР МӘГАРИФЕ ........ 52

V. СОВЕТ ЧОРЫНДА ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ ........ 92

1. Татар мәгариф системасы: мәктәп-мәдрәсәләрдән
бердәм дәүләт мәктәбенә (1917–1938) ........ 102

1.1. Укый-яза белмәүчелекне бетерү ........ 102

1.2. Мәктәпкәчә тәрбия ........ 107

1.3. Гомуми урта белем бирү мәсьәләләре ........ 120

1.4. Педагогик кадрлар хәзерләү мәсьәләсе ........ 141

1.5. Татар телендә югары белем бирү (1920–1930 еллар) ........ 156

2. Совет мәгарифе: татарлаштырудан
үзәкләштерүгә таба (1938–1958) ........ 163

3. Бердәм совет халкы төзү чорында
татар мәгарифе (1958–1989) ........ 176

VI. XX ГАСЫР АХЫРЫ – XXI ГАСЫР БАШЫНДА
ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ ........ 193

1. Татар мәгарифе үсеше (1990–2005) ........ 193

1.1. Татар мәгарифе үсеше концепцияләре ........ 204

1.2. Мәктәпкәчә тәрбия ........ 210

1.3. Гомуми белем бирү мәсьәләләре ........ 219

1.4. Татар телендә һөнәри белем бирү мәсьәләләре ........ 236

1.5. Татар милли университетын төзү мәсьәләләре ........ 248

1.6. Дини мәгариф системасы ........ 255

1.7. Татар педагогикасы өлкәсендә фәнни эзләнүләр ........ 259

2. Хәзерге чорда милли мәгариф (2005 елдан соң) ........ 266

Әдәбият исемлеге ........ 289

История татарской педагогической мысли (аннотация) ........ 306

The History of Tatar Educational Thought (annotation) ........ 307

# УКУЧЫЛАРГА

Татар педагогик фикере тирән тамырлы, бай тарихка ия. Бик борынгы чорларда барлыкка килеп, гасырлар дәвамында үскән, камилләшкән мәгариф системасы һәрдаим татар халкының милли үзаңын саклауга ярдәм итеп килгән. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татар җәмгыятендәге яңарышка нигезле җирлекне нәкъ менә мәгариф системасы булдырган. Мәгариф өлкәсен яңартудан башланган реформалар, нәтиҗәдә, бөтен татар җәмгыятенең тамырдан яңаруына китерә. Татар мәгарифе төрле чорларда Россия империясе, совет дәүләте системасы астында яшәп тә, билгеле бер дәрәҗәдә сакланып, үз йөзен саклап кала алган, татар халкының милләт булып формалашуына ярдәм иткән, халыкны алгарышка этәргән. XX гасыр ахырында Татарстан Республикасының статусы үзгәрү белән, Федераль үзәк белән ике арада төзелгән Килешү нигезендә татар мәгариф системасы тиз арада яңадан торгызылып, яңа дәрәҗәгә күтәрелә, нык үсеш ала. Татарстанның һәм, гомумән, татар халкының соңгы 20 ел эчендәге мәгариф өлкәсендәге казанышлары киләсе еллар өчен ныклы нигез салды дияргә мөмкин.

Заманында татарларның үз милли йөзен саклап кала алган хәлдә Россиянең һәм ислам дөньясының иң алдынгы, прогрессив халыкларына әйләнә алуларында да мәгариф системасының роле зур була. Алай гына да түгел, татарлар башка төрки халыкларны агартуга да шактый зур өлеш керткәннәр.

Бүген дә татарлар моннан йөз ел, ике йөз ел элек эшләгән кебек эшләргә: туган телебезне һәм башка төрки телләрне, рус һәм инглиз телләрен яхшы үзләштерергә, дөньяның иң яхшы галимнәре һәм университетлары белән хезмәттәшлек итәргә, һөнәри эшчәнлекләрендә алдынгы технологияләрне файдаланырга тиешләр. Бүген татар мәктәбе бары тик конкурентлыкка сәләтле шәхес әзерләгән очракта гына республика һәм татар халкы үсешенең мөһим чыганагы була ала.

Бүгенге көндә татар педагоглары, җәмәгатьчелек, ата-аналар алдына куелган төп бурычларның берсе – халкыбызның тәрбия өлкәсендә гасырлар буе тупланып килгән бай мирасын, педагогик тәҗрибәсен өйрәнеп, андагы милли-мәдәни кыйммәтләребезне үзләштереп, аларны заманча шартларга яраклаштырып, укыту һәм тәрбия бирүдә файдалану. Әлеге китап сезгә бу юнәлештә башкарган эшләрегездә ярдәмче булыр дип ышанабыз.

*Рафаил Хәким*

тарих фәннәре докторы, ТФА вице-президенты,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры

# ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕН ӨЙРӘНҮНЕҢ МЕТОДОЛОГИК НИГЕЗЛӘРЕ

Татар халкының мәгариф өлкәсендәге бай мирасын, гасырлар дәвамында тупланган педагогик фикерен өйрәнүнең үзенчәлекле тарихы бар. Ул галимнәр В.М.Горохов, Я.И.Ханбиков, Ә.Н.Хуҗиәхмәтов һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш таба[1]. В.М.Горохов революциягә кадәрге татар мәгарифе үсешенең аерым сәхифәләренә, аерым алганда, мәктәп-мәдрәсә тарихына тукталса, Я.И.Ханбиков, татар педагогикасы тарихында беренче тапкыр буларак, XI гасырдан алып XX гасырның беренче яртысына кадәрге вакыт аралыгында педагогик фикер үсеше тарихын, аерым педагогларның эшчәнлеген өйрәнде. Әмма бу хезмәтләр, кыйммәтле чыганак булсалар да, совет идеологиясеннән азат булмау һәм, иң мөһиме, педагогик фикер киңлеген тулаем колачлап бетермәү сәбәпле, заманча фән таләпләренә җавап бирә алмыйлар.

XX гасырның 90 нчы елларында проблема яңача күзлектән чыгып өйрәнелә башлады. Бу чорда татар педагогик фикере үсешен XI гасырдан да иртәрәк чорга бәйләп карауның дөреслеге галимнәр тарафыннан расланды[2].

Бүгенге көндә «татар педагогик фикере», «татар педагогикасы» төшенчәләрен аңлауда беркадәр төрлелек күзәтелә. Беренче караш буенча, татар педагогик фикеренең нигезен татар мәгарифенең үсе-

---

[1] Горохов В.М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. – Казань: Таттгосиздат, 1941. – 170 с.; Горохов В.М. Школьное образование среди татар Поволжья в XIX и в начале XX века. – Казань, 1947. – 50 с.; Горохов В.М. Педагогика тарихыннан очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 124 б.; Ханбиков Я.И. Из истории педагогической мысли татарского народа. – Казань, 1967. – 232 с.; Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 287 б. һ.б.

[2] Шарафутдинов З.Т. Педагогическое пространство татарского народа. – Казань, 2000. – 180 с.; Маликов Р.Ш. Тюрко-татарская гуманистическая педагогическая мысль средневековья. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. – 304 с.; Мухаметшин А.Г. Становление и развитие педагогической мысли татарского народа в Казанском крае в VIII – нач. XX в.: автореф. дис. ... докт. пед. наук. – Н.Новгород, 2009. – 29 с.

шен тәэмин иткән, аның эчтәлеген, тарихын төрле яклап өйрәнгән һәм күзалларга мөмкинлек биргән, татар телендә язылган хезмәтләрдә чагылыш тапкан фикерләр тәшкил итә. Кайбер очракларда бары тик педагогның милләтенә карап кына аның урынын билгеләү дә күзәтелә (татар милләтеннән булган, әмма гомумән мәгариф проблемаларына багышланган хезмәтләр язучы галимнәр). Төрле чорларда татар мәгарифе үсешенә өлеш керткән башка милләт педагогларының (XVIII–XIX гасырларда хезмәт күрсәткән рус һәм Европа галимнәре В.Радлов, К.Фукс, Н. Бобровников һ.б., татар мәгарифе өлкәсендә эшләүче бүгенге чор галимнәре В.М.Беркутов, И.Л.Литвинов һ.б.) шулай ук татар педагогик фикере үсешендә билгеле урыннары бар. Дөнья тәҗрибәсенә килгәндә, гомумән милли мәгариф үсешенә йогынты ясаган педагогларның эшчәнлеге, барлык башка милли мәгарифләр белән бергә, татар педагогик фикере үсешендә дә чагылыш таба (А. Дистервег һ.б.). Безнең карашка, биредә төп үлчәм булып хезмәтләрнең татар мәгарифе мәсьәләләренә багышлануы торырга тиеш.

Татар педагогик фикере, татар мәгарифе һәм мәктәбе тарихыннан аермалы буларак, халыкның төрле чорларда тәрбия, белем бирүгә, мәгариф үсешенә йогынты ясаган һәм бер үк вакытта мәгариф үсешен, аның үзенчәлекләрен чагылдырган фикерләре ул. Педагогик фикер аерым педагогларның хезмәтләрендә, рәсми документларда чагылыш таба, төрле чорларда татар мәгарифенең җәмгыять үсешендә тоткан урынын ачыкларга мөмкинлек бирә.

Татар педагогик фикерен өйрәнүдә әһәмиятле ысулларының берсе – фәнни-гамәли юнәлештәге басмалар әзерләү. Болар: татар галимнәренең педагогика, мәгариф, белем бирү һәм тәрбиягә багышланган хезмәтләрен бастырып чыгару, төрле авторларның хезмәтләреннән тупланган җыентыклар әзерләү һ.б. Әлеге юнәлештә башкарылган хезмәтләр арасында уникаль басма – «Татар педагогик фикере антологиясе»[3] дә бар.

Педагогик фикерне барлау һәм комплекслы өйрәнүнең, чагыштырмача яңа юнәлеш булса да, үзенчәлекле тарихы бар. Бу юлда башкарылган хезмәтләрдән XX гасырның 80 нче елларында беренче тапкыр серия буларак чыга башлаган күптомлы СССР халыклары

---

[3] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 407 б.; Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 2 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 486 б.

педагогик фикере антологияләрен атарга мөмкин. Әлеге басмалар борынгы чорлардан алып XX гасырның 80 нче елларына кадәр булган вакыт аралыгында СССР күләмендә педагогик фикер тарихын һәм фикер үсешенә өлеш керткән күренекле педагогларның хезмәтләрен яктыртуда беренче адым булып тора. Аның беренче томы Борынгы Русь һәм XIV–XVII гасырларда Рус дәүләтендә педагогик фикер үсешен тасвирлауга багышланган[4]. Моннан соң дөнья күргән басмалар союздаш, аерым алганда, Белоруссия, Украина, Грузия, Кыргызстан, Үзбәкстан һ.б. республикаларның педагогик мирасын тәкъдим итә.

Гомумән алганда, бу антологияләрне нәшер итүдә төп максат булып һәр совет республикасының педагогик мирасын туплау һәм системага салу, борынгы заманнардан алып әлеге басмалар дөнья күргән чоргача аерым халыкларның тәрбия һәм белем бирүгә караган карашлары, мәгариф үсешенең торышы белән таныштырудан гыйбарәт. Проект авторларының фикеренчә, антологияләрне эшләү күпмилләтле илнең педагогик мирасы байлыгын һәм төрлелеген күрсәтергә, аны танытырга мөмкинлек бирәчәк. Шул ук вакытта, төрле халыкларның педагогик фикере үсешендәге охшашлыклар белән беррәттән (ә алар, билгеле булганча, совет чоры педагогикасы үсешендә шактый), беркадәр милли үзенчәлекләрне дә күрсәтү мөмкинлеге ачылачак[5]. Басмаларның яңалыгы да, беренче чиратта, шуның белән билгеләнә. 80 нче елларның икенче яртысында басылып чыккан антологияләр совет идеологиясенә нигезләнсәләр дә, аларда һәрбер милләткә аерым якын килергә тырышу, укыту-тәрбия өлкәсендәге кайбер милли үзенчәлекләрне күрсәтү омтылышы күзәтелә.

Әлеге антологияләр төрле халыкларда педагогик фикер үсешен күпмедер дәрәҗәдә күз алдына китерергә мөмкинлек бирсәләр дә, илдәге һәр халык өчен дә төзелмәүләре һәм милли үзенчәлекләргә игътибарның аз булуы сәбәпле илдәге тулаем педагогик фикер үсешен колачлый, аның тарихынербөтен картина буларак чагылдыра алмыйлар. Мәсәлән, Россия педагогик фикере антологияләре, кайсы чорны колачлавына карамастан, бары тик рус педагогик фикере үсешен генә чагылдыра. Хәзерге заман фәне өчен, беренче чиратта,

---

[4] Антология педагогической мысли Древней Руси и Русского государства XIV–XVII вв. / Сост. С.Д.Бабишин, Б.Н.Митюров. – М.: Педагогика, 1985. – 363 с.

[5] Антология педагогической мысли Белорусской ССР / Сост. Э.К.Дорошевич, М.С.Мятельский, П.С.Солнцев. – М.: Педагогика, 1986. – С. 5.

аерым милләт һәм халыкларның педагогик фикере үсешен өйрәнү кыйммәтле һәм зур кызыксыну тудыра. Бүген аерымлыкларны өйрәнү нигезендә гомумиләштерү, ягъни аерым милләтләрнең педагогик мирасын өйрәнеп, аларның гомумпедагогик (бу урында: ил күләмендәге) киңлектә тоткан урынын ачыклау аеруча мөһим.

Гомумпедагогик фикер киңлегеннән читтә калган милли педагогикалар үсешен күрсәтү тарихи дөреслекне торгызу өчен дә әһәмиятле. Нәкъ менә шул сәбәпле Россиядә яшәүче башка милләтләр – татарлар, башкортлар, марилар, чувашлар, якутлар, удмуртлар, тувалылар һ.б. ның педагогик фикерен туплау, өйрәнү мөһим. Әмма, кызганычка каршы, бу өлкәгә бүгенге көндә игътибар бик аз бирелә.

Татар педагогик фикерен ачыклауда төп игътибар бай тарихлы, элек-электән үк гыйлем алуга омтылган, үз исәбенә мәктәп-мәдрәсәләр тоткан, революциягә кадәр үк укый-яза белү дәрәҗәсе буенча Россиядәге башка милләтләр арасында алгы урыннарны яулаган татар милләтенең педагогик мирасын барлау, педагогик фикер үсешенең үзенчәлекләрен ачыклау, бөтен ил буйлап таралган милләттәшләребезнең педагогик карашларын туплау, аларның гомумпедагогик киңлеккә кертkән өлешен ачыклауга бирелде. Дөрес, соңгы елларда дөнья күргән алты томлык Татар энциклопедиясе татар мәгарифе тарихын беркадәр күзалларга, аның аерым сәхифәләре белән танышырга мөмкинлек тудыра. Әмма ул, мәгълүмати характердагы басма булып, педагогик фикер үсешен тулаем һәм үсештә чагылдырмый. «Татар педагогик фикере антологиясе» һәм тәкъдим ителгән әлеге хезмәт беренче чиратта әнә шул мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерелде.

Билгеле булганча, татар педагогик фикерен билгеләүче иң мөһим өлешләрнең берсе – тәрбия өлкәсендә яшәп килгән карашлар, күп гасырлык халык тәҗрибәсенә нигезләнгән тәрбияләү, укыту алымнары һәм чаралары, буыннан-буынга күчеп камилләшкән педагогик белемнәре, халык өйрәтүләре, аның тәрбия тәҗрибәсе, ягъни татар халык педагогикасы. Ул татар халкы тормышында, укыту-тәрбиядә, һәм, димәк, татар педагогик фикере үсешендә дә, һәрчак үзенчәлекле рәвештә чагылыш таба: Октябрь революциясенә кадәр халык тәрбиясе иң мөһим, иң әһәмиятле факторларның берсе булса, милли үзенчәлекләрдән азат булган, бердәм совет халкын тәрбияләүгә юнәлдерелгән совет чорында халык педагогикасы мәгариф өлкәсеннән шактый ераклаштырыла. Соңгы дәвердә (XX гасырның 90 нчы елларыннан соң) этнопедагогика кабат үзенең тиеш-

ле урынын яулый, татар балаларын тәрбияләүдә һәм белем бирүдә иң үтемле чараларның берсенә әверелә.

Татар педагогик фикеренең үсеш тарихын өйрәнгәндә, тарихи хронологиягә һәм эчтәлеккә бәйле рәвештә аерым чорларны билгеләргә мөмкин. Педагогик фикер тарихын шактый тулы өйрәнгән галим Я.И.Ханбиков, мәсәлән, Идел Болгары (XI–XIII), Алтын Урда (XIII–XIV), Казан ханлыгы (XV–XVI) чорларын аерып карый. Педагогик фикер үсешендәге шуннан соңгы чорларны ул тематик принципка нигезләнеп билгели. Автор рус дәүләтенә кушылу, дини реформация, мәгърифәтчелек хәрәкәте, җәдитчелек, революцион-демократик педагогика кебек бүлекләрне аерып күрсәтә[6]. Әлбәттә, бу принципны бүгенге көндә тулысынча нигез итеп алу мөмкин түгел. Күпсанлы тикшеренүләр татар педагогик фикере үсешендә борынгы төрки, Идел буе Болгар дәүләте, Алтын Урда, Казан ханлыгы, XVI–XVIII гасырлар, XIX–XX гасырның беренче чиреген, XX гасырның 20–60 елларын, 60–80 еллар азагын һәм 90 нчы еллардан алып бүгенге көнгә кадәр булган чорларны аеру мөмкинлеген раслыйлар. Әлеге хезмәттә без татар педагогик фикере үсешенең тарихын «Борынгы төрки чорда педагогик фикер», «Урта гасырларда татар педагогик фикере», «XVII–XVIII гасырларда татар педагогик фикере», «XVIII–XX гасыр башында татар мәгарифе», «Совет чорында татар педагогик фикере», «XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар педагогик фикере» дип исемләнгән чорларга бүлеп өйрәнүне дөрес дип таптык.

Билгеле булганча, татар педагогик фикере үсешенең башлангыч дәвере борынгы төрки чор – Төрки каһанлыкка барып тоташа. VII гасыр ахырында борынгы төркиләр арасында ислам дине тарала башлау мәгариф үсешендә дә чагылыш таба: төркиләрдә мәгариф гомумислам мәгариф системасының бер өлеше буларак үсеш ала. Көнчыгыш дини белем бирү системасындагы кебек үк, укыту эше дини белемле остазларга йөкләнә. Хан сарае каршында мәктәпләр эшләгән, димәк, төрки аксөякләр арасында белемле булу зур мәртәбә саналган. Алар, үз илләрендә белем алу белән канәгатьләнмичә, чит илләрдә дә укыганнар. Шул заман өчен Кытайда белем алу иң югары һәм мактаулы, дәрәҗәле саналган[7].

---

[6] Ханбиков Я.И. Основные направления в развитии педагогической мысли татарского народа в XI–XX вв.: автореф. дис. ... докт. пед. наук. – М., 1968. – С. 6–15.

[7] Давлетшин Г. Культура древних тюрков. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – С. 60.

Борынгы төркиләрдә беренче урынга акыл, аннан соң гына көч куела. Шулай ук тарихка, бабалар рухына тугрылык саклау төп кануннарның берсе була, яшь буын борынгы бабалар үрнәгендә тәрбияләнә. Борынгы төркиләрнең педагогик традицияләре татар һәм башка төрки халыкларның мәгариф үсешенә нигез салган уртак мирас булып тора.

Татар педагогик фикере үсешен билгеләүче иң төп үзенчәлекләрнең берсе булып, аның, бер яктан, татар милли мәгариф идеяләрен чагылдыруы булса, икенче яктан, башка халык һәм ил мәгарифләре белән үрелеп үсүе тора. Мәгариф өлкәсендәге фикер алмашу һәм тәҗрибә уртаклашу, мәдәниятара бәйләнешләр бик борынгы заманнарда ук башланып, бүгенге көндә дә дәвам итә. Татар педагогик фикере үсешендә, милли үзенчәлекләр белән беррәттән, Россия, дөньякүләм мәгариф закончалыклары да чагылыш таба. Татар мәгарифендәге үсеш-үзгәрешләрне башка милли республикаларда яшәүче халыкларның, шулай ук Татарстанда яшәүче төрле милләтләрнең мәгарифе белән чагыштырганда гына тулаем күзалларга мөмкин. Татар педагогик фикере дигәндә Татарстан Республикасы белән беррәттән, Россиянең башка төбәкләрендә һәм чит илләрдә яшәүче татарларның мәктәп-мәдрәсә, укыту-тәрбиягә караган фикерләре, мәгариф эшләренең торышы, милли педагогика фәненең үсеше күз алдында тотыла. Ләкин әлеге басмада чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезнең милли мәгариф өлкәсендәге эшчәнлекләрен тасвирлауны максат итмәдек. Бу гаять катлаулы һәм мөһим мәсьәләне өйрәнү алда хәл ителәчәк әһәмиятле бурычларның берсе булып кала.

Төрле чорларда татар педагогикасы үсешен дөнья диннәренең әхлакый нормалары һәм кануннары, шулай ук татарлар борынгы заманнардан ук аралашып, үзара тәэсир итешеп яшәгән күрше дәүләт һәм халыкларның (Кытай империясе, Һиндыстан, Урта Азия, Иран, гарәп дөньясы, Төркия, Россия, Европа халыклары) тәрбия өлкәсендәге карашларыннан, укыту һәм тәрбия системалары йогынтысыннан аерып карау мөмкин түгел[8]. Бу борынгы чорларда ук башка илләргә барып белем эстәү яисә чит ил галимнәрен укыту һәм белем бирү эшенә җәлеп итүдә чагылыш таба (мәсәлән, Мәккәдән килеп Болгарда мәдрәсә ачкан Сөләйман Хуҗа турында билгеле[9]).

---

[8] Гыйбатдинов М., Мортазина Л. Гасырлардан килгән хәзинә // Чын мирас. – 2013. – № 3. – 57 б.

[9] Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация на Волге. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – С. 78.

Мәгариф өлкәсендәге мондый алмашулар халкыбыз, аның тәрбия, белем бирү системасы турындагы мәгълүматның дөньякүләм таралуына китергән.

Татар педагогик фикере үсешен, бигрәк тә XIX–XX гасыр башын, рус һәм Европа галим-педагоглары эшчәнлегеннән аерып карап булмый. Татарларның уку-укытуга карашларын, гыйлем һәм тәрбиягә булган мөнәсәбәтләрен Россия күләмендә танытккан галимнәр – К.Фукс, Я.Коблов, В.Радлов, татар тел гыйлеме, татар телен укыту һәм башка телләргә өйрәтү тарафдарлары М.Иванов, Н.Катанов, Н.Бобровников, В.Богородицкий һ.б.ның педагогик хезмәтләре дә татар педагогик фикере үсешенең үзенчәлекләрен күрсәтүче әһәмиятле факторларның берсе булып тора.

Татар педагогик фикере үсешен өйрәнүдә татарларның башка халыкларның мәгарифенә керткән өлешен билгеләү – шулай ук мөһим мәсьәләләрнең берсе. Төркестан далаларында аң-белем тараткан татар мәгърифәтчеләре, хатын-кыз педагоглар турында фәндә яхшы билгеле. Мисал өчен, 1909–1916 елларда Сәмәрканд мәктәпләрендә укыткан мөгаллимә К.Мозаффарова, Астанада кызлар мәктәбендә белем биргән М.Якупова, М.Сәгъдиева, Казах далаларында мөгаллимлек иткән М. Акмулла, Ш.Бабич һ.б., Төркестанда җәдит мәктәпләре ачкан, дәреслекләр язган күренекле педагоглар турындагы мәгълүматлар бүгенге заман укучысына җиткерелеп килә[10]. Шунысы да куанычлы: 90 нчы еллардан соң татар мәгърифәтчеләренең кардәш халыкларга аң-белем таратудагы эшчәнлекләре башка халыклар тарафыннан да таныла, өйрәнелә башлады[11].

Билгеле булганча, XVII гасырга кадәр татарларда фәннәр үсеше синкретик характерда була. Шул сәбәпле гыйлем һәм тәрбиягә караган фикерләр дә нигездә әдәби әсәрләрдә чагылыш таба. Бу үзенчәлек урта гасырларда педагогик фикер үсешен өйрәнгәндә исәпкә алынды.

---

[10] Биктимирова Т.Ә. Ил язмышын салып иңнәренә. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 239 б.; Мортазина Л.Р. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарларның Төркестанда һәм Казах далаларында мәгърифәтчелек эшчәнлеге // Историческая этнология. – 2017. – Т.2, № 1 һ.б.

[11] Насретдинова Д.М. Туркистоннинг маданий ҳаётида татар-бошқирд аёлларининг тутган ўрни (XIX аср охири – XX асрнинг биринчи чораги). Тарих ф. дисс. автореф. Тошкент, 2011. 29 б.; Уразбаева Р. Духовное образование в Каракалпакстане и формирование интеллектуальной и политической элиты (конец XIX – первая треть XX века). URL: http://ia-centr.ru/expert/2319/ (дата обращения 20.03.2017) һ.б.

Татар педагогик фикере үсешенә ислам рухи-әхлакый кыйммәтләренең тәэсире аеруча көчле булган. Бу очраклы күренеш түгел. Татар мәгариф системасы нәкъ менә мөселман цивилизациясе йогынтысында чәчәк аткан. Дәүләтчелекне югалтканнан соң да, мөселман уку-укыту системасы татар халкының рухи асылын саклап калырга ярдәм иткән. Шуны истә тотып, әлеге басмада мөселман уку-укыту системасының барлыкка килү, үсеш үзенчәлекләрен һәм бүгенге торышын яктыртуга зур игътибар бирелде, мәктәп-мәдрәсәләрдә белем биргән педагогларның эш тәҗрибәсе тасвирланды.

Бүгенге чорда татар педагогик фикерен өйрәнүдә иң төп принципларның берсе – аз өйрәнелгән, педагогика белеме киңлегеннән төшеп калган исемнәрне фәнни әйләнешкә кертүдән гыйбарәт. Моңарчы аз билгеле булган, төрле сәбәпләр (нигездә сәяси) аркасында күләгәдә кала килгән, онытылуга дучар ителгән татар педагоглары шактый. Тикшеренүчеләр алдында торган төп бурычларның берсе – XIX–XX гасыр башында яшәгән һәм татар милләтенә хезмәт иткән, китаплары һәм мәкаләләре фәнни әйләнешкә кермәгән, репрессияләр чорында хезмәтләре юк ителгән педагог-галимнәрнең, укытучыларның педагогик мирасын бүгенге заман укучысына җиткерү. Шулай ук гарәп һәм латин графикаларында язылып, рус шрифтына күчерелмәгән күпсанлы китап, дәреслек һәм методик әсбапларны өйрәнү, хәзерге графикага күчерү мәсьәләләре дә бүген аеруча актуаль. Бу, беренчедән, әлеге шәхесләребезнең исемнәрен кайтару, аларны киң җәмәгатьчелеккә таныту юлында башкарылган зур адым булса, икенчедән, татар педагогик фикере киңлеген, аның күпкырлылыгын һәм көчен күз алдына китерергә ярдәм итәчәк. Антологияне һәм тәкъдим ителгән хезмәтне әзерләгәндә әлеге мәгълүматларга да игътибар ителде.

Бу хезмәттә билгеләп кителгән материалларның, күтәрелгән проблемаларның күбесе киләчәктә татар педагогик фикерен тагын да тирәнтенрәк өйрәнүнең перспективалы юнәлешләрен билгеләргә мөмкинлек бирәчәк. Әле бүгенгә кадәр тулысынча өйрәнелеп бетмәгән мәсьәләләр арасында җирле (авыллардагы) мәдрәсәләр тарихы, төбәкләрдә белем һәм тәрбия биргән муллалар һәм мөгаллимнәр эшчәнлеге, алар тарафыннан язылган кулъязма дәреслекләр, дини тәрбия өлкәсендәге тупланган тәҗрибә, мәктәпләр тарихы һ.б. бар. Киләчәктә татар халкының педагогик фикере тарихын өйрәнүдә нәкъ менә шушы юнәлешләр нигез итеп алынырга тиеш.

# I. БОРЫНГЫ ТӨРКИ ЧОРДА ПЕДАГОГИК ФИКЕР

Татар педагогик фикеренең башлангыч нигезләре борынгы Төрки каһанлык чорына ук барып тоташа. Борынгы төркиләр дөнья халыклары диннәре (манихей, зороастризм, брахма, будда) һәм мәдәниятләре (уйгыр, согыд, борынгы грек язма традицияләре) белән таныш булалар. VII гасыр ахырында төркиләр арасында ислам дине тарала башлау да мәгариф үсешенә үзенчәлекле йогынты ясый. Төркиләр арасында гыйбадәтханәләр каршында дини тәрбия һәм белем бирү мәктәпләре булу шул хакта сөйли. Укыту эшен, Көнчыгыш дини белем бирү системасына хас булганча, тирән дини белемле остазлар башкара. Алар укучыларны дини белемгә күндерү белән бергә, укырга-язарга өйрәтәләр, әхлакый яктан тәрбиялиләр. Борынгы төркиләрдә тәрбия кылу, үзенчәлекле система буларак, күчмә кабиләләрнең яшәү шартларына яраклаштырыла. Кечкенәдән үк баланы тормыш итү күнекмәләренә өйрәтү (атка менү, ук ату һ.б.), шулай ук дала табигатенә сакчыл караш тәрбияләү – төркиләрнең педагогик карашларында төп урыннарның берсен били[1].

Төркиләрнең VI гасырда «рун» дип шартлы рәвештә аталган үз язулары була. Истәми каһан боерыгы белән төзелгән бу әлифба аралашу чарасы буларак файдаланыла. Рун язмалары рәсми документ һәм һәйкәлләрдә генә түгел, һөнәрчелек әйберләрендә дә еш очрый. Хәзәр дәүләте һәм Идел Болгары чорларына кадәр үк кулланылулары да төркиләр арасында язуның киң таралуының тагын бер дәлиле булып тора. Бу мәгълүматлар барысы да төркиләрдә рун язмалары нигезендә укый-яза белү генә түгел, ә халык өчен оештырылган белем бирү системасының да булуы турында сөйли.

Хан сарае каршында оештырылган мәктәпләр дә төрки аксөякләр арасында белемле булуның зур мәртәбә саналганлыгы хакында сөйли. Мәсәлән, төркиләрдән безгә билгеле булган беренче фикер

[1] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М. Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 29 б.

иясе Билге каһанның улы тарихчы Йолыг тәгин шундый мәктәпләрнең берсендә белем ала.

Югары катлам вәкилләре, үз илләрендә белем алу белән канәгатьләнмичә, чит илләрдә дә гыйлем алганнар. Кытайда укып кайту төркиләр арасында белемнең югары баскычына ирешүгә тиңләштерелә. Алар арасында Йолыг тәгин һәм гаскәр башлыгы, ханнарның киңәшчесе зирәк Тоньюкук та була. Аның кытай телен, тарих, география, картография кебек фәннәрне үзләштерүе дә билгеле.

Борынгы төркиләрдә беренче урынга акыл, аннан соң гына көч куела. Акыллылык, зирәклек каһаннарның Тәңре тарафыннан бирелгән аерылгысыз сыйфаты булып хисаплана. Хакимнең зирәк булмавы халык һәм дәүләт өчен төрле бәла-казалар китереп чыгарырга мөмкин дип исәпләнелә.

Безнең көннәргә хәтле килеп җиткән күп чыганакларда тәрбияви кыйммәтен югалтмаган гыйбарәләр сакланган. Мәсәлән, Турфан язмаларында да (V–IX гасырлар) бик күп тирән мәгънәле афоризмнар китерелә:

Ишеңә изге фикердә бул,
Бу яхшылык китерер.
Ишеңә яман фикердә булсаң,
Алла җәзаңны бирер.
Гыйлемне таны, йа бәгем!
Гыйлем сиңа тиң булыр;
Белеме булган ул иргә
Бер көнне бәхет булыр.
Кылырга ярамас эшләрне
Алдан уйларга кирәк;
Уйламыйча эш кылгачтын,
Ничек танарга кирәк?[2]

«Ырыг битиг» (IX гасыр ахыры – X гасыр башы) укучыларны яхшыны яманнан аерырга өйрәтүче дәреслек була. Әсәрдә гаилә, ата-ана һәм балалар мәсьәләләренә багышланган педагогик фикерләр еш очрый. Анда намуслылык, тырышлык һәм башка шундый сыйфатлар мактала, ә намуссызлык, ялкаулык, һәм башка тискәре сыйфатлар тәнкыйть ителә:

---

[2] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М. Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 31 б.

«Угыл ата-анасына үпкәләп, [өйдән] чыгып китте. Аннан сагынып кайтты. Анам нәсыйхәтен алыйм, атам сүзем тыңлыйм дип кайтты. Шуны белегез: әйбәт бу!»[3]

Борынгы төркиләрнең педагогик фикер үсешендә дини һәм дөньяви белем бирү, әхлак тәрбиясе, физик һәм экологик тәрбия һәм башка юнәлешләр урын ала. Бу педагогик традицияләр татар һәм башка төрки халыкларның мәгариф үсешенә нигез салган уртак мирас булып тора[4].



*Төрки рун язмалы «Ырыг битиг» китабы*

[3] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М. Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 33 б.

[4] Шунда ук. – 29 б.

# II. УРТА ГАСЫРЛАРДА ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ

IX–X гасырларда Көнчыгыш Европада шул чорның иң зур дәүләтләрнең берсе – Идел Болгары төзелә. Тарихи язмаларда әлеге дәүләт заманына күрә көчле, бай, мәдәниятле ил буларак билгеләп үтелә. Сәяхәтчеләр Идел Болгарында дин иреге, башка халыкларның гореф-гадәтләренә ихтирам хөкем сөргәнлеген, мәдәни үсешен, мәктәп һәм мәдрәсәләр эшләп килүен, үз галимнәре, тарихчылары, язма хезмәтләре булганлыгын искә алалар[1].

Болгар дәүләте башлыкларының сәяси һәм икътисади максатлары аларны ислам динен кабул итүгә этәргән[2]. Бу мөһим вакыйга, 922 елда ислам динен Болгар җирендә рәсми рәвештә кабул итү, үз чиратында татарларга фарсы, башка төрки халыклар, һәм бигрәк тә ул заман өчен иң алдынгы булган гарәп мәдәниятен үзләштерү өчен юл ачкан. Ә халыкның бердәм дини-мәдәни кыйммәтләр нигезендә бер дәүләткә оешуы беренче болгар шәһәрләренең үсеп чыгуына, мәчетләр салынуга, мәдрәсәләр ачылуга, кәрвансарайлар төзелүгә сәбәп булган. Чөнки, галимнәр фикеренчә, элек-электән дөньякүләм таралган диннәр, шул исәптән ислам дине дә, цивилизация үсешен билгеләгән[3].

Идел Болгарында ислам динен кабул итү белән гарәп язуы гамәлгә кергән. Болгар җәмгыятенең үсеше югарырак булган саен, аның бердәм язуга ия булу мохтаҗлыгы да арта барган. Галимнәр билгеләп үткәнчә, бары тик бердәм графика һәм гомуманлаешлы язу гамәлдә булганда гына дәүләт аппаратының эшчәнлеге тәэмин ителүе, рухи мирасның саклануы, дәүләт һәм әдәби телләренең

[1] Каримуллин Ә.Г. Безнең кардәшлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 43 б.

[2] Кляшторный С.Г., Султанов Т.И. Государства и народы Евразийских степей: от древности к Новому времени. – СПб.: Петербургское Востоковедение, 2009. – С. 172–173.

[3] Фәхретдинов Р.Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. – Казан: Мәгариф, 1996. – 28 б.

формалашуы мөмкин[4]. Мөселманнарның изге китабы Коръәнне, башка дини китапларны уку гарәп язуын һәм телен яхшы белүне таләп иткән. Шуңа күрә ислам дәүләт дине буларак киңрәк тарала барган саен, болгар халкы арасында укый һәм яза белү дәрәҗәсе арта барган. Халыкның киң катламнары арасында укый-яза белүнең таралуына мәҗүси традицияләр белән көрәшүче мөселман руханилары һәм ил башлыклары үзләре зур кызыксыну белдергән. Югары катлау кешеләренең генә түгел, гади халыкның, шул исәптән һөнәрчеләрнең дә белемлелеген төрле археологик табылдыклардагы язулар раслый. Хикмәтле сүзләрне яисә төрле теләкләрне белдергән гарәп язуындагы текстларны зәркән бизәнү әйберләрендә, хәрби коралларда, балчыктан ясалган чүлмәкләрдә һәм башка күп кенә көнкүреш әйберләрендә очратырга мөмкин[5].

Идел Болгарында гарәп язуының киң таралуы белән бергә югары үсешкә ирешә алган Көнчыгыш мөселман мәгарифе дә үтеп керә башлый. Кызганыч, болгарларның мәгариф системасы хакында чыганаклар юк дәрәҗәсендә. Әлеге хәлне, бер яктан, монгол яулары вакытында болгарларның рухи мирасы мәңгегә юкка чыгуы белән аңлатып булса, икенче яктан, кайбер галимнәр язма чыганакларның сакланмавының сәбәбен аның материалында (яисә кәгазьдә) күрәләр[6]. Әмма укыту программасы, өйрәнелә торган предметлар турында мәгълүматлар булмаса да, алар, һичшиксез, ул вакыт мөселман илләрендәге уку йортларыннан нык аерылмаган.

Әле X гасыр башында ук фарсы сәяхәтчесе Әхмәд ибне Рөстә: «болгарларның кала-салаларында имам һәм мөәзиннәре белән мәчетләр һәм башлангыч дини мәктәпләр бар», – дип язып калдырган. Болгарларның мәгариф системасы гарәпләрдән үзләштерелгән була – мәктәп һәм мәдрәсәләр һәр мәчет каршында эшләп килә[7]. Бу – мәктәпләрнең түбәнге баскычы һәм алар «башлангыч»

---

[4] Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – С. 111.

[5] Даркевич В.П. Художественный металл Востока VIII–XIII вв. (произведения восточной торевтики на территории европейской части СССР и Зауралья). – М.: Наука, 1976. – С. 48–50; Полякова Г.Ф. Изделия из цветных и драгоценных металлов // Город Болгар. Ремесло металлургов, кузнецов, литейщиков. – Казань, 1996. – С. 176; Смирнов А.П. Волжские булгары // Труды Государственного исторического музея. Вып. 19. – М., 1951. – С. 116.

[6] Каримуллин Ә.Г. Безнең кардәшлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 143–144 б.

[7] Махмутов М.И. Мир ислама. – Казань, 1996. – С. 103.

мәктәп булып саналган. Анда гарәп графикасы нигезендә укыргаязарга өйрәткәннәр, Коръән, хәдисләрне һәм дини китапларны уку өчен кирәк булган гарәп теленең кайбер кагыйдәләрен өйрәнүгә зур игътибар биргәннәр[8]. Идел Болгарында барлык балалар да башлангыч дини белемне алган[9].

IX гасырда мөселман илләрендә барлыкка килгән беренче мәдрәсәләр урта һәм югары дини уку йортларыннан саналган. Алар, гадәттә, бу илләрнең башкалаларында яисә зур шәһәрләрдә урнашкан. Мөселман мәгарифенең югары баскычы булып, Шәрыкның фәнни һәм мәдәни үзәкләрендә – Бохарада, Сәмәркандта, Нишапурда, Бәлхтә, Багдадта, Мәрвтә, Газнәдә белем алу торган. Монда укып чыккан болгарлар шул заман фәне, Шәрык мәдәнияте казанышлары белән турыдан-туры танышканнар. Күп кенә галимнәр бу Шәрык мәдрәсәләренең атаклы гыйлем ияләре кул астында белемнәр алган[10].

Уку йортларында төп игътибар дини фәннәргә бирелгән[11]. Укыту Коръәнне аңлату (тәдрис) һәм бер өлеш әйтеп яздыру (имля) белән барган[12]. Моннан тыш, укыту программасында билгеле бер дәрәҗәдә дөньяви фәннәр дә урын алган: укучылар математика, география, тарих, астрономия, медицина өлкәләренә караган белемнәр белән танышканнар. Болар дәүләт эшлеклеләре, сәүдәгәрләр, табиблар һәм башка күп белгечләр әзерләү өчен кирәк булган. Идел Болгары мәдрәсәләрендә белем алган Болгар һәм Шәрык галимнәре, шагыйрьләре турында безнең көннәргә хәтле килеп җиткән мәгълүматлар шул турыда сөйли. Болгар мәдрәсәләрендә төп игътибар руханилар – мөдәррис, имам, мулла, казыйларны әзерләп чыгаруга юнәлгән була[13].

Идел Болгарында туып, белем алган укымышлы кешеләр, кайда белем алсалар да, Шәрык илләрендә «әл-Болгари» тәхәллүсе белән билгеле булган. Мәсәлән, Бохара галиме Гобәйдулла Садр-әш-Шарига ибн Масуд үзенең хезмәтләрендә Хәсән әл-Болгари исемле га-

---

[8] История татар с древнейших времен в семи томах. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. – Казань: Изд-во «РухИЛ», 2006. – С. 561.

[9] Махмутов М.И. Мир ислама. – Казань, 1996. – С. 103.

[10] История татар с древнейших времен в семи томах. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. – Казань: Изд-во «РухИЛ», 2006. – С. 561.

[11] Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – С. 118.

[12] Мец А. Мусульманский ренессанс. – М.: Наука, 1973. – С. 154–155; Бартольд В.В. Сочинения. Т. 6. – М.: Наука, 1966. – С. 621–622.

[13] Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – С. 118.

лимне телгә ала. «Әл-Болгари» тәхәллүсе белән галимнәрнең, мөгаен, болгар мәдрәсәләренең мәшһүрлеген һәм анда укыткан остазларның танылган булуларын белдерәселәре килгәндер[14]. Моннан тыш, безнең көннәргә хәтле Якуб ибн Ногман, Сөләйман ибн Дауд әс-Саксини-Сувари, Борһанеддин Ибраһим ибн Йосыф Болгари, Факин Хуҗа Әхмәд әл-Болгари кебек Болгар дәвере галимнәренең исемнәре килеп җиткән[15].

Идел Болгарында шәрык телләрен укытуга да зур игътибар бирелгән. Гарәп теле Коръән һәм фән теле буларак билгеле булса, фарсы теле Көнчыгыш поэзиясе теле булып таныла. Укымышлы кешеләрнең гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белү дәрәҗәсе аларның төрле фәнни өлкәләргә багышланган хезмәтләрендә чагылыш таба. Гади халыкның төрле телләрне белүләрен исә эпитафия язмалары, һөнәрчеләрнең көнкүреш әйберләре, сәүдәгәрләрнең күрше дәүләтләр белән сәүдә алып барулары раслый ала. Болгар халкы тарафыннан көнчыгыш телләрне үзләштерүгә Шәрык илләреннән килгән укымышлылар, сәяхәтчеләр, төзүчеләр дә, һичшиксез, үзләреннән зур өлеш керткән.

Һәр чорда тәрбия һәм педагогиканың тәэсирле чарасы булып әдәби әсәрләр торган. Бу чорга караган матур әдәбият әсәрләре дә үзләрендә төрле фәннәр өлкәсенә караган мәгълүматларны, фәлсәфи, әхлакый, иҗтимагый карашларны чагылдырган, сәнгатьчә фикерләүнең бер өлешен тәшкил иткән. Урта гасырлар дәвере әдипләре үз заманының зур галимнәре, фикер ияләре, мәгърифәтчеләре, шагыйрьләре дә булганнар.

Йосыф Баласагунлы, Мәхмүд Кашгарый (XI гасыр), Сөләйман Бакыргани (XII гасыр) кебек төрки-татар әдипләре үзләрен бөек фикер ияләре, фән һәм мәгърифәт тарафдарлары итеп таныткан. Аларның әсәрләрендә башлыча гыйлем, акыл, тәрбия мәсьәләләре күтәрелә, шул чордагы барлык Көнчыгыш әдәбиятларына хас булганча, тәрбияви, дидактик рух көчле чагылыш таба.

Йосыф Баласагунлы «Котадгу белек» хезмәтендә «Наданнарны дәваламас табиблар, наданлыкны гыйлемең белән дәвала», – дип язып калдыра. Сөләйман Бакыргани «мәгърифәт белән сөхбәт (дуслык) кылырга» чакыра. Мәхмүд Кашгарый үзенең мәшһүр «Диване

[14] История татар с древнейших времен в семи томах. Т. 2. Волжская Булгария и Великая Степь. – Казань: Изд-во «РухИЛ», 2006. – С. 562.

[15] Мухаметшин А.Г. Развитие педагогической мысли татарского народа в Казанском крае в VIII – начале XX вв.: автореф. дис. … докт. пед. наук. – Чебоксары, 2009. – С. 23.

лөгать әт-төрк» сүзлегендә укучысын, гыйлемнең әһәмиятен белеп, белемгә, мәгърифәткә өнди. Белемсез кешенең сынаулар каршында югалып калачагын кисәтә[16].



*Мәхмүд Кашгарый*




*«Диване лөгать әт-төрк»нең бер бите*

Идел буе Болгары чорына караган һәм безнең көннәргә хәтле сакланып килеп җиткән иң гүзәл әсәрләрнең берсе булып, һичшиксез, Кол Галиның «Кыйссаи Йосыф» поэмасы санала.

Белгечләр фикеренчә, Урта гасырлар дәверендә мондый әсәрнең барлыкка килүе үк инде болгар җәмгыятендә иҗтимагый-сәяси, педагогик фикернең үсеше югары булу турында сөйли[17]. Дөнья классик әдәбиятының кыйммәтле хәзинәсе булган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы XIII йөздә монгол яулары алдыннан иҗат ителгән һәм берничә гасыр дәвамында башта кулъязма китап рәвешендә, соңрак басма нөсхәләрдә татар халкының рухи, әхлакый, эстетик ихтыяҗларына хезмәт итеп килгән. Озак гасырлар дәвамында татар мәдрәсәләрендә дәрес-

[16] Махмуд ал-Кашгари. Диван Лугат ат-Турк / Пер. З.-А.М.Ауэзовой. – Алматы: Дайк-Пресс, 2005. – С. 120.

[17] Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация – наше наследие // Булгарская цивилизация – наше наследие. – Ульяновск, 2005. – С. 16; Маликов Р.Ш. Становление и развитие тюрко-татарской гуманистической педагогической мысли Средневековья: автореф. дис. ... докт. пед. наук. – Казань, 2000. – С. 32.

лек ролен үтәгән «Кыйссаи Йосыф» китабында гәүдәләндерелгән гаделлек һәм сабырлык, намуслылык һәм тугрылык кебек югары әхлакый сыйфатлар татарларның буыннан буынга гуманистик кыйммәтләре формалашуына зур йогынты ясаган.



*Кол Гали. Рәссам Т.Хаҗиәхмәтов*

Төрки-татар әдәбиятында үзәк мәсьәләләрнең берсе булып гадел хөкемдар проблемасы санала. Көнчыгыш хакимнәренең залимлеге, бертуктаусыз феодаль фетнәләр һәр олуг фикер иясен кешелекле һәм гадел хөкемдар турында хыялланырга[18] һәм бу проблеманы үз әсәрләрендә үзәк мәсьәләләр рәтендә яктыртырга мәҗбүр иткән. Кол Гали дә «Кыйссаи Йосыф» поэмасының үзәгенә хөкемдар һәм халык бәхете идеясен куя. Калган барлык мәсьәләләр иҗтимагый, әхлакый, эстетик планда шушы үзәк тирәсенә туплана. Проблема каһарман образы аша хәл ителә[19]. Ә хөкемдар шәхесе нинди булырга тиеш? Кол Гали гадел хөкемдарда булырга тиешле сыйфатларны күрсәтә һәм алар кешенең бәхеткә ирешүе өчен төп шарт икәнен белдерә: «буе зифа, чибәр үзе, якты чырай, күркәм йөзе, теле төзек, туры сүзе; алып йөрәкле һәм гайрәтле, күп кешедән ул куәтле, дине бөтен, диниятле, хаин (хыянәтче) түгел, әманәтле, холкы йомшак, теле татлы».

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәрендәге гадел хөкемдар образы Болгар халкын рухи яктан тәрбияләүгә, аларның әхлакый сыйфатларын формалаштыруга да зур өлеш кертә.

Ил өстенә якынлашып килә торган афәт алдыннын Кол Гали үз әсәрендә гадел хөкемдар, кардәшләр ызгышын гаепләү, үз максатыңа ирешүдә сабырлык идеяләрен күтәреп чыгып, кавемдәшләренә бу куркыныч чорда дошманнан саклану өчен төп чара көчле һәм гадел дәүләт, татулык һәм бердәмлек икәнен күрсәтү максатын куйган.

Шул рәвешле, Идел буе Болгар илендә мәгариф системасы дәүләтчелекнең аерылгысыз өлеше булып тора. Болгар чоры педагогик фикеренә Мөселман Көнчыгышы зур йогынты ясаган булса да, ул үзенә генә хас үзенчәлекле йөзен формалаштыруга ирешә. Чит

---

[18] Маликов Р.Ш. Становление и развитие тюрко-татарской гуманистической педагогической мысли Средневековья: автореф. дис. ... докт. пед. наук. – Казань, 2000. – С. 30.

[19] Хисамов Н.Ш. Хәтер сагында: Әдәби-фәнни мәкаләләр, иҗат портретлары һәм публицистика. – Казан: Мәгариф, 2004. – 99 б.

дәүләтләрнең педагогик казанышлары болгарларның җирле икътисад, халык традицияләренә яраклаштырылып үзләштерелә. Киләчәктә исә Болгар дәверендә үсеш алган педагогик фикерләр, күп кенә Урта Идел һәм Чулман буе халыкларының да мәгариф үсешенә йогынты ясап, татар педагогик фикеренең нигезен тәшкил итәчәк[20].

1236 елда Идел Болгары монгол гаскәрләре һөҗүменә дучар була. Монгол явында Болгарның күп шәһәрләре туздырыла. Биләр, Сувар, Җүкәтау һәм башка шәһәрләр зур зыян күрә. Бай китапханәләр яндырыла, сарайлар, мәчетләр җимерелә. Алтын Урда дәүләте төзелгәч, Көнчыгыш Европаның башка илләре һәм халыклары кебек үк, Идел Болгары шул яңа дәүләткә кушыла. Алтын Урданың шәһәр мәдәнияте җирле халыкларның мәдәни, сәнәгый үсешенә корыла.

Алтын Урдага, Дәшти Кыпчак, Түбән Идел буе һәм Себер далалары белән бергәттән, борынгы цивилизация үзәкләре – Харәзем, Кырым, Кавказ, Болгар керә. Бу дәүләткә шәһәр һәм дала, утрак һәм күчмә мәдәниятләр үзара килешеп яшәү хас булса да, мәдәният учаклары булып, нигездә, шәһәрләр тора. Шундый мәдәни һәм фәнни үзәкләрнең берсе булып, һичшиксез, Сарай шәһәре санала. Ул тарихка мәдәният үсешенә үзеннән зур өлеш керткән иң яшь мөселман башкаласы буларак кереп кала[21]. XIV гасыр гарәп тарихчысы Ибне Гарәбшаһ «Сарай гыйлемнең һәм бәрәкәтнең бергә тупланган җиренә әверелде һәм кыска вакыт эчендә анда голәмаларның, олуг кешеләрнең, сүз осталарының, һөнәрчеләрнең һәм һәртөрле атаклы затларның мөхтәрәм төркеме җыйналды. Мисырның күп халыклы төбәкләрендә дә, аның авылларында да мондый хәлнең күрелгәне булмады», – дип язган[22].

Алтын Урда дәүләтендә мәчет, мәдрәсәләр кору ханнар арасында мәртәбәле эшләрдән санала. Гарәп язучысы Ибне Халдун Бәркә хан турында болай дип яза: «Ул ислам динен үзенең бар халкы арасында таратты. Үзенең бар биләмәләрендә мәчет һәм мәктәпләр төзи башлады, үзенә галимнәрне, хокук белгечләрен тартты, алар белән дуслашты»[23]. Моннан тыш, Бәркә ханның Мисырга: «Ба-

---

[20] Мухаметшин А.Г. Развитие педагогической мысли татарского народа в Казанском крае в VIII – начале XX вв.: автореф. дис. … докт. пед. наук. – Чебоксары, 2009. – С. 23.

[21] Амин аль-Холи. Связи между Нилом и Волгой в XIII–XIV вв. – М.: Восточная литература, 1962. – С. 28.

[22] Тизенгаузен В.Г. Сборник материалов, относящихся к истории Золотой Орды. В 2-х томах. Т. 1. – СПб., 1884. – С. 463.

[23] Шунда ук. – С. 379.

лалар мәдрәсәләрдә Коръән Кәримне укыйлар», – дип горурланып язуы да билгеле[24].

Гадәттә, мәдрәсәләр ханнар яки башка зур шәхесләр канаты астында эшләгәннәр. Гарәп сәяхәтчесе әл-Гомәри Үзбәк ханның Сарай шәһәрендә гыйлемлек өчен мәдрәсә салдыруы хакында яза[25]. Үзбәк хан заманында Алтын Урда бөтен Евразия күләмендәге иң зур дәүләтләрнең берсе буларак таныла[26]. Илнең иң зур шәһәрләреннән булган Солхатта Үзбәк хан мәдрәсәсе бинасының матурлыгы белән аерылып тора. Бу мәдрәсә илдә иң зур фән, мәгърифәт учагы була. Тарихтан шулай ук Солхат башлыгының хатыны Инҗибәкнең дә зур мәдрәсә салдыруы билгеле[27]. Бу уку йортлары зур фән һәм мәгариф учаклары булган, үз чорының «университетлары» һәм «академияләре» ролен үтәгән[28].

Хакимияткә килгән Үзбәк ханның өченче улы Җанибәк тә этисенең халык арасында белем һәм мәгърифәт тарату эшен дәвам итә. Тарихи чыганакларда ул галимнәргә һәм белемле кешеләргә зур хөрмәт күрсәткән шәхес буларак телгә алына[29].

Алтын Урда дәүләтендә иң атаклы мәдрәсәләр Сарай, Харәзем, Болгар, Кырым, Хаҗитархан шәһәрләрендә урнаша. Бу дәвердә иҗат ителгән әдәби әсәрләрдә төрле мәктәпләр булуы турында «китап», «дәфтәр», «хат», «битек» (язу), «имтихан» дигән сүзләр сөйли. Соңгысы мәктәп-мәдрәсәләрдә белем бирүнең максатчан булуын күрсәтә[30]. Теге яки бу мәктәп-мәдрәсәне тәмамлау хакында рәсми кәгазьләр – шәһадәтнамәләр дә бирелгән. Шундыйларның берсе –

---

[24] Шунда ук. – С. 64.

[25] Шунда ук. – С. 379.

[26] Фәхретдинов Р.Г. Татар халкы һәм Татарстан тарихы. – Казан: Мәгариф, 1996. – 113 б.

[27] Крамаровский М. Золотоордынский город Солхат-Крым: к проблеме формирования городской культуры (новые материалы) // Татарская археология. – 1997. – № 1. – С. 103.

[28] Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – С. 275.

[29] Родословное древо тюрков. Сочинение Абуль-Гази, Хивинского хана // Известия общества археологии, истории и этнографии при императорском Казанском университете. Том XXI. Вып. 5–6. – Казань, 1906. – С. 154.

[30] Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – С. 277.

Ибраһим Шәех бине Мөхәммәд Хуҗа бине Мәүләна Таҗеддин әл-Кыртимәни дә була. Укып белем алгач, остазы Әбү Мөхәммәд Болгари тарафыннан 1369 елда «Иҗазәтнамә» («Шаһәдәтнамә») ала[31].

Алтын Урда дәүләте Шәрык һәм Көнбатыш илләре белән тыгыз мәдәни элемтәләрдә тора. Ә бу бәйләнешләрнең нигезен Алтын Урдада мәдәни һәм фәнни фикернең югары дәрәҗәсе һәм алга киткән дәүләтләр ирешкән казанышларның әһәмиятен аңлау тәшкил итә[32]. Галимнәр, шәех һәм казыйлар Идел буеннан Мисырга барып белемнәрен арттыралар, шундагы мәдрәсәләрдә мантыйк, риторика, хокук фәннәрен өйрәнәләр. Мәмлүкләр идарәсе башланганнан соң (1260–1516), тел һәм мәдәният уртаклыгы сәбәпле, Мисыр һәм Алтын Урда арасындагы бәйләнешләр тагын да ныгый. Алтын Урда укымышлылары Мисыр, Сүрия мәдрәсәләренә барып дәресләр бирәләр. Шулай ук Алтын Урда мәдрәсәләрендә гарәп илләреннән килгән остазлар да укыта[33].

Алтын Урда чоры галимнәреннән Сарай һәм Хорезм шәһәрләрендә белем алган Әш-шәех Мингазетдин Ибраһим бине Сөләйман; башта Болгар, Тәбриз, Бохара, Ганҗа мәдрәсәләрендә укып, соңыннан шуларда шәкертләр укыткан Әш-шәйхел-имам Хуҗа Гомәр әл-Болгари; Сарай, Үргәнеч шәһәрләрендә белем алган Әш-шәех Ногманетдин әл-Харәзми; Сарай, Болгар, Кырым, Хаҗитархан мәдрәсәләрендә укыган Әш-шәех Хафизетдин Мөхәммәд һ.б. исемнәрен атарга мөмкин[34].

Әйткәнебезчә, бу дәвердә укымышлы кешеләр үз Ватаннарында алган белем белән генә чикләнмичә, укуларын чит дәүләтләрдә дәвам иткәннәр. Мисал өчен, югарыда телгә алынган Әш-шәех Хафизетдин Мөхәммәд Византия уку йортларында белем алган, Әш-шәех әл-Вагыйз ән-Насыйх Әхмәд бине Шәмсел-өммәт әс-Сараи исә Сүрия һәм Мисыр мәдрәсәләрендә укыткан[35].

---

[31] Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Т. 1. – Казан, 1885. – 82 б.

[32] Амин аль-Холи. Связи между Нилом и Волгой в XIII–XIV вв. М.: Восточная литература, 1962. – С. 28.

[33] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. (борынгы төрки чор – XX гасыр башы) / Ред. Ф.М. Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 56 б.

[34] Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – С. 275.

[35] Шунда ук. – С. 275.

Монда шул нәрсә күзгә ташлана: чит ил мәдрәсәләрендә белем алу һәм укыту Алтын Урда зыялыларына бер кыенлык та тудырмаган. Моннан ул чор ислам дөньясында мәгариф системасының, укытыла торган дәресләрнең охшаш булуы аңлашыла.

Укый-яза белү һәм язма мәдәният Алтын Урда дәүләтендә зур әһәмияткә ия була. Алтын Урда мәдәниятенә караган чыганаклар илдә шактый алга киткән мәгариф системасы булуын раслый. Башлангыч мәктәп-мәдрәсәләр белән беррәттән, башкалада һәм эре шәһәрләрдә зур мәдрәсәләр эшләп килә. Алар Алтын Урдадагы иң зур фән һәм мәгърифәт учаклары булалар. Бу чорда мәгърифәт дин һәм фән белән тыгыз бәйләнештә тора.

Алтын Урда җәмгыятендә хатын-кызларның дәрәҗәсе югары санала. Анда хатын-кызлар өчен ачылган махсус мәдрәсәләрнең булуы шул хакта сөйли. Мәсәлән, «Туйбикә» һәм «Рабига» мәдрәсәләре турында хәбәрләр, халык телендә сакланып, безнең көннәргә төрле риваятьләрдә килеп җиткәннәр[36].

Бу чор мәктәп-мәдрәсәләрендә Коръән, сәнгатьле уку осталыгы, тәфсир, хәдис, гарәп, фарсы телләре, әдәбият, хокук фәне, тарих, геометрия, география, астрономия һәм фәлсәфә укытылган[37]. Шулай ук Әбүгалисина, Әл-Фараби, Ибн-Рөшти фәлсәфәсе, Фирдәүси, Сәгъди, Хафиз, Хәйям һәм башка әдипләрнең шигърияте өйрәнелгән[38].

Алтын Урда мәгарифенә кагылышлы кайбер мәгълүматларны археологик ядкәрләрдән дә белергә мөмкин. Мәсәлән, Сарай-Батуда табылган керамик такта кисәгендә әбҗәднең бер өлеше сакланып калган. Мөгаен, ул уку-укыту әсбабы буларак кулланылгандыр. Әбҗәд – ул гарәп әлифбасының сан мәгънәсе бирелгән аерым хәрефләренең махсус тәртибе. Аның нигезендә укучылар тапкырлау җәдвәлен үзләштергәннәр. Бер үк вакытта тулы һәм вакланмалы саннар өстендә дүрт арифметик гамәлне башкарганнар[39].

---

[36] Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 26–27, 37 б.

[37] Шәймәрдәнов Р.Х., Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Татар милли педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 109 б.

[38] Мәхмүтов М. Мәдәният мәгълүмати көрәштә // Казан утлары. – 2004. – № 4–5. – 53 б.

[39] Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – С. 278.

Алтын Урда чорында әдәби әсәрләр, алдагы дәверләрдәге кебек үк, гыйльми һәм мәгърифәтчелек фикерләрен таратучы төп чараларның берсе булып торалар. Гыйлемгә зур хөрмәт белән сугарылган әдәби әсәрләрдә акыл, белем, мәгърифәт мактала.

1358 елда Мәхмүд әл-Болгари әхлакый-педагогик мәсьәләләрне яктырткан «Нәһҗел-фәрадис» әсәрен иҗат итә. Шул чорның җәмгыять күренешләрен сурәтләү бу әсәрне тарихи, шул исәптән рухи дөньяны өйрәнүдә әһәмиятле чыганак дәрәҗәсенә җиткерә. Хисам Кятибнең 1369 елда язылган «Җөмҗөмә солтан» әсәре дә иҗтимагый-әхлак идеяләренең байлыгы белән аерылып тора. Алтын Урда башкаласы Сарайда яшәгән Котб 1342 елда «Хөсрәү вә Ширин» поэмасын иҗат итә. Алтын Урда шагыйре Сәйф Сараи «Сөһәйл илә Гөлдерсен» (1394) поэма-дастанында Җирнең кояш тирәсендә әйләнүен бик табигый, бар кешегә дә аңлаешлы бер күренеш итеп тасвирлый. Һәм бу – Алтын Урда җәмгыятендә Коперникка кадәр шактый элек теркәлгән фикер.

Шулай итеп, Алтын Урда мөселман дөньясында күренекле мәгариф үзәгенә әйләнә. Илнең төрле шәһәрләрендә зур мәдрәсәләр эшләп килә. Алтын Урда дәүләте Шәрык һәм Көнбатыш илләре белән тыгыз мәдәни элемтәләрдә тора. Алтын Урданың укымышлы кешеләре, үз Ватаннарында белем алгач, укуларын чит мәмләкәтләрдә дәвам итәләр, андагы уку йортларында үзләре дәрес бирәләр. Әмма 1359 елда Алтын Урда дәүләте көчсезләнә башлый, чөнки кабатланып торган фетнәләр, бәрелешләр, хакимлек итү өчен көрәш, ханнарны бер-бер артлы үтерү илне һәлакәткә илтә. Нәтиҗәдә, бу мәшһүр дәүләт таркалып, ул Казан, Әстерхан, Кырым, Себер ханлыкларына, Ногай урдасына һәм Зур Урдага бүленә.

Казан ханлыгында, Идел буе Болгары һәм Алтын Урдадагы кебек үк, мәгариф һәм дин аерылгысыз була. Мәгърифәт эшләре дин әһелләренә йөкләнә. Алар укырга-язарга өйрәтү белән бергә, дәүләт эшлеклеләрен, хәттатларны, ясак җыючыларны, галимнәрне, шагыйрьләрне, дин белгечләрен дә әзерлиләр. Гарәп, фарсы телләре киң кулланылышта була[40]. Татар теле исә әдәби һәм дәүләт теле булып санала. Казан ханнары сарайларына төрки дөньяга танылган шагыйрьләр, галимнәр, фикер ияләрен чакыралар, китапханәләрдә фәнни басмалар туплана[41]. Алтын Урда дәүләте варисларыннан бер-

---

[40] Шунда ук. – С. 280.

[41] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М. Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 75 б.

се булган Кырым ханлыгында да мәдрәсәләр эшләве, мәшһүр галимнәр һәм остазлар яшәгәнлеге мәгълүм. Кырым ханлыгында яшәгән ике дистәдән артык галимнең исеме безнең көннәргә кадәр килеп җиткән: Әмир бине Осман Суфи, Зияэтдин бине Садуллаһ әл-Кырыми, Мәүләнә Рукнетдин Әхмәд бине Мөхәммәд һ.б.[42]

Казан ханлыгының зыялы тормышын тасвирлап, Ш. Мәрҗани «галимнәр, шул исәптән габбаси изгеләр вә галәви сәедләр күп иде» дип белдерә[43]. Казан ханлыгында укымышлы кешеләрнең, галим һәм шәкертләрнең, китапханәләрнең күплеге татар риваятьләрендә дә сакланып кала[44].

Казан ханлыгы халкының мәдәнилеге һәм белемлелеге турындагы фикерләр ул вакытта Казанга килгән чит ил кешеләренең юльязмаларында да чагылыш таба. Мәсәлән, Австрия илчесе, сәяхәтче Сигизмунд Герберштейн татарлар турында «алар башкаларга караганда укымышлырак» дип язып калдыра[45].

Галимнәр Казан ханлыгында фәнни һәм педагогик фикернең үсешен иң беренче чиратта аның югары икътисади халәте, иҗтимагый-сәяси торышы белән аңлаталар. Казан ханлыгында крепостнойлык хокукы булмау һәм халыкның шәхси азатлыгы илдә икътисад, һөнәрчелек, шәһәрләр һәм авыллар, эчке һәм тышкы сәүдә үсешенә ярдәм итә, бу исә, һичшиксез, халык арасында фәнни белемнәрнең таралуына, шәһәрләрдә генә түгел, авылларда да яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр үсеп чыгуына китерә. Россия, Әрмәнстан, Иран, Ногай Урдасы, Төркестан илләре белән тыгыз сәүдә мөнәсәбәтләре халыкара товар әйләнешенә генә түгел, шул ук вакытта Казан ханлыгына башка дәүләтләрдән төрле өлкәгә караган белемнәрнең, алдынгы педагогик фикерләрнең, уку-укыту әсбапларының, фәнни һәм әдәби әсәрләрнең үтеп керүенә хезмәт итә[46]. Сәүдә үсеше география, геодезия, математика өлкәләренә караган белемнәрнең артуына китерсә, шәһәрләр, мәчетләр, җәмәгать биналары төзү төгәл фәннәрнең алга китүенә ярдәм итә.

---

42 История татар. В семи томах. Т. 4. – Казань: Институт истории АН РТ, 2014. – С. 552.

43 Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар фи ахвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан, 1989. – 2 б.

44 Татар халкы иҗаты: Риваятьләр һәм легендалар. Казан, 1987. – 55 б.

45 Герберштейн С. Записки о Московии. М., 1988. – С. 145, 157.

46 Мухаметшин А.Г. Развитие педагогической мысли татарского народа в Казанском крае в VIII – начале XX вв.: автореф. дис. … докт. пед. наук. – Чебоксары, 2009. – С. 17.

Казан ханлыгында, нигездә, Алтын Урда дәверләрендә үсеш алган мәгариф традицияләре дәвам итеlә. Башлангыч һәм урта мәктәп-мәдрәсәләрдән тыш, югары белем бирүче мәдрәсәләр эшләп килә. Шундыйларның берсе булып илнең иң зур һәм атаклы уку йортларыннан булган Кол Шәриф мәдрәсәсе санала[47].

Укый-яза белү югары катлау кешеләре арасында гына түгел, гади халык арасында да киң таралган була. Мәдрәсәләрдә аерым фәннәргә бүлеп укыту кертелә башлый, математика, астрономия һәм башка фәннәрне укытыр өчен махсус дәреслекләр языла. Мәсәлән, безнең көннәргә кадәр арифметика кагыйдәләренә багышланган 243 биттән торган «Мәҗмәгыл кавагыйд гыйльме хисаб» исемле кулъязма җыентык килеп җиткән. Ул 1542 елда Мөхетдин Мөхәммәд ибн әл-Хаҗи Атмаҗи тарафыннан төзелгән[48].



*Мөхәммәдъяр. Рәссам Р.Шәмсетдинов*

Казан ханлыгы вакытында да әдәби әсәрләр тәрбия бирүнең, мәгърифәтнең төп чарасы булуын дәвам итә. Бу дәвердә татар әдәбияты Мөхәммәд Әмин, Кол Шәриф, Өммикамал, Гарифбәк, Хәсән Кайгы исемнәре белән баетыла. Казан ханлыгы әдәбиятының иң күренекле вәкилләреннән берсе гуманист-шагыйрь Мөхәммәдъяр була. Ул үзенең «Төхфәи-мәрдән» (1540) һәм «Нуры-содур» (1542) поэмаларын тулысынча әхлакый һәм тәрбияви мәсьәләләргә буйсындыра. Укучысында иң мөһим әхлакый сыйфатларны сәнгатьчә фикерләү ярдәмендә тәрбияләргә тырыша:

Чын, хакыйкать, тугры эшне эшлә син
Һәм үзеңнән яманлыкны ташла син.
И намуслым, изге кыл һәр кешегә,
Ул һич кылмас мәкер синең ишегә.
Яманлык кылучыга кылма яман,
Яхшылык кыл, булдыралсаң, һәр заман.

---

[47] Фахрутдинов Р.Г. Фахрутдинов Р.Р. История татарского народа. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – С. 128.

[48] Беркутов В. Борынгы кулъязма // Совет мәктәбе. – 1968. – № 9. – 19 б.

Казан ханлыгы чоры матур әдәбият әсәрләре, тәрбияви вазифаларны башкару белән бергә, дини һәм дөньяви белемнәрне таратуда да нәтиҗәле чара булып торган. Мәсәлән, без Мөхәммәд Әмин әсәрләрендә метрология терминнарын, Мөхәммәдъяр поэмаларында география, астрономия, медицина өлкәләренә караган мәгълүматларны очрата алабыз.

Шулай итеп, Казан ханлыгы чоры мәгарифе Алтын Урда мәгарифе традицияләрен дәвам иттерә. Белем бирү һәм тәрбия системасы ислам кыйммәтләренә нигезләнә. Дини гыйлем белән беррәттән, дөньяви фәннәр дә укытыла. Әмма 1552 елның октябрендә Казан ханлыгы Мәскәү патшасы Иван IV тарафыннан яулап алына. Әлеге тарихи вакыйгадан соң татар халкының дәүләтчелеге яшәүдән туктый. Бу вакыттан башлап, татарларның язмышы, шул исәптән мәгарифе дә, Россия патшалыгының рус булмаган халыкларга карата алып барган сәясәте белән бәйле була.

# III. XVI–XVIII ГАСЫРЛАРДА ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ

Казан ханлыгы җимерелү, дәүләтчелек югалуы барлык өлкәләрдә дә чагылыш таба. Шул рәвешле татар мәгарифе нигездә авыл шартларында гына сакланып кала. Хөкүмәтнең көчләп чукындыру һәм руслаштыру сәясәте дә татар мәгарифенә тискәре йогынты ясый. Халыкның гасырлар буе тупланып килгән мәдәни мирасының күпчелеге – китапханәләр, кульязма истәлекләр яндырыла, мәчетләр, алар каршында урнашкан мәктәп-мәдрәсәләр җимерелә.

Бу чорда татарлар, дини яктан көчләү сәясәте белән килешмичә, Урта Азия, Казахстан, Төркия, Кырым, Себер мәдрәсәләрендә белем алалар[1]. Шулай да мәктәп-мәдрәсәләрнең яшәве Идел-Урал төбәгендә дә тулаем туктатылмый, алар авыл җирлегендә дәвам ителә, «кайбер авылларда кечкенә генә һәм күбесе яшерен рәвештә гыйбадәтханәләр ачыла, муллалар барлыкка килә. Алар ир һәм кыз балаларны үз өйләренә җыеп иман һәм намаз өйрәтәләр»[2].

Рус дәүләте составында яшәү чорында татарларның мәдәнияте башка шартларда үсеш ала башлый. Монда рус хакимиятенең йогынтысы зур була, беренче чиратта рус дәүләте мәнфәгатьләре исәпкә алына. Шәһәрләрдән куылып, авылларга барып урнашкан татарларның мәгариф системасын да яңа дәүләт үз кулына алырга тырыша һәм аны христианлаштыруның бер ысулы буларак куллана. Мәсәлән, 1555 елда Казан епархиясенә – чиркәү идарәсе органына нигез салына һәм аңа христианлаштыру сәясәтен уздыру йөкләнә. Казан архиепископы Гурий беренчеләрдән булып руслаштыру сәясәтен мәктәпләр аша алып баруны тәкъдим итә. Аның җитәкчелегендә чукындырылган халыкларның балалары өчен Казанда, Спас-Преображение, Елан тавы һәм Свияжскидагы Успенский мо-

[1] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 94 б.

[2] Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 245 б.

настырьлары янында беренче христиан мәктәпләре ачыла. Аларда руханилар һәм башка дин эшлеклеләре хәзерлиләр[3]. Балаларны әлеге уку йортына мәҗбүри җыеп, рус, славян әлифбасын, Библияне өйрәтәләр[4]. Укучыларның яшәү чыгымнары, дәреслекләр белән тәэмин итү эшләре дәүләт хисабына алып барыла. Дини китапларны башта татарча, соңрак бары тик русча гына уку сәбәпле, укучылар тиешле белемне бик авырлык белән генә үзләштерәләр. Чөнки чит җирлеккә әләгеп, мәҗбүри укыту, рус телен белмәү кебек каршылыклар укучыларда белем алуга кызыксыну тудырмый. Шуның нәтиҗәсендә мәктәптә балалар саны кими һәм бу монастырь мәктәпләренең ябылуына этәргеч була[5].

Бу чорда христиан динен тарату өчен дини мәктәпләр күп ачылса да, гомумән уку-укыту эшләренә дәүләт тарафыннан тиешле әһәмият бирелми. Хакимият христиан динен кабул итүчеләргә төрле ташламалар бирү юлы белән христиан диненә җәлеп итәргә тырыша. Ләкин шулай да әлеге чорда христианлаштыру сәясәте зур уңышларга ирешә алмый кала.

XVII гасырда Европа илләрендә белем бирү төрле юнәлештә алып барыла. Көнбатыш Европада Яңарыш чоры дип аталган дәвердә кеше шәхесен, аның хокукларын, сәләтен ачу алгы планга куела. Бу илләрдә белем һәм тәрбия бирүдә диннең йогынтысы шактый аз була, шулай да дин кеше тормышында мөһим урынны били. Россиядә бу вакытта, Европадан аермалы буларак, дини уку-укыту системасы өстенлек итә.

XVIII гасырда Көнбатыш Европада яңа кеше тәрбияләү, бөтен дөньяны яңарту принцибына нигезләнгән мәгърифәтчелек күренеше үсеш ала. Россия исә XVIII гасыр башында күпмилләтле феодаль дәүләткә әверелә. Илнең сәяси-икътисади яктан үсешен тәэмин итү максаты белән Петр I мәдәният, фән һәм техника өлкәләрендә төрле реформалар үткәрә. «Цифирь мәктәбе», гимназия ачылу, вакытлы матбугатның барлыкка килүе, Фәннәр академиясе оештырылу, беренче дөньяви дәүләт мәктәпләре ачылу Россия мәдәнияте үсешенә зур йогынты ясый. Ләкин бу чорда татарларның гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, динен эзәрлекләү, белем алуларын чикләү дәвам итә. XVIII йөз

---

[3] Горохов В. Педагогика тарихыннан очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 6 б.

[4] Износков И. Об образовании инородцев и о миссии в Казанской епархии. – М., 1909. – С. 3.

[5] Шунда ук. – С. 5.

башында татар халкын төрле юллар белән руслаштыру сәясәте тагын да көчәеп китә. Мәсәлән, Казан архиепископы Лука Канашевич (Аксак Каратун) вакытында миссионерларның, татарларны көчләп чукындырып, монастырьларга җибәрүләре киң тарала. Ләкин аның тарафыннан Казанда ачылган ике керәшен мәктәбе, укучыларның качулары, авырулары һәм үлүләре сәбәпле, озак эшли алмыйлар. Монастырьлар каршында ачылган бу мәктәпләрдә чиркәү хезмәткәрләре әзерләгәннәр. Биредә белем бирү бары тик дини китаплар уку, дини җыр һәм чиркәү хезмәтләренә механик рәвештә өйрәнү аша алып барылган[6].

Хөкүмәт тарафыннан алып барылган сәясәт (көчләп чукындыру, мәктәп-мәдрәсәләрне җимерү кебек гаделсезлекләр) татар халкында ризасызлык тудыра. Мәсәлән, динне, халыкны саклап калу өчен барган көрәшләрдән мөһим рольне Батырша баш күтәрүе алып тора[7].



*Әсән авылы мәчете. XVIII гасырда салынган*

Әлеге күтәрелеш җиңелүгә дучар булса да, Россия хөкүмәте Идел-Урал төбәгендә яшәүче башка халыклар белән беррәттән, татарларга карата да көчләп чукындыру сәясәтен беркадәр йомшартырга мәҗбүр була. Ул ислам динен Россия империясе җирләрендә саклап калырга мөмкинлек бирә[8].

XVII–XVIII гасырларда илдә барган сәясәт кысаларында халык иманын саклап калып, төрле юллар белән белем алуга омтыла. Шуның нәтиҗәсендә бу чорларда татар педагогика фикере үсешендә әхлакый тәрбия, суфичылык, дини тәрбия алгы планга чыга.

Әлеге чорда әхлак тәрбиясе әдәби әсәрләрдә кешегә яхшылык кылу, изгелек эшләү, олыны-олы, кечене-кече итә белү, хезмәттә

---

[6] Горохов В. Педагогика тарихыннан очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 7 б.

[7] Ислаев Ф. Батырша восстаниесе. 1755 ел: Тарихи очерк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 68 б.

[8] Шунда ук.

ихласлылык, намуслылык, ата-ананы тәрбия итү, балаларга гыйлем-тәрбия бирү һ.б. шундый сыйфатлар аша яктыртыла.

Татарларда, алдагы чорлардагы кебек үк, ата-ананы хөрмәтләү, аларга «мәдхия җырлау» кебек сыйфатларны тәрбияләү максат итеп куела. Ата-ана ярдәмгә мохтаҗ булганда, аларга булышу, мөмкин кадәр тормышларын җиңеләйтергә тырышу – баланың изге бурычы. Ул аларга карата түземле һәм кайгыртучан булырга тиеш.

Атаң берлән анаңа хезмәт иткел күп-күп,
Иртә торып, һәр көндә аякларын үп-үп.
Һәр нә әйтә, анларның сүзләрен күр йөп-йөп (җөплә, хак күр),
Сабыр кылгыл, һәр нәчә кыйнасалар дөп-дөп[9].

Әхлак тәрбиясенең тагын бер мөһим сыйфаты – гыйлемлелек. Ул кешеләргә тормыш авырлыкларын җиңәргә, аның серләрен ачарга ярдәм итә торган гаять куәтле чара, корал дип санала. Татарлар аң-белемгә, гыйлем-мәгърифәткә омтылып яшәгәннәр, укымышлы, белемле кешеләрне зурлаганнар, балаларның гыйлемле булуын кайгыртканнар. Бу чорда да халык укуны, белем алуны барлык байлыклардан да югары бәяләгән. Әлеге фикерләр М.Колый, Габди, Я.Сәфәргали кебек шагыйрьләрнең әсәрләрендә чагылыш таба.

Галимнәр – күк йөзендә көнәш (кояш) яңлыг(кебек),
Шәкертләр – тулып торган айга яңлыг,
Мөэминләр күк йөзендә йолдыз яңлыг,
Наданлар коңгыз-кортка охшар булгай[10].

* * *

Тәм бирүчедер безгә гыйлем, белем,
Сәламәт ясаучыдыр гамәлне анык белү. [...]
Галимлекнең асыл максаты – мәгариф.
Мәгарифе юк икән, барлык фәннәр дә
«Сад» хәрефе кебек каты булырлар[11].

---

[9] Габди Ата-ананны хөрмәт ит // Татар поэзиясе антологиясе. 1 кис. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 192 б.

[10] Мәүла Колый. Хикмәтләр / Төз., кереш сүз авт. М.Гайнетдин. – Казан: Иман, 2000. – 98 б.

[11] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 118–119 б.

Сабырлык, юмартлык, ярдәмчеллек, изгелек эшләү, кешелеклелек, түземлелек, гөнаһ эшләүдән тыелу кебек әдәп-әхлак сыйфатлары да бу гасыр әдәбиятында киң яктыртылыш ала.

Мөселманнар, сабыр кылыңыз, агыр булды бу дәвер,
Һәр ни булса, Алладиндер, димәгел кяфер – гәвер![12]

* * *

Һәр нә тапсаң, дус-иш берлә
Ултырубән бергә йиеңез (ашагыз),
«Кем оҗмахлык (оҗмахка керә)? – дип сорасалар,
«Сәхи (Юмарт)!» – диегез[13].

Әхлак тәрбиясенә караган әлеге сыйфатлар бу чорда миһербанлылык, олыларны, ата-ананы хөрмәтләү, ярату, яхшылык кылу, изгелек эшләү кебек әдәп-әхлак сыйфатларын булдыруны максат итеп куя.

XVII–XVIII гасырларда әхлак тәрбиясе белән бергә дини тәрбия дә зур үсеш ала. Халыкның этник берәмлек буларак сакланып калуында диннең роле зур була. Бу гасырда дәүләт структурасы таркалгач, төрле авырлыклар кичергән чорда ислам дине таяныч noktaсы булып тора.

Иман берлә үлсәм диү өмидем вар. […]
Бу дөньядан иман берлә үтәр булса,
Гүрдә юлдаш гүр эчрә ятар, имеш.
Оҗмахка илтер, кыямәт көн йитәр булса,
Оҗмах өмид идеп, иман әйгем килер[14].

* * *

[…] Кер шәригать юлыга, булгыл фәкыйрь,
Нәфсе чөн күрмә шәригатьне хакыйрь (түбән).[…]
Нәфсеңне үлтер (үтер), Ходага бәндә бул[15].

* * *

Сагыйрь (начар) улды колагым, зәгыйфь улды күзләрем,
Тәсбих, тәһлил телдә юк, гайбәт һава (тәкәбберлек) сүзләдим.

---

[12] XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия. – Казан: Дом печати, 2006. – 17 б.

[13] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 99 б.

[14] Мәүла Колый. Хикмәтләр / Төз., кереш сүз авт. М.Гайнетдин. – Казан: Иман, 2000. – 84 б.

[15] Яхин Ф. Һәмдәми һәм аның «Нәсыйхәтнамә» поэмасында дини мифологик күзаллауларның үстерелеше // Урта гасырлар татар әдәбияты: Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: Раннур, 2003. – 359 б.

Зекре тәсбих әймәдим, тәгать-коллык (буйсыну) кыйлмадыйм,
Үтди гомрим файдасыз, кәндүи (калган) халим белмәдем[16].

Бу чорда ислам диненең рухы, бер юнәлеше, дин әйтеп-тоеп бетерә алмаган матурлыкны һәм дөньяны танып белү – суфичылыкка нигезләнгән[17]. Ул мөселман кешесенең үз-үзен, рухын камилләштерү юлы белән Ходайга якынаюын һәм кушылуын күздә тоткан төрле дини-фәлсәфи карашлар җыелмасыннан тора. Аллаһ еш кына әдәбиятта хаклык, сафлык, шәфкатьлелек, куәтлелек, юмартлык кебек сыйфатларга ия булган идеал рәвешендә сурәтләнә.

XVII–XVIII йөзләрдә рус хөкүмәтенең милли сәясәтенә ризасызлык йөзеннән суфичылык аерым юнәлеш ала. Ислам дине һәм мәгариф суфичылык традицияләре белән бәйләнеп карала. Аның үзенчәлекләре булып Аллаһка якынаю, аңа таяну тора.

Мактау Ходага, кылды Җир-Күкләрне,
Тамчыдан яратты пакь гәүһәрләрне.
Тераксез тотты күкләрнең өен ул,
Җиһанга хөкмен күрсәткән Бөек ул.
Асылын Җирнең балыкка йөкләде,
Өләште адәмнәргә, җан бикләде[18].

Суфичылык – ислам дөньясында зур яңгыраш тапкан, дөньявилык белән мавыкмаган, күңелне изгелеккә баглауны, тормыш сынауларын түземлелек белән үткәрүне алга сөргән агым[19].

Суфичылык әдәбиятында нәфеснең явызлыгы, дөньяның фанилыгы кебек темалар да яктыртыла, тәрбияви карашларда кешенең күңеленә үтеп керергә омтылу чагылыш таба. Аллаһны, динне онытып дөнья мәшәкатьләре белән генә гомер кичермәскә, мал-мөлкәт артыннан кумаска, нәфесне тыярга, күңелен, рухын пакъ кылып яшәргә кирәклек ассызыклана:

Туным бар, – тиб, дөнья тунын кигән кеше,
Хак кашында ябынурга туны юкдыр...
Бу дөньяны үләксә ит кебектер бел,

[16] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 434–435 б.

[17] Сибгатуллина А. Суфичылык серләре: Төрки-татар шигъриятендә динисуфичыл символлар, образлар, атамалар. – Казан: Заман, 1998. – 15 б.

[18] Яхин Ф. Суфи Аллаһияр иҗатында дини мифологик фикерләрнең шигъри фәлсәфәсе // Урта гасырлар татар әдәбияты: Татар шигъриятендә дини мистика һәм мифология. – Казан: Раннур, 2003. – 386 б.

[19] Идел буенда суфичылык: тарихы һәм үзенчәлекләре. – Казан: Иман, 2000. – 3 б.

Дөнья өчен талашканлар – этләрдер, бел.
Талашканлар китәр, дөнья калыр, күргел, –
Гыйбрәт алып тәүбә – тәүфикъ итәйен мән[20].

Суфичылык тәрбиясендә үлем, гүр газапларына зур игътибар бирелә. Шулардан курку көчле тәрбия чарасы булып тора. Кем булуына һәм нинди вазифа башкаруына да карамастан, үлем барысы өчен дә котылгысыз бер чара. Үлем яшәүнең дәвамы гына, ул – кешенең җир йөзендә яшәвенә караганда шактый өстенрәк, чөнки ул – «чын яшәү» дип аңлау кешегә үлемне кабул итүне җиңеләйтә төшә[21].

Әгәр сән йир йөзенең падишаһы булыб хөкем әйласәң дә,
Ахыр бер көнне үлем чәнгаленә, ягъни тырнагына тотылыб,
Кара йир астына керерсең, үлемдән калмазсән[22].

Дини тәрбия гаделлек, мәрхәмәтлелек, намуслылык, кайгыртучанлык кебек сыйфатларны алга сөрә. Шушы сыйфатлар халкыбыз тормышының нигезен биләп тора һәм алар төрле начар адымнар ясаудан саклап килә.

XVII–XVIII гасырларда халыкның рухын, әхлагын, иманын саклап калуда әхлак тәрбиясе, дини тәрбия мөһим урынны алып тора.

Татарлар элек-электән гарәпләр, Урта Азия халыклары, Иран һәм башка Көнчыгыш дәүләтләре белән икътисади һәм мәдәни мөнәсәбәттә торалар, аларның сәүдә юлларында урнашкан булулары мөһим роль уйный. Шулай ук дин уртаклыгы, кайбер Көнчыгыш халыклар белән тел якынлыгы да аларны берләштерә. Казан ханлыгы җимерелгәч, Россия территориясен, көнчыгыш чикләрне киңәйтү, шәрык халыклары, илләре белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыру бурычы килеп баса. Моның өчен төрле ысуллар, шул исәптән дипломатик чаралар, кулланыла. Россия хөкүмәте бу максатларда беренче чиратта төрки телләрне, гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән, ислам йолалары, гореф-гадәтләре белән яхшы таныш булган укымышлы татарларны җәлеп итә. Мәсәлән, Мәскәү илчелегенең Мөхәммәдйосыф Касыймов җитәкчелегендә Һиндыстанга; татар милләтеннән булган Дәүләт Казыйнның рус хөкүмәтенең илчесе буларак Хивага барулары

[20] Мәүла Колый. Хикмәтләр / Төз., кереш сүз авт. М.Гайнетдин. – Казан: Иман, 2000. – 136 б.

[21] Гыйззәтов К. Философия: ике китапта. К. 1. – Казан: Мәгариф, 2002. – 355 б.

[22] Ялчыгол Т. Рисаләи Газизә. – Казан: Хозур, 2014. – 301 б.

кебек тарихи фактлар моның ачык дәлиле булып тора[23]. Иранга, Һиндыстанга, Урта Азиягә оештырылган дипломатик сәфәрләрдә катнашу, татарларның белемнәрен киңәйтүгә һәм татар мәдәниятен баетуга ярдәм итә. Академик В. Бартольд Казан татарларының XVII–XVIII йөзләрдә үк Россиянең Көнчыгыш Азия дәүләтләре белән төрле мөнәсәбәтләр урнаштыруда зур булышлык күрсәтүләрен, ә татар теленең Россия белән Иран арасында дипломатия теле булуын ассызыклый[24]. Татар теленең рус дәүләтенең Урта Азия, Казахстан һ.б. илләр белән мөнәсәбәтләрендә төп аралашу коралы буларак кулланылуы русча-татарча, татарча-русча, русча-гарәпчә-татарча һ.б. төр сүзлекләр төзүгә этәрә. Әлеге сүзлекләрне нигездә чит ил галимнәре яисә рус галимнәре эшли[25].

Татарларда мәгариф системасының үсеш алуы Оренбург төбәге белән бәйле. XVIII гасыр башларында корылган Оренбург, Сәгыйть бистәсе, Троицк һәм башка төбәкләр тиз арада Урта Азия белән сәүдә итүнең мөһим үзәкләренә әвереләләр. Урта Азия, Иран, Кавказ илләре белән сәүдә мөнәсәбәтләренә керү Шәрык дөньясы белән татарлар арасындагы элеккеге мәдәни һәм мәгариф өлкәсендәге багланышларны торгызырга мөмкинлек бирә. Рус сәүдәгәрләре аша гына Көнчыгыш илләр белән тыгыз элемтә урнаштырып булмавын аңлаган хөкүмәт, Россиянең чик буе җирләренә татарларны җәлеп итә башлый. 1758 елда Казан губернасыннан күченеп килгән берничә гаилә Сәгыйть Хәялин җитәкчелегендә Оренбургтан ерак түгел Каргалы бистәсенә нигез сала. Соңрак исә бу якларга Әстерхан, Уфа якларыннан да күпләп татарлар күченеп килә башлый. Аларга үз диннәрен тотарга, мәчет-мәдрәсәләр ачарга рөхсәт ителә. Оренбург өлкәсе XVIII гасырның беренче яртысында белем бирүнең көчле үзәгенә әверелә. Бу чорда Каргалы бистәсендә һәм Эстәрлебаш авылы мәдрәсәләрендә татарлардан тыш, төрки телле барлык милләт вәкилләре, казахлар, башкортлар, үзбәкләр һ.б. да белем ала.

---

[23] Бартольд В. История изучения Востока в Европе и России. – СПб., 1911. – С.34.

[24] Шунда ук. – С.34.

[25] Кара: Булич С. Очерк истории языкознания в России. – СПб., 1904; Крачковский И. Очерк по истории русской арабистики. – М.-Л., 1950; Нугманов М. Русско-татарские рукописные словари XVII–XVIII веков. – Казань, 1964. һ.б.

XVIII гасырның икенче яртысында Россиягә Европаның уку-укыту системасы килеп керә. Перт I һәм Екатерина II белем бирү системасын Европа дәрәҗәсенә куярга омтыла. Алар илдә киң фикерләүче, мәгърифәтле кешеләр барлыкка килүен теләде. Белем бирү нигездә катлауларга бүленеп оештырыла. Ягъни һәр катлауның махсус белем бирү системасы була. Катлау югарырак булган саен, белем бирү дәрәҗәсе дә яхшырак оештырыла. Шул рәвешле, Россиядә әкренләп гомуми белем бирү мәктәпләре челтәре үсә башлый, Мәскәү университеты ачыла, ил тарихында беренче тапкыр халык мәгарифе системасы оештырыла.


*Каргалы мәчете. XVIII гасырда салынган*

Белем бирү, уку-укыту традицияләренең татар халкында яңаруында XVIII гасыр ахыры да мөһим роль уйный. Екатерина II дәүләт белән идарә иткән чорда татарларга карата сәясәт бераз йомшый төшә. Идел буе мөселманнары арасындагы мөнәсәбәтләр җайга салына, «Яңа чукындырылганнар эшләре конторасы» ябыла, мөселманнар өчен Диния нәзарәте оештырыла, акрынлап мәчетләр төзергә һәм алар каршында мәдрәсәләр ачарга рөхсәт бирелә[26]. Екатерина IIнең «Барлык диннәргә карата түземлелек һәм православие дине архиерейларына башка диннәр эшләренә, шул исәптән аларның гыйбадәтханәләре төзелешенә дә кысылмау...» турындагы указы беренче тапкыр исламны дәүләт күләмендә тануның ачык мисалы булып тора[27]. Бу үзгәреш уку-укыту системасына да зур йогынты ясый. Акрынлап мөселманнар гына яшәгән авылларда мәчетләр төзелә һәм мәктәп-мәдрәсәләр ачыла башлый. XVIII гасырның икенче яртысында Казан губернасында Кариле, Бай Оланнар, Ашыт, Мәчкәрә, Ташкичү, Минзәлә, Казаклар һ.б. авылларда мәдрәсәләр ачыла. Сәяхәтче, этнограф Г. Георги бу чорда һәрбер татар авылында махсус гыйбадәтханә һәм мәктәп булуын, ә Казан бистәләрендә

[26] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 150 б.

[27] Загидуллин И. Исламские институты в Российской империи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. – С. 70–71.

һәм зур авылларда шуңа охшашлы кызлар мәктәпләре барлыгын ассызыклый[28]. Мәдрәсәләр шулай ук татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә оештырыла башлый. Мәсәлән, XVIII гасырларда Себер татарлары яшәгән һәр авылда ир балалар өчен башлангыч мәктәп булган. Мөгаллим вазифасын урындагы имам (мулла) үтәгән. Себер җирлегендә иң беренче мәдрәсә Тубыл шәһәрендә ачыла[29]. Голландия галиме Витзен бу чорда Тубыл шәһәрендә «гарәп мәктәбе булып, анда укучыларга Коръән гарәп телендә» укытылган, ә укытучылар вазифасын Бохара хаҗиларыннан берәү алып барган дип ассызыклый[30]. Рус тарихчысы С. Бахрушин бу мәдрәсәнең Тубыл шәһәре татарлары өчен мәгърифәт учагы булуы турында яза[31].

Россия хөкүмәте тарафыннан мөселман уку йортларына дәүләттән акча бирелми, шул рәвешле татар мәктәп-мәдрәсәләре халыктан кергән акча бәрабәренә генә эшли. XVIII гасырның икенче яртысында мәгърифәт учаклары мәгарифкә ярдәм итүче шәхесләр, сәүдәгәрләр хисабына яши башлыйлар. Казанда Ахун, Апанай мәдрәсәләре, Әмирхановлар йортындагы мәдрәсә – моның ачык мисалы[32]. XVIII гасырның 70 нче елларында Казанда Апанай мәчете каршында сәүдәгәр Якуб Солтангалиев акчасына салынган Апанай мәдрәсәсен[33] еш кына Күл буе, Кәримия, Касыймия һ.б. исемнәр белән дә атап йөртәләр. Ул үз чоры өчен шактый зур һәм



*Апанай мәчете. XVIII гасырда салынган*

---

[28] Татарстан АССР тарихы. – Т.1. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 256 б.

[29] Вәлиев Ф. Себер мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 186 б.

[30] Шунда ук.

[31] Шунда ук. – 187 б.

[32] Шунда ук.

[33] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014 – 396 б.

дәрәҗәле уку йорты санала. Монда заманында Г.Исхакый, М.Бигиев, С.Максуди, Г.Камал, З.Бигиев һ.б. лар белем ала[34].

Дагыстан, Кырым, Төркиягә белем алырга дип киткән татарлар, хөкүмәтнең сәясәте бераз үзгәргәч, яңадан туган җирләренә кайталар, шунда укыган китапларын («Устуани», «Мөхәммәдия», «Алты бармак», «Мәгърифәтнамә» һ.б.лар[35]) күчереп язып, үзләре белән алып кайталар. Мәсәлән, Дагыстанда белем алып кайткан шәхесләрдән Мәчкәрә мәдрәсәсе имамы, мөдәррисе, ахун Мөхәммәдрәхим әл-Ашыти (дин белгече, галим Г.Курсавиның беренче укытучысы)[36] һәм Казанның беренче мәхәллә имамы, мөдәррисе, ахун Ибраһим Хуҗашины атап үтәргә мөмкин[37].

Шулай ук Оренбургтан ерак түгел Сәгыйтъ бистәсе мәдрәсәсендә Дагыстаннан килгән Мөхәммәд бине әл-Дагыстани белем биргән[38]. Аның шәкертләре арасында Диния нәзарәтенең беренче мөфтие Мөхәммәджан Хөсәен, Каргалы мәдрәсәсе мөдәррисләре Габдрахман бине Мөхәммәдшәриф әл-Каргалый, Нигъмәтулла әт-Тәүзыйхи һ.б. булуы билгеле[39]. Әлеге мәдрәсә Идел-Урал буе төбәкләре өчен дин белгечләрен әзерләүче үзәккә әйләнә. Шуның нәтиҗәсендә бу чорларда татарлар яшәгән төбәкләргә Дагыстан дини белем бирү тәртибе үтеп керә. Ул татарларга хокук, хәдис, риторика, нәхү (гарәп теле синтак-



*Кышкар мәчете. XVIII гасырда салынган*

[34] Шунда ук. – 397 б.

[35] Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 238 б.

[36] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 263 б.

[37] Шунда ук. – 266 б.

[38] Мухаметзянова Д. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2008. – С. 83.

[39] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 244 б.

сисы), сарыф (гарәп теленең морфологиясе) кебек фәннәрдән белем бирүне алгы планга куя. Ләкин бу укыту системасы әлеге шәхес вафатыннан соң туктатыла. Р.Фәхретдинов үзенең хезмәтендә әлеге белем бирү тәртибе турында «Дагыстан әхвалендә булган тәхсыйль үз кавемебез өчен файдалы булган» дип ассызыклап үтә[40].

Урта Азия белән сәүдә элемтәләренең ныгуы дини элемтәләрне дә көчәйтә. Югары дини белем алу максатыннан шәкертләр Урта Азиягә юнәләләр. Татарларны бигрәк тә Бохара мәдрәсәләре үзләренә җәлеп итә. Мәсәлән, иң беренчеләреннән булып Казаннан Бохарага укырга барган татар шәкерте Юныс бине Иванай Оруви турында билгеле[41]. Ул гарәп һәм татар телләренең чагыштырма грамматикасы буенча китап һәм Идел буе мөселманнарының дини әхлак нормаларына багышланган хезмәт авторы булып таныла. Бохара мәдрәсәләрендә белем алу өчен башлангыч белем таләп ителә, уку якынча 10 елга сузыла. Укуны тәмамлаган шәкертләр, туган якларына кайтып, Урта Азия белем бирү системасы үрнәгендә мәдрәсәләр ачалар. Диния нәзарәтенә барып, дин белгечлеге буенча уңышлы гына имтихан тапшыра алган кеше мөдәррис таныклыгы алып, мәдрәсә ача алган. Мәдрәсәләр һәрбер мәхәлләдә булсалар да, белем ягыннан аларның барысы да берүк дәрәҗәдә булмаган. Мәсәлән, Кышкар мәдрәсәсе[42] атаклы мәдрәсәләрнең берсе булып санала. Озак еллар әлеге мәдрәсәдә мантыйк һәм фәлсәфә югары дәрәҗәдә укытылган. Шуңа күрә анда Оренбургтан, Әстерханнан, Касыймнан һәм Казаннан килеп тә белем алганнар[43]. XVIII йөздә Казан, Оренбург янындагы Каргалы, Кышкар, Бәрәскә, Эстәрлебаш, Мәчкәрә, Тайсуган, Ташкичү мәдрәсәләре үз заманнары өчен зур һәм күренекле мәдрәсәләр булып исәпләнгәннәр. Әлеге фикерне тарихчы Г.Гобәйдуллин да ассызыклап үтә: «...татарлар мәдрәсәләр ачалар, ... Урта Азиядә киң таралыш тапкан фарсы телен өйрәнәләр. Казандагы һәм аның тирәсендәге барлык мәдрәсәләрдә Урта Азия белем бирү системасы белән бергә,

---

[40] Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 239 б.

[41] Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 193 б.

[42] Казан губернасы һәм өязендә (Татарстанның хәзерге Арча районы) XVIII гасыр уртасында сәүдәгәр Баязид бине Госман бине Габделкадыйр әл-Кышкари ярдәмендә салына.

[43] Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар. – Казань: Иман, 1998. – С. 30; Лотфи Г. Кышкар мәдрәсәсе // Мәдрәсәләрдә китап киштәсе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 150–171 б.

аның идеологиясе дә кабул ителә». Дагыстан дини белем бирү тәртибе әкренләп төшеп кала, барлык мәдрәсәләрдә дә Бохара ысулы белән укытыла башлый. Мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлегенең Бохара һәм башка Көнчыгыш мөселман дәүләтләрендәге белем бирү ысулы үрнәгендә алып барылуы шәкертләрнең Бохарага барып белем алу ихтыяҗын киметә.

Бу вакытта Европа илләрендә чех педагогы Ян Амос Коменский тарафыннан кертелгән класс-дәрес системасы ныклап урнаша. Әлеге системаның төп үзенчәлеге мәктәпкә укучыларны елына бер тапкыр гына кабул итеп, укытучының бөтен сыйныф белән күмәк эш алып баруыннан гыйбарәт. Болай укытуның аерым билгеләре бар: дәресләр елның бер вакытында башлана һәм һәр көнне уздырыла; билгеле бер яшьтәге балалар туплана; материалны өйрәнү бертөрле темпта бара. Укыту билгеле бер тәртиптә алып барыла: укучыларның игътибарын туплау, дәресне аңлату, укучыларның аңлаганлыкларын тикшерү һәм үзләштерүләрен тикшерү[44]. Ян Амос Коменский, укытуны болай оештырганда, укытучы укучыларның игътибарын һәрвакыт үзенә тартып тора, дип аңлата. Планнар һәм программалар нигезендә билгеле бер укучылар составы белән бара торган класс-дәрес формасы ул чорда барлык Европа илләре мәктәпләренә үтеп керә. Аның нигезе хәзерге көнгә кадәр яши, ләкин алдынгы педагоглар һәм методистлар тарафыннан һаман да камилләштерелә[45]. Татар мәгарифендә әлеге система XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында гына тулаем формалаша.

XVIII гасырда татарларда уку-укыту Бохара системасы аша алып барыла. Мәктәпләр һәрбер татар авылында, мәчет каршында, шулай ук мулланың үз йортында оештырыла. Мөселман мәктәпләрен тоту дәүләт карамагында булмаганлыктан, әлеге уку йортлары халык хисабына яши. Мәктәптә гадәттә 8–14 яшьлек ир балалар белем ала, уку вакыты исә 4–5 елдан артмый[46]. Уку йортында белем бирүче булып мөгаллим санала. Моннан тыш, мөгаллим белән бергә хәлфәләр дә (мәдрәсәдә укучы шәкертләр) уку-укыту процессында актив катнашалар. Ә кыз балаларга белем бирүдә абыстайлар (мулла хатыннары) зур өлеш кертәләр. Әлеге дини башлангыч уку йортында аерым предметлар түгел, ә дин нигезләрен һәм изгеләр-пәйгам-

---

[44] Хуҗиәхмәтов Ә. Дидактика. – Казан: Мәгариф, 2002. – 58–59 б.

[45] Шунда ук. – 59 б.

[46] Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар. – Казань: Иман, 1998. – С. 16.

бәрләр тормышын чагылдырган хикәятләрне үз эченә алган китаплар укытыла. Мәсәлән, Җ.Вәлиди үзенең хезмәтендә мәктәптә укучы шәкертләрнең нинди китаплар белән шөгыльләнүен ассызыклап үтә: беренче елны «Әлифба» («Иман шарты») һәм «Ясин» сүрәсе (Коръәннән) өйрәнелсә, икенче елны – «Һәфтияк»не (Коръәннең җидедән бер өлеше) укыганнар. Ә өченче һәм дүртенче елны – «Иҗек»не (Коръәнне иҗекләп) һәм «Сүрә»не (Коръәнне тулысынча) кабатлаганнар[47]. Я.Коблов[48] һәм Р.Фәхретдинов[49] мәктәптә әлеге санап үтелгән китаплардан тыш, дини-дидактик әсәрләр һәм шәригать кануннарын, хәдисләр турындагы җыентыкларны да укыганнар дип искәртәләр.

Мәктәпләрдә укыту сорау-җавап рәвешендә алып барыла. Бу очракта укытучы өйрәнелә торган дәрес буенча сораулар куеп, үзе үк аңа җавап та бирә, ә укучылар мөгаллим артыннан кабатлап барып материалны өйрәнәләр. Икенче дәрестә укытучы үткән дәрестәге сорауларны беркадәр үзгәртә, һәм шәкертләр сөйләнгән материалларга таянып җавап бирәләр. Бу укыту ысулы ярдәмендә укучы аз вакыт эчендә зур күләмле материалны үзләштерә, төпле белем ала[50].

Мәктәптә башлангыч белем алган шәкерт укуын мәдрәсәдә дәвам иткән. Мәдрәсәләрне оештыру һәм тиешенчә эшләвен тәэмин итү өчен, беренчедән, мәхәллә халкының махсус бина кору, аны тоту, мөгаллимнәрнең эшләрен тулы рәвештә тормышка ашырырлык финанс мөмкинлекләре булдыру, икенчедән, тиешле белемнәре булган мөгаллимнәр туплау, өченчедән, шәкертләр санының тиешле күләмдә булуы кирәк була[51]. Мәктәпләр кебек әлеге уку йортлары да күп очракта халык яки аерым кешеләр (сәүдәгәр) хисабына яшәгән. Мәдрәсәләрдә укытуны үз төбәгендә белем алган муллалар яки Бохара, Казан һәм башка җирләрдә укып кайткан мөгаллимнәр алып барган. Бохарада укып кайткан муллалар татарлар арасында аеруча зур ихтирам казаналар, аларны дамелла («бөек мулла») дип йөртәләр. Һәр мәдрәсә аерым укыту тәртипләре белән яши, белем

[47] Шунда ук. – С. 14–17.

[48] Коблов Я. Конфессиональные школы казанских татар. – Казань: Центр. тип., 1916. – С. 20–24.

[49] Фәхретдин Р. Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 240 б.

[50] Заһидуллина Д. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 24 б.

[51] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 8 б.

бирү системасы тулаем мөдәррис куйган тәртип буенча алып барыла. Мәдрәсәнең дәрәҗәсен күп очракта мөгаллимнең белеме билгеләде. Мөдәррис мәдрәсәләрдә урта һәм югары баскычларда белем бирсә, мулла югары мәдрәсәләрдә укыткан. Уку-укыту эшчәнлеге китапны баштан алып ахырына кадәр укып чыгу, хәтердә калдыру һәм ятлауга нигезләнә. Мәдрәсәләрдә эвристик укыту (эзләнү рәвешендә) ысулы файдаланыла. Бу ысул буенча укытучы өйрәнелә торган фәннән билгеле бер фикерне укучыларга җиткерә, шәкертләр мәктәптә алган белемнәренә нигезләнеп бу турыда үз фикерләрен әйтә торган була. Мөгаллим шәкертләрнең җавапларына карата бәя бирә һәм үзенең тәкъдимнәрен әйтә, киңәшләрен бирә. Моның нәтиҗәсендә баланың иҗади фикерләү сәләте үсә, үз фикерен нигезле итеп җиткерергә өйрәнә[52].

Укытуда материалны мөстәкыйль рәвештә үзләштерү, зур күләмле чыганак материалны истә калдыру кирәклеге мәдрәсәләрдә репродуктив методны (кат-кат үзләштерелгән белемнәрне, күнегүләрне кабатлау) да куллануга китерә. Репродуктивлык шулай ук уку процессында өлкән шәкертләрнең кечерәкләре белән бердәмләшеп, үзләштерелгән материалны кабатлауларында күренә[53].

Мәдрәсәләрдә уку гадидән катлаулыга таба алып барылган, ягъни билгеле бер китапны укып чыканнан соң гына икенче китапны үзләштерә башлаганнар. Укучылар зур булмаган төркемнәргә бүленеп укыганнар. Нигездә укучы яшь аермасына карап түгел, үзләштерү сәләте буенча (әлеге баскыч укып-ятлап бетерелергә тиешле китапны тәмам иткәннән соң) югарырак баскычка күчә. Шәкертләрнең төрле баскычта укуы белем ала торган китапка «хан» сүзе кушып билгеләнгән. Мәсәлән, «Исагуҗи»не (мантыйк буенча дәреслек) өйрәнә башлагач, шәкертләрне «исагуҗанхан» дип атап йөрткәннәр. Мәдрәсәдә барлык курсны укып бетергән шәкертне «пишкадәм» дип атаганнар. Пишкадәм (фарс. алдынгы, иң яхшы) – төп дәреслекләрдән тыш, өстәмә китаплар белән дә таныш булган, шәригать законнарын яхшы үзләштергән, Коръәнне мәкамгә салып укый белгән[54].

---

[52] Заһидуллина Д. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы.– Казан: Мәгариф, 2000. – 23 б.

[53] Мухаметзянова Д. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах.– Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2008. – С. 168–169.

[54] Лотфи Г. Кышкар мәдрәсәсе // Казан утлары. – 1980. – № 4. – 164 б.

Я.Коблов уку-укыту барышын 3 кә бүлеп карый[55]: 1) гыйльме гарәбия – гарәп теле һәм әдәбият буенча гыйлемнәр. Әлеге бүлектә гыйльме ләгать (гарәп тел белеме), гыйльме сарыф (гарәп морфологиясе), гыйльме нәхү (гарәп теле синтаксисы), гыйльме әт тәварих (пәйгамбәрләр тарихы) һ.б.; 2) гыйльме хикмия – иҗтимагый фикердәге акыл үсеше. Монда исә мантыйк (логика), табигия (табигать фәннәре белеме), гыйльме хисаб (арифметика), илаһия (метафизика) һ.б. предметлардан белем алалар; 3) гыйльме шәргыя – ислам динен өйрәнү. Аларга Коръән, тәфсир (Коръән сүзләренә аңлатма), хәдис (Мөхәммәд пәйгамбәр сүзләре), фикъһ (хокук белеме), гыйльме каләм – дини белем нигезләре, гыйльме фәраиз (мирас бүлү тәртипләре), гыйльме кыйраәт (Коръәнне дөрес укырга өйрәтү) һ.б. керә.

Җ.Вәлиди[56] исә мәдрәсәдә укытуны ике төркемгә бүлеп карарга тәкъдим итә: гыйлем әл-галия һәм гыйлем әл-шәргыя. Гыйлем әлгалия янәдән гарәбият (гарәп теле һәм әдәбияты) һәм гакылия (акыл предметлары) кебек өлешләргә аерыла. Я.Коблов акыл предметларын аерым тәкъдим итсә, Җ.Вәлиди аларны ислам динен өйрәтүче предметның бер өлеше дип карый.

Гыйльме каләм, гыйльме фәраизны үзләштергән шәкерт мулла вазифасына әзер булып саналса, югары белем бирүче мәдрәсәләрдә укытыр өчен фикъһ фәнен белү мөһим шарт була[57]. Уку йортларында фәлсәфә (хикмәт), мантыйк (логика) өйрәнүгә аерым игътибар бирелә[58]. Шәкертләр дәресләрдә мантыйк буенча бирелгән китапларны («Исагуҗи», «Шәмсия», «Тәүзиб», «Мулла Җәләл» һ.б.) укып, аларның төп идеясен, язучының фәлсәфи фикерен табарга өйрәнгәннәр. Мантыйк дәресе, гадәттә, берәр сәгать чамасы вакыт таләп иткән ике яки өч матна гыйбарәсеннән (конспект, тезис харак-

[55] Коблов Я. Конфессиональные школы казанских татар. – Казань: Центр. тип., 1916. – С. 17–19.

[56] Заһидуллина Д. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 23 б.

[57] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 11 б.

[58] Ялалов Ф. Гимназическое образование народов России. – Казань: Магариф, 2002. – С. 53; Заһидуллина Д. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 24–25 б.; Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар. – Казань: Иман, 1998. – С. 7; Мухаметзянова Д. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2008. – С. 173–174.

терындагы төп текст) торган. Мантыйк материалларын китапка карамыйча хәтердән кабатлаганнар, чөнки әлеге фән аңлауга һәм зиһенгә нигезләнгән. Җ.Вәлиди бу уңайдан шәкертләрнең тәнкыйди анализда көчле булуларын, фәлсәфи төшенчәләр белән иркен эш итә алуларын ассызыклый[59]. Моннан тыш, мәдрәсәләрдә мантыйкны өйрәнү буенча төрле фәлсәфи ярышлар – моназаралар да (диспут) уздырылган. Бу ярышлар шәкертләр белән шәкертләр арасында һәм шулай ук башка мәдрәсәдәге шәкертләр арасында уздырыла торган була. Әлеге ярышлар шәкертләрне үз фикерләрен әйтергә, аларны дәлилләргә һәм башкаларны үз фикеренең дөреслегенә ышандырырга, үзе белән ияртеп бара алырга өйрәткәннәр[60].

Мәдрәсәләрдә шулай ук иҗади эш дәресләре дә бик актив оештырылган. Аларның берсе – мөшәгарә – шигырь язу осталыгында ярышу. Мәсәлән, хәлфә кәгазь кисәгенә шигырьнең беренче юлын яза, андагы билгеле фикергә ым күрсәтелә, укучы әлеге фикерне танып, шигырьне тәмамларга тиеш була. Мондый ярышлар укучыда тапкырлыкны, иҗади фикерләүне үстерә[61].

Язу күнекмәләрен өйрәнүгә мәктәп-мәдрәсәләрдә артык зур игътибар бирелмәсә дә, дәресләрдән соң шәкертләрнең күбесе, китап күчерү белән шөгыльләнеп, үзләренең язма күнекмәләрен булдыралар. Китап күчерү өчен зур сабырлык, пөхтәлек, белемгә, матур язуга ия булу таләп ителгән. Нигездә әлеге эш мәдрәсәләрдә шактый гына белем туплаган, яхшы осталыкка ия булган укучыларга тапшырылган. Дини уку йортларында басма китаплар барлыкка килгәнче, шәкертләр кульязма китаплардан белем алганнар, Көнчыгыш һәм җирле галимнәрнең хезмәтләрен, халык авыз иҗаты үрнәкләрен һәм дәреслекләрне күчереп язганнар. Татарлар арасында кульязма китапларның күп таралуында шәкертләрнең дә роле зур була. Мәсәлән, Бохарадагы танылган Сарайбҗа китапханәсендә көнчыгыш китапларын күчереп язу буенча Казан артындагы Түнтәр авылы мәдрәсәсен тәмамлаган хаттатлар (каллиграфлар) дан казана[62]. Бу эш белән шулай ук матур язуга сәләтле кешеләр дә шөгыльләнгәннәр. Атаклы каллиграф-хаттатлар арасында шагыйрь Г. Утыз-Имәни

---

[59] Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар. – Казань: Иман, 1998. – С. 26.

[60] Ялалов Ф. Гимназическое образование народов России. – Казань: Магариф, 2002. – С. 53.

[61] Коблов Я. Конфессиональные школы казанских татар. – Казань: Центр. тип., 1916. – С. 43–44.

[62] Тирән тамырлы Түнтәрем / Төз. Р.Ш.Зарипов. – Казан: Школа, 2008. – 245 б.

һәм аның улы Әхмәтҗанны, Казан университетының Көнчыгыш факультеты укытучысы Мөхәммәдгали Мәхмүдовны һ.б. әйтеп үтәргә мөмкин.[63]

Әлеге чорда мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укытуның, тәрбиянең эчтәлеге һәм оештыру өлеше башка мөселман илләрендәге уку йортларыннан бер дә аерылмаган. Мәсәлән, Алжир, Константинополь, Брус мәктәп-мәдрәсәләренең Идел буендагы уку йортлары белән охшашлыгын Н.Бобровников ассызыклап үтә[64].

Дини уку йортларында кулланылган китаплар, дәреслекләр хәзерге вакытта күз алдында тоткан билгеле бер кануннарга буйсынып эшләнгән дәреслекләрдән ерак тора[65]. Бохара үрнәгендә укыту нәтиҗәсендә, әлеге мәдрәсәләрдә Шәрык илләрендә танылган белем ияләренең (Низами, Нәваи, Фирдәүси, Хәйәм, Физули һ.б.) хезмәтләре өйрәтелә. Мәсәлән, Алишер Нәваинең «Китабе-гаруз», «Мизан әл-әүзан», «Рисаләи мөһиммә» кебек әсәрләре киң таралган дәреслекләр булып хезмәт иткәннәр[66].

Мәдрәсәләрдә кулланылган дәреслекләрнең күпчелеген динидидактик әсәрләр алып тора. Алар Урта Азия мәдрәсәләреннән татарлар тарафыннан алып кайтылып, кулланылышка килеп кергән дәреслекләр. Мәсәлән, шәех Борһанетдинның фикъһ буенча «Һәдия», хәдис буенча «Кырык хәдис», Нәваинең «Әл әрбәгыйнел Нәвави фил хәдис», тәфсир буенча «Мәвәкибе тәфсир», «Тәфсире Хазын», «Тәфсире Рухелбәян» әсәрләрен атап үтәргә мөмкин[67]. «Шәрьятел иман» («Иман шарты») дәреслеге татарларда әлифба китабы булып тора. Китап татарлар арасында гына түгел, ә башка мөселман халыклары арасында да гарәп язуы, ислам нигезләре буенча башлангыч уку әсбабы булып тарала[68]. Дәреслекнең авторлары турындагы мәгълүмат әле дә бәхәсле: кайбер чыганакларда үз авылында мәктәп ачып, озак еллар буе шунда белем биргән укымышлы хәлфәләрнең берсе – Мортаза бине Котлыгыш әс-Симети дип ассы-

---

[63] Фархшатов М. Просвещение // История татар с древнейших времен: в 7 томах. Т. 5. – Казань, 2014. – С. 578.

[64] Бобровников Н. Русско-туземные училища, мектебы и медресе Средней Азии. – СПб., 1913. – С. 228.

[65] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 52 б.

[66] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 187 б.

[67] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 53–54 б.

[68] Шунда ук. – 54 б.

зыкланса, башкаларда Каргалы мәдрәсәсе хәлфәсе Ишнияз бине Ширнияз Харәзми төзегән дип исбат ителә[69]. Ш.Мәрҗани исә, әлеге уку китабының язылу дәверен Болгар дәүләте чоры белән бәйли[70].



*Татарларның беренче әлифбасы «Иман шарты»*

Дини уку йортларында татар теле аерым укытылмаса да, татарча уку фикерне үстерү, ирекле әңгәмә һәм бәхәскә хәзерләнүче дәресләрдә (моназара), гамәли шөгыльләрдә кулланылган. Шул максаттан «Кыйссаи Йосыф», «Кисекбаш», «Бакырган», «Сөбател-гаҗизин», «Мөхәммәдия», «Кыйссаи Рабгузи», «Бәдәвам», «Рисаләи Газизә» һ.б. китаплар файдаланылган[71]. Кулъязма хәлендә булса да, маҗаралы сюжетка корылган әлеге дини-әхлакый эчтәлекле әсәрләр шәкертләр тарафыннан бик яратылып, кызыксынып укыла. Дөньявилыктан шактый ерак торып, ислам дине, пәйгамбәрләр, изгеләр

[69] Ибраһимов Ф. Белем әлифбадан башлана: татарча грамотага өйрәтү методикасы тарихы һәм әлифбалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973.

[70] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 54 б.

[71] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 189 б.

тормышыннан алынган вакыйгалар турында гына мәгълүмат биргән әлеге китаплар шәкертләрнең зиһенен арттыруга да ярдәм иткәннәр[72].

Мәктәп-мәдрәсәләрдә уку гарәп әлифбасы нигезендә алып барыла. Уку китапларының күбесе диярлек гарәп телендә булу сәбәпле, уку йортларында бу телне өйрәнүгә зур игътибар бирелә. Мәсәлән, гарәп телен шәкертләр «Шәрхел Габдулла» исемендә йөртелгән китап буенча өйрәнә башлаганнар, ләкин китап фарсы телендә язылганга күрә, өйрәнү өчен берникадәр авырлык тудырган. Соңрак «Кавагыйдъ», «Гавамил фин нәхү», «Тәркиб шәрх мулла» һ.б уку китаплары гарәп теленә өйрәтү дәреслекләре буларак кулланылалар[73]. Шулай ук Хәсән әл-Катинең «Исагуҗи», «Шәрхе Шәмсия» кебек мантыйк һәм әхлак буенча язылган хезмәтләре дә гарәп теле грамматикасын өйрәнгәндә еш кына дәреслек вазифасын үтәгәннәр[74]. Мәдрәсәләрдә гарәп, фарсы, төрки телләрне яхшы үзләштергән шәкертләр Урта Азия галимнәре һәм шагыйрьләре Фирдәүси, Әбү Рәйхан Бируни, Алишер Нәваи һ.б.ның фәлсәфи фикерләре белән дә таныша алганнар.

Моннан тыш, дини уку йортларында дөньяви фәннәр (география, математика, тарих) махсус укытылмаса да, укучылар әлеге предметлар буенча күпмедер дәрәҗәдә хәбәрдар булалар. Мәсәлән, географик белем – намазны кайсы якка карап уку, мәчет төзү, мәет күмү һ.б. йолаларны башкарганда тиешле кагыйдәләрне ялгышмыйча үтәү өчен кирәк булса, математик белем шәригать нигезендә дөрес итеп мөлкәт бүлү һөнәренә өйрәткән[75]. «Иман шарты», «Сөбател-гаҗизин», «Пиргули» уку әсбапларында математикага караган бүлекләр бар. Анда сату-алу, кәсеп итү, гади исәп белән мәгълүматлар бирү кебек математик мисаллар яктыртыла. Шулай ук Юныс Оруви тарафыннан алгебра элементларын кертеп язылган «Фәраиз» исемле математик кулланма мәдрәсәләрдә озак еллар буе дәреслек хезмәтен үтәгән[76].

Дини мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту системасының уңай һәм тискәре якларын искәртеп, күп кенә галимнәр, язучылар матбугат

---

72 Шунда ук.

73 Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 53 б.

74 Мәрдан Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләрендә гамәлдә булган басма гарәп теле дәреслекләре // Фән һәм мәктәп. – 1996. – № 5. – 10 б.

75 Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 58–59 б.

76 Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 190 б.

битләрендә, фәнни хезмәтләрдә, әдәби әсәрләр мисалында үзләренең фикерләрен җиткерәләр. Бигрәк тә совет чоры тикшеренүчеләре элекке мәдрәсәләрне җәдиди ысул белән чагыштырып, алардагы белем дәрәҗәсе бик түбән булуын, аларның яңалыкка омтылырга теләмәүләрен ассызыклап үтәләр. Мәсәлән, В. Горохов «Мәктәпләрдә уку вакытының иң зур өлеше дин өйрәтүгә бирелә. Дәресләр укучыларга аңлаешсыз булган гарәп, фарсы телләрендә алып барыла. Мәктәптә укытыла торган фәннәр белән практик тормыш арасында бернинди дә бәйләнеш юк. Болар барысы да мәктәп эшенең сыйфатын төшерәләр, балаларда белемгә омтылышны сүндерәләр»[77], – дип ассызыклап үтә. Бу мәдрәсәләргә карата галимнәр арасында озак вакытлар берьяклырак караш яшәп килде, алар дини фанатизм тарату үзәкләре буларак тасвирланды. Шулай да әлеге мәдрәсәләрнең татар милләте өчен бик күп зыялыларны, әдипләрне (Г.Курсави, Х.Фәезханов, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин, К.Насыйри һ.б. шәхесләр) тәрбияләп чыгаруын, халыкны аң-белемле итүгә зур өлеш кертүләрен онытырга ярамый.

Татарлар тормышы белән якыннан таныш булган уку йортлары инспекторы Я.Коблов әлеге уку йортларының татарлар арасында бик мөһим урын биләвен, мәктәп-мәдрәсәләрнең мөселманнарны шактый кануннар белән яшәргә өйрәтеп, аларны берләштерүче көч булуын билгеләп[78]. Казан уку-укыту округы инспекторы В. Радлов мәдрәсәдә укучы шәкертләр турында: «Шәкертләрнең фикри үсеше зур һәм белемнәренең берьяклылыгына карамастан, алар безнең шәһәрдәге приход мәктәпләре укытучыларына караганда зиһен ягыннан өстенрәк торалар»[79], – дип яза. Татарлар тормышында дини уку йортларының тоткан урынын билгеләп Г. Георги да татарларның укуга карата мөнәсәбәтләрен тасвирлап: «...Казан татарлары балаларын әдәплелеккә, сакчыллыкка вә ата-бабадан килгән бәгъзе гадәтләргә генә күнектереп калмастан, аларны укырга, язарга, гарәп теленә, иманга өйрәтү хакында да кайгырталар»[80], – дип яза.

Бу гасырда әлеге дини уку йортлары татарларның иҗтимагый-сәяси тормышында мөһим урын билəп тора. Татар милләтен, аның

---

[77] Горохов В. Педагогика тарихыннан очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 5 б.

[78] Коблов Я. Мечты татар-магометан о национальной общеобразовательной школе. – Казань: Типо-лит. Имп. ун-та, 1908. – С. 1.

[79] Татарстан Үзәк Дәүләт архивы, 92-ф., 58-эш, 15 б.

[80] Шәймәрданов Р., Хуҗиәхмәтов Ә. Татар милли педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 44 б.

мәдәни, рухи, дини байлыкларын саклап калуда әлеге уку йортларының да урыны зур.

Бу чорда татар халкының милләт буларак үзен саклап калу мәсьәләсе алга килеп баса. Ислам дине бу чорда халык өчен ныклы таяныч була. Татарлар тормышында суфичылык тагын да көчәеп китә. Ул кешене Аллаһны истә тотарга, Аңа лаеклы булып яшәүгә өнди. Бу чорда суфичылык халыкны чыдамлылыкка, сабырлыкка чакыра һәм халыкка гореф-гадәтен, телен саклап калырга ярдәм итә.

Татар дәүләтчелеге бетү белән мәдәният һәм милли мәгариф, мәктәп системасына да зыян салына. Патша хөкүмәте татарларга белем алуга мөмкинлекләрне чикли (руслаштыру, христианлаштыру сәясәте алып барыла һ.б.), халык төрле юллар белән гыйлемгә омтыла. Иң элек ул авылларда мулла өйләрендә оешкан мәктәпләрдә генә алып барылса, соңрак мәчет каршындагы мәктәп-мәдрәсәләрдә белем алу мөмкинлеге туа.

Татар халкының белем бирү, уку-укыту традицияләренең яңаруы XVIII гасыр ахырларында башлана. Моңа сәбәп булып, мөселманнарга дин иреге бирелү, Diния нәзарәте оештырылу һ.б. тора.

Мәктәп-мәдрәсәләрдә белем һәм тәрбия Бохара системасы буенча алып барыла. Бу чорда мәктәпләрдә балаларны ислам дине нигезләре белән таныштыру аша әхлак тәрбиясен бирү үзмаксат булса, мәдрәсәләрдә ислам дине кыйммәтләрен халыкка җиткерә алырлык дин әһелләре, мөгаллимнәр әзерләү вазифасы йөкләнә. Әлеге дини мәдрәсәләр татар милләте өчен күп зыялыларны, галимнәрне, әдипләрне әзерли. Бу шәхесләр исә татар халкына аң-белем таратуга зур өлеш кертәләр, халыкның рухи мәдәниятен үстерүдә мөһим роль уйныйлар.

# IV. XVIII ГАСЫР АХЫРЫ – XX ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР МӘГАРИФЕ

Татар җәмгыятенең барлык катламнарына да тәэсир иткән мәгърифәтчелек хәрәкәтенең беренче чаткылары XVIII гасыр урталарында ук күренә башлый. Мәсәлән, Батыршаның мөселман укуукыту системасы булдыру турындагы фикерләре Елизавета патшабикәгә язган хатында чагылыш таба [1].

XVIII гасыр ахырына илдә башланган икътисади, сәяси һәм мәдәни үзгәрешләр татар иҗтимагый фикере үсешенә дә уңай йогынты ясый, җәмгыятьтә яңарыш, мәгърифәтчелек идеяләре уянуга этәргеч бирә.

XVIII–XIX гасырлар чигендә туган яңарыш идеяләренең төп үзенчәлеге булып, болгарлар исламны кабул иткән вакыттагы саф ислам нигезләренә әйләнеп кайту, фикер хөрлеге, иҗтиһад идеяләре тора. Бу чорда мәгърифәтчелек фикерләре мөселман дине кысаларында үсә. Әлеге юнәлештә фикер йөрткән шәхесләрне дини ислахчылар (реформаторлар) дип атыйлар. Дини үзгәреш идеяләре беренчеләрдән булып Г.Утыз-Имәни һәм Г.Курсави хезмәтләрендә чагылыш таба[2].

Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари җәмгыятьтә хөкем сөргән гаделсезлекләрнең, икейөзлелекнең, җәбер-золымның сәбәбен наданлыкта, кешеләрнең әхлаксызлыгында күрә. Җәмгыятьне кешеләрне әхлакый камилләштереп кенә үзгәртеп була дип саный. Г.Утыз-Имәни карашлары буенча кеше матур әхлак сыйфатларына, гыйлемлеккә ия булырга тиеш. Ул тик укыган, белемле-мәгърифәтле кеше генә яхшы әхлаклы була ала, надан кеше үзенең наданлыгы

---

[1] Ислаев Ф.Г. Батырша. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 18.

[2] Юзеев А.Н. Татарская религиозно-реформаторская мысль. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 76–77.

аркасында әхлаксыз була, дип саный. Шуңа күрә замандашларын укырга, белемле булырга, мәгърифәткә өнди.

Мәңге яшәргә теләсәң, и угыл, ал гыйлем, чөнки тереклек суы ул...
Чын бәхетне бирә тик гыйлем генә, баш ияләр һәрвакыт белемлегә.
Ал, гыйлем, чөнки яшәүнең аслы шул, хәл итә барлык кыенлыкны тик ул.
Кем гыйлемле, бел асылташ дип аны, һич җиңалмас угры яки дошманы[3].

Мәгърифәтче заманы өчен көтелмәгән фикер – хатын-кызларның җәмгыятьтәге ролен күтәрү, аларны укыту мәсьәләләрен дә яктырта.

Г.Утыз-Имәни шул чордагы дини һәм иҗтимагый тәртипләр белән килешеп бетми. Аларны гасырлар буе җыелып килгән бозыклыклардан арындырырга, болгарлар исламны кабул иткән вакыттагы беренчел халәтенә кайтарырга, тормышка яраклаштырып үзгәртергә кирәк, дигән фикергә килә. Гыйлем мәсьәләсендә дә заманы өчен алдынгы булган фикерләр әйтә. Мәдрәсәләрдә хөкем сөргән дини схоластика, тормыш өчен яраксыз гыйлемнәр, аеруча идеалистик фәлсәфә һәм формаль логика укыту белән килешә алмый. Алар урынына тормыш өчен кирәкле булган фикъһ һәм хәдис фәннәре укытуны алга куя. Һәр укыган нәрсәгә сукырларча иярүгә каршы чыга, һәр кешегә мөстәкыйль фикер йөртергә хокук, акыл һәм зиһен иреге таләп итә. Аның үзенчәлекле фикер юнәлеше «Утыз Имәни мәсләге» дип атап йөртелә[4].

Г.Утыз-Имәни карашлары белән бер юнәлештә торган, исламның шул чорда тоткан урыны белән килешмәгән, фикер иреге таләп иткән тагын бер мәгърифәтче – Габденнасыйр Курсави. Ул шулай ук үз хезмәтләрендә иҗтиһад, ягъни мөстәкыйль фикер йөртү иреге мәсьәләләрен күтәрә. Үз замандашларыннан аермалы буларак, Г.Курсави абсолют иҗтиһадка омтыла. Галим фикеренчә, һәр кеше, кайчан гына булмасын, үзенең көче җиткән кадәр уйлап, иҗтиһад белән эш итәргә, Коръәндә җавап табарга мөмкин булмаган сорауларга җавап эзләргә хокуклы. Ул торгынлыкны тәнкыйтьли, иманны чистартырга чакыра, тәкълидчелеккә (борынгы авторитетлар әйткән сүзләргә таянып эш итү) каршы чыга. Г.Курсави халыкның килә-

---

[3] Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар / Төз. Ә.Шәрипов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 165 б.

[4] Шунда ук. – 5–14 б.

чәге, аның алгарышы һәм мәгърифәт юлына баса алуы фәнни белемнәр һәм мәдәният таралуга бәйләнгән дип карый. Шуннан чыгып, гыйлемнең таралуына булышлык итә торган мәдрәсәләр салу, китаплар язу эшенә өнди[5].

Беренче дини-мәгърифәтчеләрнең, аз санлы булса да, тарафдарлары һәм аларның эшләрен дәвам итәргә теләүчеләр дә була. Ләкин, милли үзаңның үсешенә каршы булган дәүләт әһелләре тарафыннан алар төрле эзәрлекләүләргә дучар ителәләр. Мәсәлән, Хоҗанд (Худжанд, Таҗикстан) мулласы Хаҗибат мөселман мәктәпләрендәге укыту тәртипләре белән килешә алмаганы өчен укытучылык эшеннән читләштерелә, ә Сәмәрканд казые Әбү-Сәгыйтьнең милке тартып алына[6].

Татар дөньясында яңалыкка, гыйлемгә омтылучы, халыкны мәгърифәт юлына бастырырга теләүче шәхесләр җитлексә дә, аларның гамәлләре, фикер үсеше әлегә мөселман җәмгыяте тарафыннан кабул ителми. Ләкин алар гамәлдә булган мөнәсәбәтләрне үзгәртеп коруны таләп итеп, башкалардан аерылып торган фикерләрен халыкка таратып, XIX гасырның икенче яртысында татарлар арасында киң таралган мәгърифәтчелек хәрәкәтенә нигез салалар.

XVIII–XIX гасырлар чигендә христиан дөньясы белән икътисади мөнәсәбәтләргә керү, чит мәмләкәт, бигрәк тә Көнбатыш Европа, эшмәкәрләре белән эшлекле бәйләнешләр урнаштыру татар мохитенә яңа фикер агымнары, рус һәм Көнбатыш Европа әдәбияты һәм мәдәнияте, дөнья казанышлары үтеп керүгә мөмкинлекләр тудыра, җәмгыятьтә урнашкан тәртипләрнең заман ихтыяҗларына җавап бирә алмавын күрсәтә. Урта Азия мәдрәсәләрендә кулланылган схоластик уку-укыту системасы күпләрне инде канәгатьләндерми башлый. Белем алырга теләгән яшьләрне үзләренең алдынгы карашлары белән таныла башлаган Каһирә, Искәндәрия һәм Истанбул уку йортлары җәлеп итә[7]. Татар дөньясында алдынгы карашлы зыялылар, эшмәкәрләр, дөньяви белем алган шәхесләр саны арта. Мәгърифәтчеләр, ислам традицияләрен саклап калып, аны татар җәмгыяте үсеше шартларына яраклаштырып яңарту, алдынгы фән һәм мәдәният казанышларын татар халкы арасында аң-белем таратуда куллану, дөньяви фәннәрне өйрәнү кирәклеген алга сөрәләр.

---

[5] Абдуллин Я., Хәйруллин Ә. Мәгърифәтчелек хәрәкәте карлыгачы // Казан утлары. – 1977. – № 1. – 144–151 б.

[6] Шунда ук. – 150 б.

[7] Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 120 б.

Россиянең казах һәм Урта Азия халыкларын буйсындыру сәясәтендә, сәүдә һәм эшлекле сөйләшүләр вакытында татар теле рәсми дипломатия теле буларак кулланыла. Әлеге халыклар белән аралашу өчен татар телен яхшы белгән хезмәткәрләр, тылмачлар, арадашчымөселманнар кирәк була. Шушы максаттан чыгып, Россиянең чиновниклар әзерләүче уку йортларына, булачак дәүләт эшлеклеләрен татарча аралашырга өйрәтү максаты белән татар телен укыту кертелә. Мәсәлән, 1764 елдан Әстерханда солдат балаларына татар теле өйрәтелә, XVIII гасыр азагыннан Мәскәү университеты каршындагы Академик гимназиядә, Омск Азия мәктәбендә һәм Тубыл төп халык училищесында татар теле укытыла. Казандагы беренче ирләр гимназиясендә татар телен укыту 1769 елда кертелә. Татар теле укытучысы итеп Адмиралтейство конторасы тылмачы Сәгыйть Хәлфин билгеләнә, соңрак аның эшен Ибраһим Хәлфин дәвам итә. Бу чорда татар телен укыту методикасына нигез салына башлый: татар галимнәре тарафыннан беренче сүзлекләр[8], грамматика[9] китаплары дөнья күрә. Русларны татар теленә өйрәтү буенча үз тәҗрибәсенә таянып, методик планда язылган беренче басма татар әлифбасы төзелә[10]. Әлеге дәреслек гарәп шрифтын кулланып, татар һәм рус әлифбасы белән таныштыра, киң кулланылыштагы сүзләрне ике телдә чагыштырып бирә[11].

И.Хәлфин беренчеләрдән булып татар мәгарифен үзгәртүгә омтылыш ясый. Ул татарларга югары белем бирү турында хыяллана, дөнья казанышларын өйрәнеп кенә алгарышка ирешеп була дигән фикердә тора, туган тел белән бергә рус телен дә өйрәнү кирәк дип саный. Аның бу фикерләре «И.Хәлфиннең татарларга гыйлем бирү

---

[8] Хальфин С. Татарский словарь и краткая татарская грамматика в пользу обучающегося юношества татарскому языку. – Казань, 1785.

[9] Хальфин И. Букварь этимологии и лексики татарского языка. – Казань, 1804; Хальфин И. Азбука и грамматика татарскаго языка с правилами арабскаго чтения, преподаваемыя в Императорской Казанской гимназии. – Казань: Тип. Казан. ун-та, 1809. – 168 с.

[10] Хальфин С. Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочиненная Казанских гимназий учителем и Адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфиным, и татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях, рассмотренная и одобренная. – М.: Имп. Московский ун-т, 1778. – 52 с.

[11] Шәкүрова М.М. Татар теле укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). – Казан: Ислах, 2012. – 11–12 б.

хакындагы фикерләре» дигән план-проектында чагылыш таба[12]. Проектта ул университет студентларын укый-яза белмәгән халык белән эшләүгә тарту фикерен тәкъдим итә[13]. Ләкин әлеге проект гамәлгә ашырылмый.

XIX гасырның икенче яртысында үсеш алган мәгърифәтчелек хәрәкәтенең төп нигезен дини мәгърифәтчелек идеяләре тәшкил итә, ләкин ул моңа кадәрге фикерләрдән нык аерылып тора[14]. Бу чорда мәгърифәтчелек хәрәкәтенең алга таба үсешенә Х.Фәезханов, Ш.Мәрҗани һәм К.Насыйриларның эшчәнлекләре нык тәэсир итә. Аларның фикер үсешләрен ике чорга бүлеп карарга мөмкин: эшчәнлекләренең беренче дәверендә дини ислахчылык карашларына өстенлек бирсәләр, икенче дәвердә мәгърифәтчелек идеяләре алга чыга. Галимнәрнең куйган максатлары бер булса да, фикер юнәлешләрендә үзенчәлекләр сизелә. Х.Фәезханов белән К.Насыйриның дөньяга карашлары формалашуга рус һәм Көнбатыш Европа мәдәниятләре нык йогынты ясаганлыктан, аларның мәгърифәтчелек идеяләрендә дөньяви юнәлеш өстенлек ала, шул сәбәпле аларның фикер агымы заманы өчен кискенрәк тоела. Ш.Мәрҗанинең карашлары татар җәмгыятенең чынбарлыгына күбрәк туры килгәнлектән, аның юнәлеше җәмәгатьчелек тарафыннан уңай кабул ителә[15].


*Х.Фәезханов*

Мәгърифәтчелек хәрәкәтенә беренчеләрдән булып юл салучы – Хөсәен Фәезханов. Галим тарих, татарларның этногенез мәсьәләләре белән кызыксына, татар теле өлкәсендә күп эшли, студентлар өчен татар теленнән дәреслек яза[16], лингвистик тикшеренүләр үткәрә, Көнчыгыш телләре укыта.

[12] Хальфин И. Любопытные соображения И.Хальфина к просвещению татар. – Казань, 1819.

[13] Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. – Казань: КГПУ, 1998. – С. 12.

[14] Юзеев А.Н. Татарская религиозно-реформаторская мысль. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 101.

[15] Юзеев А.Н. Просветительская мысль татарского народа (XIX – нач. XX вв.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. – С. 409.

[16] Краткая учебная грамматика татарского языка. – СПб., 1862. – 95 с.

Аның мәгариф өлкәсендә игътибарга лаек булган казанышы булып мәктәп системасын яңарту һәм яшь буынга дөньяви белем бирү мәсьәләләре тора.

Х.Фәезханов мөселман уку-укыту системасын үзгәртү буенча проект төзи. Проект ике кисәктән тора. Беренчесе «Ислахе мәдарис» («Мәдрәсә реформасы») исеме белән, икенчесе «Рисалә» («Трактат» яки «Язмалар») дип атала. Мәгърифәтче татар мәктәп-мәдрәсәләрендә кулланылган белем бирүнең Бохара системасын, аларда хөкем сөргән урта гасыр мохитен тәнкыйтьләп чыга. Рус гимназияләрендәге белем бирү системасы белән якыннан таныш булганлыктан, татар мәдрәсәләрен оештырганда аларны үрнәк итеп алырга тәкъдим итә.

Мәдрәсәнең эчтәлегенә килгәндә, яңартылган татар мәдрәсәләрендә рус гимназияләрендә укытылган барлык фәннәр, дини фәннәр һәм гарәп теле, Европа телләре, география, табигать белеме, медицина, рус һәм төрек телләре укытылырга тиеш була.

Татар мәдрәсәләрендә гимназияләргә караганда күбрәк фәннәр укытылганга күрә, уку вакыты ун ел дип алына. Беренче өч елда барлык укучылар тарафыннан рус, татар, төрек, гарәп, фарсы телләре, география, геометрия, сәнгатьле уку һәм матур язу фәннәре өйрәнелә. Калган җиде елда белем бирү ике юнәлештә алып барыла. Беренчесе – ислам бүлеге. Монда дини фәннәр өстенлек ала, шул ук вакыт рус гимназияләренең төп фәннәре укытыла. Икенчесе – дөньяви бүлек. Укыту программасы тулысынча рус гимназияләренә туры килә һәм ислам буенча төп фәннәр укытыла. Европа телләрен, географияне, медицинаны, табигать белемен укыту рус телендә алып барылып, калган фәннәр татар телендә укытылырга тиеш була[17].

Күренгәнчә, Х.Фәезханов тәкъдим иткән проект буенча, ислам бүлегендә булачак муллалар һәм мөгаллимнәр хәзерләнә, ә дөньяви бүлектән университетка кереп укый алырлык, киләчәктә югары белемгә ия булырга тиешле кадрлар хәзерләнеп чыга. Кызганычка каршы, Х.Фәезхановның проекты тормышка ашмый.

Х.Фәезхановның татар мәдрәсәләрен яңарту идеяләре үз вакытында тормышка аша алмасалар да, алар җәдитчелек чорында оештырылган татар мәктәп-мәдрәсәләренең нигезен тәшкил итәләр.

Х.Фәезхановка кадәр дә мәктәп-мәдрәсә реформасы уздыру буенча берничә проект тәкъдим ителә. Беренче проектларның берсе булып 1818 елда Оренбург мөселман диния нәзарәте (ОМДН) бе-

[17] Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. – Казань: КГПУ, 1998. – С. 15–16.

ренче мөфтие М.Хөсәенов тарафыннан төзелгән проект санала. Аның буенча Казанда һәм Оренбургта ике дөньяви уку йорты төзелергә тиеш була. Казандагы уку йорты университет каршында эшли, анда дини фәннәр белән бергә дөньяви фәннәр, шул ук вакытта телләр өйрәнелә. Аны тәмамлаучылар тәрҗемәче белгечлеге буенча университетка керергә мөмкинлек алырга тиеш булалар. Ә Оренбургтагы уку йортын губернатор кул астында ачу күз алдында тотыла. Аны тәмамлаучылар Казах далаларында һәм Урта Азиядә тәрҗемәче булып эшли алачаклар. Ләкин бу проект та дәүләт башлыклары тарафыннан яклау тапмый.

Мондый проектлар алга таба да әзерләнә. Мәсәлән, 1866 елда мөфти С.Тәфкилев Уфа мәчете каршында дини фәннәр белән беррәттән дөньяви предметлар да укытыла торган мәктәп ачу тәкъдиме белән чыга.

Гомумән алганда, 1818–1880 еллар аралыгында патша хөкүмәтенең төрле даирәләренә татарлар өчен Европа үрнәгендәге мәктәпләр ачу идеяләре белән барлыгы сигез проект тәкъдим ителә. Алар арасында В.Радлов, Ш.Мәрҗани, Р.Фәхретдин һ.б.ларның проектлары да була. Әмма аларның барысы да кире кагыла[18].



*Ш.Мәрҗани*

Җәдитчелек хәрәкәтенең тагын бер алхәбәрчесе – Шиһабетдин Мәрҗани – үзенең карашларында[19] Г.Утыз-Имәни һәм Г.Курсавилар юлын дәвам итә, аларның фикерләрен яңа шартларга туры китереп үзгәртә һәм тирәнәйтә, исламны яңача шәрехләргә кирәклегенә басым ясый.

Үз чорының дин белгечләреннән аермалы буларак, Ш.Мәрҗани дөньяви белем алу белән динне бер ясылыкка куя. Галим фикеренчә, фән үсеше, дөньяви белемнең халык арасында таралуы татар җәмгыятен алга җибәрергә булышлык итсә, диннең тәрбия нигезләмәләре җәмгыятьнең әхлакый яктан камилләшүенә китерә.

[18] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 154 б.

[19] Мәрҗани Ш. Назурат ал-хакк фи фардият ал-аша ва ан лям ягиб-ш-шафак. – Казань: Тип. ун-та, 1870. – 164 с.

Ш.Мәрҗани үз мәктәбендә үзе төзегән программа буенча укыта. Аның педагогик карашларының бер юнәлеше булып, укучыларны мөстәкыйльлеккә, фикер йөртергә, уйларга өйрәтү принцибы тора. Ш.Мәрҗани рус телен өйрәнүне яклап чыга. Аның фикеренчә, ислам белем алырга булышлык иткән телләрне өйрәнүне тыймый. Ләкин, фикердәшләреннән аермалы буларак, укучыларның руслашуларын булдырмас өчен, укытуны татар телендә алып барырга тәкъдим итә. Хәтта рус теле дәресләрен дә. Фикер иясе уйлавынча, һәр кеше, үзенең мәнфәгатьләрен яклар өчен хаким милләтнең телен, язуын, законнарын яхшы белергә тиеш[20].

Галим халыкның үзаңы уянсын, җәмгыять дөньякүләм мәдәни уңышларга ирешсен өчен тарихи үткәнне һәм бүгенге мәдәниятне өйрәнергә кирәклеген ассызыклый. Ш.Мәрҗани «татар халкы тарихының чыганаклар корпусын борынгы чордан алып, XIX йөз ахырына кадәр киң колачта барлаган, тикшергән һәм фәнни әйләнешкә керткән»[21] шәхес. Хәзерге галимнәр фикеренчә, ул тарихи белемне гыйльми юнәлешкә борып җибәрүче, татар милли тарих фәненә нигез сала[22].



*К.Насыйри*

Татар мәгърифәтчеләренең фикер үсешенә рус педагогларының тәэсире зур була. Каюм Насыйри рус мәгърифәтчеләренең эш алымнарын өйрәнеп, аларны беренче булып татар балаларын укытуда куллана башлый. Рус булмаган халыкларны христианлаштыру максатыннан чыгып кабул ителгән «Кагый-

---

[20] Марджани о татарской элите (1789–1889) / Пер. со старотат. и примеч. А.Н.Юзеева и И.Ф.Гимадеева; [отв. ред. И.Л.Алексеев]. – М.: Изд. дом Марджани, 2009. – С. 26–35.

[21] Госманов М.А. Шиһабетдин Мәрҗани һәм тарихи чыганакларны өйрәнү // Мәрҗани: Тарих һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Мастер Лайн, 1998. – 20 б.

[22] Хәйри Ә.Н. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфаде-л-әхбар...» китабы // Шиһабетдин Мәрҗани: Мирасы һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Алма-Лит, 2008. – 102–108 б.; Госманов М.А. Шиһабетдин Мәрҗани һәм тарихи чыганакларны өйрәнү // Мәрҗани: Тарих һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Мастер Лайн, 1998. – 20 б. һ.б.

дәләр» (1870 ел, 26 март) нигезендә Казанда ачылган беренче башлангыч рус-татар мәктәбендә (1871) татар мәктәп-мәдрәсәләренә хас булмаган класс-дәрес системасын кертә, күрсәтмә материаллар (глобус, карталар, геометрик фигуралар, сызымнар, грамматик таблицалар) куллана башлый, белемне ныгыту өчен экскурсия һәм сәяхәтләргә чыгарга тәкъдим итә. Әлеге ысуллар белемнәрне тизрәк истә калдырырга булыша, укыту процессын җиңеләйтә дигән фикердә тора. Ул белем бирүне тормыш белән бәйләп алып барырга чакыра, укытуда эзлеклелек принцибын алга куя, укучылардан аңлылык һәм активлык таләп итә, ләкин ирекле тәрбия алымнарын кабул итми.

К.Насыйри фән һәм мәгарифнең күп өлкәләренә үз өлешен кертә: татар балаларына рус теле һәм рус балаларына татар теле укытуга зур игътибар бирә, татар һәм рус телләренең грамматикасын яхшы белә, укытуда чагыштырма методны куллана, бу юнәлештә дәреслекләр һәм сүзлекләр төзи. Аның «Әнмүзәҗ» дигән хезмәте шул чорның беренче гыйльми тулы грамматикасы дип санала[23], ә «Ләһҗәи татари» сүзлеге лексик байлыкны туплауга һәм фәнни терминология булдыруга юл ача. К.Насыйри дөрес һәм матур язу күнекмәләре булдыру өчен дә кулланмалар төзи[24].

К.Насыйри балаларны дөньяви фәннәрнең нигезләре белән таныштыру максатыннан татар телендә кызыклы, бай материал туплаган, тормыш белән бәйләп бирелгән география, табигать белеме, математика, геометрия, ботаника, физика дәреслекләре төзи[25].

К.Насыйри татар педагогларыннан беренче булып мәктәпкәчә тәрбия мәсьәләсенә әһәмият бирә. Аның «Бала тәрбияләүче аналарга теләкләр» китабы бу юнәлештә татар телендә язылган беренче китап. Китапта галим фикерләрен фәнни яктан дәлилләп, педагогик һәм тән тәрбиясе буенча тәкъдимнәр бирә.

---

[23] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 24–25 б.

[24] Насыйри К. Кыскача татар нәхүе. – Казан, 1860; Насыйри К. Кавагыйд кыйраәт русия мәҗмугасы. – Казан: Ун-т тип., 1889. – 24 б.; Насыйри К. Нәмүнә, яки Әнмүзәҗ. – Казан: Ун-т тип., 1891. – 184 б.; Насыйри К. Әнмүҗәз. – Казан: Ун-т тип., 1895. – 87 б.; Насыйри К. Кавагыйде китабәте [Язу кагыйдәләре]. – Казан: Ун-т тип., 1892. – 32 б.; Насыйри К. Ләһҗаи татари. I–II т. – Казан: Ун-т тип., 1895. – 96 б.; Насыйри К. Татарча-русча лөгать китабы. – Казан: Ун-т тип., Амашев нәшр., 1878. – 120 б. һ.б.

[25] Насыйри К. Ысуле җәгърафия кәбир. – Казан: Ун-т тип., 1894. – 206 б.; Насыйри К. Хисаплык. – Казан: Казан ун-ты тип., 1873. – 52 б.; Насыйри К. Истыйляхате гыйльми һәндәсә. – Казан: Ун-т тип., 1895. – 24 б. һ.б.

К.Насыйри халыкчанлыкны һәм гуманлылыкны тәрбиянең төп принциплары дип саный. Беренче принцип халыкка, алгарышка хезмәт итү өчен тәрбия бирүне чагылдырса, икенчесе тәрбиядә балага гуманлы якын килү, баланы шәхес буларак хөрмәт итүне күздә тота[26]. Үзенең ярдәмлекләрендә[27] балада туган илгә мәхәббәт, хезмәт сөючәнлек, дөреслек, тапкырлык, өлкәннәргә хөрмәт, кыюлык кебек әхлак сыйфатлары тәрбияләргә кирәклегенә басым ясый.

Югарыда санап үтелгән мәгърифәтчеләрнең барлык уй-хыяллары тормышка ашмаса да, аларның эшчәнлеге милли үзаң уянуда, татар мохитен урта гасыр идеологиясеннән азат итүдә зур роль уйный. Алар җәдитчелек хәрәкәтенең алхәбәрчеләре булалар.

Шулай итеп, XIX гасырның икенче яртысында татар җәмгыятендә дөньяви яңарышка юнәлдерелгән фикер агымы туа, мәгърифәтчелек идеяләре нигезендә дөньяга яңача караш формалаша. Яңа идеология тарафдарлары иҗтимагый тормышны заман таләпләре кушканча үзгәртеп коруны таләп итәләр. Бохара ысулы белән укыту татар җәмгыяте мәнфәгатьләрен канәгатьләндерми башлый. Яңа идеология тарафдарлары шәхеснең мөстәкыйль фикер үсешен, белем бирүдә дөньяви фәннәргә өстенлек бирүне, фәнни белемнәр таратуны, укытуны ана телендә алып баруны, ягъни Европа мәктәпләре калыбындагы уку-укыту системасын булдыруны алга сөрәләр. Яңа агым тарафдарларын «җәдитчеләр» дип йөртә башлыйлар. Аларга каршы «кадимчеләр» (иске), ягъни традицион тәртипләрне үзгәрешсез саклау юнәлеше тарафдарлары каршы чыга. Алар өч принципка нигезләнеп эш итәләр. Беренчесе – иҗтимагый тормышка европалаштыруны кертмичә, ата-бабалардан килгән тормыш үзенчәлеген саклап калу. Икенчесе – хатын-кызларга белем алу мөмкинлекләрен чикләү. Өченчесе – рус телен өйрәнүне тыю[28]. Кадимчеләр мөселманнарга хас булмаган барлык үзгәрешләр ялган, һәр яңалык татар дөньясын җимерүгә китерә дип саныйлар.

Татар халкын, гомумән, төрки халыкларны тәрәккый итү мәсьәләләрен күтәреп чыккан тагын бер мәгърифәтче – Исмәгыйль Гаспралы (Гаспринский). Ул кадимчеләрнең принципларына үзенең җәдиди идеяләрен каршы куя. Россиядәге мөселман халыкларын

---

[26] Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. – Казань: КГПУ, 1998. – С. 57.

[27] Насыйри К. Әхлак рисаләсе. – Казан: Ун-т тип., 1884. – 24 б. һ.б.

[28] Мухаметдинов Р. Исмаил Гаспринский // Татарские интеллектуалы: исторические портреты / Сост. Р.М.Мухаметшин. 2-е изд., перераб. и доп. – Казань: Магариф, 2005. – С. 67.

торгызу өчен башлангыч һәм урта мәктәпне яңарту, бердәм төрки әдәби тел булдыру, хатын-кызларның белем дәрәҗәләрен күтәрү, рус телен белүне камилләштерү кирәк дип саный[29], мөселман дөньясында беренчеләрдән булып, 1867 елны Бакчасарайның Зынҗырлы мәдрәсәсендә рус телен укыта башлый.



*И.Гаспралы*

Х.Фәезханов, К.Насыйри һәм аларның тарафдарлары укыту программаларына математика, рус теле, география кебек дөньяви фәннәр укытуны кертсәләр дә, укырга һәм язарга өйрәтү хәреф-иҗек ысулы белән алып барыла. И.Гаспралы исә, әлифба чорында яңа ысул – аваз-хәреф ысулын («ысулы саутия») куллана. Шуннан чыгып, ысулы саутия методы, аның методик яңалыгын исәпкә алып, «ысулы җәдидия», ягъни җәдидчә укыту дип атала башлый. Иске ысул белән укыту «ысулы кадимия», ягъни кадимчә укыту була. Беренче мәгърифәтчеләр гомумән белем бирү системасына үзгәреш кертүне, укыту программаларына дөньяви фәннәр кертүне таләп итсәләр, И.Гаспралы белем бирүнең ысулын яңарта, Россия мөселманнары арасында башлангыч мәктәп реформасын башлап җибәрүче булып санала[30].

1884 елда Бакчасарайда И.Гаспралы тарафыннан ысулы саутия белән укытуга нигезләнгән беренче мәктәп ачыла. Мәгърифәтче анда үзенең «Хуҗаи сыйбъян» исемле әлифбасын кулланып белем бирә. Яңа ысул бер уку елы дәвамында укырга, язарга, ислам дине нигезләре белән танышырга, арифметика нигезләрен өйрәнергә, Коръән уку серләренә төшенергә мөмкинлек бирә.

Мәгърифәтче барлык төрки халыкларны берләштерү максатыннан бердәм төрки әдәби тел булдыруны максат итеп куя. Әлеге тел башлыча гадиләштерелгән төрек теленә нигезләнгән һәм, мөмкин булганча, гарәп һәм фарсы алынмаларыннан азат ителеп, галим үзе әйткәнчә, «Босфор көймәчеләреннән алып, Кашгар кәрванчыларына

[29] Шунда ук. – С. 67.

[30] Надир Давлет. Исмаил Гаспринский / [пер. с тур. яз. Б.Ногманова]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – С. 17–19.

кадәр» аңлаешлы булган тел[31]. 1883 елның 10 апрелендә Россия мөселманнары тарихында беренче тапкыр шушы телдә язылган «Тәрҗеман» газетасы чыга башлый. И.Гаспралы үзенең газетасында яңача укытуны, ягъни мәктәп-мәдрәсәләргә Европа мәгарифен һәм гыйлемен кертүне, Россия мөселманнарын Европа цивилизациясе белән таныштыруны, аларны Россия мәдәниятенә һәм мәгарифенә якынайтуны, ә моның өчен Европа, рус педагогикасына яраклаштырып язылган яңа дәреслекләр булдыруны һәм мәктәп-мәдрәсәләрдә үз ана телендә генә укытуны алга сөрә[32].

Ике телдә, төрки һәм рус телләрендә, чыккан газета төрки халыкларны милли-мәдәни мираслары, дөнья казанышлары белән таныштырса, рус укучыларын мөселман мәдәнияте һәм мөселман җәмгыятендә булган яңалыклар белән таныштыра. «Тәрҗеман» 1905 елга кадәр Россия территориясендә бердәнбер төрки-татар газетасы булып кала һәм татар җәмгыятендә җәдиди мәктәпләрнең тарала башлавына зур йогынты ясый.


خواجۀ صبیان

صبیان مکتبلرینه مخصوص یکی و ینکل اصول

الفبا و درس کتابی‌در .

( آز وقتده اوقومق یازمق و حساب بیلدیرر )

مؤلفی

جریدۀ «ترجمان» محرری اسماعیل غصپرنسکی

شهر باغچه‌سرای

— ولایت قریم —

(ایکنجی دفعه)

باصلمه‌سنه رخصت برلدی. س. پتربورغ

سنه ١٨٩

ترجمان باصمه خانه‌سی

Татарстан Җөмһүриятенең Милли китапханәсе Национальная библиотека Республики Татарстан

*И.Гаспралының «Хуҗаи сыйбъян» дәреслеге*

Яңартылган белем бирү системасының кирәклеген иң беренче булып татар җәмгыятенең алдынгы карашлы даирәләре күтәреп ала. Бу юнәлешне татар буржуазиясе дә яклап чыга. Алар гомумроссия һәм чит ил базарларындагы конкуренциягә каршы торыр өчен, дөньяви белемнәрнең билгеле бер дәрәҗәсенә ия булган, телләр белгән, җитештерүне киңәйтеп, эшне тиешле югарылыкта алып бара

[31] Исмаил бей Гаспринский. Россия и Восток. – Казань: Фонд Жиен; Татар. кн. изд-во, 1993. – С. 88.

[32] Исмәгыйль бәк Гаспринский. – Казан: Алма-Лит, 2004. – 5 б.

алырлык кешеләр кирәклеген аңлыйлар, мәгариф өлкәсен яңартуда үзләренең матди ярдәмнәрен күрсәтә башлыйлар: яңа төр мәктәп-мәдрәсәләр ачалар һәм аларны тәэмин итеп торалар, мөгаллимнәрне үз хисапларына тоталар, сәләтле шәкертләрне чит ил югары уку йортларына, стажировкаларга җибәрәләр һ.б. Дөньяви белемне алга сөрү тарафдарлары арасында Әхмәд һәм Гани Хөсәеновлар, Шакир һәм Закир Рәмиевләр, фабрикант Акчуриннар, Үтәмешевлар, Әҗемовлар һ.б. татар буржуазиясе вәкилләрен атарга була[33].

Бу эшкә иң күп көч керткән шәхесләр булып бертуган Хөсәеновлар санала. Алар ярдәме белән 1889 елда Оренбургта «Хөсәения», 1899 елда «Вәлия» мәдрәсәләре ачыла һәм алар хисабына яши. Каргалыда һәм Оренбургта, татар дөньясында беренче мәртәбә буларак, мөгаллимнәрнең белемен күтәрү курслары оештырыла. Кыз балалар өчен рус гимназияләре үрнәгендә өч махсус мәктәп ачыла: 1896 елда Каргалыда һәм 1897 елда Оренбургта Фатыйма Әдһәмова, 1908 елда Багбостан Мөэминова мәктәпләре. Хөсәеновлар җәдидчә укытуга керешкән башка мәдрәсәләргә дә, аеруча алганда Казандагы «Мөхәммәдия» һәм Уфадагы «Госмания» мәдрәсәләренә, акчалата иганә кылып торалар[34], башка төбәкләрдә дә үзләренең хәйриячелек эшчәнлеген җәелдерәләр. 1893 елда Сәмәркандта Гани бай Хөсәеновның матди ярдәме белән тәҗрибә җәдит мәктәбе оештырыла. Җирле халык бу мәктәпкә «Машина мәктәп» дип исем куша[35]. Хөсәеновларның Эрбер, Мәкәрҗә ярминкәләрендә, Коканд шәһәрендә һәм ислам дине үзәге




*«Хөсәения» мәдрәсәсе. XIX гасыр ахыры*

[33] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 158 б.

[34] Хәмидуллин Л. Иганәче Хөсәенов байларның варислары // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2009. – № 1. – 201 б.

[35] Надир Давлет. Исмаил Гаспринский / [пер. с тур. яз. Б. Ногманова]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – С. 21.

булган Мәккәдә дә мәчет һәм җәдит мәдрәсәләре ачулары турында мәгълүматлар бар[36].

Әлбәттә, кадими һәм җәдиди мәктәпләрне бер-берсенә каршы куеп карарга ярамый. Беренче чорда күп кенә мәктәпләрдә дөньяви фәннәр кертелмәсә дә, укытуның аваз ысулы кулланылган. Алга таба дөньяви фәннәр дә кертелгән. Җәдиди дип саналган уку йортларында дини фәннәр дә байтак урын алып торган: Коръән, Коръән тәфсире, хәдис, ислам тарихы, пәйгамбәр һәм сәхабәләр (пәйгамбәрләрнең иярченнәре) турында әсәрләр, гакаид (иман), фикъһ (шәригать нигезләре) укытылган. Мәсәлән, «Бубый» мәдрәсәсенең төп сигез сыйныфында 30 предмет укытылган. Шуларның 8е дини, 22се – дөньяви фәннәргә караган[37]. Шулай итеп, алар мөселман мәгариф системасының бөтенлеген тәшкил иткәннәр.



*«Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре. XX гасыр башы*

[36] Мортазина Л. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарларның Төркестанда һәм Казах далаларында мәгърифәтчелек эшчәнлеге // Историческая этнология. – 2017. – Т. 2, № 1.

[37] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 161 б.

Казанда яңа ысул белән укыту беренчеләрдән булып 1890 елдан «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең ир балалар һәм кызлар (Маһруй абыстай мәктәбе) мәктәпләрендә кулланыла башлый. Ул шулай ук 1888 елда Уфа шәһәренең беренче мәчете каршындагы мулла Х.Госманов ачкан «Госмания» мәдрәсәсенең башлангыч сыйныфларында, 1893 елдан Троицкидагы «Рәсүлия» мәдрәсәсе мәктәбендә дә кертелә.



*Мөхәммәдгали Мәхмүдов гаиләсе белән. 1870 ел*

XIX–XX гасырлар чигендә яңартылган татар мәктәпләре зур кыенлыклар белән үсеш ала. Бер яктан, аларга татар җәмгыяте эчендә туган капма-каршы юнәлеш тарафдарлары каршы торса, икенче яктан, Россия империясенең рус булмаган халыкларга карата уздырылган сәясәте зур йогынты ясый.

Миссионерлык эшен киңрәк җәелдереп җибәрү максатыннан Казан руханилар академиясендә (1800 елдан) һәм Казан руханилар семинариясендә (1818 елдан) татар теле укытыла башлый. Соңрак бу эшкә татар галимнәре дә җәлеп ителә. Мәсәлән, 1845 елда руханилар академиясендә каллиграфия дәресләре алып бару өчен Мөхәммәдгали Мәхмүдов чакырыла, 1855–1871 елларда руханилар семинариясендә К.Насыйри татар теле укыта.

Руслаштыру максатыннан чыгып, Россия территориясендә яшәүче христиан булмаган халыкларның телләрен, тарихын, этнографиясен, географиясен, мәдәниятен өйрәнүгә юнәлдерелгән сәясәт нәтиҗәсендә татар теле һәм тарихы фәнни яктан тирәнрәк өйрәнелә башлый. Бу эшкә күп кенә татар зыялылары да тартыла һәм үзләренең өлешләрен кертәләр. Мәсәлән, Г. Ваһапов Азия типографиясе ихтыяҗларын үтәп, борынгы шәрыкъ кулъязмаларын уку белән шөгыльләнә[38], татарлар арасында чыганаклар белеменә нигез салучы

[38] Вагапов Г.А. Татарские сказания. Взятие Булгара Тимуром // Казанские губернские ведомости. – 1852. – № 43. – С. 45.

була, төрле халыкларның тату яшәве өчен төп шарт дип ул аларның бер-берсенең телләрен өйрәнүне саный. Әлеге юнәлештә ярдәмлекләр төзи[39]. М. Мәхмүдов исә, татар теленең үсеш закончалыкларына, татар халык иҗаты үрнәкләренә, көнкүреш, гореф-гадәтләргә таянып, татар теленә өйрәткеч яза[40].

XIX йөз урталарында татар әдәбияты буенча беренче уку китаплары төзелә. Оренбургның Неплюев кадет корпусы укытучысы М. Иванов 1842 елда «Татарская грамматика» исемле уку китабы чыгара. Шул ук уку йорты укытучысы С. Күкләшев[41] татар халык иҗаты үрнәкләре (мәкальләр, әйтемнәр, бәетләр, җырлар, тапкыр сүзләр) һәм урта гасыр кульязма китапларыннан, тарихи хезмәтләрдән өзекләр туплаган татар әдәбияты хрестоматиясе һәм аңа сүзлек төзи.

Хөкүмәтнең халыкларны көчләп чукындыру һәм руслаштыру сәясәте көтелгән нәтиҗәләргә китерми. Ул, киресенчә, татар җәмгыятенең тупланып ныгуына, татар халкында милли аң уянуга, мөселман халыкларының дини берләшүенә этәргеч бирә. Көтелгән нәтиҗәләр күренмәгәч, руслаштыру сәясәтенә үзгәрешләр кертү таләп ителә. Мөселманлыкка кире кайту очракларының артуы, чукындырылган халыкларга татарларның йогынтылары көчәю дә руслаштыру сәясәтен үзгәртүне сорый. Ул хәзер, дәүләт теле буларак рус телен мөселманнар арасында җәелдерүне, аны мәктәп-мәдрәсәләрдә мәҗбүри укытуны кертүне күздә тота[42]. 1864 елның 14 июлендә кертелгән «Башлангыч халык училищелары турында нигезләмә», 60–70 еллардагы либераль реформалар, рус булмаган халыкларның рус телен өйрәнүгә кызыксынулары арту уйланылган чараларны тормышка ашырырга булышлык итә.

---

[39] Вагапов Г.А. Самоучитель для русских по-татарски и для татар по-русски. – Казань: Тип. Казан. Имп. Ун-та, 1846. – 61 с.; Вагапов Г.А. Грамматика русского языка, составленная для татар Восточной России. Ч.1. – Казань: Тип. Ун-та, 1873. – 114 с. һ.б.

[40] Махмудов М.М. Практическое руководство к изучению татарского языка, составленное старшим учителем Казанской гимназии Махмудовым. – Казань, 1857. – 255 с.

[41] Кукляшев С.Б. Диване хикәяте татар = Татарская хрестоматия, составленная Салих-Джаном Кукляшевым. – Казань: Тип. Казан. ун-та, 1859. – 124 с.; Кукляшев С.Б. Словарь к Татарской хрестоматии, составленный С.Кукляшевым. – Казань: Тип. Казан. ун-та, 1859. – 104 с.

[42] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 13 б.

Яңа борылышның беренче адымы булып, 1862 елда Н.И.Ильминскийның Мамадыш өязе Никифоровка авылы керәшене Василий Тимофеев беләнберлектә «Керәшеннәр өчен кыска православие догалары һәм дини хикәятләр белән әлифба» бастырып чыгаруы тора. Анда гарәп әлифбасы урынына беренче тапкыр кириллица кулланыла, мөселман динендә кулланылган терминнар рус сүзләре белән алыштырыла. Автор моны керәшеннәрне мөселманнардан аеру һәм аларны рус мәдәниятенә якынайту максаты белән эшли[43].

Алга китеп шуны әйтергә кирәк, Н.И.Ильминский алфавиты керәшен татарлары арасында Октябрь революциясеннән соң да байтак вакыт кулланыштан төшми. Шул алфавит белән керәшен мәктәпләрендә уку-укыту эшләре алып барыла, газета («Киңәш») һәм кайбер махсус китаплар чыгарыла. Яңалиф гамәлгә куелгач кына, ул үз көчен югалта[44].

Н.И.Ильминскийның яңа системасы балаларга башлангыч белемне туган телләрендә бирүне, мәктәпләрдә һәм чиркәүләрдә рус телен яхшы белгән җирле халык вәкилләренең хезмәт итүен, югары классларда рус телен өйрәтүне һәм аларның рухи тормышларын акрынлап православие нигезләренә күчерүне, гыйбадәтнамәләрне Россиядәге рус булмаган халыкларның туган теленә тәрҗемә итүне, дини китапларны шул телләрдә бастыруны күздә тота.

Миссионер әлеге система нигезендә 1863 елда Казан Үзәк керәшен-татар мәктәбе (ул Изге Гурий һәм Православие миссионерлык җәмгыятьләренең башлангыч мәктәпләре өчен укытучылар хәзерли) һәм 1872 елда Казан рус-әҗнәби укытучылары семинариясе (керәшен авыллары өчен земство һәм министрлык мәктәпләренә укытучылар хәзерли) оештыра.

Рус дәүләтенең милләтләрне руслаштыру сәясәте нигезендә 1870 елның 26 мартында «Россиядә яшәүче рус булмаган халыкларга белем бирү чараларына кагылышлы кагыйдәләре» кабул ителә. Әлеге «кагыйдәләр» нигезендә Ильминский системасы ята. Документ буенча шәһәр һәм авылларда казна хисабына башлангыч рус-татар мәктәпләре оештырыла. Аларда уку вакыты 4 ел була. Төп фәннәр булып рус теле һәм математика тора. Балалар рус сөйләм телен яхшы үзләштерсеннәр өчен белем бирү беренче чорда туган телдә алып барыла. Алга таба рус теленең грамматикасы өйрәнелә.

---

[43] Исхаков Р.Р. Миссионерство и мусульмане Волго-Камья (последняя треть XVIII – начало XX в.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – С. 71–72.

[44] Курбатов Х. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 100 б.

Математика да балаларның туган телләре нигезендә алып барыла. Мөселман дине нигезләре мәхәллә хисабына укытыла.

«Кагыйдә» буенча, мәктәп-мәдрәсәләр каршында татарларның үз хисапларына рус сыйныфлары булдыру күздә тотыла. Рус сыйныфларына йөрү һәм аның программасын үзләштерү мәктәпләрдәге һәр бала өчен, ә мәдрәсәләрдә 16 яше тулмаган шәкертләр өчен мәҗбүри итеп куела. Рус классларында укытучылар булып рус телен яхшы белгән татарлар яки җирле телне белгән рус милләте вәкилләре торырга тиеш була. Халык хисабына чакырылган рус теле укытучысы булмый торып, яңа мәктәп-мәдрәсә тыела. Шушы «кагыйдәләр» нигезендә татар мәктәп-мәдрәсәләренең ирекле яшәүләренә чик куела башлый.

Тәрбия барышында төп урынны хатын-кыз алып торганлыктан, рус-татар мәктәпләрендә кызлар өчен аерым сменалар, ә рус сыйныфлары гына булган урыннарда, дәүләт хисабына кызлар өчен мәктәпләр ачу тәкъдим ителә[45].

«Кагыйдәләрне» тормышка ашыру һәм мәктәпләрнең эшчәнлеген күзәтеп тору, алар турында мәгълүмат туплау, мәктәпләрне дәреслекләр һәм уку әсбаплары белән тәэмин итү өчен махсус инспектор вазифасы кертелә. Бу эшкә шәркыять галиме В.В.Радлов билгеләнә.

Беренче елларда рус-татар мәктәпләре татар халкы тарафыннан тискәре кабул ителә. Кайберләре укучылар аз булу сәбәпле берничә елдан ябылырга мәҗбүр булалар. Мәсәлән, 1873 елда Б.Әпсәләмова үтенече белән ачылган беренче рус-татар кызлар мәктәбе 1874 елның гыйнварында укучылары аз булу сәбәпле ябыла. Икенче рус-татар кызлар мәктәбе 1901 елда гына ачыла һәм ул 1917 елга кадәр эшләп килә[46].

Рус-татар мәктәпләре XX йөз башында гына арта башлый. 1874 елның 1 гыйнварына Казан уку-укыту округында рус-татар мәктәпләренең һәм мәктәп-мәдрәсә каршындагы рус сыйныфларының гомуми саны 29 булса, 1913–1915 елларда 155 кә җитә[47].

Шулай итеп, рус хөкүмәте 1870 елгы «Кагыйдәләр» нигезендә, бер яктан, руслаштыру сәясәтен алып барса, икенче яктан, мәктәп

[45] Саматова Ч. Имперская власть и татарская школа во второй половине XIX – начале XX века (по материалам Казанского учебного округа). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – С. 15–17.

[46] Шунда ук. – С. 120.

[47] Шунда ук. – С. 231.

сәясәтенең хокукый нигезләрен билгели, татар милли мәктәпләрен үз күзәтүе астына ала.

«Кагыйдәләр» нигезендә ачыла башлаган мәктәпләр һәм рус сыйныфлары өчен рус телен һәм җирле халык телен яхшы белгән кадрларга ихтыяҗ туа. Шул максат белән 1872 елның 27 мартында дөнья күргән «Уфа һәм Симферополь шәһәрләрендәге татар укытучылар мәктәпләре нигезләмәсе» нигезендә 1872 елда Уфада һәм Симферопольдә, 1876 елда Казанда татар укытучылар мәктәпләре ачыла. Казан татар укытучылар мәктәбе (КТУШ) Идел, Урал һәм Урта Азия төбәкләрендәге рус-татар мәктәпләре өчен укытучылар хәзерли. Мәктәпнең беренче инспекторы итеп М. Мәхмүдов билгеләнә.

Әлеге дүртъеллык урта белем бирү мәктәбендә кыска курслы геометрия һәм сызым белән арифметика, география, табигать белеме, педагогика һәм дидактика, матур язу һәм рәсем, дин гыйлеме укытыла. Төп игътибар рус телен укытуга бирелә. Дин гыйлеме дәресләрендә гарәп грамматикасы һәм гарәп язуы өйрәтелә. КТУШта татар галимнәреннән төрле елларда Ш. Мәрҗани, И. Терегулов, Ш. Таһиров, Ш. Әхмәров, Т. Яхин һ.б. эшли.




*Казан татар укытучылар мәктәбе (КТУШ). XX гасыр башы фотосы*

Мәктәпкә килгән укучыларның күпчелеге рус телен яхшы белмәгәнлектән, В.В.Радлов КТУШ укытучыларының барысы да татар телен белергә тиеш дигән таләп куя. Мәктәптә төп игътибар рус теле укытуга бирелгәнлектән, рус теле укытучысына таләпләр зуррак була. Аннан, телләрне чагыштырып өйрәтү өчен, татар һәм гарәп телләрен дә яхшы белү сорала. Уку дәресләрендә текстларны татар теленә тәрҗемә итү тәҗрибәсе дә кулланыла. Яңа килгән балаларга аңлаешлырак булсын өчен 1–2 сыйныфларда кулланылган дәреслекләрдә рус текстлары янына аларның татарча тәрҗемәләре дә бирелә.

КТУШ ачылуның беренче елларыннан ук татар җәмәгатьчелеге бу мәктәпне кабул итми. Ш. Мәрҗанине миссионерлыкта гаеплиләр, ә мәктәпне руслаштыру инструменты буларак күрәләр. Кадимчеләр

мәктәптә рус телендә дөньяви фәннәр укыту белән килешмәсәләр, җәдитчеләр мәктәп өстеннән дәүләт күзәтүе булуны, татар теле һәм әдәбияты, татар тарихы укытылмауны тәнкыйтьлиләр.

Шул ук вакытта мәктәпне оештыручыларның аңа баглаган өметләре дә акланмый. Мәктәп дин нигезләрен яхшы белгән, рус телендә камил сөйләшкән, дөньяви фәннәр белән тиешле дәрәҗәдә хәбәрдар булган шәкертләр әзерләүне күздә тотып ачыла. Ш. Мәрҗани аларда татар зыялыларын күрсә, В.В. Радлов, үзенең миссионерлык күзлегеннән чыгып, мәчет-мәдрәсәләргә барып эшләрлек дин белгечләрен күрә. Ләкин мәктәпкә бер-ике чыгарылыштан соң, тиешле дини белемнәре булмаган балалар да алына башлый. Киләчәктә аларның бары рус телен генә укыта алачаклары ачыклана. Шул ук вакытта татар җәмәгатьчелеге рус телендә белем бирүче уку йортын тәмамлап чыккан шәхесләрне мәчетләргә якынайтырга тырышмый.

Ләкин КТУШ үз вакыты өчен шактый югары дәрәҗәдәге уку йорты булган. Анда 1876–1917 еллар аралыгында 389 укытучы хәзерләнеп чыга[48]. Татар укытучылар мәктәбе укытучылары яңа төр татар мәктәпләренең укыту-методик базасын булдыру эшен дә әйдәп бара. В.В. Радлов гомуми белем бирү предметлары буенча 20 дәреслек, Ш. Әхмәров татар укытучылары мәктәпләре өчен рус теле дәреслеге, Ш.Таһиров аваз ысулы белән беренче татар әлифбасы, кириллицада язарга өйрәтү өчен таблицалар җыентыгы бастыралар[49]. КТУШта төрле елларда Г. Рафиков, Г. Камай, М. Корбангалиев, Г. Исхакый, С. Сүнчәләй, С. Максуди, Х. Ямашев, М. Мөштәри, И. Казаков кебек күренекле шәхесләр белем ала.

Руслаштыруның бер чарасы буларак ачылган укытучылар мәктәпләре халык арасында рус телен, дөньяви һәм педагогик белем таралуга зур булышлык итәләр, җәдиди мәктәпләрдә эшли алырлык укытучылар хәзерлиләр. Моны хөкүмәт даирәләре дә таный. Куйган максатларга җавап бирмәве сәбәпле, 1890 елның 1 июль карары нигезендә Уфа укытучылар мәктәбе ябыла.

---

[48] Казанская татарская учительская школа 1876–1917 гг.: Сборник документов и материалов / Отв. сост. Л.В. Горохова; сост. Н.С. Горицкая, Н.А. Шарангина; под общ. ред. Д.И. Ибрагимова; отв. ред. Д.Р. Шарафутдинов. – Казань: Гасыр, 2005. – С. 5.

[49] Татар халкы тарихы (XVIII гасыр – XIX гасыр башы): татар телендә урта гомуми белем бирү мәкт. 11 нче с-фы өчен уку әсбабы / И.К.Заһидуллин, Д.Ф.Заһидуллина, М.М.Гибатдинов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. – 249 б.

Хөкүмәтнең 60–70 елларында башланган, милли халыкларның иҗтимагый һәм мәдәни тормышын күзәтү астына алырга тырышулары алдагы елларда тагын да кискенләшә. Бу юнәлештә төрле карарлар кабул ителә. Шулай да халыкның ризасызлык белдерүе аркасында аларның кайберләре үзгәртелә. 1882 елның 5 февраль карары нигезендә барлык милли уку йортлары Мәгариф министрлыгы карамагына тапшырылырга тиеш була. Ләкин шул ук көнне Александр III мәктәп-мәдрәсәләрне элеккечә калдырып, алар турында бары тик статистик мәгълүмат җыюны гына йөкли. 1891 елдан мөселман дин әһеле булырга теләүчеләргә мәҗбүри русча белем цензы кертелә: алар, рус телендә укый һәм яза белүләрен раслап, имтихан тапшырырга тиеш булалар. 1892 елда мәдрәсәләрдә кулланылган чит илдә басылган дәреслекләрне җыеп алу һәм ислам илләрендә белем алган муллаларга укыту эшчәнлеге белән шөгыльләнүне тыю турында карар чыга. Ләкин ул халык арасында иҗтимагый киеренкелек тудыру сәбәпле, 1894 ел карары белән гамәлдән чыгарыла. Бу чаралар татарларның хөкүмәткә ышанычын киметә, кадимчеләр һәм җәдитчеләр арасындагы каршылыкларны тагын да көчәйтә.

Яңа төр мәктәпләрнең бердәм программалары булмаса да, гомумән, дини фәннәр белән беррәттән арифметика, алгебра, геометрия, география, тарих, табигать белеме, химия, физик культура, җыр, рәсем кебек предметлар укытыла, шулай ук педагогика, дидактика, физиология, психология, укыту ысулияте (методикасы) кебек махсус предметлар өйрәтелә. Яңа ысуллы мәдрәсә шәкертләре татар телен һәм әдәбиятын, рус телен, гарәп, фарсы телләрен өйрәнгәннәр. Барлык дини предметлар гарәп һәм фарсы телендә, ә гомуми белем предметлары туган телдә укытылган. Гарәп, фарсы, татар язуында гарәп графикасы, русча язуда кириллица кулланылган. Кайбер мәдрәсәләрдә үзенчәлекле фәннәр дә кертелгән. Мәсәлән, «Бубый» мәдрәсәсендә теләгән кешеләргә бухгалтерлык эше өйрәтелгән, немец һәм француз телләреннән дәресләр бирелгән.

Җәдиди мәктәпләрнең эчке тәртипләренә дә җитди үзгәрешләр ясала. Аларда атналык расписание һәм белем бирүнең тиешле күләмен күрсәткән укыту программалары кертелә. Һәрбер юнәлеш буенча фәннәрне аерым укытучы укыта башлый.

Укыту һәм белем сыйфатын тикшерүнең дә яңа формалары булдырыла. Уку елы ахырында (апрельдә) барлык укучылар өчен имтиханнар оештырыла. Укучыларның ата-аналарын, күренекле кешеләрне, иганәчеләрне чакырып уздырылган ачык имтиханнар бу чорда зур танылу ала. Әлеге имтиханнар ике максатны күз алдында

тотып уздырылганнар. Беренчесе, халыкка мәктәп-мәдрәсәнең белем бирү дәрәҗәсен күрсәтү булса, икенчесе, уку йортының матди хәлен яхшырту булган. Имтиханнардан соң укучыларның эшләреннән (иншаларыннан, кул эшләреннән) күргәзмәләр ясалган.

Моназаралар, зиһенне чарлау кебек, бәхәс формасындагы зиһен ярышлары уздырыла башлый. Алар шәкертләрдә фикерләүне формалаштыруга, сөйләү осталыгы, үз фикереңне яклый белү, үзеңнең хаклы булуыңны дәлилли һәм исбатлый белү күнекмәләрен үстерүгә булышлык иткән. Шәкертләр тезләнеп утырырлык тәбәнәк парталар һәм кара такталар кулланыла башлый. Яңа ысуллы мәктәп-мәдрәсәләрдә күрсәтмә материаллар киң кулланылышка керә: плакатлар, карталар (шул ук вакытта тарихи карталар да), атласлар, химия һәм физика дәресләрендә төрле тәҗрибәләр куела.

Җыеп әйткәндә, яңа ысуллы мәдрәсәләрнең нигезен өч төп яңалык тәшкил итә: беренчедән, хәреф-аваз ысулы белән укытуны кертү; икенчедән, дөньяга фәнни караш тәрбияләүче дөньяви фәннәр укытыла башлау, туган телне һәм рус телен укыту; өченчедән, мәктәп җиһазларын файдаланып, сыйныф-дәрес системасы булдыру[50].



*Р.Фәхретдин*

Җәдитчелек хәрәкәтенең бер юнәлеше булып хатын-кыз мәгарифе мәсьәләсе тора. Татар халкын торгынлыктан чыгаруны үз бурычы итеп куйган җәдитчеләр тәрәкъкыйпәрвәр – «яңа кеше» тәрбияләүне хатын-кызның җәмгыятьтә һәм гаиләдәге хәлен үзгәртү белән бәйләп карыйлар. Беренчеләрдән булып бу проблеманы Ризаэддин Фәхретдин күтәреп чыга. Ул яхшы тәрбияле, киң белемле кызлар гына чын милләт аналары булып җитешәчәк һәм киләчәктә милләтне алга алып барырлык шәхесләр тәрбияләячәк дигән фикерне дәллиләп чыга[51].

XIX–XX гасыр чикләрендә мәгърифәтчелек идеяләре йогынтысы белән хатын-кызлар арасында да яңарыш дулкыны сизелә башлый. Нәкъ шушы елларда хатын-кыз авторларының әсәрләре нәшер

---

[50] Ялалов Ф. Татар халкы элитар мәгарифенең этнодидактик принциплары // Фәнни Татарстан. – 2005. – №3/4. – 3–8 б.

[51] Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / Төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. – Казан: Җыен, 2012. – 4 б.

итеlә башлый. Алар арасында Галимәтелбанат Биктимерия, Хәнифә Гыйсмәтуллина, Галимә Рәхмәтуллина, Хәбирә Насыйрия һ.б. бар. Алар үзләренең әсәрләрендә беренче чиратта хатын-кызлар арасында гыйлем-мәгърифәт тарату, гаилә мөнәсәбәтләрен һәм балалар тәрбиясен яхшырту, кыз балаларны укыту зарурлыгы кебек актуаль проблемаларны күтәреп чыгалар[52].



*Казандагы җәдит мәктәбендә укучы кызлар. XX гасыр башы фотосы*

Кызлар өчен җәдиди мәктәпләр 1905–1907 елгы революциядән соң күпләп ачыла башлый. Боларга Казандагы Ләбибә Хөсәения, Маһруй Мозаффария, Сәгадәт Әмирхания, Оренбургтагы Фатыйма Әдһәмова, Багъбостан Мөэминова, Чистайдагы Ф.Гайнетдинова мәктәпләрен кертергә була. Уфа мөселман ханымнар җәмгыяте тарафыннан Уфада кызлар мәктәпләре челтәре барлыкка килә. Авылларда урнашкан җәдиди мәктәпләр исемлегенә Вятка губернасындагы Иж-Бубый (1857 елда ук Бәдрелбанат Иманкулова нигез салган), Самара губернасы Бөгелмә өязендә Кәрәкәшле (Фатыйма-

[52] Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре / Төз., кереш сүз һәм искәрмәләр авторы М. Гайнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 3 б.

Фәридә мәктәбе), Минзәлә өязендә Сарман, Казан губернасы Чуел өязендә Акъегет (З.Шәфигуллин мәктәбе), Тәтеш өязендәге Кече Тархан, Сембер губернасында Комаер (укытучысы Хәдичә Сәнгатьзадә-Шаммасова), Себердәге Манчыл, Торбы мәктәпләрен күрсәтергә кирәк[53]. Әлеге уку йортларының программаларына, гомуми белем бирү фәннәре белән беррәттән, тормыш өчен кирәк булган кул эшләре һәм йорт эшләре буенча да дәресләр кертелә.

Яңа система белемне дүрт баскычка бүлеп бирүне күздә тота: ибтидаия (башлангыч), рөшдия (урта), игъдадия (уртадан югарырак) һәм галия (югары). Игъдадия бүлегендә уртачадан югарырак белем бирелә, һәм шәкертләрне ул иң югары бүлеккә керү өчен әзерли, шул ук вакытта аларга хәлфә, мөгаллим (укытучы) һәм казый сыйфатында профессиональ педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукы бирелә.

Ләкин һәрбер уку йорты үзенең укыту планнарына карап, үзенчә бүленеш керткән. Мәсәлән, 1913/14 ел укыту планы буенча «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә өч бүлек булган: башлангыч (ибтидаия) – хәзерлек сыйныфы һәм биш ел уку, урта (санавия) – уку вакыты алты ел, һәм югары (галия) – уку вакыты өч ел. Ә «Хөсәения» мәдрәсәсендә дүрт баскычлы система кулланылган: өч сыйныфлы башлангыч белем, дүрт сыйныфлы урта белем, дүрт сыйныфлы игъдадия һәм өч сыйныфлы югары белем. Игъдадияне тәмамлаган шәкертләр урта мәктәп укытучысы дигән шәһадәтнамә алып чыкканнар[54].

Җәдиди уку йортларының рәсми кабул ителгән, барлык төр уку йортлары өчен дә мәҗбүри булган укыту программалары һәм планнары булмый. Белем бирү үрнәк рәвешендә аерым шәхесләр яки иҗтимагый чараларда коллективлар тарафыннан тәкъдим ителгән, һәр уку йорты үзе өчен дөрес дип тапкан программалар нигезендә алып барылган.

1898 елда И.Гаспралының «Рәһбәре мөгаллимин яки мөгаллимләргә юлдаш» исемле китабы чыга. Әлеге китап яңа ысулны халык арасында тарату өчен язылган була. Анда сыйныфларда дәресләр бүленеше, уку, язу, грамматика, фәннәрне укытуның кыскача планы, дәресләр расписаниесе үрнәге бирелгән. Галимнәр әлеге китапны җәдиди мәктәпләр өчен беренче укыту программасы буларак кабул

---

[53] Биктимирова Т.А. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. – Казан: Печатный двор, 2002. – 33 б.

[54] Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. – Оренбург: Яңа Вакыт, 1997. – С. 16.

итәргә мөмкин дип саныйлар. Бу чорда җәдиди уку йортлары татар җәмгыятендә күп булмаганлыктан һәм китап төрек теленә якын тел белән язылганлыктан, әлеге кулланма татар халкы арасында киң кулланылышка керми[55].

1899 елда эчтәлеге ягыннан И.Гаспралы китабына якын булган «Ысулы тәдрис» исемле китап дөнья күрә. Китапта дәресләр бүленеше, ислам нигезләрен укучыларга җиткерү алымнары, уку йортының эчке кагыйдәләре аңлатыла. Татарлар арасында таралыш алган әлеге әсбапта татар мәктәпләре өчен яңалык булган «һәр сыйныфка һәм һәр фәнгә аерым укытучы билгеләргә» дигән кагыйдә алга куела. Әлеге китап ислам принципларын саклап калып, җәдидчә укытуга нигезләнгән[56].

Беренче рус революциясеннән соң җәдитчә уку-укыту эшенә яңалыклар кертү, программалар төзү эше киң тарала. Бу вакытта күп төрле программалар дөнья күрә. Алар төрле комиссияләрдә, җыелышларда, съездларда кабул ителә яки мәктәп-мәдрәсә укытучылары тарафыннан эшләнелә.

Казанда 1906 елның 10–13 августында узган укытучылар җыелышы үрнәк буларак ибтидаи сыйныфлар өчен уку программасы һәм планы, дәресләр расписаниесе, укытылырга тиешле һәрбер фән буенча кулай дип табылган дәреслек исемлеге, шулай ук укытучыларның һәм укучыларның мәктәптә үз-үзләрен тоту кагыйдәләре булдыра.

Рөшдия, ягъни 5–8 сыйныфлар өчен беренче уку программасы 1907 елда Казанда узган икенче укытучылар җыелышында эшләнә. Рөшди уку планнарына татар теле, табигать белеме, педагогика, рус теле кебек яңа фәннәр өстәлә. Шулай ук сыйныфлар өчен кулай булган дәреслекләр исемлеге, укытучылар өчен ярдәмлек әсбаплар һәм мәктәп китапханәләрендә булырга тиешле китаплар исемлеге бирелә[57]. Әлеге ике җыелышта кабул ителгән материаллар «Мөгаллимнәрә нәмүнә»[58] исемле китапларда чагылыш таба.

Алдагы елларда узган җыелышларда (Омск, 1908; Богырыслан, 1912) әлеге программалар камилләштерелә, дөньяви фәннәрнең дини

---

[55] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 37 б.

[56] Шунда ук. – 38 б.

[57] Шунда ук. – 39–41 б.

[58] Мөгаллимнәрә нәмүнә. – Казан: Ун-т матбагасы, 1906. – 20 б.; Мөгаллимнәрә нәмүнә. – Казан: Ермолаев матбугасы, 1907. – 32 б.

фәннәр белән тыгыз бәйләнештә булганлыгы ассызыклана. Һәрбер җыелыш саен фәннәрне укытырга кулай булган дәреслекләр исемлеге бирелә. 1912 елда Уфа шәһәрендәге Садретдин Нәзири мәдрәсәсе укытучылары тарафыннан алдагы программалар калыбында «Мөгаллимәләрә нәмүнә» исемле программа әзерләнә. Әлеге программа, алдагыларыннан аермалы буларак, шәһәр уку йортлары өчен генә түгел, ә авыл мәктәпләрен дә истә тотып төзелә. 1913 елда «Мәктәп» журналында «Дүрт сыйныфлы ибтидаи мәктәп программасы» басылып чыга. Программада Мәгариф министрлыгының 1889 елгы фәрманын истә тотып, ир балалар өчен гимнастика, ә кыз балалар өчен кул һөнәре өйрәтелергә тиеш диелә. 1914 елда «Мөгаллимләргә үрнәк яки гомуми программа» исеме астында Ф.Сәйфи тарафыннан төзелгән программа басылып чыга. Автор сүзләренчә, программа русча укытыла торган мәктәпләргә яраклаштырыбрак төзелгән. Ләкин ул киң җәмәгатьчелек тарафыннан яклау тапмый һәм аның эшләнеп бетмәгән яклары күп булу сәбәпле, кискен тәнкыйть ителә.

1916 елда Троицкида һәм 1917 елда Казанда алты еллык ибтидаи мәктәпләр өчен яңадан ике программа эшләнә. Троицкида төзелгән программа алдагыларыннан рәсем дәресләренең тулы программасын бирүе, һәр фәнне укытканда искә алынырга тиешле үзенчәлекләрне билгеләве, бала тәрбияләүнең юлларын күрсәтүе белән аерылып тора.



*Троицкидагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе укытучылары. XX гасыр башы*

Казанда чыккан «Русиядәге мөселман төрек-татар халкы өчен алты еллык ибтидаи мәктәп программасы ләихасы» Троицк программасы нигезендә эшләнә. Программада бөтен фәннәр дә ана телендә укытылырга, рус теле генә русча укытылырга тиеш, диелә. Бу программа алдагы программалардан рус теле буенча уку планының рус телендә бирелүе белән аерылып тора. Бу татар программалары өчен яңалык булып тора[59].

Күренгәнчә, татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен программалар күп төрле булган. Алар алдагыларыннан карап камилләштерелгәннәр. Ләкин барлык уку йортлары өчен дә туры килгән, бердәм программалар кабул ителмәгән. Программаларда шулай ук дәреслек исемлеге дә бирелеп килгән. Монда, әлбәттә, һәрбер автор үзе тиешле санаган дәреслекләрне керткән. Яңа программалар барлыкка килү белән кулланылырга тиешле дәреслекләрнең исемнәре дә үзгәргән.

Мәктәптә татар халкы тарихын өйрәнү күптәнге традицияләргә ия. Махсус уку программалары нигезендә милли тарих (төрки-татар тарихы) системалы уку фәне буларак татар дини уку йортларында (җәдиди мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә) XX гасыр башында укытыла башлый.

Кадими мәдрәсәләрдә, махсус тарих фәннәре булуына карамастан, шәкертләр программадан тыш татар һәм гарәп авторларының тарихи әсәрләре белән дә таныша алганнар. Риваять, миф формасындагы әлеге әсәрләрнең күпчелегендә төгәлсезлекләр һәм хаталар күп була. Әмма алар рәсми идеологиянең милли тарихны инкарь иткән һәм берьяклы аңлатуга корылган дәверендә, татар халкы тарихы турындагы белемнәрне саклауга һәм таратуга, яшьләрне милли тарих белән кызыксындыруга ярдәм иткәннәр.

Дәүләт тарафыннан ачылган уку йортларында татар халкы тарихын (шул исәптән Казан ханлыгы тарихын) өйрәнү мөмкинлеге булмаган, булган очракта да, ул берьяклы яисә бик гади генә бирелгән.

1906 елның 31 мартында Россия мәгариф министрлыгы тарафыннан кабул ителгән «Инородецлар өчен башлангыч училищелар кагыйдәләре» нигезендә төрле милләтләргә рус телен таратуны һәм «Ватанга мәхәббәт аша рус халкы белән якынайтуны» максат иткән махсус башлангыч училищелар булдыру карала[60]. Аларда рус теле һәм арифметикадан тыш, программага тарих, география һәм башка

---

[59] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 41–50 б.

[60] Правила о начальных училищах для инородцев. – Казань, 1907. – С. 1.

фәннәрне кертү мөмкинлеге була. Әмма әлеге мәктәп программаларының, империянең гомуми уку йортлары программаларына яраклаштырылган булуы сәбәпле, бары гомуми Россия тарихы һәм географиясе генә укытыла.

1914 елда «көнчыгыш инородецлар»ның мәгариф мәсьәләләренә багышланган җыелышта мөселманнарның, аеруча татарларның, «онытылмас һичшиксез бай сәяси үткәне, тарихы булуы» ассызыклана[61]. Һәм бу халыкны яхшырак аңлар өчен, аларга карата нәтиҗәле сәясәт алып барыр өчен аларның тарихын, мәдәниятен һәм гореф-гадәтләрен белү кирәклеге белдерелә. Шунлыктан чик буе өлкәләрендәге уку йортларында рус тарихын, география һәм этнографияне укыткан вакытта анда яшәүче «көнчыгыш кабиләләре һәм халыклары» белән таныштыру тәкъдим ителә. Моның өчен Рус тарихы китапларына кыскача өстәмәләр кертү дә карала. Бу, үз чиратында, рус мәктәбенең җирле халык белән мөнәсәбәтен ныгытырга тиеш була.

Шәрык телләрен практик өйрәнү өчен мәктәпләрнең татар төркемнәрендә уку планнарына (аларның берсе Казан укытучылар семинариясе каршында оештырыла) тел дәресләрендә укучыларда «рус гражданлыгы» хисләрен көчәйтү максатыннан параллель рәвештә Идел буе, Көнбатыш Себер тарихы, этнографиясе буенча мәгълүматлар бирү каралган була. Рус-татар мәктәпләрендә кертелгән Россия тарихы курсына, төп материалга өстәмә рәвештә «күрсәтмәлеккә корылган әңгәмә һәм өлешчә аңлатмалы уку өчен» татар халкы тарихыннан кыскача мәгълүматлар бирелү карала.

Шулай итеп, XX гасыр башында татар халкы тарихы буенча системалы белемнәр бирелә торган бердәнбер урын булып татар мәдрәсәләре (күбесенчә җәдиди) тора.

Татар җәдиди мәдрәсәләрендә тарих укыту пәйгамбәрләр тарихы, ислам тарихы, гомуми тарих, Россия тарихы һәм татар халкы тарихы яисә төрки-татар тарихын укытуга нигезләнә. Боларның һәрбер курсында татар халкы тарихы элементлары карала, әмма тулы рәвештә ул «Татар тарихы», яисә «Тарих кауми төрки», «Төрек-татар тарихы» курсында чагылыш таба.

1917 елның 3 августында мөселман укытучыларының Бөтенроссия съездында барлык башлангыч (ибтидаи) 6 еллык мәктәпләр өчен бердәм программа кабул ителә. Аның нигезендә 6 нчы сыйныфта төрки-татар тарихын тулы итеп өйрәнү өчен тарих курсы

---

[61] Труды Особого совещания по вопросу образования восточных инородцев. – СПб., 1915. – С. 88.

кертелә[62]. Бу программа нигезендә укучылар төрки-татар дәүләтчелегенең оешуы һәм үсеше, рухи һәм матди мәдәнияте, гореф-гадәтләре, күрше милләтләр (аеруча рус халкы) белән аралашулары турында төп мәгълүматны алырга тиеш булалар.

Җәдиди мәдрәсәләрнең башлангыч (ибтидаи) бүлегенең 5 нче сыйныфында тарих укытуга атнага ике сәгать бирелә. Бер сәгать вакыт татар халкы тарихының аерым вакыйгаларын күзаллау өчен карала (Болгарлар, аларның мәдәнияте һәм дошманнары; Татарлар, Чыңгыз, Җүчи, Батый ханнар; Алтын Урда; Казан ханлыгы һәм аның данлыклы хөкемдарлары). Икенче сәгать борынгы чордан алып Александр II дәверенә кадәр Россия тарихын тирәнтен өйрәнүгә юнәлдерелә. Әлеге программада «Рус тарихында татар дәвере»; «Татарлар һәм аларның тормышы»; «Русия кенәзләренең татар ханнарына мөнәсәбәте» кебек темалар да карала.

Төрки-татар тарихы урта бүлекнең 1–3 нче сыйныфларында тулырак өйрәнелә (атнага 1 сәгать). Россия тарихына 5, 6 нчы сыйныфларда 1 сәгать, гомуми тарихка 4, 5, 6 нчы сыйныфларда ике сәгать вакыт бирелә. 3 нче сыйныф программасы аеруча тулы була. Монда Казан падишаһлыгы (Казан ханлыгы оешуыннан алып, аның 1552 елда яулап алынуы чорына кадәр сәяси тарихы) зур урын алып тора.

Бу программалар татар милли үзаңының формалашу процессын күзалларга мөмкинлек бирә. Бу чорда әле гомумтөрки тарих татар тарихыннан чын мәгънәсендә аерылмый. Ләкин татар халкының килеп чыгышы процессына аеруча тәэсир иткән дәүләтләргә игътибар ителә.

Бу чорда татар халкы тарихы буенча иң популяр булган дәреслекләрдән Г.Әхмәровның «Болгар тарихы» (1909) һәм «Казан тарихы» (1910), М.Рәмзинең 1908 елда чыккан «Казан һәм Болгар тарихы, татар идарәчеләре турында җыйналма мәгълүмат» хезмәте, Ә.-З.Вәлидинең 1912 елда басылган «Төрек вә татар тарихы», Г.Зәбиринең «Мәкятибе ибтидаия өчен кыскача тарихе Болгар» (1907), Г.Батталның «Татар тарихы» (1913) санала. К.Фуксның «Казан тарихы», Турнереллиның «Болгар тарихы» кебек китаплары да дәреслек буларак кулланыла[63].

---

[62] Программа для мусульманских начальных училищ с 6-ти годичным сроком обучения. – Казань, 1917. – С. 22.

[63] Гибатдинов М. Преподавание истории татарского народа и Татарстана в общеобразовательной школе: история и современность. – Казань: Алма-Лит, 2003. – С. 18.

Җирле тарих буенча Һ. Атласи, Г. Җиһанша, Г. Мөхәммәтгариф[64] хезмәтләре, Россия тарихы буенча К.Насыйри, Н.Надиев[65] дәреслекләре кулланылган.

Җәдиди мәктәпләрдә дөньяви фәннәрдән география дәресләренә зур урын бирелә һәм дәреслек сыйфатында бик күп авторларның китаплары кулланыла. 1913 елда гына да 41 мең тираж белән 7 китап дөнья күрә[66].

География буенча дәреслекләр төзү эшендә иң зур хезмәт куючыларның берсе Х.Фәйзи. Аның рус, төрек, француз авторлары хезмәтләренә нигезләнеп 1905 елда нәшер иткән «Ысуле җәгърафия» хезмәте зур уңыш казана. Ф.Кәриминең, заманында рус укымышлыларының да югары бәясен алган М.Корбангалиевның[67] дәреслекләре дә киң кулланылышта була.

География буенча татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен М.Идриси, М.Әшрәф, М.Җәлил, Ә.Хәлил тарафыннан төзелгән карталар һәм атласлар билгеле. Әмма татар тарихы буенча төзелгән аерым карталар булмый. Тарих дәресе укытканда рус һәм чит ил карталары кулланылышта була. Мәсәлән, тарих дәресләрендә Шпронер атласындагы 87 номерлы картаны кулланулары билгеле[68].

Җәдитчелек хәрәкәтенең төп яңалыкларыннан берсе булып үз ана телендә укыту һәм татар телен укыту мәсьәләләре тора. XX гасыр башында башлангыч мәктәптә татар телендә укырга-язарга өйрәтү, җәдиди мәктәпләр өчен дөньяви әлифбалар төзү, татар әдәби теленең фонетик-орфографик нормалары, алфавит алыштыру турында бәхәсләр бара (1899 елда Уфада узган киңәш мәҗлесе).

Татар телендә бер-бер артлы татар теле һәм әдәбияты буенча мәктәп дәреслекләре чыга башлый[69]. Г.Сәгъдинең «Үз телебезчә

---

[64] Алтаси Һ. Себер тарихы. 1 җөзьэ. – Казан, 1911. – 177 б. һ.б.

[65] Насыйри К. Зөбәдәт мин тәварихи әр-Руси. – Казан: Ун-т тип., 1890. – 27 б. һ.б.

[66] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 203 б.

[67] Кәрими Ф. Мохтәсар җәгърафия. – Казан: Ун-т тип., 1899. – 48 б.; Корбангалиев М. Дөнья. Ибтидаи гавәм мәктәпләре өчен тәртип иделмеш җәгърафия рисаләсе. Беренче кисәк. – Казан: Мәгариф, 1912. – 91 б. һ.б.

[68] Гибатдинов М. Преподавание истории татарского народа и Татарстана в общеобразовательной школе: история и современность. – Казань: Алма-Лит, 2003. – С. 22.

[69] Ибраһимов Г. Татар нәхүе. – Казан: Хәсәни, 1911. – 74 б.; Ибраһимов Г. Татар имлясы: Мәктәпләр өчен дәреслек. – Казан: Хәсәни, 1914. – 28 б.; Максуди Һ. Төрки сарфы: Ибтидаи мәктәпләр өчен. – Казан: Харитонов

мөкәммәл сарыф-нәхү» (1915) дәреслеге, галимнәр фикеренчә, үз вакытында укытучыны телнең бөтен мөмкинлекләрен күзаллап, грамматик конструкцияләрдән файдаланырга, әдәбият белән бергә үреп бирергә өйрәтә. Тыныш билгеләрен билгеле бер тәртипкә китереп, укучыларда пунктуацион грамоталылык тәрбияли[70].

Җәдиди уку йортларында, мөстәкыйль фән буларак, уку дәресләре барлыкка килә. Алар «кыйраәте төрки» дип йөртелә.

Кыйраәт китаплары тәрбияви һәм дөньяви белемнәрне камилләштерү максатыннан чыгып төзеләләр. Аларда әдәби әсәрләрдән башка әхлак кагыйдәләре, нәсыйхәтләр, киңәш-үгетләр бирелә.

Ибтидаи сыйныфларда Х. Зәбиринең «Әхлак дәресләре», Ш.Хәмидинең «Тәһзибе әхлак сыйбиян» һәм башка авторларның китаплары кулланыла.

Урта сыйныфларда Г. Сәгъдинең «Әдәбият мөгаллиме: Рөшди мәктәпләр өчен дәрес китабы», Я. Адутовның «Сөлләмель кыйраәт: Рөшди мәктәпләрнең соңгы сыйныфларында укытыр өчен» һ.б. дәреслекләрдән укытыла. Әлеге дәреслекләр урта сыйныф укучысын сәнгатьле уку, укыганның эчтәлегенә төшенеп сөйләү, матур җөмлә төзи белү күнекмәләренә генә өйрәтеп калмыйча, әдәбиятның теоретик ягы белән да таныштыра башлыйлар[71].

Математика (арифметика, алгебра, геометрия) буенча берничә дистә исемдәге хезмәт кулланылышта йөри. Арифметика дәресләрендә М. Идрисовның «Хисабе зиһни», «Хисап гамәле», Г.Хәбировның «Хисаб» һ.б. дәреслекләре, геометрия буенча Г. Гыйсмәтинең «Гамәли вә нәзари ысулы һәндәсә», М. Рафикыйның «Нәзари вә гамәли һәндәсә» һ.б. китаплар кулланыла.

Башка дөньяви фәннәрдән: табигать белеме буенча Х. Корбангалиевнең «Хикмәте табигыя», астрономиядән Д. Абызгильдинның «Гыйлем әл-галаик тарихчасы», Р. Ибраһимовның «Дәүри галәм», ботаникадан Г. Фәхретдиновның «Рәсемле гыйльме нәбатат», И. Хәмидинең «Гыйльме нәбатат», зоология буенча И. Хәмидинең «Гыйльме хәйванат», «Рәсемле гыйльме хәйванат», химия буенча Г. Шнаси-

---

матб., 1910. – 48 б.; Сәгъди Г. Мохәсар кавагыйде әдәбия. Рөшди дүртенче, игъдади беренче сыйныф мәктәпләре өчен. – Уфа: Хөсәенов, 1911. – 98 б. һ.б.

[70] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 35–43 б.

[71] Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 92–98 б.

ның «Мохтасар кимия», физикадан Г. Гыйсмәтинең «Гыйльме әшья яки тарихе табигый», Х. Зәбиринең «Әшья дәреслеге» һ.б. бик күп исемдәге дәреслекләре кулланылышта йөри[72].

1905–1907 елгы революцион хәрәкәт татар җәмгыятендә зур гына үзгәрешләргә этәргеч бирә. Татар мәктәп-мәдрәсәләренә караган күп төрле мәсьәләләрне (программалар, шәһәр һәм авыл мәктәп-мәдрәсәләрендә эшнең куелышы, уку йортларының матди ягы, идарә итү тәртипләре һ.б.) үз эченә алган съездлар, җыелышлар, киңәш мәҗлесләре үткәрелә. Уку-укыту тәртибенә үзгәрешләр кертүне, мәдрәсәләрдә китапханәләр, уку бүлмәләре булдыруны, төрле уку түгәрәкләре оештыруны таләп иткән шәкертләр оешмалары («Берек») оеша. Россия империясенең төрле төбәкләрендә мәгарифнең төрле мәсьәләләрен дә яктырткан татар вакытлы матбугаты барлыкка килә[73].

Россия мөселманнары арасында иң зур мәдрәсәләр булып Казандагы «Мөхәммәдия» һәм «Касыймия», Иж-Бубыйдагы «Бубый», Оренбургтагы «Хөсәения», Уфадагы «Галия» һәм «Госмания», Троицкидагы «Рәсүлия» санала.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә XX йөз башында рус теле, арифметика, матур язу, рәсем, хисап-счет, география, физика, метрика, логика, педагогика, психология, гарәп, фарсы телләре, гарәп әдәбияты һ.б. фәннәрдән дәрес бирелгән. Татар теле «Төрки тел» исеме астында укытылган, ә ана телендә уку «кыйраәте төрки», ягъни төркичә уку дип йөртелгән.

Мәдрәсәдә рус теленә зур әһәмият бирелгән. Мәсәлән, башлангыч һәм урта сыйныфларда шәкертләр 11 ел буенча (1913 елдан мәдрәсә 14 еллыкка әверелә) рус телен көн саен өйрәнәләр, ягъни ул атнасына 6 мәртәбә керә.

Мәдрәсәнең төп классларына өстәмә рәвештә 5 нче мәхәллә мәчете бинасында ярлы вә ятим балалар өчен фөкара (фәкыйрьләр) мәктәбе дә эшли. Анда ятим яисә укытырга матди мөмкинлеге булмаган кешеләрнең балалары укый. Аларга уку әсбаплары, карандаш-дәфтәр һ.б. бирелә, шулай ук кием-салым белән тәэмин итү дә карала. Мондый балаларны уку белән кызыксындыру, урамда хәер-сә-

---

[72] Кара: Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 184–212 б.

[73] Кара: Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 401–402 б.

дака сораудан биздерү өчен дәрескә килгәндә аларга өчәр тиен «стипендия» дә түләнә.

Фәкыйрьләр мәктәбеннән тыш мәдрәсәдә 1915–16 елларда Польша татарлары өчен дә бер сыйныф ачыла. Ләкин телләр аермасы зур булу сәбәпле, ул озак яши алмый.

Мәдрәсәдә әдәбият һәм драма түгәрәкләре эшли, кулъязма газеталар чыгарыла, 1905-1906 елларда ул шәкертләр хәрәкәте үзәге булып тора.

Күренгәнчә, мәдрәсәгә нигез салучы һәм аның җитәкчесе Г.Баруди әлеге уку йортын дини җирлектән аерылмаган килеш, дөньяви юнәлештә, ягъни Европа казанышларына таянып үсүенә булышлык итә, татар халкына аң-белем таратуда, милли үзаң формалашуда үзенең зур өлешен кертә. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе Октябрь революциясенә кадәрге татар университеты дип санала[74]. Анда Ф.Әмирхан, М.Гафури, К.Тинчурин, Г.Камал, Х.Бәдигый кебек татар халкының күренекле шәхесләре белем алган.



*Г.Баруди*

Бу чор милли мәгариф системасында шулай ук күренекле урынны «Хөсәения» мәдрәсәсе алып торган. XX йөз башында биредә 8 дини, 20 дөньяви фән укытылган. Әлеге мәдрәсә матди яктан иң яхшы тәэмин ителгән уку йортларының берсе санала. Бары тик мәдрәсәнең бинасын төзү өчен генә Әхмәд бай 97 мең сум акча тота[75].

Химия һәм физика бүлмәләрен җиһазлау, төрле күрсәтмә материаллар алу өчен ел саен зур суммалар сарыф ителә. Мәсәлән, 1914 елда гына әлеге максат өчен 1691 сум акча тотыла. Мәдрәсәнең попечительләр советы әгъзалары З.Рәмиев белән Ш.Рәмиевлар бүләк итеп физика бүлмәсе өчен Германиядән җиһазлар кайтарталар. Мәдрәсәдә шулай ук барлык кирәк-ярак белән тәэмин ителгән хезмәт бүлмәсе дә була.

---

[74] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 212–226 б.

[75] Шунда ук. – 159–162 б.

Мәдрәсәдә ике бай китапханә эшли. Анда матур әдәбият әсәрләре, педагогика, медицина, авыл хуҗалыгы, тарих һ.б. өлкәләр буенча фәнни әдәбият, энциклопедияләр, сүзлекләр, белешмәләр, татар, рус, казах телләрендә газета һәм журналлар алдырыла.

Мәдрәсәдә күптөрле түгәрәкләр (әдәби, тарихи, музыкаль, драма һ.б.), «Шәрык музее» эшләп килә[76].

Җәдиди мәктәп-мәдрәсәләрнең дәрәҗәләре татар җәмгыятендә генә түгел, бөтен Россия мөселманнары арасында да югары була. Кайбер мәдрәсәләр («Бубый», «Мөхәммәдия», «Галия», «Хөсәения» һ.б.) Россия күләмендә төрки халыклар өчен педагогик кадрлар хәзерләү үзәкләренә әвереләләр. Бер «Галия» мәдрәсәсе генә үзенең эшләү дәверендә (1906–1916) 950 имам, мөгаллим, язучы, журналист һ.б. укытып чыгара. Аларның 224е Урта Азия, Казахстан, Кырым, Кавказ якларыннан килгән шәкертләр була.



*Уфадагы «Галия» мәдрәсәсе*

Татар белем бирү системасының югары баскычка күтәрелүе хөкүмәт эшлеклеләрен нык борчый. XX гасыр башында ук инде Н.И.Ильминский «Рус белеме алмаган, рус телен белми торган фанатик безнең өчен русча белем алган татарга караганда яхшырак, тагын да яманы аристократ, аннан да яманы университет белеме алган кешедер»[77], дип белдерә.

Җәдиди мәктәпләрнең киң таралуы дөньяви белем бирә алырлык укытучы кадрларга мохтаҗлык тудыра. Моңа кадәр укытып килгән күп кенә мулла һәм абыстайлар яңа төр мәктәпләр куйган таләпләрне канәгатьләндерә алмыйлар. Бу татар дөньясы алдына мөселман уку йортлары өчен педагогик кадрлар хәзерләү мәсьәләсен куя. Укытучылар хәзер «мөгаллим» яки «мөгаллимә» дип атап йөртелә башлыйлар.

[76] Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. – Оренбург: Яңа Вакыт, 1997. – С. 25–27.

[77] Письма Н.И.Ильминского к обер-прокурору Святейшего Синода К.П.Победоносцеву. – Казань, 1898. – С. 178.



*Петропавловск шәһәре хатын-кызлар мәдрәсәсе мөгаллимәләре һәм укучылары. XX гасыр башы*



*«Сафаҗәй» мәдрәсәсендә дәрес вакыты. Мөгаллим – Габделбари Хәбибуллин. XX гасыр башы*



*Буадагы «Нурия» мәдрәсәсе шәкертләре*




*М.Бәхтияровның математика дәреслегенең бер бите (1898)*



*Красноуфимск шәһәре мәдрәсәсе шәкертләре имам Габделгазиз-хәзрәт Бикишев белән. 1910 ел*



*«Сафаҗәй» мәдрәсәсе шәкертләре мөгаллимнәре белән. Түбән Новгород өлкәсе, 1907 ел*

XIX йөз ахыры – XX йөз башында яңа җәдиди мәктәпләргә укытучылар хәзерләү өчен махсус курслар оештырыла башлый. 1897 елда Г.Хөсәенов һәм Ф.Кәрими җитәкчелегендә Оренбургта, ә 1899 елда Сәгыйть бистәсендә педагогик курслар ачыла. Мөмкинлекләре булган мөгаллимнәр гасыр ахырында «Зынҗырлы» мәдрәсәсе каршында И. Гаспралы тарафыннан ачылган курсларга килә. 1907 елның маенда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе каршында курслар ачыла. 1908–1911 елларда «Бубый» мәдрәсәсендә өч айлык (май-август) мөгаллимнәр хәзерләү курслары оештырыла. Бирегә илнең төрле төбәкләреннән белем эстәргә киләләр. Бу курсларда өч ел эчендә барлыгы 274 мөгаллим, шул исәптән 106 хатын-кыз мөгаллимлек дәрәҗәсе ала[78]. Хатын-кызлар өчен 1912 елда Уфада «мөгаллимәләр курсы» исеме белән дүрт урында курс ачыла[79] һ.б.

Җәдиди мәктәп-мәдрәсәләрне тәмамлаган кызларның күпчелеге укытучы булып эшләп китә. Рус кызлар гимназияләрен тәмамлаган татар кызлары мәктәпләргә килә. Ләкин аларның саны бик аз була. Мәсәлән, 1906 елның 1 гыйнварына Казан уку-укыту округының барлык кызлар гимназияләрендә нибары 20 мөслимә, ә 1910 елның 1 гыйнварына 37 мөслимә генә белем алган[80]. Шулай итеп, әлеге чаралар гына булган ихтыяҗны канәгатьләндереп бетерә алмый. Махсус уку йорты – дарелмөгаллимәт, ягъни хатын-кыз мөгаллимәләр хәзерләп чыгаручы уку йорты ачарга кирәклеге көн алдына килеп баса.



*Ф.Аитова*

Казанда татар хатын-кызлар гимназиясе ачу мәсьәләсе Ф.Аитова тарафыннан күтәрелә, Троицк шәһәрендә исә танылган сәүдәгәр һәм иганәче Яушевлар дарелмөгаллимәт булдыру турында кайгырта башлыйлар.

Аерым кешеләр уку йорты ачу мәсьәләләрен 1914 елның 1 июлендә расланган «Халык мәгариф министрлыгының шәхси уку йортлары, класслары һәм курслары турындагы кагыйдәләр»гә[81] нигезләнеп эш итәргә тиеш булалар. Әлеге кагыйдәләр уку йортлары ачучыларга берникадәр мөстәкыйльлек бирсәләр

[78] Гимазова Р. Просветительская деятельность Нигматуллиных-Буби (конец XIX – начало XX вв.) – Казань: Печатный двор, 2004. – С. 33.

[79] Ягъкупова М. Мөгалиммәләр курсы // Тормыш. – 1914. – 2 май.

[80] Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / Төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. – Казан: Җыен, 2012. – 364 б.

[81] Циркуляр по Казанскому учебному округу. – 1914. – август. – С. 497–508.

дә, әйтик, уку йортын тотучыга нинди уку йорты (башлангыч, урта һәм югары, гомуми белем яки профессиональ белем, яисә, катнаш мәктәп) ачу, аларда укуны үзе теләгән телдә алып бару, нинди предметларны укыту, программаларын төзү һ.б (уку йортының төрен сайлау хокукы һ.б.) һичшиксез үтәлергә тиешле таләпләр дә була. Мәсәлән, кагыйдәләрнең 6 нчы маддәсе буенча белем йорты ачучылар нинди фәннәр укытуны үзләре хәл итә алса, башлангыч һәм урта дәрәҗә уку йортларында җитәрлек күләмдә рус теле дәресләрен рус телендә укыту, югары дәрәҗә уку йортларында дин белеме һәм туган тел дәресләреннән кала, белемне дәүләт телендә (ягъни – рус телендә) алып бару мәҗбүри була. Милли башлангыч һәм урта төр уку йортларында фәннәрне шул җирлектәге халыкның туган телендә укыту фәкать шул телдә сөйләшә торган балалар өчен генә мәҗбүри, ә рус теле һәм әдәбияты, тарих һәм география фәннәре рус телендә укытылырга тиеш була.

Әлеге законга таянып, 1915 елда Россия мөселманнары дөньясында беренче дарелмөгаллимат оештырыла. Уку йортының рәсми җитәкчесе Гайния Яушева, ә мөдирәсе итеп Мөхлисә Бубый тәгаенләнә[82].



*М.Бубый*

Мәктәп рәсми рәвештә биш һәм бер еллык хәзерлек сыйныфларыннан тора. Анда унике яшьтән кечерәк булган шәкертләр кабул ителә. Хәзерлек сыйныфында голүм диния, татар теле, рус теле, хисап, табигыять, кул эшләре, рәсем һәм матур язу дәресләре кергән. Рәсми сыйныфларда голүм диния, татар теле, гарәп теле, рус теле, хисап, җәбер, һәндәсә, җәгърафия, табигыять, хифзы сыйххәт, хикмәт вә кимия, гомуми тарих, татар тарихы, рус тарихы, тәгълим вә тәрбия, кул эшләре, рәсем вә хәсән хат, идарәи биния фәннәре укытылган[83].

Ф.Аитова да күп каршылыклар кичергәннән соң, югарыда искә алынган закон нигезендә, 1916 елның 29 октябрендә рәсми рәвештә беренче татар кызлар гимназиясе ачуга ирешә.

Ф.Аитованың укытучылар хәзерли торган гимназиясендә уку вакыты 8 ел була. Анда шәригать нигезләре, татар һәм гарәп, рус

---

[82] Биктимирова Т.Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. – Казан: Печатный двор, 2002. – 44 б.

[83] Зиннәтуллина А. Русия татарлары дөньясында дарелмөгаллимат ачу мәсьәләсе // Фән һәм мәктәп. – 2010. – № 4. – 7–10 б.

телләре, гомуми тарих һәм Россия тарихы, гомуми һәм Россия географиясе, математика (арифметика, алгебра һәм геометрия), физика, табигать белеме, анатомия, кеше физиологиясе, гигиена, педагогика, русча һәм татарча матур язу, рәсем һәм кул эшләре укытыла. Рус теле дәресләреннән тыш, рус телендә Россия тарихы һәм Россия географиясе дәресләре алып барыла. Барлык калган фәннәр татарча укытыла. Предметлар буенча программа дәүләти хатын-кызлар гимназиясе күләмендә төзелгән була[84].



*Аитова мәктәбе укучылары*

Дөньяви фәннәрне өйрәнеп, яңа ысуллы мәдрәсәләрне тәмамлаган яшьләрнең шактый зур өлеше Россия уку йортларында һәм чит илләрдә белем алуын дәвам итәләр. Мәсәлән, Казан университетының төрле факультетларында төрле елларда Ә.Терегулов, Г.Гобәйдуллин, Н.Хәлфин һ.б. белем алган. Татар яшьләре шулай ук Петербург, Томск, Мәскәү университетларында укый. Татар хатын-кызлары да югары белем алуга ирешә. 1914 елда Петербург университетының медицина факультетын С.Колахметова-Агеева тәмамлый. Югары медицина белеменә шулай ук М.Әхмәрова-Дәүләткилдиева, Х.Ямашева, Г.Батталова һ.б. ия булалар.

XX гасыр башында татарларның чит ил югары уку йортларында укуы киң колач ала. Татарлардан йөзләгән кеше Париж, Женева, Токио шәһәрләре, шулай ук, Төркия, Мисыр, Сүрия һ.б. илләр университетларында һәм көллиятләрендә белем ала. Мәсәлән, 1909 елда Стамбулның төрле уку йортларында 63 татар кешесе, шул исәптән университетта – 14, укытучылар семинариясендә – 12, урта уку йортларында – 20, солтан училищеларында – 4, шәһәр училищеларында 10 кеше белем алган. Хатын-кызлар арасында чит ил югары уку йортларында белем алган шәхесләр бар, ләкин аларның саны күп түгел. Бүгенге көнгә мондый адымга барган өч кызның исеме мәгълүм. Казанлы Зәйнәп Габдрахманова һәм уфалы Суфия Сыртлановалар Женева университетында укыганнар, Касыйм шәһәрендә туган Сара

[84] Махмутова А. Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса. 1861–1917). – Казань: Изд-во Каз. ун-та, 1982. – С. 90.

Шакулова Франциянең Сорбонна университетында югары белем алган[85].



С.Шакулова

Йомгак ясап шуны әйтергә кирәк, мәгърифәтчелек идеяләреннән башланган җәдитчелек хәрәкәте Октябрьгәчә дәвердә үзенең иң югары ноктасына җитә. Татар традицион белем бирү системасы, Европа һәм Россия педагогикасы тәҗрибәсен кертә барып, тамырдан үзгәрә. Татар җәмгыятендә барлыкка килгән консерватив агымның каршылыгына һәм дәүләт даирәләренең көчле басымына карамастан, җәдиди уку йортлары зур үсеш ала. 1910 елда Казан губернасындагы барлык мәктәп-мәдрәсәләрнең 90%ы укытуның аваз ысулына күчә[86]. Алар үзләренең уку-укыту программалары буенча классик гимназияләр дәрәҗәсенә якынлаша. Әлеге белем бирү йортларыннан заманының алдынгы карашлы шәхесләре чыга һәм алар алга таба татар халкының, милли мәгарифнең урынын билгеләүдә үзләренең зур өлешләрен кертәләр.



*Истанбулда белем алучы татар шәкертләре. 1910 ел*

[85] Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / Төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. – Казан: Җыен, 2012. – 531 б.

[86] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 164 б.

# V. СОВЕТ ЧОРЫНДА ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ

Совет чоры – татар мәгарифе һәм мәдәнияте өчен тамырдан үзгәреш кичергән чор. Татар мәгарифенең тулысынча гомумсовет дәүләт мәгариф системасы эченә кертелүе, дәүләти булмаган мәктәпләрнең бетерелүе һәм мәктәпнең диннән аерылуы сәбәпле, Октябрь революциясеннән соң татар халкының гасырлардан бирле яшәп килгән милли мәгариф системасы юк ителә.

РСФСР Халык Комиссарлары Советының (ХКС) «Чиркәүнең дәүләттән һәм мәктәпнең чиркәүдән аерылуы» (1918 ел, 21 гыйнвар) турындагы декреты, бигрәк тә Советларның X Бөтенроссия съезды (1927 ел, декабрь) карарлары нәтиҗәсендә шәхси милек һәм дини белем бирүне оештыруның һәртөрле формалары юк ителә. Нәтиҗәдә татар мәгарифенең нигезен тәшкил иткән дини белем бирү системасы җимерелә, дини уку йортлары ябыла яки дөньяви белем мәктәпләре итеп үзгәртелә. Дини китаплар һәм кульъязмалар күпләп юк ителә. Бу чорда атеистик тәрбиягә аеруча зур әһәмият бирелә. Россия мәгарифендәге Ян Коменский нигез салган класс-дәрес системасы татар мәгарифендә ныклап урнаша.

Дәүләтнең татар мәгарифенә карата булган вәзгыятеннән чыгып, совет дәверендәге татар педагогик фикере үсешен төп өч чорга бүлеп карарга мөмкин.

Беренче чор – 20–30 нчы еллар. Бу еллар Татарстанның республика буларак оешкан, татар мәгарифен һәм татар телен үстерүгә иң күп игътибар бирелгән, аның дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелгән, мәктәп системасы күптөрле яңалыклар һәм экспериментлар кичергән вакыт. Ләкин 30 нчы елларда илдә башланган сәяси вәзгыять нәтиҗәсендә татар мәгарифендәге омтылышлар акрынлап кысыла, илдәге мәгариф системасын стандартлаштыру процессы ныгый башлый. Сәяси репрессияләр нәтиҗәсендә күренекле шәхесләр юк ителә. Шулай итеп, милли үзенчәлекләргә нигезләнеп ныгый башлаган татар мәгарифе акрынлап бетерелә.

Яңартылган мәгариф системасын төзү Советларның II Бөтенроссия съезды (1917 ел) карары нигезендә Мәгариф Халык комисса-

риаты оештыру белән башланып китә. Тиздән мондый комиссариатлар урыннарда да барлыкка килә. 1918 елның февралендә Казан губерна Мәгариф халык комиссариаты (МХК) оештырыла. Әлеге орган соңрак Губерна халык мәгарифе бүлеге, 1920 елдан ТАССР Мәгариф халык комиссариаты, 1946 елдан ТАССР Мәгариф министрлыгы, 1988 елдан ТАССР Халык мәгарифе министрлыгы, 1995 елдан ТР Мәгариф министрлыгы, 2004 елдан ТР Фән һәм мәгариф министрлыгы итеп үзгәртелә. Беренче мәгариф комиссары итеп А.А.Максимов билгеләнә.

Яңа мәгариф системасының төп нигезен тәшкил иткән максатларның берсе булып һәркем кереп укый алырлык бердәм дөньяви мәктәп төзү тора. Әлеге мәктәпләрдә белем хезмәт күнекмәләре аша алып барылырга тиеш дип санала. Яңа совет мәктәбе турында беренче документ (МХКның «Мәктәп төзелешенең нигезләре» карары) 1918 елның июлендә дөнья күрә. Аның нигезендә мәктәп бердәм һәм эш, хезмәт нигезендә белем бирүгә юнәледереп төзелергә тиеш була. 1918 елның 16 октябрендә «Бердәм эш мәктәпләре турында»гы (БЭМ) декрет кабул ителә. Аның нигезендә моңа кадәр булган барлык төр мәктәпләр I һәм II баскыч мәктәпләре итеп үзгәртелә. Укытуны хезмәт белән бәйләп алып баруга юнәлдерелгән, укучыларны фән нигезләре белән таныштырган политехник мәктәп төзү башлана.

Халык мәгарифе системасының төп принциплары 1919 елның мартында кабул ителгән Коммунистлар партиясенең икенче программасында билгеләнә. Алар түбәндәгеләрдән гыйбарәт: 17 яшькә кадәр булган барлык балаларга да (җенесеннән бәйсез рәвештә) түләүсез һәм мәҗбүри гомуми политехник белем бирү; мәктәпкәчә оешмалар челтәрен булдыру; бердәм эш мәктәпләре принципларын туган телдә укыту юлы белән тулысынча тормышка ашыру; ир һәм кыз балаларны бергә укыту; 17 яшьтән узган яшьләр өчен һөнәри белем бирүне киң җәелдерү; эшче халык балаларына югары уку йортларына юлны ачу; коммунистик идеяләр белән сугарылган яңа педагогик кадрлар хәзерләү һ.б.

Мәктәпкәчә тәрбия эше мәгариф системасы карамагына кертелү сәбәпле, актив рәвештә төрле төрдәге мәктәпкәчә тәрбия йортлары оештыру бурычы куела (яслеләр, балалар бакчалары, мәйданчыклар, колонияләр, балалар учагы һ.б.). Балалар оешмаларын төзү, анда эшне оештыру, тәрбия һәм белем бирүдә татар халкының гореф-гадәтләрен, тормыш-көнкүрешен күз алдында тоткан программалар һәм кулланмалар төзелә (К.Вәлитов, М.Ялымова, С.Миңлекәй, З.Салихова, Г.Айдаров һ.б.).

1920 елларда баланың мөстәкыйльлеген арттыру максаты белән белем бирүдә комплекс системасы нигезендә эзләнү, лаборатор, экскурсия, звено методлары киң кулланылыш ала. Укыту экскурсияләр, диспутлар, гамәли конференцияләр формасында алып барыла. Мөстәкыйль эшне дөрес оештыру өчен баланың шәхси үзенчәлекләрен, аның яшәеш шартларын ачыклау сорала. Әлеге сорауларга яңа барлыкка килгән педология фәне җавап бирергә тиеш була. Ләкин 30 нчы елларда ул ялган фән дип табыла һәм кулланыштан алына.

Егерменче еллар башында яңа мәгарифне урнаштыруда төрле кыенлыклар килеп чыгу сәбәпле, мәктәпләр дәүләт тарафыннан тәэмин итүдән алынып, җирле финанслауга күчереләләр. Җирле үзидарәләрнең үз финанслары мәгарифнең барлык өлкәләрен дә тәэмин итәргә җитми. Шунлыктан уку өчен түләү кертелә, ләкин күп кенә категория кешеләренә ташламалар бирелә, ә кайберләреннән бөтенләй түләү алынмый.

Татар телен гамәлгә кую мәсьәләсе совет хөкүмәте урнашкач ук күтәрелә һәм тиз арада иң мөһим милли һәм иҗтимагый әһәмияткә ия эшләрнең берсенә әверелә. Халыкның тулаем укый-яза белүен тәэмин итү, татар әдәби теленең нормаларын булдыру, татар язуын, язу кагыйдәләрен билгеле бер калыпка салу, камилләштерү, мәгариф челтәренең һәрбер буынында (башлангыч мәктәптән алып югары уку йортларына кадәр) татарча укытуны кертү, татар теленең кулланылыш даирәсен киңәйтү, аны рәсми оешмалар теленә әверелдерү, милли кадрлар әзерләү һ.б. – бу елларда татар телен гамәлгә кертү проблемасын хәл итүнең аерым баскычлары әнә шулардан гыйбарәт була.

Казанда 1918 елның маенда Бөтенроссия мөселман укытучылары съезды, 1919 елның гыйнварында тел мәсьәләләренә багышланган Бөтенроссия конференциясе уздырыла. Аларда тел, әдәбият, тарих буенча мәктәпләр өчен татарча программа һәм дәреслекләр төзү, татар әдәби теле нормаларын юлга салу мәсьәләләре карала. Татарстан эшче, крестьян һәм Кызыл гаскәр вәкилләре советларының Мәркәз башкарма комитеты һәм ТАССР ХКСның 1921 елның 25 июнендә кабул ителгән «Татарстан җөмһүриятендә татар телен гамәлгә кую турындагы» беренче декреты нигезендә татар телен барлык хөкүмәт учреждениеләренә мәҗбүри рәвештә кертү, тиз арада татар теленә өйрәтү курслары ачу карала. I һәм II баскыч мәктәпләрдә татар теле, татар мәктәпләрендә рус теле укыту эше җайга салына. Татар теле, рус теле белән беррәттән, Татарстан республикасының дәүләт теле дип игълан ителә. Шулай итеп, аны

барлык мәктәпләрдә, урта һөнәри-техник һәм югары уку йортларында рәсми рәвештә укыта башлау мәҗбүрияте туа.

Дөньяви мәктәпләр оешу белән татар мәктәпләре өчен педагогик кадрлар хәзерләү юнәлеше иң әһәмияле мәсьәләләрнең берсенә әверелә. Әлеге бушлыкны тиз арада тулыландыру өчен махсус кыска вакытлы курслар, конференцияләр үткәрелә башлый. 1918–1919 еллардан Татарстанның күп кенә район һәм шәһәрләрендә, РСФСРның татарлар күпләп яшәгән төбәкләрендә татар педагогик семинарияләре, педагогия курслары, педагогия техникумнары, икееллык курслар, педагогик училищелар, татар педагогия техникумнары ачыла.

1918 елда, университет булган шәһәрләрдә дүрт еллык уку срогы белән педагогия институтлары ачу турында карар кабул ителгәннән соң, Казан укытучылар институты Казан педагогия институты дип үзгәртелә (Халык мәгарифенең югары институты, Көнчыгыш педагогия институты, Татар педагогия институты).

РСФСР МХКы советының 1919 елның 26 декабрендә дөнья күргән «РСФСР халыклары арасында укый-яза белмәүчелекне бетерү турындагы» декреты XX гасыр мәгариф тарихындагы иң зур һәм колачлы кампаниягә нигез сала. Ул 8 яшьтән алып 55 яшькәчә булганнарны укырга-язарга өйрәтүне күздә тота. 1920 елның 21 гыйнварында Казан губерна башкарма комитеты президиумы «Казанда һәм губернада укый-яза белмәүчелекене бетерү проекты»н кабул итә. Шушы ук елның 25–29 мартында узган мәктәптән тыш белем бирү буенча III губерна съездында кампанияне үткәрү буенча конкрет план билгеләнә. Озакламый Казан губернасы буенча ликпунктларның саны 5717 гә җитә[1].

Зурлар өчен татар телендә язылган уңышлы дәреслекләр һәм татарча эшләүче ликвидаторларның (ликбез мәктәпләрендә укытучылар) аз булуы да эшкә комачаулык ясый. Шул ук проблема Россиянең татарлар яшәгән башка төбәкләрендә дә күзәтелә. 1921 елгы ачлык нәтиҗәсендә укыту эшләре сүлпәнәя, ликпунктлар саны кими, губернада 1922 елга аларның саны 215 кенә кала[2]. Балалар мәктәпләренең аз булуы да кампаниянең үтәлешенә комачаучылык итә. 1922 елда 15 татар ликпункты ачыла. 1923/24 уку елыннан укый-яза белмәүчелекне бетерү кампаниясе планлы, эзлекле рәвеш-

---

[1] Галиев Р. Беренче күчмә мәктәпләр // Совет мәктәбе. – 1972. – № 10. – 58 б.

[2] Хакимова Р.Ш. Борьба татарской партийной организации за ликвидацию неграмотности среди населения // Борьба КПСС за развитие народного образования и культуры. – Казань, 1972. – С. 13.

тә, 1920 елгы халык санын алу нәтиҗәләренә нигезләнеп төзелгән бердәм план нигезендә тормышка ашырыла башлый.

Укыту алымнарын сайлауга килгәндә, беренче чорда, беркадәр өстәмә материаллар кертеп, балалар мәктәпләре тәҗрибәсенә таяныла. Әмма иске метод һәм алымнардан азат булган яңа методикага нигезләнеп укыту тарафдарларының карашлары дөрес дип табыла һәм нәтиҗәдә укытуның комплекслы методы, бөтен сүзләр, әңгәмә ысуллары, уку эчтәлеген тормыш һәм һөнәри эшчәнлек белән бәйләп алып бару, теорияне практика белән бәйләп алып бару, белем бирүдә эзләнү-тикшеренү элементларын куллану, иллюстрация һәм күрсәтмәлелеккә игътибарны юнәлтү кебек метод һәм алымнарга өстенлек бирелә. Психологик аспектны («һәрбер яңа нәрсә балаларны үзенә тарта, ә олылар үзләренә күпмедер таныш булган нәрсәләр белән генә кызыксыналар»[3]) истә тотып эшләнгән методика отышлы дип табыла. Шулай итеп, уку-укыту барышын оештыруның яңа, моңарчы күрелмәгән формалары кертелә («Дальтон-план, бригада-лаборатор системасы, проектлар методы һ.б.»).

1921 елда татар халкының тарихын, мәдәниятен, мәгариф өлкәсендәге казанышларын барлау, яңа дәреслекләр, программалар, уку планнары төзү, төрле курслар ачу, орфография һәм имля, балалар әдәбияты, педагогик журналлар чыгару һ.б. әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итү максатында, Гыйльми һәйәт (соңрак Гыйльми үзәк, Академик үзәк) төзелә (Г.Максудов, Г.Ибраһимов, М.Х.Таһиров, С.Атнагулов). 1918 елның 7 ноябрендә «Мәгариф» журналы чыга башлый.

1923/24 уку елына кадәр мәктәпләрдә стабиль программалар булмый. Әлеге уку елыннан, белем бирү системасын стандартлаштыру максатыннан, укыту ГУС программалары нигезендә алып барыла башлый. 1927 елда Татарстан шартларына яраклаштырылган программалар кулланышка керә.

1923 елның 20 августында РСФСР ХКС тарафыннан 10 ел эчендә гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирүгә күчеп бетү бурычын куйган декрет кабул ителә. Бу проблеманы яктырткан тагын берничә карар дөнья күрә. 1925 елның август карары буенча, 1933/34 уку елына гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирүгә күчеп бетү карала. ВКП(б) ҮКның 1930 ел 25 июль «Гомуми мәҗбүри башлангыч белем турында»гы карары нигезендә 1934 елга 8, 9 һәм 10 яшьлек балалар I баскыч; 11 яшьтән алып 15 яшькә кадәр I бас-

[3] Дистанов Г. Укый-яза белмәүчеләрне һәм аз белемлеләрне укытучылар өчен кулланма. – Казан: Татиздат, 1926. – 17 б.

кыч белемнәре булмаган балалар яшүсмерләр мәктәбе; шәһәр, поселок һәм эшчеләр районнарындагы балалар өчен җидееллык мәктәп күләмендә мәҗбүри белем бирелергә тиеш була. Укучыларның мөстәкыйль эшләү күнекмәләрен арттыру, мөстәкыйль белем алу осталыгын үстерү күздә тотыла, укучының оешкан коллективта эшләү осталыгын булдыруга басым ясала.

Атеистик тәрбиягә аеруча зур әһәмият бирелә. Дини китаплар һәм кульязмалар күпләп юк ителә, мөселман йолаларын һәм бәйрәмнәрен үткәрү катгый тыела.

1920 ел азакларында Татарстанда дингә каршы радиоуниверситет эшли башлый. Авыл җирләрендә дингә каршы пропаганда избачитальняларда уздырыла. Гади халыкка аңлаешлы булсын өчен, атеизм турындагы брошюраларны, кечкенә китапларны төрле телләргә тәрҗемә итәләр.

Татар халкын милләт булып оештыруда зур роль уйнаган ислам диненә каршы 1925–1937 елларда Мәскәүдә «Сугышчан алласыз» журналы, Казанда 1929–1933 елларда «Сугышчан алласызлар» газетасы һәм «Сугышчан алласызлар» журналы чыгып килә. 20 ләп татар галиме һәм язучысына (Г.Ибраһимов, Г.Гобәйдуллин, Ф.Сәйфи-Уфалы, К.Нәҗми, Ш.Шәрәф һ.б.) «Диннең килеп чыгышы», «Ни өчен без дингә каршы», «Совет Россиясе политикасында дин мәсьәләләре», «Тарих һәм дин» кебек темаларга әдәби әсәрләр, мәкаләләр, брошюралар язу бурычы йөкләнә.

30 нчы еллар уртасында илдә бердәйләштерү процессы башлану сәбәпле, ВКП(б) ҮКның «Башлагыч һәм урта мәктәп өчен дәреслекләр турында» 1933 ел карары дөнья күрә. Карар белем бирү һәм тәрбия оешмаларында һәр предмет буенча бердәм мәҗбүри дәреслекләр кертүне раслый. Нәтиҗәдә совет чорының соңгы елларына кадәр барлык халыклар өчен дә күбесенчә рус теленнән тәрҗемә ителгән, бердәм калып нигезендә төзелгән дәреслекләр, программалар һәм методик кулланмалар файдаланыла башлый. Әлеге карар мәктәпкәчә тәрбия оешмалары өчен чыккан әсбапларда да чагылыш таба.

Егерменче еллар ахырында илдә көчәйгән идеологик басым нәтиҗәсендә мәгариф өлкәсендә дә дәүләт күзәтүе арта, 30 нчы еллар уртасында укыту процессы тулысынча бердәм нигезгә салына, укытучыларның мөстәкыйль эш алымнары куллану мөмкинлекләре юкка чыга. 1933–1934 елдан укытучылардан беренче тапкыр дәреснең җентекле планы таләп ителә башлый. 12 пункттан торган дәрескә әзерләнү кагыйдәләре чыгарыла. Дәрес алып бару буенча күр-

сәтмәләр бирелә. Сәяси яктан дөрес дип табылган «традицион дәрес» формасы кулланыла башлый. Укучының танып-белү, мөстәкыйль эшчәнлеген үстерүгә юл ябыла, 30–40 елларда укыту системасында эзләнү методы бөтенләй юкка чыгарыла. Бу хәл 50 нче еллар ахырына кадәр, новаторлык дулкыны башланганчы дәвам итә.

Утызынчы елларда СССРда I һәм II баскыч мәктәпләре кушыла, укыту программалары революциягә кадәр булган гимназия программаларына туры китереп үзгәртелә, укытучыларга персональ дәрәҗәләр (башлангыч мәктәп укытучысы, урта мәктәп укытучысы, атказанган укытучы) булдырыла. 1928 елдан башлап мәгариф өлкәсендә аеруча зур уңышларга ирешкән педагогларга «Хезмәт Батыры» дигән мактаулы исем бирелә башлый. Беренчеләрдән булып, әлеге исемгә Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Г. Рафиковлар лаек була[4].

1934 елның 15 май карары белән СССР территориясендә бердәм мәктәп төрләре билгеләнә: башлангыч (1–4 сыйныфларны үз эченә ала), тулы булмаган урта (1–7 сыйныфлар), урта (1–10 сыйныфлар). Группалар «класслар» дип атап йөртелә башлый. Кайбер мәктәпләрдә эшләп килгән «нулевая группалар» (7 яшьлек балалар өчен) «хәзерлек класслары» дип йөртелә башлыйлар[5].

Татар язуының ике тапкыр алыштырылуы татар мәгарифе үсешендә дә чагылыш таба. 1920 елның 4 декабрендә ХКС Президиумы тарафыннан татар шрифтын гадиләштерү карары чыгарыла. 1927 елда гарәп имлясыннан латин алфавитына (яңалифкә) күчү процессы башлана. 1939 елның 5 маенда ТАССР Югары Советы Президиумы указы нигезендә татар язуы кириллицага күчерелә. Әлеге вакыйгалар нәтиҗәсендә гарәп язулы матур әдәбият, кулъязмалар, дәреслекләр кулланыштан алына.

Коммунистлар партиясенең интернацияльләштерү, барлык халыкларның да мәдәниятен берләштерү сәясәтен тормышка ашыру максатыннан, рус телен һәм әдәбиятын укытуга игътибар арта. 1938 ел карары[6] белән милли мәктәпләрнең икенче сыйныфыннан рус телен укыту мәҗбүри итеп куела.

---

[4] Муртазина Л.Р. Династия Рафиковых. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – С.29.

[5] Постановление СНК СССР и ЦК ВКП(б) от 15 мая 1934 г. «О структуре начальной и средней школы в СССР».

[6] Постановление СНК СССР, ЦК ВКП(б) от 13.03.1938 N 324 «Об обязательном изучении русского языка в школах национальных республик и областей».

Икенче чор – 40–50 нче еллар. Бу чорда татар мәгариф системасы тулысында гомумдәүләт системасы эченә кертелә, идеологик басым көчәя. Шуның нәтиҗәсендә һәрбер башлангыч ныклап тикшерелә. Татар халкы тарихын «дөрес чагылдыру» мәсьәләләре күтәрелә, сәяси күзлектән чыгып барлау эше башлана, патриотик бердәм совет кешесе тәрбияләү төп бурыч итеп куела. Белем бирүне рус телендә алып баруга күчерү мәгариф өлкәсендә төп бурыч итеп куела. Нәтиҗәдә татар мәктәпләренең саны кими.

Сугыш елларында төп бурыч булып патриотизм хисе тәрбияләү тора. Гомуми укыту планнары һәм программаларына шактый үзгәрешләр кертелә (мәктәп һәм мәктәптән тыш эшләр оборона максатларыннан чыгып оештырыла башлый).

Идеологик басымның көчәюе татар мәгарифенең торышында чагылыш таба. ВКП(б) ҮК 1944 елның 9 августында «Татарстан партия оешмасында массакүләм-сәяси, идеологик эшнең торышы һәм аны яктырту чаралары турында»гы карар кабул итә. Әлеге карарны гамәлгә ашыру максатыннан, Татарстан ӨКның 1944 елның 6 октябрендәге «Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты эшендәге хаталар һәм җитешсезлекләр турында»гы, 1946 елның 21 мартындагы «ТАССР тарихы буенча очерклар» төзү эшнең торышы турында»гы, «Урта мәктәпнең 8 нче сыйныфы өчен татар әдәбиятыннан дәреслек турында»гы һ.б. карарлар дөнья күрә. Бу карарларның төп мәгънәсе – татар халкының куәтле дәүләтләре белән бәйле булган тарихны сызып атарга, фән һәм иҗат интеллигенциясен рәсми догмалар кысаларына кертергә тырышуда чагыла.

Сугыш елларында хәрби-физик тәрбиягә игътибар көчәя. 1941 елның 24 октябрендә мәктәпләрдә булачак сугышчыларны хәзерләү программасын гамәлгә кертү турындагы махсус карар кабул ителә[7].

Сугыш елларында мәктәпләр тормышында җитди үзгәрешләр була. Мәктәпнең өлкән классларында белем алуга түләү (1940); балаларны 7 яшьтән башлап укыту (1943) кертелә; эшче яшьләр (1943) һәм авыл яшьләре кичке (1944) мәктәпләре оештырыла; укучыларның өлгерешен күтәрү максаты белән белемнәрне бәяләүнең 5 баллы системасы булдырыла (1944), «Укучылар өчен кагыйдәләр», башлангыч һәм җидееллык мәктәпләрне тәмамлаучыларга чыгарылыш имтиханнары булдырыла (1944); урта мәктәпне тәмамлаучыларга өлгергәнлек аттестатына имтихан тапшыру, өлгерештә югары нәтиҗәләр күрсәткән укучыларны «алтын» һәм «көмеш»

[7] Учительская газета. – 1942. – 29 октябрь.

медальләр белән бүләкләү гамәлгә кертелә (1944), 1943/44 уку елыннан балаларны җенесләре буенча бүлеп укыту тәҗрибәсе тормышка ашырыла башлый. Ләкин 50 нче еллар уртасында бергә укыту кире кайтарыла.

Бөек Ватан сугышы елларында, ир-егет укытучыларның фронтка алынуы нәтиҗәсендә, мәктәпләрне кадрлар белән тәэмин итүдә киеренке хәл туа. Шул сәбәпле, Казан, Алабуга, Тәтеш, Мамадыш, Аксубайда татар һәм рус башлангыч мәктәпләренә укытучылар хәзерләү буенча өч айлык курслар оештырыла[8].

1944 елда Казан дәүләт университетының (КДУ) тарих-филология факультеты кысаларында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла.

Фән өлкәсендә татар галимнәре танылган галимнәр белән тыгыз элемтәдә эшлиләр. Алар оборона өчен кирәкле фәнни проблемаларны бергәләп хәл итәләр (Г.Камай, Ә.Г.Терегулов, Б.М.Йосыпов һ.б.). 1945 елның 13 апрелендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалын ачу турында карар кабул ителә. Анда биш тикшеренү институты: Математика, Физика һәм механика; Химия; Геология; Биология; Әдәбият, тел һәм тарих институтларын булдыру күз алдында тотыла.

1949 елда авыл мәктәпләрен гомуми мәҗбүри җидееллык укытуга күчерү башлана. Гомуми белем бирү мәктәпләре яңадан политехник укытуга күчә. Беренче сыйныфтан ук хезмәт дәресләре кертелә. Мәктәпләрдә остаханәләр булдырыла.

1955–1957 елларда Россиядәге татар педучилищеларының күбесе ябыла, Татарстанда 4 училище генә кала. Нәтиҗәдә алдагы елларда татар мәктәпләрендә башлангыч сыйныф укытучылары җитми башлый.

1950 елларга татар теленең дәрәҗәсе бик нык төшә. Татар мәктәпләренең саны кими. Татар балаларының күпчелеге белемне рус телендә ала башлыйлар. Татар мәктәпләрендә рус теле дәресләренә сәгатьләр арттырыла, татар теле сәгатьләре кыскара бара. Республикадагы тел сәясәтенә С.Д. Игнатьев тарафыннан үзгәреш кертү омтылышы ясала.

Өченче чор – 60–80 нче еллар. Бу елларда мәгариф мәсьәләләре үзәктән торып хәл ителә. Татар мәктәпләренә игътибар кими, аларның күпчелеге авыл шартларында гына сакланып кала. Төп игътибар рус телен өйрәнүгә юнәлдерелә. Совет җәмгыятенә файдалы җитештерүчән хезмәткә әзерләү юнәлеше билгеләнелә.

---

[8] Кәбирова А. Ватан сугышы елларында – мәгариф // Мәгариф. – 1999. – №11. – 75 б.

1958 елның декабрендә «СССРда мәктәпнең тормыш белән бәйләнешен ныгыту һәм халык мәгарифе системасын тагын да үстерү турында»гы закон нигезендә мәктәптә политехник белем бирү, укытуны тормыш белән бәйләп алып бару бурычлары куела. Укучылар мәктәп тәмамлаганда, аттестат белән беррәттән, һөнәри квалификация турында шәһадәтнамә дә алып чыга башлыйлар. Бу хәл 1966 елга кадәр дәвам итә.

1958 елда сигезьеллык мәҗбүри укыту кертелә. Ата-аналарга укыту телен сайлау хокукы бирелә. Нәтиҗәдә татар мәктәпләренең абруе төшә. 80 нче еллар башына Казан шәһәрендә бары 2 татар мәктәбе сакланып кала.

Татар мәктәпләренең кимүе татар зыялылары арасында канәгатьсезлек тудыра (Маннур Ш.Ф., Госманов Х.Г. һ.б.). Алар балалар бакчаларыннан башлап татар һәм рус төркемнәре оештыруны тәкъдим итәләр. Татарларны рус мәктәпләрендә укытуны тыярга дигән радикаль тәкъдимнәр дә яңгырый (Фәттах Н.С.).

Рус телен укытуга игътибар арту белән татар балаларына рус теле һәм әдәбиятын укытуның эчтәлеге һәм методикасы буенча хезмәтләр чыга башлый (Шакирова Л.З., Жданова Г.А., Әсәдуллин А.Ш. һ.б.).

50–60 елларда һөнәри белем бирүне камилләштерү, укучылар белән индивидуаль эшләү, проблемалы укыту, укучының танып белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген арттыруга игътибар бирелә.

КПССның XXII съездында «Коммунистик җәмгыять төзү программасы» кабул ителгәннән соң, интернациональ тәрбия бирүгә игътибар арта. КПСС программасында пролетар интернационализм һәм социалистик патриотизм үстерү бурычы ассызыклана[9]. «Бердәм совет халкы», «бердәм совет мәктәбе» формалаштыру процессы бара.

[9] Әхмәтова А.В. Укучыларны халыклар дуслыгы рухында тәрбияләү мәсьәләләре: тарихи тәҗрибә (1960–1980 еллар) // Материалы открытой городской научно-практической конеренции «Реализация этнокультурного содружества образования в рамках Федеральных государственных образовательных стандартов (ФГОС)». – Казань: ХЭТЕР, 2013. – 61–65 б.

## 1. Татар мәгариф системасы: мәктәп-мәдрәсәләрдән бердәм дәүләт мәктәбенә (1917–1938)

### 1.1. Укый-яза белмәүчелекне бетерү

1920 елның 30 ноябрендә ТАССР МХК каршында ликбез буенча бөтентатар комиссиясе төзү турындагы күрсәтмә кабул ителә[10]. Әлеге комиссия иң беренче чиратта ликбез мәктәпләре өчен дәреслек-кулланмалар, әлифбалар төзү мәсьәләсен карарга тиеш була. Шул елның җәендә Казан губернасында 50 мең әлифба дөнья күрә[11]. Иң беренче әлифбалар М.Корбангалиев һәм Т.Бәдигый авторлыгында басыла[12]. Республикада яшәүче башка рус булмаган халыклар белән чагыштырганда, методик әдәбият белән тәэмин ителеш ягыннан татарлар беренче урында була һәм бу тенденция кампания азагына кадәр саклана. Бу вакытта Казан шәһәрендә аерым «татар инструкторы» да була. Гомумән алганда, татарлар арасыннан ликбез мәктәпләре өчен педагоглар әзерләү мәсьәләсенә Татарстанда гына түгел, татарлар яшәгән башка төбәкләрдә дә игътибар ителә. Мәсәлән, Төмән өлкәсендә 1927–28 елда 28 «татар ликвидаторы» була[13]. Татарлар өчен махсус матбугат органы ачу турындагы мәсьәлә күтәрелсә дә, ул бары тик 30 елларда гына хәл ителә: аз белемлеләр өчен «Башлап уку», «Уку ударнигы» газеталары басыла башлый.

Ликбез системасында «грамоталы» сүзе элементар рәвештә укый-яза белүне аңлаткан. Ләкин аның эчтәлеге үзгәреп торган. Мәсәлән, беренче чорда ликбез мәктәбендә уку-язуга һәм санарга өйрәтү максат итеп алынса, 30нчы елларда, моннан тыш, икътисади география, җәмгыять белеме, тарих, авыл хуҗалыгы һәм зоотехник (авылда), политехник (шәһәрдә) белем бирү каралган. Ликбез мәктәп-

---

[10] Муртазина Л.Р. Педагогический анализ деятельности ликбезов (на примере Республики Татарстан). – Казань: Печатный двор, 2002. – С. 23.

[11] Куманев В.А. Социализм и всенародная грамотность. – М.: Наука, 1967. – С. 88.

[12] Корбангали М. Олылар өчен рәсемле татар әлифбасы. – Казан: Милләт, 1920. – 46 б.; Корбангали М. Олыларны укырга-язарга өйрәтү юллары һәм дәрес бирү үрнәкләре. – Казан: Татар. дәүл. нәшр., 1921. – 43 б.; Бәдигый Т. Зурлар әлифбасына үрнәк. – Казан: Татар. дәүл. нәшр., 1920. – 15 б.

[13] Национальная школа сибирских татар. Том 3. – Тюмень: Вектор Бук, 2005. – С. 81.

ләрендә укыту, куелган максаттан чыгып, ике баскычка (төргә) бүленгән: белемсезләр һәм аз белемлеләрне укыту; шуңа карап белем бирүнең эчтәлеге билгеләнгән: 20 нче елларда хәреф танырга өйрәнгән, саный белгән кеше аз белемле саналса, 30 нчы елларда инде ликпунктларны тәмамлаучылардан газеталар белән эш итә белү, беркадәр сәяси мәсьәләләрдә ориентлаша белү таләп ителгән.

Татарлар арасында ликбез үткәрүнең, башка милләтләр белән чагыштырганда, үзенчәлекләре бар. Бу, беренче чираттта, Октябрь революциясенә кадәр татарларның ана телләрендә белем дәрәҗәсе югары булу, әмма халык саны алу вакытында рус телендә укый-яза белү генә исәпкә алыну белән билгеләнсә, икенчедән, татар язуының берничә тапкыр үзгәреш кичерүенә, ягъни графика алыштыруга бәйле рәвештә, укый-яза белүчеләрнең кабат белемсез дип танылуы белән бәйле. К.Толстяков фикере буенча, революциягә кадәр татарлар арасында белем дәрәҗәсе 12, 1897 елгы халык санын алу материаллары буенча 18,8% дип билгеләнә. Бу очракта татарларның ана телендә укый-яза белүләре исәпкә алынмаган, нәтиҗә рус телендәге грамоталылык нигезендә билгеләнгән. Шул сәбәпле ясалган нәтиҗәләр гомуми күрсәткечләр белән (аерым алганда руслар арасында укый-яза белү) чагыштырганда күпкә түбән булып күренгән. Әмма татарлар арасында Октябрь революциясенә кадәр укый-яза белү дәрәҗәсе 60–80% тирәсе тәшкил иткәнлеге инде фәндә расланды[14]. Шулай ук татар хатын-кызлары арасында укый-яза белү дәрәҗәсе, башка милләтләр белән чагыштырганда, шактый югары булуын рус галимнәре дә таный (Я.Коблов). 1926 елгы халык санын алуга кадәр гарәп графикасында укый-яза белүчеләр белемсез дип саналса, 20 нче еллар башында һәрбер халыкның үз телендә белем алуга хокукы турындагы мәсьәлә каралып, уңай хәл ителгәннән соң[15] татарларның гарәп шрифтында укый-яза белүләре грамоталылык дәрәҗәсе итеп таныла башлый[16]. 1926 елгы халык санын алу нәтиҗәләре буенча татарлар арасында грамоталылык дәрәҗәсе 92,5% булып, алар СССР халыклары арасында беренче урынга чыгалар[17].

---

[14] Амирханов Р.У. Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. – Казань, 1992. – С. 46–47.

[15] Языковая политика в Республике Татарстан. – Казань, 1998. – С. 51–609.

[16] Муртазина Л.Р. Педагогический анализ деятельности ликбезов (на примере Республики Татарстан). – Казань: Печатный двор, 2002. – С. 16.

[17] Галиев Р. Беренче күчмә мәктәпләр // Совет мәктәбе. – 1972. – № 10. – 60 б.

Ликбез кампаниясенең беренче чоры билгеле бер эзлеклелекнең булмавы һәм алып барылган эшләрнең төрлелеге белән характерлана. Агитация һәм пропаганда нигездә рус телендә алып барыла. Киң халык массаларын җәлеп итү максатыннан «Бетсен наданлык» җәмгыяте төзелә, урыннарда аның күпсанлы бүлекчәләре (ячейкалары) барлыкка килә. Белемсезлек белән көрәшкә халык үзе – яңа гына ликпунктларны тәмамлаган эшче һәм крестьяннар җәлеп ителә. Яңа төр чаралар – «атналыклар», «өчкөнлекләр» уздыру да эшне югары баскычка күтәрергә мөмкинлек бирә. Уку-укыту әсбаплары белән тәэмин ителеш мәсьәләсе дә уңай якка кузгала: Казан шәһәрендә «Бетсен наданлык» җәмгыятенең Татар өлкә советы типографиясе оештырыла. Ликбез мәктәпләрендә белем бирү методикасын камилләштерү максатында Казанда 1923 елның 15–20 сентябрендә I Көнчыгыш методик конференциясе уздырыла. Анда зурларны укыту өчен бөтен сүзләр методының уңышлылыгы раслана һәм төп метод буларак кабул ителә.



*20 нче еллар башында ликбез мәктәбе*

Ликпунктлар белем алучыларның социаль һәм һөнәри составыннан чыгып оештырылганнар: эшчеләр, крестьяннар, хезмәтчеләр, хуҗабикәләр, профсоюз әгъзалары өчен һ.б. Дәреслекләр, аерым алганда, әлифбалар төзегәндә дә бу принцип нигез итеп алынган (авыл өчен крестьян әлифбасы һәм шәһәр варианты (эшчеләр өчен)[18].

Шул елларда хатын-кызлар өчен аерым мәктәпләр ачу мәсьәләсе күтәрелә, озакламый андый мәктәпләр урыннарда ачыла.

Ликбез системасында файдаланылган төп әсбаплардан әлифбаларны, уку китапларын, төрле предметлар буенча дәреслекләрне, программа һәм инструктив хатларны аерып күрсәтергә мөмкин.

---

[18] Корбангалиев М., Бәдигый Х. Крестьян әлифбасы (зурлар өчен). – М., 1925. – 48 б.; Мөхәммәдев М.Н. Эшчеләр әлифбасы. – М., 1924. – 80 б.; Дистанов Г., Бурнаш В. Яңа ил (Зурлар әлифбасы). Авыл өчен. – Казан: Татиздат, 1930. – 95 б.; Зурлар әлифбасы (шәһәр өчен). – Казан: Шәһәр культпоход штабы нәшр., 1929. – 16 б.; Зәйни Х., Исхаков Ф. Крестьян әлифбасы. – М.: СССР халыклары ҮН, 1928. – 71 б.; Саттаров Ш. Кызылармеец әлифбасы. – М.: Дәүл. Хәрби нәшр.,1925. – 64 б. һ.б.

Комплекс программалары нигезендә төзелгән әлифбалар, укырга өйрәтү белән беррәттән, бер үк вакытта язу күнекмәләре, санарга өйрәтү материалларын да үз эченә алган. Баштагы чорда аваз методына нигезләнгән балалар әлифбалары да файдаланыла. Комплекс системасы бетерелгәннән соң дөнья күргән әлифбалар үзләренең төзелешләре белән хәзерге әлифбаларны хәтерләтәләр[19]. Уку китаплары (эш китаплары)[20] аз белемлеләр мәктәпләрендә кулланылган һәм аларның максаты уку күнекмәләрен ныгыту белән беррәттән, иҗтимагый-сәяси тәрбия бирүдән гыйбарәт. Математика һәм икътисади география дәресләкләре сәнәгать һәм авыл хуҗалыгы, дөнья базарында СССРның тоткан урынын һ.б. билгеләүгә багышланган темаларны үз эченә ала.

20 нче елларның икенче яртысында гомуммән мәгариф өлкәсендә барган үзгәрешләр ликбез мәктәпләрендә дә чагылыш таба – дәүләт телләрен укытуга игътибар арта. Шул уңайдан татар ликпунктлары өчен рус теле дәресләкләре язу эше күтәрелә[21]. Гомумән алганда, 20 нче еллар азагына татар ликпунктларында укыту методикасы тулысынча эшләнеп беткән була инде.

Ликбез мәктәпләренең төп максаты олыларны укырга-язарга һәм санарга гына өйрәтү булмыйча, иң беренче чиратта совет иленең гражданнарында яңа, пролетар аң, социалистик җәмгыять төзелешендә катнашу теләге тәрбияләүдән гыйбарәт була. Азаккы максат – белемле һәм сәяси яктан грамоталы кеше формалаштыру. Шул максатларны тормышка ашыру сәяси сәгатьләр уздыру, мәктәптән тыш пропаганда алып бару, белем алучыларны сәяси тормышка тарту юллары аша алып барылган. Шуңа күрә укырга-язарга өйрәткәндә дә җәмгыяви-сәяси тормыш материалына нигезләнелгән.

Укыту алымнарын сайлауга килгәндә, беренче чорда, беркадәр өстәмә материаллар кертеп, балалар мәктәпләре тәҗрибәсенә таянылса, зурларны укыту методикасы эшләнү белән, комплекслар ме-

---

[19] Күльбиков З. Зурлар мәктәбе өчен әлифба. – Уфа: Башк. дәүл. нәшр., 1935. – 75 б.

[20] Мөхәммәдев М., Арсланов Ш., Шамов А. Безнең ил СССҖ. Аз укый-яза белүчеләр мәктәпләре өчен беренче уку китабы. – М.: СССР халыклары ҮН, 1926. – 72 б.; Дистанов Г., Бурнаш В. Яңа ил (Аз белемле зурлар өчен эш китабы). – Казан: Татиздат, 1929. – 61 б.; Бәдигов Х. Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 98 б.

[21] Никаноров В.А. Русский язык для татар. Рабочая книга для комвузов, совпартшкол, рабфаков, техникумов и курсов для взрослых. – Казань: Татиздат, 1931. – 224 с.

тоды, бөтен сүзләр, әңгәмә ысуллары, уку эчтәлеген тормыш һәм һөнәри эшчәнлек, теорияне практика белән бәйләп алып бару, белем бирүдә эзләнү-тикшеренү элементларын куллану, иллюстрация һәм күрсәтмәлелеккә игътибарны юнәлтү кебек метод һәм алымнарга өстенлек бирелә. Психологик аспектны («һәрбер яңа нәрсә балаларны үзенә тарта, ә олылар үзләренә күпмедер таныш булган нәрсәләр белән генә кызыксыналар»[22]) истә тотып эшләнгән методика отышлы дип табыла. Шулай итеп, уку-укыту барышын оештыруның яңа, моңарчы күрелмәгән формалары кертелә («Дальтон-план, лаборатор-бригада системасы, проектлар методы һ.б.»). 1927/28 уку елыннан кертелгән индивидуаль һәм индивидуаль-төркемле укыту моңарчы уку мөмкинлеге булмаганнарны тарту өчен бик уңайлы була. Нәтиҗәдә бик күп хатын-кызлар, вак предприятиеләрдә эшләүчеләр, авылда яшәүчеләр ликпунктларга килә. Татарстан шартларында кулланылган үзенчәлекле оештыру формасы буларак зурлар һәм балалар төркемнәреннән гыйбарәт булган ликпунктларны атарга мөмкин. Балалар өчен мәктәпләр ачылмаган авылларда мондый оештыру формасы уңай нәтиҗәләргә китергән.

1927 елда укый-яза белмәүчелекне бетерүнең икенче җиделлык планы кабул ителә. Аның буенча төп игътибар 15–30 яшьтәгеләрне укытуга бирелә. Эш темпларын тагын да арттыру максатында 1928 елның 15 октябрендә Татарстанда яңа форма – культпоход старт ала. Ликвидаторлар буларак студентлар, югары сыйныф укучылары, укытучылар, табиблар, инженерлар файдаланыла.

Ликбез юнәлешендә үзгәрешләр яңалифкә күчү һәм укый-яза белмәүчелекне латин графикасы гигезендә алып бару белән бәйле. Бу исә өстәмә авырлыклар тудыра, чөнки гарәп шрифтында хәреф танучылар яңалифкә күчкәннән соң кабат укый-яза белмәүче дип танылa. 1931 елда 100 000 нән артык кеше латин графикасы нигезендә укырга һәм язарга өйрәтелә, иске алфавит яңасы белән тулысынча алмаштырылып бетерелә[23].

30 нчы еллар башында ликбез системасында белемлелек дәрәҗәсен билгеләүнең яңа параметрлары эшләнә. Аның буенча бераз укый-яза белүчеләр грамотасыз дип танылa. Ликбез мәктәпләренең максаты – укый-яза, саный белгән, шулай ук үзенең хезмәт юнәле-

---

[22] Дистанов Г. Укый-яза белмәүчеләрне һәм аз белемлеләрне укытучылар өчен кулланма. – Казан: Татиздат, 1926. – 17 б.

[23] Гарипова З.Г. Культурно-просветительская работа в Татарии в годы I пятилетки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – С. 95.

шендә ныклы белемнәргә ия булган кеше тәрбияләү. Ликпункт тәмамлаган кеше агрономия, техника, учет буенча күзаллауларга ия булырга, китап белән мөстәкыйль эшли белергә, бер үк вакытта сәяси яктан грамоталы булырга тиеш. Шул максатны күздә тотып, 1931/32 уку елыннан алып ликбез мәктәпләренең төп эчтәлеген иҗтимагый-сәяси тәрбия тәшкил итә.

1939 елның урталарыннан алып аерым совхоз-колхоз, район һәм берләшмәләрдән укый-яза белмәүчелекне бетерү турындагы дәүләт актлары кабул ителә башлый. 1940 елдан исә илебез, шул исәптән Татарстан республикасы да, тулаем белемлеләр иле дип таныла. Әмма аз санда укый-яза белмәүчеләрнең Бөек Ватан сугышы чорында, хәтта 50 нче елларда да булуы билгеле[24].

## 1.2. Мәктәпкәчә тәрбия

Россиядә балалар бакчалары оештыру тәҗрибәсе Октябрь революциясенә кадәр башлана. Бу рус халкының югары катлау балалары өчен ачылган шәхси бакчалар була. Башка милләт вәкилләре арасында, шул исәптән татарларда да, мәктәпкәчә тәрбия йортлары оештыру эше революциядән соң, төгәлрәк әйткәндә, 1918 елдан тормышка ашырыла башлый. Ләкин 1917 елга кадәр чыккан милли матбугат битләрендә татарлар яшәгән кайбер төбәкләрдә җәйге балалар бакчалары ачылу турында мәгълүматлар очрый[25]. Шулай ук, патша хөкүмәтенең миссионерлык сәясәтен тормышка ашыру буенча 1910–1911 елларда үткәрелгән «Махсус киңәшмә»дә дә рус-татар мәктәпләренә хәзерлек формасында балалар бакчалары ачу турында тәкъдимнәр булуы билгеле[26].

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү йортлары Казанда 1919 елда барлыкка килә башлый. Яңа ачылган 40 бакчаның 7 се татар балалар бакчасы була. Шул ук елны балалар бакчасы оештыру эше авылларда да башланып китә. Мәсәлән: 1919 елда Казан артында беренче балалар бакчасы Кече Солабаш авылында ачыла[27].

---

[24] Укый-яза белмәүчеләрне укыту буенча инструктив-методик күрсәтмәләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958 – 62 б. һ.б.

[25] [16 нчы майда балалар бакчасын ачу тантанасы...] // Тормыш. – 1915. – 21 май; [Бу ел балалар бакчасы...] // Тормыш. – 1915. – 17 июнь һ.б.

[26] Саматова Ч.Х. Школьная политика самодержавия в отношении татар-мусульман во второй половине XIX – начале XX вв. (на примере Казанского учебного округа): дис. ... канд. ист. наук. – Казань, 2010. – 74–76 б.

[27] Хәмидуллин Ф. Беренче балалар бакчасы // Мәгариф. – 1967. – № 11. – 57 б.



*Казандагы 4 нче балалар бакчасы. 1928 ел*

Совет дәүләте мәктәпкәчә яшьтәге балалар оешмалары булдырып җәмгыятьтә барлыкка килгән ике төп мәсьәләне чишү максатын куя. Беренчедән, хатын-кызларны бала караудан азат итү һәм аларга җәмгыять тормышында катнашырга күбрәк мөмкинлекләр тудыру; икенчедән, балаларга тиешле дәрәҗәдә тәрбия һәм белем бирү, балаларның сәламәтлеген ныгыту.

20–30 еллар аралыгында мәктәпкәчә тәрбия йортлары, илдә барган сәяси һәм икътисади шартлар нәтиҗәсендә, төрлечә үсү һәм кыскару дәверләре кичерәләр. 1918–1920 еллар – мәктәпкәчә тәрбия йортлары үсеш алган чор. Бу елларда финанслау дәүләт карамагында була, тоткарлыксыз кирәкле күләмдә тәэмин ителә, шәхси биналарны хосусыйлаштыру нәтиҗәсендә балалар бакчалары ачу өчен буш биналар күп була. 1921–1925 елларны мәктәпкәчә тәрбия оешмаларының саны кыскару чоры дип әйтергә кирәк. Кыскару чоры башлангач, иң башлап авыллардагы мәктәпкәчә тәрбия йортлары ябыла башлый һәм озакламый алар барысы да диярлек ябылып бетә[28]. Моңа, иң беренче чиратта, 1921 елгы ачлык йогынты ясый. Икенчедән, балалар оешмаларын финанслау урындагы бюджетларга күчерелү сәбәпле, бу төр оешмаларның матди хәлләре начарлана, тотылган акча җентекләп тикшерелә һәм чыгымнар кыскартыла, эреләндерү процессы башлана.

[28] Мөхетдинов Н. Татарстан җөмһүриятендә гомуми-мәҗбүри уку кертү мәсьәләләре. Мәктәпкәчә тәрбия // Мәгариф. – 1927. – №1. – 11 б.

Әлеге процесс азрак чыгымнар тотып күбрәк балага хезмәт күрсәтүне максат итеп куя. Нәтиҗәдә, бер тәрбияче 35–40 бала карарга мәҗбүр була. Кайбер балалар бакчалары сәнәгать оешмаларына беркетелә, бакчада йөргән өчен түләү кертелә. 1926–1941 елларда мәктәпкәчә тәрбия оешмалары челтәре яңадан киңәя башлый. Бу елларда авыл җирләрендә күмәк хуҗалыклар, шәһәрләрдә сәнәгать оешмаларының киң таралыш алуы ил күләмендә балалар оешмаларын үстерүгә нык әһәмият бирелүне таләп итә[29].

Мәктәпкәчә тәрбия йортлары оешуының беренче елларында тәрбия буенча бердәм система, расланган бердәм юнәлеш булмый. Күбесенчә «мөстәкыйль тәрбия теориясе», Фребель һәм Монтессори системаларының кайбер элементлары кулланыла.

Балалар бакчаларын оештыру, аларның төрләрен билгеләүдә 1919 елның май аенда узган I Бөтенроссия съезды зур роль уйный. Шул елда чыккан «Балалар бакчасы һәм балалар учагы буенча инструкция» бу өлкәдә иң беренче документ булып тора.

Совет чорында мәктәпкәчә тәрбия йортларының иң киң таралган төрләре булып балалар бакчалары, балалар учагы һәм җәйге балалар мәйданчыклары санала. Болар тыш тагын: яслеләр, колонияләр, балалар шәһәрчеге, клублар янында балалар почмагы, балалар бүлмәсе һ.б. була.

20 елларда Татарстан җирлегендә – шәһәрдә, МТСта, совхозда эшләүчеләренең балалары өчен – балалар бакчалары; эшче районнар өчен – балалар учагы; ялгыз аналар өчен – интернатлар; колхозлар өчен – балалар мәйданчыклары эшләп килә[30].

Мәктәпкәчә балалар йортлары эшенә җитәкчелек итәр өчен МХКның БЭМ бүлекчәсендә мәктәпкәчә тәрбия секциясе оештырыла. Соңрак ул мәктәпкәчә тәрбия бүлекчәсе итеп үзгәртелә. Районнарда мәктәпкәчә тәрбия эше буенча инструкторлар эшли. Алар бүлекчә белән берлектә инструкторлар коллегиясен хасил итәләр. Коллегия Казан шәһәрендәге һәм губернадагы башка балалар бакчаларының эше белән җитәкчелек итә. Татар балалар бакчаларының беренче инструкторы итеп С.Г. Фәйзуллина билгеләнә[31].

---

[29] Мардашова Р.С. Становление и развитие дошкольного образования в Татарстане (конец XVIII – середина XX в.): автореф. дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 2010. – 21 с.

[30] Корнеева М. Татарстанда мәктәпкәчә тәрбия эшенең үсеше // Мәгариф. – 1967. – №11. – 35 б.

[31] Тутаев М.З. Октябрь и просвещение. – Казань, 1970. – С. 232.

Мәктәпкәчә тәрбия йортлары татар халкы арасында моңа кадәр билгеле булмаганлыктан, педагоглар алдында әлеге оешмаларның төп максатларын билгеләү, төрләрен ачыклау, һәрбер төрнең оештыру юлларын һәм аларның эшчәнлеген алып бару мәсьәләләрен чишү зарурлыгы килеп баса. Әлеге мәсьәләләрне чишү юлларын И.Бикчәнтәй, К.Вәлитова, Г.Айдаров, М.Ялымова, М.Мөштәриләр үз хезмәтләрендә тәкъдим итәләр.


М.Ялымова

Әлеге өлкәдә иң күп һәм нәтиҗәле эшләгән кешеләрнең берсе булган М.Ялымова, балалар бакчаларында эшне аңлы һәм планлы оештырган очракта гына кечкенәләрнең дөрес тәрбия алуларына, физик һәм рухи яктан сәламәт булып үсүләренә ирешергә мөмкин булганлыгын әйтә. Ул үзенең хезмәтләрендә көндәлек һәм туклану режимнарының, шулай ук тирә-як мохит, гаиләдәге вәзгыятьнең бала үсешенә, аның җәмгыять өчен кирәкле, чын кеше булып формалашуына тәэсире зур булуын ассызыклый[32].

Татар халкы өчен бу төр хезмәт күрсәтү чаралары яңа эш булганлыктан, мәктәпкәчә тәрбия йортлары турында гади халыкның мәгълүматы булмый. Шуңа күрә балалар бакчаларын оештыручылар күптөрле каршылыкларга очрыйлар. Мондый очраклар күбрәк авылларда күзәтелә. Халыкның бу эш белән таныш түгеллеген истә тотып, К.Вәлитова «бездә (ягъни, татарларда – *З.А.*) халык әле баласын үзеннән аерып ясле, колония шикелле җирләргә биререгә өйрәнмәгән»[33], – ди. Шунлыктан, тәрбиячеләргә, беренче чиратта, ата-аналар белән эш алып барырга, алар белән танышырга, әлеге төр оешмаларның ни өчен кирәклеген, аларның эшләү шартларын аңлатып бирергә кирәк була[34]. Педагоглар тәрбия йортларын ачканда ата-аналарның ярдәменә мөрәҗәгать итүне дә кулай күрәләр[35].

---

[32] Мортазина Л. Мәрьям Ялымованың педагогик эшчәнлеге // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2010. – № 3/4. – 191–195 б.

[33] Вәлитова К. Мәктәпкә кадәр тәрбия // Мәгариф. – 1921. – №1–2. – 42 б.

[34] Ялымова М. Авылларда мәктәпкәчә тәрбия эшен оештыру юллары // Мәгариф. – 1926. – № 6–7. – 87 б.

[35] Балалар мәйданчыгы нәрсә һәм аны ничек төзергә? – М.: Нәшрият, 1926. – 8–9 б.

XX гасырның 20 елларыннан балаларга дөрес тәрбия һәм белем башлангычын бирү буенча татар телендә басылган эш программалары, методик кулланмалар дөнья күрә башлый. Алар революциядән соң илдә урнашкан иҗтимагый-сәяси вәзгыять басымына дучар булсалар да, татар халкының гореф-гадәтләрен, тормыш-көнкүрешен күз алдында тотып, күп очракта тәрбиячеләрнең үзләренең шәхси тәҗрибәләренә нигезләнеп язылалар. Әлеге авторлардан беренче чиратта, К.Вәлитова, С.Миңлекәй, З.Салихова исемнәрен атап узарга кирәк. Болардан тыш, гомумән, укыту-тәрбия мәсьәләләрен өйрәнгәндә бер юнәлеш буларак мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем һәм тәрбия бирү юлларына тукталган авторлардан М.Корбангалиев, С.Камал, И. Богданович, М. Фазлулла, Н. Салихова, Г. Айдаров, Х. Гали, Х. Зәйни һ.б.ларны искә алырга кирәк.



*М.Корбангалиев*

1921 елда «Балалар бакчасында эш алып бару буенча күрсәтмә» дөнья күрә. Бу чорда балалар бакчаларында тәрбиянең төп төрләре булып физик һәм эш тәрбиясе бирү тора. Балаларга мөстәкыйльлек, шөгыльләрне үзләренә сайлау мөмкинлеге бирү алга сөрелә. Тәрбияче эш процессын оештыручы ролен генә үти. Мәктәпкәчә тәрбия эшендә уен, сөйләм телен үстерү, рәсем, җыр дәресләре, кисү-ябыштыру күнекмәләренә өйрәтү кебек шөгыльләр төп урынны алып тора.

Югарыда әйтеп узылганча, мәктәпкәчә тәрбия йортларына төрле яшьтәге балалар кабул ителә. Шунлыктан төп бурычларның берсе булып баланың сөйләм телен үстерү тора. Сөйләм теленең үсеше баланың акыл ягыннан гомуми үсешенә нык йогынты ясый. Баланың сөйләм теле яшенә туры килгән дәрәҗәдә үсеш алмый икән, бала иптәшләреннән читләшергә, үзенә тиешле һәм тиешсез әйберләрне аңлап бетермәскә мөмкин. Кечкенә бала әйберне турыдан-туры сизеп, күреп, танып исендә калдыра. Аның теле, тел байлыгы үскән саен, ул күп нәрсәләрне инде сүз аркылы да аңлый башлый. Аның фикерләү сәләте, кызыксынуы арта. Әлеге мәсьәләгә күп кенә авторлар әһәмият биреп узганнар. Шулар арасыннан аеруча Х.Галинең «Мәктәпкәчә тәрбия яшендә баланың телен үстерү юллары», М.Фазлулланың «Баланың теле ничек ачыла?», Н.Салихованың

«Мәктәпкәчә тәрбия йортларында җанлы сүз» хезмәтләрен атап үтәргә кирәк. Соңгы автор әйтүе буенча, «мәктәпкәчә тәрбия яшендәге бала фәкать сөйләшә генә башлый әле; һәм шушы яшьтә өйрәнгән тәҗрибәсе баланың киләчәктә сөйләү, уйлау көчләренең киңәюенә нигез була. Менә бу мәктәпкәчә яшьтәге балалар арасында җанлы сүздән бик уйлап һәм бик тикшереп файдалануны безнең өстебезгә йөкли»[36], – ди. Авторлар фикеренчә, бала беренче чиратта үз ана телен өйрәнергә, туган телгә ия булырга тиеш. Н.Салихова фикеренчә, «Ана теле» дип семьяда (баланың өендә) сөйләнә торган телгә әйтәләр. Мәсәлән, бер рус баласы кече яшеннән ук татар семьясында торып, татарча гына сөйләшә белә. Аның белән татарча сөйләшеп, аны татарчага өйрәтергә кирәк»[37], – дип аңлата. Х.Гали исә, бала ана теленә өйрәнеп бетмәгән килеш, аңа чит тел өйрәтү (татар балалары өчен рус теле чит тел булып тора – *З.А.*) баланың нормаль үсешенә комачаулык ясый, дип саный. Чөнки «сүз аңнан туа. Икенче төрле әйткәндә, сүз аңның тышкы формасы була. Бер аңга ике форма бирү балага авыр була. Ике төрле сүзгә энергия артык китә. Энергиянең артык китүе аркасында аң тупаслана [...] баланың аңын конкретлыктан чыгарып, ориентациясен чуалта»[38]. Ул мәктәпкәчә яшьтәге балаларны акыл үсешләре буенча дүрт дәвергә бүлә: 1) туган көннән алып 3 яшь тулганчы; 2) 3–5 яшь; 3) 5–6 яшьләр арасы; 4) 6–7 яшьләр арасы, шул дәверләргә туры килгән күләмдә баланың телен үстерү юлларын булдырырга тәкъдим итә[39]. К.Вәлитова исә, мәктәпкәчә яшьтәге татар балаларының теле ярлы, сүз байлыгы аз, дип исәпли. Шул ук вакытта, татарлар дәүләтнең төрле төбәкләренә чәчелеп яшәгәнлектән, телләре дә саф татар теле түгеллеген искәртә. Шунлыктан ул бала мәктәпкә кергәнче аның телен дөресләргә, ягъни әдәби телгә өйрәтергә кирәк, дип саный[40].

Әлбәттә, тел үсеше аерым бер эш төре булып кына кала алмый, ул барлык тәрбия эшләре белән тыгыз бәйләнгән. Баланың сөйләм теле дөрес һәм матур булсын өчен, аның әйләнә-тирәсендәге кеше-

---

[36] Салихова Н. Мәктәпкәчә тәрбия йортларында җанлы сүз. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 3 б.

[37] Салихова Н. Мәктәпкәчә тәрбия йортларында җанлы сүз. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 10 б.

[38] Гали Х. Мәктәпкәчә тәрбия яшендә баланың телен үстерү юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 7–8 б.

[39] Гали Х. Мәктәпкәчә тәрбия яшендә баланың телен үстерү юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 16 б.

[40] Вәлитова К. Балалар бакчасында ничек эшләргә? – М., 1929. – 35 б.

ләрнең, беренче чиратта, тәрбияченең, сөйләме саф ана телендә, грамоталы һәм әдәби булырга тиеш. Шул ук вакытта, баланың сөйләм теле дөрес формалашсын өчен, тәрбияче баланың телендәге җитешсезлекләрне төзәтергә, аларны дөрес юлга салырга тиеш.

Баланың сөйләм телен үстерүдә җанлы сүз зур роль уйный. Н.Салихова җанлы сөйләмне түбәндәге төрләргә бүлә: 1) балалар белән сөйләшү; 2) әңгәмәләр; 3) хикәя сөйләү; 4) шигырь сөйләргә өйрәнү; 5) балаларга китап уку. «Шушы җанлы сүз төрләре аркылы без балаларның телләрен ачуга һәм аны дөресләүгә ярдәм итә алабыз»[41], – ди ул. Ләкин, шул ук вакытта, җанлы сүзне артык югары дәрәҗәгә күтәрергә дә тәкъдим итми, чөнки «тәҗрибә нигезенә корылмаган күп сүзлелек тәрбиядә начар нәтиҗәгә алып бара: бала күп сөйләүчән, бигрәк тә кирәксез һәм үзенә билгеле булмаган нәрсәләр турында сөйләүчән булу куркынычы бар»[42], – дип искәртә.



*Зөһрә Салихова гаиләсе белән*

Мәктәпкәчә яшьтәге баланың төп шөгыле уен. Баланың яшенә, физик мөмкинлекләренә туры китереп, дөрес сайланган «уен вакытында баланың хиссияте ныгый, акылы үсә, ул физик яктан чыны-

[41] Салихова Н. Мәктәпкәчә тәрбия йортларында җанлы сүз. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 9 б.

[42] Салихова Н. Мәктәпкәчә тәрбия йортларында җанлы сүз. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 8 б.

га»[43], шул ук вакытта, уен сөйләм теле үсешенә дә зур йогынты ясый. Уеннарны нәкъ шушы күзлектән чыгып яктырткан педагог – З.Салихова. Ул – балаларга шигырьләрне өйрәткәндә җиңелдән – авырга принцибына таяну, башта кыскарак, күңеллерәк шигырь һәм уеннарны, соңрак авыррakларына күчәргә кирәклеген әйтә. Материалны сайлаганда балаларның яшь һәм шәхси үзенчәлекләрен искә алу принцибын алга сөрә. [...] Ул тәкъдим иткән җырлы уеннар, шигырь текстлары кече яшьтәге балаларның психологиясенә туры килә, әйтү өчен җиңел, сөйләм үстерүгә ярдәм итә. Аларның күбесен бүгенге көндә файдалану өчен тәкъдим итәргә була»[44].

Мәктәпкәчә тәрбия оешмаларында уеннарның әһәмияте, аларның төрләре һәм тәрбия барышында аларны куллану юллары шулай ук С.Миңлекәй[45] һәм Х.Зәйни[46] хезмәтләрендә чагылыш тапкан. Әлеге авторлар татар балалар бакчаларында кулланышка кергән уеннарның, бигрәк тә җырлы уеннарның, текстларының төзелеше, көйләре ярты-йорты булуына борчылуларын белдерәләр, аларның татар халкының рухына чит булуларын ассызыйклыйлар. С.Миңлекәй мисал итеп «Вот пошел наш козел», «В хороводе были мы» һ.б. тәрҗемәләрне китерә. «Бу җырлы уеннар үзләренең сүз төзелешләре, көйләре белән тәмам урыс аһәңен, урыс көен бозып бездә җырланалар. Чөнки безнең тәрбиячеләр үзләре дә ул көйләрне ватып кына беләләр», – ди ул һәм саф татарча текстлардан гыйбарәт булган җырлар тәкъдим итә[47]. Гали Х. исә, татар халкының кайбер җырларын, мәсәлән «Бас, кызым Әпипә»не, урам җырларына кертә һәм аларны тәрбия йортларына кертмәү, баланың колагына ишеттермәү чараларын күрергә кирәклеген искәртә[48].

20–30 елларда мәгариф өлкәсендә хезмәт тәрбиясе бирү, хезмәт аркылы башка кирәкле сыйфатлар – пөхтәлек, матурлыкны тою, фикерләү, уйлап чыгару сәләте һ.б. тәрбияләү алгы планга чыга.

Баланы кече яшьтән үк эшкә өйрәтү максатыннан, балалар бакчалары ачу өчен йорт сайлаганда, җәйге балалар мәйданчыклары

---

[43] Мортазина Л. Җырлы уеннар // Мәгариф. –2010. – №10. – 41–43 б.

[44] Шунда ук. – 41 б.

[45] Миңлекәй С. Балалар өчен җырлы уеннар. – Казан: Татиздат, 1925. – 48 б.

[46] Зәйни Х. Мәктәп, балалар бакчасы һәм балалар мәйданы өчен уеннар. – Уфа, 1919. – 101 б.

[47] Мортазина Л. Татар балалар бакчаларында белем һәм тәрбия // Фән һәм мәктәп. – 2010. – №5–6. – 19 б.

[48] Гали Х. Мәктәпкәчә тәрбия яшендә балалның телен үстерү юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 48 б.

ачканда әлеге оешмалар тирәсендә җиләк-җимеш яки яшелчә бакчасы булды – төп теләкләрнең берсе булып тора[49].

К.Вәлитова эш элементларын балалар бергә төркем белән уйнарга өйрәнгәч кертә башларга мөмкин дип исәпли. Беренче чиратта, ул балаларга үз артыннан уенчыкларын, эш коралларын, дәфтәр һәм карандашларын җыеп кую, зуррак балаларның киенгәндә-чишенгәндә кечкенәләргә булышу күнекмәләрен тудыруны кирәк таба, кизү тору тәҗрибәсен кертүне тәкъдим итә. Зурлар төркеменә йөргән балалар белән завод-фабрика, кырларга, болыннарга экскурсияләр ясап, балаларны төрле һөнәрләр белән таныштыруны бик файдалы күрә[50].

Хезмәт тәрбиясе бирүдә төрле эш кораллары белән эшләү, төзү эше белән шөгыльләнү зур урын алып тора. Мәктәпкәчә чорда төзү эше «баланың нәрсәдән генә булмасын, төрле нәрсәләр ясавын үз эченә ала. Мәсәлән, балалар бакчасындагы яки өйдәге җиһазларны урнаштыру, төрле әйберләрне төрле урыннарга куеп карау, материал һәм уенчыкларны җирле җиренә кую, түтәлләр эшләү, утын ташу һәм өю»[51].

С.Камалның «Декоратив эшләр...», «Катыргы эшләре...», «Кәгазь эшләре...»[52] кулланмалары балаларга хезмәт тәрбиясе бирү, хезмәт дәресләре уздыру өчен төзелгән. Бу яктан караганда, балалар яратып башкара торган кисү, ябыштыру эшләре, ягъни аппликация эшләре, тәкъдим ителгән соңгы кулланма аеруча игътибарга лаек. Автор фикеренчә, «Аппликация эше [...] тәрбия эшендә бик мөһим урын тота. [...] Соңгы елларда гына булса да, тәрбия эшләрендә бу сәнгатьтән файдалану бездә дә күренгәли башлады. [...] бу сәнгать безнең арада бик акрынлык белән алга бара, моның сәбәбе, әлбәттә, билгеле, ул да булса гаиләдәге аналарның, мәктәптәге укытучыларның, мәктәпкәчә тәрбия йортларындагы мөрәбби һәм мөрәббияләрнең (ир-ат һәм ха-

[49] Балалар мәйданчыгы нәрсә һәм аны ничек төзергә? – М.: Нәшрият, 1926. – 11 б.

[50] Вәлитова К. Балалар бакчасында ничек эшләргә? – М., 1929. – 29–30 б.

[51] Вәлитова К. Балалар бакчасында ничек эшләргә? – М., 1929. – 31 б.

[52] Камал С. Декоратив эшләр. Мәктәпкәчә тәрбия йортларында, мәктәп һәм пионер отрядларында куллану өчен. – Казан: Татгосиздат, 1932. – 48 б.; Катыргы эшләре. Мәктәпкәчә тәрбия йортлары, мәктәп, пионер отрядлары һәм түгәрәкләрдә куллану өчен. – Казан: Татгосиздат, 1932. – 64 б.; Кәгазь эшләре белән: Мәктәпкәчә тәрбия йортлары, мәктәп, пионер отрядлары һәм түгәрәкләрдә куллану өчен. – Казан: Татгосиздат, 1932. – 42 б.

тын-кыз тәрбияче) бу сәнгатьтән хәбәрләре булмаудыр»[53]. Шуны истә тотып, автор өч кулланмасында да дәрес өчен кирәкле материалларның, коралларның, өстәмә материалларның исемнәрен китерә, эшләрне башкару эзлеклелеген аңлата. «Декоратив эшләр»[54] кулланмасында шулай ук тәрбиячеләргә матур язу үрнәкләре, газета чыгару, плакатлар әзерләү буенча киңәшләр дә бирелә.

Педагоглар яшь буынны тәрбияләгәндә, шулай ук тән тәрбиясенә (гигиена) зур әһәмият бирүне мөһим күрәләр, балаларга сәламәт яшәү күнекмәләрен өйрәтүне алга сөрәләр. «Сугыш аркасында чыккан икътисади торгынлык, тормышның көннән-көн авырая баруы, ачлык вә моның өстенә йогышлы авырулар сәбәпле, эшчекрестьян сыйныфының балалары тазалык ягыннан һаман да начарая бара», – дип яза К.Вәлитова[55]. М.Мөштәри фикеренчә, яслеләр, бигрәк тә авылларда, «крестьян көнкүрешен тазалыкка, саулыкка алып бара, мәдәни тәрбия бирә, балалар үлеме белән көрәшә, балаларда чисталык, тазалык гадәтләрен урнашытуга булыша»[56].

Тән тәрбиясенең төп бурычы – балаларны чисталыкка өйрәтү. Моның өчен, беренче чиратта, балаларны әйләндереп алган тирәлек чиста, пөхтә булырга тиеш. Шулай ук ясле яшеннән үк балаларны үз-үзләрен карап, чиста йөререгә өйрәтә башлау зарури. «Балаларны каршы алгач, тәрбияче аларга юынырга, тешләрен чистартырга һ.б. эшләрне эшләргә булышырга тиеш»[57]. Тән тәрбиясе биргәндә, балаларның һава һәм кояш ванналары алуларын оештыруга зур әһәмият бирелә[58]. Педагоглар фикеренчә, югарыда санап узылган барлык күнекмәләр балаларга боерык нигезендә түгел, ә бәлки бала үзе аңлап эшләрлек дәрәҗәдә аңлатып бирелергә тиеш. Бала «өйдә вакытта да шуны дәвам итәрлек»[59] булырга тиеш. К. Вәлитова әйтүенчә, «бакчада алган гадәтләрен бала өенә дә алып кайта, шул рәвешчә

---

[53] Камал С. Кәгазь эшләре белән: Мәктәпкәчә тәрбия йортлары, мәктәп, пионер отрядлары һәм түгәрәкләрдә куллану өчен. – Казан: Татгосиздат, 1932. – 3 б.

[54] Камал С. Декоратив эшләр. Мәктәпкәчә тәрбия йортларында, мәктәп һәм пионер отрядларында куллану өчен. – Казан: Татгосиздат, 1932. – 48 б.

[55] Вәлитова К. Мәктәпкә кадәр тәрбия // Мәгариф. – 1921. – №1–2. – 41 б.

[56] Мөштәри М. Авылда яслеләр. – Казан: Татиздат, 1930. – 6 б.

[57] Балалар мәйданчыгы нәрсә һәм аны ничек төзергә? – М.: Нәшрият, 1926. – 11 б.

[58] Вәлитова К. Балалар бакчасында ничек эшләргә? – М., 1929. – 18–19 б.

[59] Балалар мәйданчыгы нәрсә һәм аны ничек төзергә? – М.: Нәшрият, 1926. – 11 б.

балалар бакчасы аркылы семьяда да гигиена ягыннан зур үзгәрешләр ясарга мөмкин»[60].

20–30 нчы елларда балалар бакчалары эшчәнлегенә караган әдәбиятта балаларга коллектив белән эшләү күнекмәләрен тудыру бурычы куелганы күренеп тора. Тәрбиянең кайсы гына төрен алсаң да, беренче чиратта, бала коллективта үз-үзен тотарга, коллектив белән эшләргә өйрәнергә, тату коллектив төзи белергә тиеш санала.

20 еллар ахырына таба ил күләмендә коммунистик тәрбия алгы планга чыккач, балалар бакчалары да шул юнәлештә эшли башлыйлар. Беренче еллардагы милли рух әкренләп тәрбия бирү процессыннан чыгарыла, революцион бәйрәмнәр үткәрү, пионерлар белән эш төрләре кертелә. Тәрбия бирү ана телендә булуга карамастан, рус мәдәнияте һәм әдәбияте белән таныштыру алгы планга куела, күпләп рус халык әкиятләренең һәм башка балалар өчен язылган әдәби әсәрләрнең тәрҗемәләре кулланыла башлый[61].

Авыл хуҗалыгы һәм сәнәгать алга китү сәбәпле, мәктәпкәчә тәрбия оешмаларының саны арта. Балалар бакчалары балалар учагы дип үзгәртеләләр, аларның эш сәгатьләре арттырыла. Авыл җирләрендә күбрәк балалар мәйданчыклары үсеш ала. Мәсәлән, 1927 елда Буа кантонында барлык балалар мәйданчыкларының 58% татар мәйданчыклары була[62].

30 еллар ахырына таба киң таралган бердәйләштерү сәясәте мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү өлкәсен дә әйләнеп узмый. Тәрбия эше бердәм дәүләт документлары нигезендә алып барыла башлый[63]. Бердәм Устав буенча, балалар бакчасы: баланың сәламәтлеге турында кайгырта; баланың аңын, акыл сәләтен һәм сөйләм телен үстерә; балаларны мөстәкыйльлеккә, чисталыкка, хезмәткә, өлкәннәрне хөрмәт итәргә, тәртипкә, оешканлыкка өйрәтә; патриотизм тәрбияли. Шунысын да әйтеп узарга кирәк, Устав буенча балалар бакчаларында тәрбия эше ана телендә алып барыла, диелә[64]. Бәлки шул сәбәпледер, бу елларда татар телендә чыккан методик куллан-

---

[60] Вәлитова К. Балалар бакчасында ничек эшләргә? – М., 1929. – 19 б.

[61] Корнеева М.С. Очерки по истории общественного дошкольного воспитания в ТАССР (1917–1941 гг.): автореф. дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 1960. – С. 11.

[62] Шунда ук. – С. 11.

[63] «Программа детского сада» (1934), Постановление ЦК ВКП(б) от 4 августа 1936 г. «О педагогических извращениях в система Наркомпросов», «Руководство для воспитателя детского сада» и «Устав детского сада» (1938) һ.б.

[64] Балалар бакчасы тәрбиячесе өчен кулланма. – Казан: Татгосиздат, 1938. – 3–4 б.

маларга һәм балалар әдәбиятына зур әһәмият бирелә башлый. Аларны тикшерү буенча махсус комиссияләр төзелә. Билгеле, бу елларда татар балалар әдәбияты милли нигездә түгел, ә совет чорына хас тәрбия алымнарына туры китерелеп, коммунистик, интернациональ, патриотик рухта иҗат ителә.

Мәктәпкәчә балалар оешмалары белем бирү мәсьәләсен беренче урынга куймасалар да, балалар бакчаларының өлкәннәр төркеме мәктәпкә әзерлек чоры булып тора. 6 яшьтән 8 яшькә кадәр балалар йөри торган төркемнәр Бердәм эш мәктәпләре (БЭМ) челтәренә кертелә[65].

Методик кулланмалардан күренгәнчә, әлеге чорда балаларга уку-язу күнекмәләрен өйрәтүгә зур урын бирелгән. Ләкин «уку-язу мәктәптәге төсле баланың бөтен эшләрен капларлык дәрәҗәдә аерым бер нәрсә итеп кертелми, бәлки башка эшләр белән бергә катнашып, аларны тагын да тутырырлык булырдай бер ярдәмче итеп кенә кертелә»[66]. Балаларга бу күнекмәләрне 6–8 яшьләр аралыгында өйрәтү тиешле дип санала. Чөнки «бу чорда сөйләү аппараты көйләнгән, күрү һәм ишетү көчләре җитәрлек кадәр үскән, хәрәкәт аппаратын бала үзенә буйсындырырлык була. Бу чорда уку-язуга өйрәнүне балалар үзләре үк сорый башлыйлар»,[67] дип исәпләнелә. Х. Гали исә «укырга-язарга өйрәткәндә ... иң әһәмиятле нәрсә балада укырга-язарга кызыгуны уяту, теләк, омтылуны кузгату», – дип саный. «Бу нәрсә булмаса, баланы көчләмәскә кирәк. Мәсәлән, кайсы бала укуга кызыгып та, язуга кызыкмавы мөмкин. Кызыкмаса, язмый йөрсен, кызыккан көнне язар»[68], – ди.

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларны укырга-язарга өйрәтү ысулларын Х.Гали, М.Корбангалиев, Р.Шакирова һәм Д.Сафин хезмәтләрендә[69] очратырга мөмкин.

---

[65] Постановление (декрет) ВЦИК РСФСР от 16.10.1918 г. «О единой трудовой школе» [Электронный ресурс]. URL: http://dorogiistorii.ru/istoricheskie-dokumenti /postanovlenie-dekret-vtsik-rsfsr-ot-16-10-1918-g-o-edinoy-trudovoy-shkole.html (14.04.2017)

[66] Вәлитова К. Балалар бакчасында ничек эшләргә? – М., 1929. – 36 б.

[67] Шунда ук. – 36 б.

[68] Гали Х. Мәктәпкәчә тәрбия яшендә баланың телен үстерү юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 64 б.

[69] Гали Х. Мәктәпкәчә тәрбия яшендә баланың телен үстерү юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 68 б.; Корбангалиев М. Балалар бакчасындагы һәм балалар йортындагы балаларны укырга-язарга өйрәтү юллары // Мәгариф. – 1923. – № 1. – 44–46 б.; Мария Монтессориның балаларны язарга өйрәтү

«Балалар бакчасында һәм балалар йортындагы балаларны укырга-язарга өйрәтү юллары» мәкаләсендә М.Корбангалиев балаларны укырга-язарга өйрәтүнең яңа ысулларын табарга кирәклеген әйтә, һәм соңгы елларда күбәеп киткән ысуллардан М.Монтессори ысулын яклап чыга[70]. Әлеге ысул аваз методына нигезләнгән. М.Монтессори фикеренчә, бала үзенең язган сүзен укыганда хәрефләрне авазларга әйләндерсә, сүзне язганда авазларны хәрефләргә әйләндерә. Аның фикеренчә, бала язган сүзне мәгънәсе белән аңлап укыса, димәк ул укырга өйрәнгән була. Әгәр укыганда төрле авазлар гына чыгарып укыса, дөрес сүз чыгармаса, дөрес басым ясамаса, мәгънәсен аңламаса, ул укырга өйрәнмәгән булып чыга[71]. Әлеге метод, балаларның үзлекләреннән эш итүне, шул исәптән, үз теләкләре белән укырга-язарга өйрәнүне алга сөрә.

Укырга-язарга өйрәтүдә МХК тарафыннан Америкада кулланыла торган бөтен сүзләр методы белән эшләргә кирәклек турында күрсәтмә бирелгәч, М. Корбангалиев уку-укыту өлкәсендә бөтен сүзләр методына игътибар итә, әлеге ысул дөрес дигән нәтиҗәгә килә. Аның Р. Шакирова һәм Д. Сафин белән берлектә төзелгән «Балалар бакчасында һәм мәктәпнең хәзерлек классында грамотага өйрәнү өчен беренче китап» дәреслеге нәкъ шушы ысул нигезендә төзелгән. Китапта шулай ук бераз күләмдә язу үрнәкләре дә бирелгән. Әлеге китап белән эшләгәндә, балаларга язу күнекмәләрен өйрәтү өчен, шушы ук авторларның «Грамотага өйрәтү дәфтәре» дә файдаланылырга тиеш.

Нәтиҗәдә, педагоглар «мәктәпкәчә тәрбия йортлары хәреф таныган, уку-язу процесслары белән таныш, уку механизмасын үзләштерә башлаган балалар чыгарырга тиеш. Бу йомгакның эченә ишетеп яза белү, үзеннән чыгарып яза белү, йөгерек укый белү теләкләре керми. Ул эшләр I баскыч мәктәпләрнең үз өсләренә йөкләнә»[72], – дигән фикергә киләләр.

---

юллары // Мәгариф. – 1923. – № 5–6. – 85–88 б.; Балаларның табигый юл белән укырга-язарга өйрәнүләре // Мәгариф. – 1923. – №7–8. – 36–41 б.; Корбангалиев М., Шакирова Р., Сафин Д. Балалар бакчасында һәм мәктәпнең хәзерлек классында грамотага өйрәнү өчен беренче китап. – Казан: Татгосиздат, 1935. – 65 б.

[70] Корбангалиев М. Балалар бакчасындагы һәм балалар йортындагы балаларны укырга-язарга өйрәтү юллары // Мәгариф. – 1923. – № 1. – 44–46 б.

[71] Корбангалиев М. Мария Монтессориның балаларны язарга өйрәтү юллары // Мәгариф. – 1923. – № 5–6. – 85–88 б.

[72] Гали Х. Мәктәпкәчә тәрбия яшендә баланың телен үстерү юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 65 б.

Бу елларда мәктәптә укымаган, ләкин яшьләре 7 дән арткан балалар белән эшләүнең тагын бер төре барлыкка килә. Ул – балалар клублары. Алар балалар бакчалары бинасында кичке сәгатьләрдә оештырылалар. Монда балаларны теге яки бу хезмәт күнекмәләренә өйрәтү эше максат итеп куела. Мәсәлән, үрү, читекчелек һ.б.[73]

Бу елларда мәктәпкәчә тәрбия оешмалары балага тәрбия һәм белем бирүдән тыш, халык арасында агарту-тәрбия эшен алып барырга да ярдәм итәләр. Мәсәлән, кайбер балалар бакчаларында балага гаиләдә дөрес тәрбия бирү буенча түгәрәкләр оештырыла. 20 елларда татар теленең дәрәҗәсе күтәрелүе, коренизация башлану нәтиҗәсендә аналар өчен татар телен өйрәтү дәресләре үткәрелә башлый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар мәгарифе өлкәсендә мәктәпкәчә яшьтәге балалар оешмалары төзү эше яңа юнәлеш булуга карамастан, К.Вәлитова, С.Миңлекәй, М.Мөштәри, М.Ялымова, З.Салихова, М.Корбангалиев, Х.Гали, С.Камал кебек күренекле педагоглар тарафыннан зур эш башкарылган. Алар үзләренең гамәли һәм тәгълимати хезмәтләре белән бу эшенең куелышына һәм таралышына зур йогынты ясаганнар.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен татар педагоглары тарафыннан татар мохитенә якынайтып язылган кулланмалар XX гасырның 30 нчы еллар уртасына кадәр дөнья күрә. 30 нчы еллар уртасында илдә тәрбия һәм белем бирү өлкәсенә дә зур йогынты ясаган яңа сәясәт урнашу белән, барлык әлеге кулланмалардан файдалану мөмкинлеге чикләнә. Моннан соң нәшер ителгән программалар һәм кулланмалар югары органнар тарафыннан расланып, барлык милләт халыклары өчен дә гомуми планда чыгарыла башлый.

### 1.3. Гомуми урта белем бирү мәсьәләләре

Октябрь революциясеннән соң белем бирүнең максат, бурычлары һәм эчтәлеге тамырдан үзгәрә. Татар мәгариф системасына кагылышлы төп яңарышларның берсе булып мәктәпне дини йогынтыдан азат итү тора. Төрле карарлар[74] нигезендә барлык уку йортлары, булган җиһазлары белән, МХК карамагына күчерелә, бер үк бинада

---

[73] Тутаев М.З. Октябрь и просвещение. – Казань, 1970. – С. 234.

[74] «Вөҗдан ирегe, чиркәү һәм дини оешмалар турында»гы декрет (20 гыйнвар 1918 ел), «Чиркәүнең дәүләттән һәм мәктәпнең чиркәүдән аерылуы турында»гы декрет (21 гыйнвар 1918 ел), «Бердәм эш мәктәпләр турында»гы декрет (16 октябрь 1918 ел).

дингә өйрәтү һәм гомуми предметлар укыту кайтгый тыела. Нәтиҗәдә дини мәктәп-мәдрәсәләр ябылырга тиеш була. Ләкин 20 нче еллар башында әле яңа совет мәктәпләре белән параллель рәвештә дини мәктәпләр дә эшләп килә. Моңа берничә сәбәп була. Беренчедән, мәктәпләрне тәэмин итү дәүләт карамагыннан җирле бюджетка күчерелгәч, халык, дин әһелләре басымы астында, укытучыларны һәм мәктәп чыгымнарын каплаудан баш тарта. Шул рәвешле, күп кенә яңа мәктәпләр ябыла. 1924/25 уку елы эчендә беренче баскыч мәктәпләренең 20%ы кыскара: 1923/24 уку елында – 2125 мәктәп булса, 1924/24 уку елына 1968 мәктәп кала. Шул ук вакытта, яңа төр мәктәпләргә күнекмәгән татар халкы, мөмкинлек булган очракта, балаларын абруйлы мулла һәм мөгаллимнәр укыта торган, сыналган мәктәпләргә бирергә тырыша. Икенчедән, мәктәп биналары, уку әсбаплары, әзерлекле укытучылар җитешмәү сәбәпле, дин әһелләре укыту эше белән шөгыльләнүләрен дәвам итәләр. Өченчедән, илдә, бигрәк тә Татарстан җирлегендә, сәяси һәм икътисади шартлар кыенлашу нәтиҗәсендә дингә каршы вәзгыять бераз йомшара төшә. 1923 елның июнь аенда Уфада узган II Бөтенроссия мөселманнар съезды басымы астында хөкүмәт мөселманнар яшәгән өлкәләрдә мәчеттә һәм шәхси йортларда дин белеме бирүне рөхсәт итә. Нәтиҗәдә дини мәктәпләрнең саны саны арта[75]. Мәсәлән, 1925 ел ахырына ТАССРда 240 дини мәктәп исәпләнсә[76], 1926 ел ахырына аларның саны, төрле чыганаклар буенча, 800–1000гә җитә[77]. Бу хәл озак бармый, 1928 елда махсус карарлар нигезендә дини белем бирүне оештыруның һәртөрле формалары юкка чыгарыла. Нәтиҗәдә татарларның гасырлар буе дин нигезләренә таянып алып барылган тәрбия һәм белем бирү системасы бетерелә. Татар милли уку йортлары дәүләт карамагында булган мәктәпләр челтәренә кертелә һәм совет мәктәпләренең төп кагыйдәләренә буйсына башлый. Укыту программаларына дингә каршы көрәш юнәлеше бирелә.

Совет республикасы мәгариф бүлеге хезмәткәрләренә иске мәктәпне үзгәртеп кору эшен чиста биттән башларга туры килми. 1918–1920 еллардагы мәктәп реформасы тулысынча 1915–1916 елларда мәгариф министры граф П.Н. Игнатьев тарафыннан тәкъдим

---

[75] История татар с древнейших времен. В 7-ми томах. Т. VII. Татары и Татарстан в XX – начале XXI в. – Казань, 2013. – С. 362.

[76] Тутаев М.З. Развитие народного образования в Татарии (1917–1940 гг.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С. 56.

[77] История татар с древнейших времен. В 7-ми томах. Т. VII. Татары и Татарстан в XX – начале XXI в. – Казань, 2013. – С. 363.

ителгән урта белем бирү системасын үзгәртеп кору проектына нигезләнеп башкарыла. Революциягә кадәрге проект буенча, берничә баскычтан торган бердәм мәктәп төзү; туган телдә белем бирә торган милли мәктәпләрне үстерү; мәҗбүри рәвештә дини белем бирелми торган дөньяви мәктәп булдыру; гомуми мәҗбүри, түләүсез башлангыч белем бирү; ир һәм кыз балаларны бергә укыту карала[78]. Димәк, мәктәп системасында булган үзгәртеп корулар ихтыяҗы инде революциягә кадәр үк барлыкка килә. Ул революциядән соң тагын да кискенләшә, ә революция, үз чиратында, күптән өлгереп килгән үзгәртеп кору мәсьәләләрен тормышка ашырырга мөмкинлекләр тудыра[79].

Революциянең беренче көннәреннән ук моңарчы эшләп килгән төрле төрдәге мәктәпләр Бердәм эш мәктәпләре итеп үзгәртелә башлыйлар. Декрет[80] нигезендә гомуми мәҗбүри башлангыч белем бирү кертелә. Яңа совет мәгарифенең төп принциплары булып: 17 яшькә кадәр булган барлык балаларга түләүсез һәм мәҗбүри гомуми һәм политехник белем бирү, ир һәм кыз балаларны бергә укыту, һөнәри белем бирүне үстерү, эшче халык балаларына югары мәктәпкә юл ачу, коммунистик идеяләр белән сугарылган педагогик кадрлар әзерләү һ.б. тора. Эш мәктәпләренең нигезен җитештерүчән хезмәт тәшкил итә.

Әлеге декрете буенча, БЭМ ике баскычтан тора: I баскыч – 8 яшьтән 13 яшьтәге балалар өчен (5 еллык); II баскыч – 13–17 яшьлекләр өчен (4 еллык). Халык мәгарифе мәсьәләре буенча узган беренче партия җыелышы илдәге икътисади хәлне яхшырту теләге белән мәктәптә политехник белем бирүне арттыру бурычы куя. Балалар һөнәри белемне иртәрәк алып чыксын өчен урта мәктәп җидееллыкка әйләндерелә. Нәтиҗәдә мәктәп системасында үзгәрешләр була. 1921–22 уку елыннан ТАССРда эш мәктәпләренең түбәндәге төрләре барлыкка килә: 4 еллык уку вакыты белән I баскыч мәктәпләре (8–12 яшь); ике концентрдан торган (4+3) җидееллык мәктәп (8–15 яшь); беренче һәм икенче концентрлардан торган (4+3+2) тугызъеллык мәктәп (8–17 яшь)[81]. I баскыч мәктәпләре –

---

[78] Днепров Э.Д. Четвертая школьная реформа в России. – М.: Интерпракс, 1994. – С. 29.

[79] Шакиров Р.В. Казанская педагогическая школа во второй половине XX в. – Казань: Матбугат йорты, 1999. – С. 38.

[80] «Бердәм эш мәктәпләре турында»гы декрет (1918 ел 16 октябрь).

[81] Тутаев М.З. Развитие народного образования в Татарии (1917–1940 гг.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С. 53.

башлангыч, II баскыч мәктәпләре – урта мәктәп дип санала башлый-лар. Урта мәктәпне тәмамлаган балага һөнәри белем алу йортларына керү мөмкинлеге ачыла.

20 нче елларда сыйныфлар «группалар» дип атап йөртеләләр. Һәр группада балалар саны 25 тән артмаска тиеш була. Балаларны җәзалау тыела, өй эшләре бирелми, экзаменнар системасы бетерелә. Баланың сыйныфтан сыйныфка күчү һәм мәктәпне тәмамлап чыгу мәсьәләләре педсовет карары нигезендә хәл ителә. Эш мәктәп-ләренең һәр баскычында да белем бирү политехник нигездә алып барылырга тиеш була. I баскыч мәктәпләрдә белемне хезмәт белән бәйләп алып бару, ә II баскыч мәктәпләрдә хезмәт күнекмәләрен үстерү таләп ителә. Укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеген арттыру-га, эстетик һәм физик тәрбия бирүгә нык игътибар бирелә. Мәҗбүри рәвештә рәсем, җыр, физкультура дәресләре кертелә.

Совет мәктәбе оешуның беренче елларында, тиешле план һәм программалар, аңлатмалар һ.б. кулланмалар булмау сәбәпле, хөкү-мәт куйган таләпләрнең барысы да укытучыларга тиешенчә аңла-шылып бетми. Мәсәлән, политехник белем бирү мәктәп бинасын җыештыру, җылыту кебек эшләргә кайтып кала. Тәрбия барышында балаларның мөстәкыйльлеген һәм активлыгын арттыру принципла-ры аларга тулысынча ирек бирүгә кайтып кала һәм бу эчке тәр-типнең бетүенә китерә.

20–30 нчы елларны укыту системасында эзләнүләр чоры дияргә кирәк. Бу елларда укытуның традицион предмет системасы ком-плекслы укыту системасы белән алыштырыла, яңа укыту ысуллары кертелә башлый. Гомуми мәгариф өлкәсен үзгәртү һәм яңарту эшендә катнашкан Көнбатыш галимнәре (А.Лай, Д.Дьюи, В.Рейн, Г.Винекен, Е.Паркхерст, Ф.Гансберг һ.б.) әлеге процесска зур йогынты ясый.

Комплекс системасына туры китерергә тырышып «эзләнү», «лаборатор-бригада», «проектлар» методлары кулланышка кертелә. Дәресләр күбрәк экскурсия, конференция, әңгәмә, лаборатор эш формасында алып барыла.

Укучының мөстәкыйль һәм коллектив белән эшләвен берләш-тергән яңа метод – «лаборатор-бригада» методы «Дальтон-план» ни-гезендә тормышка ашырыла. «Дальтон-план» – Америка укытучысы тарафыннан гамәлгә кертелгән метод. Катгый расписанияле сый-ныф-дәрес системасыннан аермалы буларак, ул балаларның лабора-торияләрдә ирекле һәм иҗади эшчәнлегенә таянып төзелә. Аның бу-енча, биремнәр укучының шәхси үзенчәлекләреннән һәм мөмкин-лекләреннән чыгып, көчле, урта һәм йомшак балалар өчен төзелергә

тиеш була. Совет мәктәпләрендә исә шәхси үзенчәлекләр исәпкә алынмый, бер үк төрле биремнәр 4–5 кешедән торган аерым төркемнәргә бирелә. Укучылар һәр фән буенча бер айга бирем алалар. Әлеге биремгә алар мөстәкыйль рәвештә әзерләнәләр. Бу очракта да укытучы читтән күзәтүче ролен үти. Эш нәтиҗәләре буенча тикшерүләр яки конференцияләр үткәрелә. Биремнәр лаборатор-бригада методы нигезендә үтәлсә, бригада башлыгы яки бригаданың һәрбер әгъзасы эшләгән эш буенча доклад ясый. Доклад нәтиҗәсе буенча бөтен бригададагы һәрбер укучыга билге куела.

Америка фәлсәфәчесе һәм педагогы Дж.Дьюи тарафыннан 1920 елларда кертелгән «проектлар методы» шулай ук шактый киң таралә. Аның төп идеясе укучылар тарафыннан махсус биремнәрне (проектларны) практик яктан башкарудан гыйбарәт була.

Яңа методлар мәктәпләрдә 1923 елдан башлап кулланыла башлыйлар. Беренчеләрдән булып әлеге ысулларны сынап караучы, бу ысулларны куллануның теоретик нигезләрен булдыручы – Р.С.Газизов. Аның «Мәгариф» журналында бик еш кына әлеге уку-укыту системасы белән бәйле мәкаләләре басылып тора[82].

Ләкин алга таба әлеге методларның укучыларга системалы белем һәм күнекмәләр бирә алмаганлыгы ачыклана. Укыту яңадан традицион дәрес системасына кайтарыла.

1918 елның 31 октябрендә дөнья күргән «Азчылык милләтләр мәктәпләре турында»гы карар нигезендә мәктәпләргә укытуны үз ана телендә алып бару хокукы бирелә.

Милли мәгарифнең үсеш юллары 1919 елның августында булган Бөтенроссия съездында билгеләнә. Делегатлар арасында һәр милләт үз мәгарифе һәм мәдәните үсешен үзе хәл итәргә тиеш, дигән фикерләр яңгыраса да, мәгариф өлкәсендә тиешле югарылыкка ирешү өчен барлык милләтләрнең берлеге кирәк дип табыла. Милли мәгарифнең интернационализм нигезендә үсәргә тиешлеге раслана[83]. Шулай итеп, совет хөкүмәтенең беренче елларыннан ук мәгариф өлкәсен бердәйләштерү идеяләре алга сөрелә.

Революциядән соңгы елларда яңа мәктәпләр өчен программалар, рус һәм татар телендә дәреслекләр төзү зарурлыгы туа. 1918 елның маенда узган III Бөтенроссия татар укытучылары съездында

---

[82] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 71 б.

[83] Тутаев М.З. Развитие народного образования в Татарии (1917–1940 гг.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С. 11.

Фатыйх Сәйфи-Казанлы әлеге мәсьәләне күтәреп чыга[84]. Нәтиҗәдә, әлеге эшләр белән шөгыльләнү өчен Гыйльми һәйят төзелә. 1920 елдан ул Гыйльми үзәк, ә 1921 елның декабрь аеннан Академик үзәк итеп үзгәртелә. Үзәк берничә комиссиядән тора. Яңа дәреслекләр һәм программалар, уку планнары төзү, педагогик журнал чыгару, Дәүләт гыйльми советы (ДГС, ГУС) программаларын һәм методик принципларын җирле шартларга яраклаштырып уку йортларына тәкъдим итү эшләре белән Академик үзәкнең фәнни-педагогик комиссиясе шөгыльләнә.

ВКП(б)ның XIII съезды карарларында сәяси һәм методик яктан югары сыйфатлы дәреслекләр һәм методик кулланмаларны тиз арада бастырып чыгару төп бурычларның берсе итеп куела[85]. Чөнки алар укучы һәм укытучы эшчәнлеген бәйләүче, берләштерүче төп кораллар һәм бары тик алар ярдәмендә генә белем һәм тәрбия бирүне максатчан, эзлекле итеп алып барырга мөмкин. Ләкин югары сыйфатлы дәреслекләрне тиз арада төзеп, бастырып чыгару мөмкин булмый. Шунлыйктан күпчелек очракта дәреслекләрнең, методик кулланмаларның яңалары төзелгәнче, искеләренең уңышлылары[86] аерым төзәтмәләр, үзгәрешләр белән яңадан басылып, файдалану өчен мәктәпләргә тәкъдим ителә. Мәсәлән, М.Корбангалиевның 1912 елда чыккан «Татар әлифбасы»[87] 1919 елда, берникадәр камилләштерелеп, «Ысулы саутия белән төзелгән рәсемле һәм тәмринле татар әлифбасы» исеме белән сигезенче тапкыр бастырыла. Әлеге әлифбаның тышкы битендә «Эш мәктәпләренең беренче елында укытылырга яраклы» диелә[88]. Г.Ибраһимовның 1919 елда яңадан тулыландырылып басылып чыккан «Яңа әдәбият» китабында идея-эстетик яктан искергән яки сәнгати яктан түбән булган әсәрләрдән өзекләр шул заманны яктыртуга якын торганы белән алмаштырыла. Дәреслектәге әсәрләр укучыларны әхлакый-эстетик яктан тәрбияләү юнәлешендә сайлана.

---

[84] Академический центр Татарии: 1920-е годы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – С.11.

[85] Вәзиева Җ. Совет мәктәпләрендә әдәбият дәреслекләре // Вопросы татарской литературы. Ученые записки. Вып. 106. – Казан, 1972. – 117 б.

[86] Тукай Г. Мәктәптә милли әдәбият дәресләре. – Казан: Мәгариф, 1919. – 112 б.; Ибраһимов Г. Яңа әдәбият. – Казан: Сабах, 1919. – 224 б. һ.б.

[87] Корбангалиев М. Ысуле саутия үзрә тәртип иделмеш татар әлифбасы. Гавам мәктәпе өчен. – Казан, 1912.

[88] Вәлеева Ф.С. Халкына багышланган гомер. – Казан: Мәгариф, 2004. – 31–32 б.



*Казандагы 17 нче мәктәп укучылары һәм директор Г.Рафиков . 1931 ел*

Иске дәреслекләрне үзгәртү белән параллель рәвештә яңаларын булдыру өстендә дә эш алып барыла. Мәсәлән, 1919 елда Г.Рафиковның Ф.Әмирхан белән берлектә чыгарылган «Ана теле» дәреслеге. Әлеге дәреслек I баскыч мәктәпләренең 1–3 уку елы өчен төзелә. Дәреслектәге материаллар, башка дәреслекләрдән аермалы буларак, дидактика кагыйдәләренә туры китерелеп, баланың яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, фикерләү сәләтен һәм, гомумән, шәхесне һәрьяклап үстерүгә нигезләнеп бирелгән. Анда, шул вакыт өчен билгеле булган татар авторларның (Г.Тукай, М.Гафури, Н.Думави, С.Сүнчәләй һ.б.) белем алуга, хезмәткә өнди торган иң яхшы әсәрләре урын алган, үгет-нәсыйхәть бирә торган, әти-әнигә хөрмәт, туган телгә, туган илгә мәхәббәт тәрбияли торган мәкаль-әйтемнәр, экиятләр кертелгән[89]. Шулай ук башка фәннәрдән дә дәреслекләр төзәтелеп бастырылып килә[90].

---

[89] Муртазина Л.Р. Династия Рафиковых. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – С. 16–17.

[90] Корбангалиев М. Хисап мәсьәләләре һәм гадәди мисаллар. VIII басма. Беренче китап. – Казан, 1919; Корбангалиев М. Дөнья. Ибтидаи мәктәпләр өчен тәртип иделмеш җәгърафия рисаләсе. Икенче басма. – Казан, 1918 һ.б.

Гомумән алып әйткәндә, 1918–1920 еллар аралыгында язылган, үзгәртелеп бастырылган дәреслек-хрестоматияләрнең күпчелегенең кимчелекләре булып, педагогик-методик яктан системага салынмыйча, әдәби-теоретик материалларның сыйныфларга бүленмичә бирелүе саналса, әһәмияте булып, укучыларда шул чор турында күзаллаучы әсәрләрне тәкъдим итү, баланы берникадәр сәяси-иҗтимагый яктан тәрбияләүгә хәзерлек тора.

1920 елларда белем бирү системасы төп игътибарны нәзари белем бирүгә генә түгел, ә балада әйләнә-тирәгә кызыксыну уятуга, хезмәт эшчәнлеген, укучының танып-белү активлыгын үстерүгә юнәлдерергә тырыша. Югарыда санап үтелгән таләпләргә туры килгән очракта, программаларның төрлелеге рөхсәт ителә. Шул сәбәпле, совет мәктәпләре оешуның беренче елларында мәктәпләрдә тотрыклы программалар булмый.

1922/23 уку елына Академик үзәк тарафыннан I һәм II баскыч мәктәпләре өчен гомуми дәрес программалары төзелә. Әлеге программалар бу елларда кулланышка керә башлаган комплекслы укыту системасына да, шул ук вакытта традицион предмет системасына да нигезләнеп төзеләләр.

1923 елдан мәгариф системасында хөкем сөргән ирек әкренләп кысыла башлый. Шул елның 18 декабрендә расланган БЭМ уставы буенча укыту программаларының, дәреслек-хрестоматияләрнең күләмен һәм эчтәлеген МХК билгели. Ил күләмендә комплекслы укыту системасы кертелә, укыту программаларының төп нигезен ДГС төзегән программалар тәшкил итә. Комплекс системасында белем бирү сыйныф-дәрес системасыннан баш тарту дигәнне аңлата. Уку фәннәре урынына өч юнәлеш буенча комплекс кертелә: табигать, хезмәт һәм җәмгыять. Комплекс программаларын кертү шул чорда иске мәктәпнең төп кимчелеге булып саналган проблеманы – фәннәрнең тормыш белән бәйләнеше булмау мәсьәләсен хәл итәргә тиеш була.

ДГС программаларының төп юнәлеше булып белем бирүне җәмгыять, партия сәясәте, революцион идеяләр белән бәйләү, бер яссылыктан алып бару тора. Моның өчен балаларны коммунистик, интернациональ рухта тәрбияләү кирәк була. Әлеге бурычларны иҗтимагый фәннәр, шул исәптән тарих, башкарырга тиеш була. Совет власте урнашканнан соң, берникадәр вакыт милли тарихның пропедевтик (башлангыч) һәм төп курсларын өйрәнү дәвам ителә. Әмма тарихны аерым фән буларак уку программасыннан чыгару татар халкы тарихын укытуга да зур тәэсир ясый. Яңа кертелгән җәмгыять белеме курсында (1923/1924 уку елыннан) милли тарихка

караган кайбер темалар гына сакланып кала. «Җәмгыять белеме» курсын укытуда сыйнфый карашка нигезләнгәнлектән, төбәкне (крайны) өйрәнүгә каралган тарихи материал өлеше бик аз була.

Бу чордан алып җәмгыять белеме совет мәктәбенең төп гуманитар фәннәренең берсенә әверелә һәм тарих фәнен тулысынча алыштыра. Татарстанда җәмгыять белеме буенча берничә дәреслек һәм методик кулланма басылып чыга (Гайнуллин Х. Җәмгыятьне өйрәнү; Казаков И. Җәмгыятьне өйрәнү методлары һ.б.). Ләкин 1936 елда, хөкүмәт сәясәте өчен куркыныч фән буларак, әлеге предмет мәктәп программасыннан чыгарыла.

1925 елга Академик үзәк яңа таләпләргә туры китереп, авыл мәктәпләренең беренче ике елы һәм шәһәр мәктәпләренең I баскычы, ә 1926/27 уку елына барлык төр мәктәпләр өчен дә яңа программалар төзеп чыгара. Әлеге беренче программаларның барысы диярлек ДГС программалары нигезендә төзелә, аларның эзлеклелеген һәм идеологик нигезен кабул итә. I баскыч мәктәпләренең өченче уку елы өчен бары тик «Безнең як» темасы гына төшереп калдырылып, Академик үзәкнең үз программасы раслана[91]. Тиздән комплекс системасына нигезләнеп төзелгән дәреслек һәм кулланмалар да дөнья күрә башлый (Корбангалиев М., Газиз Р., Бәдигый Х. Комплекс системасында ана телен укыту; Корбангалиев М., Газиз Р. Комплекс системасында ана телен укыту юллары һ.б.). Бу чор дәреслекләрендә хезмәт күнекмәләре үзәккә алына. Укучыларга төрле эшләр башкару процессында (табигатьне күзәтү, үзләре утырткан орлыкларның исемлеген булдыру, мәктәптә, гаиләдә бер-берсенә ярдәм итү, өлкәннәргә булышу һ.б.) яңа тормышка әзерлек, хезмәт тәрбиясе бирелә[92].

Җәмгыять белеме буенча да беренче комплекс программалары тулысынча диярлек ДГС программаларына туры килә. Программада республика җирлегенә туры килгән бердәнбер «Күрше милләтләр» темасы карала. Ул үз эченә республика халыкларының тормышын, милли бәйрәмнәрен, шөгыльләрен һәм патша вакытындагы дәүләт сәясәтен өйрәнүгә багышлана[93].

---

[91] Академический центр Татарии: 1920-е годы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – С. 36.

[92] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 67 б.

[93] Комплексные программы для школ первой ступени Татреспублики. Сельский вариант. Выпуск первый / Под ред. Г. Линсцера и М. Курбан–Галеева. – Казань: НПК Академцентр, 1925. – С. 74.

1926 елда өченче уку елы өчен авыл мәктәпләре өчен җәмгыять белеме программасы чыга. Шәһәр мәктәпләре өчен аерым программа төзелми, чөнки укытучылар әлеге программаны кирәк чакта үз таләпләренә яраклаштыра алачаклар дип фараз ителә.

Программага шактый күләмле – «Халык составы, аның мәдәни тормышы һәм үзидарә» темасы кертелә, ул «Безнең өлкә» темасы белән берлектә милли мәктәп ихтыяҗларын кәнагәтьләндерергә тиеш була. Монда халыкларның милли һәм сыйнфый составына, өлкәдәге мәгърифәтчелек үсешенә, Көнчыгыш халыклары белән багланышларга, көнкүрешкә, гадәтләргә, аерым милләтләрнең дини карашларына, шулай ук Болгар һәм Казан ханлыкларының тарихына, өлкәне колониальләштерү сәясәтенә, патша хөкүмәтенең дини сәясәтенә һ.б. басым ясала[94]. Болар җәмгыять белеме курсында милли тарихка кагылган темалар буларак каралалар.

Кантоннардагы һәм районнардагы педагоглар тарафыннан әлеге программаларга карата тәнькыйть сүзләре һәм тәкъдимнәр килә башлый. Бу үз чиратында укытучыларның әлеге предмет белән кызыксынуларының һәм эшли башлауларының күрсәткече була. Моннан тыш, Академүзәк тарафыннан программага карата фикерләрне, бәяләмәләрне белер өчен, анкета әзерләнә. Программаның җитешсезлекләре арасында анда материалның артык күп бирелүе, ике соңгы баганадагы материаллар бүленешендә ачыклык һәм төгәллек булмавы күрсәтелә. Шулай ук аерым педагоглар программаның локальләшүенә, җирле материалның аз булуыннан зарлана. Н.Мөхетдинов «На путях к новой школе» журналында бу турыда шактый зур гына мәкалә урнаштыра һәм төп кимчелекләр арасында программаның локальшү ягыннан начар эшләнешен билгели: «Мәктәп белән җирле совет хуҗалыклары һәм иҗтимагый оешмалар яраклаштырылган хезмәтнең конкрет төрләре күрсәтелми. Хезмәтнең бик күп төрләре карала, аларны дәрестә яисә китап аша балаларга җиткереп булмый. Татар программасы бөтенләй уңышсыз эшләнелгән, татарга караган темалар бөтенләй күрсәтелми»[95]. Җәмгыять белеменең 3 нче уку елы программасында тарих һәм хәзерге заман буенча материал бер-берсеннән аерылмыйча кушылып, бербөтен итеп бирелә. Ләкин уку материалы аз конкретлаштырылганлыктан,

[94] Комплексные программы для школ первой ступени Татреспублики: Выпуск второй: Программы для III года обучения / Под ред. Г. Ф. Линсцера и Н.К. Мухитдинова. – Казань: Красный печатник, 1926. – С. 59.

[95] Шунда ук. – С. 105.

13–14 яшьлек балаларга күбесенчә аңлаешсыз була. Моннан тыш, тарихта данлыклы шәхесләр турындагы мәгълүматларның булмавы программаның җитешсез якларыннан берсе булып тора.

Беренче һәм икенче баскыч мәктәпләр программаларын төзүдә һәм укучыларга методик ярдәм күрсәтүдә 1926 елда Көнчыгыш институты каршысында төзелгән «Җәмгыятьне өйрәнү» секциясе зур өлеш кертә. Секция тарафыннан «Бюллетень» дигән методик ярдәмлек чыгарыла башлый. Анда «Җәмгыять белеме укытучысы нәрсә турында сорый» дигән сәхифә ачыла. Әлеге сәхифәдә укытучыларны кызыксындырган сорауларга җаваплар бирелә.

Икенче баскыч мәктәпләрдә җәмгыять белеме программасына нигез итеп ДГС принциплары һәм уку материаллары куела. ТАССРда җәмгыять белеменә, ДГС программаларыннан аермалы буларак, атнага ике сәгатькә күбрәк вакыт (ТАССРда – 12, ДГС программасы буенча – 10 сәгать) бирелә, чөнки Татарстанда бишенче һәм алтынчы уку елына бирәр сәгать артык вакыт карала.

Җәмгыять белеме буенча программалар булуга карамастан, 1928 елның 15–19 июнендә Казанда узган җәмгыятьне өйрәнү методик атналыгында катнашучылар дәресне укытуда күп кенә кимчелекләрне ассызыклыйлар, шуның белән бергә, икенче баскыч мәктәпләрнең беренче концентры өчен җәмгыятьне өйрәнү программаларын яңа баштан төзү кирәклеге искәртелә[96].

1927 елдан бердәм программалар кертелүгә карамастан, 1933 елга кадәр ТАССР программаларында җирле материалны куллануга мөмкинлекләр була[97]. Ләкин программалар, җирле материаллар белән тулыландырылып, күпмедер дәрәҗәдә милли мәктәп таләпләренә җавап бирсә дә, иң беренче чиратта балаларга коммунистик тәрбия бирүгә юнәлдерелә, барлык укыту процесслары марксизм-ленинизм идеяләре нигезендә алып барыла.

Урта мәктәп процессына тарих фәненең мөстәкыйль фән буларак кире кайтарылуы (1934 ел) татар халкы тарихын укытуда мөһим үзгәрешләр кертми. Яңадан кайтарылган системалы тарих курсы вуз программасының иҗтимагый формация курсының гадиләштерелгән вариантын тәшкил итә. Программаның Ватан тарихы бүлегендә

---

[96] Казанда җәмгыятьне өйрәнү методик атнасы (1928 ел 15–19 июнь) // Мәгариф. – 1928. – № 6–7. –138–141 б.

[97] Башлангыч мәктәп өчен җәмгыять белеме һәм тарих программасы. – Казан: Татиздат, 1932. – 88 б.; Җәмгыять белеме. Башлангыч классның 1–4 уку елы программасы. – Казан: Татиздат, 1933. – 35 б.; Урта мәктәп программасы: Җәмгыять белеме (5–7 класслар). – Казан: Татгосиздат, 1935. – 85 б.

СССР халыклары тарихы түгел, ә гомуми Россия тарихы бирелә. Милләтләр үсешенә һәм, аерым алганда, милли тарих материалларын өйрәнүгә урын табылмый.

1921 елның 25 июнендә чыгарылган декрет нигезендә татар теле рус теле белән бер дәрәҗәдә дәүләт теле итеп куела.Ләкин төрле сәбәпләр аркасында (илдәге гражданнар сугышы, икътисади кыенлыклар, Идел буендагы ачлык) татар телен гамәлгә кую мәсьәләсен 1923 елга кадәр тукталып тора.

1923 елда Татарстан республикасында рус теле белән беррәттән, татар теле дә дәүләт теле итеп таныла. Шул елда хөкүмәт тарафыннан Татарстан республикасында татар булмаганнарга татар телен өйрәтү турындагы карар кабул ителгәч, аны барлык мәктәпләрдә, югары уку йортларында системалы рәвештә укыту мәсьәләсе алга куела, дәреслекләр төзү эше башлана. «Мәгариф» («Совет мәктәбе»), «Безнең юл» («Совет әдәбияты»), «Татарстан», «Кызыл Татарстан» кебек газета-журнал битләрендә татар тел белемен яктырткан мәкаләләр зур урын ала, төрле конференцияләрдә тел-әдәбият укыту мәсьәләләре күтәрелә. Галимнәр бу чорны татар теленең чәчәк аткан чоры дип саныйлар[98].

Татар телен дәүләт теле дәрәҗәсендә куллану өчен, әдәби телне билгеле бер нормага салырга да кирәк була. Әлеге эш әдәби телне халык теленә якынайту, «аңлаешсыз» сүзләрдән арындыру, термин-атамалар булдыру юнәлешендә бара[99].

Татар булмаганнар өчен татар теле һәм татарлар өчен рус теле буенча дәреслекләр төзү мәсьәләләре белән күбесенчә М.Корбангалиев, Х.Бәдигый, Р.Газизов Я.Богданович, С.Дәүләтләр шөгыльләнәләр.

XX гасырның беренче яртысында татар мәгарифе өлкәсендә иң актив хезмәт куйган кешеләрнең берсе – М.Корбангалиев. Ул күпкырлы галим, күренекле педагог, методист, тел галиме һәм җәмәгать эшлеклесе. Төрле тип мәктәпләр өчен төрле фәннәр буенча дәреслекләр, кулланмалар төзүче. М.Корбангалиев тарафыннан төзелгән дәреслекләрне түбәндәге төрләргә аерырга мөмкин: әлифба китаплары, уку китаплары, грамматика дәреслекләре, методик кул-

---

[98] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 44 б.

[99] Нәбиуллина Г.Ә. 20–30 нчы елларда татар телен гамәлгә кую проблемалары // Материалы научно-практической конференции «Языковая ситуация в Республике Татарстан: состояние и перспективы» (17 ноября 1998 года). – В 2-х ч. Ч. II. – Казань: Мастер Лайн, 1999. – С. 40–43.

ланмалар, математика һәм география дәреслекләре, татар мәктәпләре өчен рус теле дәреслекләре, татар булмаганнарга татар теле дәреслекләре[100]. Методист тел өйрәтү мәсьәләсендә ана теле белән чагыштырма рәвештә алып барыру принцибын алга сөрә.

М.Корбангалиев укучыларны мәктәптә дөрес укырга һәм язарга өйрәтү методикалары буенча күп кенә дәреслекләр һәм кулланмалар төзи. Ул үзенең эш дәверендә берничә төрле метод белән эш итә. Башта аваз[101], аннан соң бөтен сүзләр[102] һәм соңгы елларда аналитик-синтетик аваз методы[103] белән эшли. Уку-язуга өйрәтү эшен җиңелләштерү максатыннан автор рәсемнәр, шигырь-хикәяләр, уеннар, шакмаклар һ.б.ны файдаланырга кирәклекне хуплый һәм дәреслекләрдә аларны иркен куллана[104]. Укырга-язарга өйрәтүдә кисмә хәрефләрдән файдаланырга тәкъдим итә, һәм кисмә хәрефләр төзеп бастыра[105]. Матур язу күнекмәләренә өйрәткәндә укучының дөрес утыруына игътибар итәргә тәкъдим итә. Граммоталы язарга өйрәтүдә имля, күчереп язу, ятлаганнарны язып карау кебек эш алымнарына да туктала, сүзлек белән эш итү күнекмәләренә өйрәтергә кирәклегенә басым ясый[106].

Татар булмаганнарны татар теленә өйрәтү буенча яшь һәм белем, үсеш дәрәҗәләрен искә алып, программа таләпләренә туры китерe төзелгән төрле дәреслекләр дөнья күрә (Корбангалиев М., Бәдигый Х. Рус мәктәпләре өчен татар теле дәреслеге (1924); Корбангалиев М., Бәдигый Х. Җанлы сөйләү теле сабаклары (1924); Грамматика татарского языка в сравнении с грамматикой русского языка» (1924), Корбангалиев М., Газизов Р. «Русларга татар телен өйрәтү өчен кулланма һәм дәреслек» (1925), «Комплекс системасында ана теле укыту юллары» (1926), Корбангалиев М.Х., Газизов Р.С. Татарлардан башкаларга татар теле дәреслеге: 1 нче кис.

---

[100] Вәлеева Ф.С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевның татар телен укыту методик системасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 31 б.

[101] Корбангалиев М. Ана теле методикасы. – Казан, 1918.

[102] Корбангалиев М., Газизов Р., Бәдигый Х. Комплекс системасында ана телен укыту юллары. – Казан, 1926.

[103] Корбангалиев М. Укырга-язарга өйрәтү методикасы. – Казан, 1940.

[104] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 44 б.

[105] Вәлеева Ф.С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевның татар телен укыту методик системасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 38 б.

[106] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 50 б.

5 нче уку елы өчен (1931) һ.б.). Аларда «татар сүзләрен дөрес әйтергә күнектерүне һәм татар авазларын дөрес тотып калуны тәэмин итү максаты белән, җанлы сөйләү дәресләре, аннан соң алфавит белән таныштыру һәм татар теленең төп грамматик формалары белән таныштыру дәресләре, күнегүләр өчен мисаллар, уку текстлары бирелә. Таныш булмаган сүзләрнең тәрҗемәсе, кагыйдәләр бирелә»[107]. Әлеге дәреслекләрдә шулай ук укытуны тормыш белән бәйләп алып баруга, укучыларны зур тормышка әзерләүгә игътибар бирелә: бер-береңә ярдәм итү, хезмәтне ярату, өлкәннәрне хөрмәт итү, үзеңне чиста тоту, сәламәт балалар тәрбияләү һ.б.[108]

Гомумән алганда, 1920–1930 елларда чыккан татар теле дәреслекләренең күбесендә марксистик идеология үткәрелә һәм төрле лозунглар, плакатлар, бирелгән текстлар аркылы теге яки бу мәсьәләне пропагандалау сизелеп тора[109].

Комплекс системасы чорында укыту эше, ел вакытына карап, аерым триместрларга бүленә. Әлеге система нигезендә укучыларга уку барышында тулысынча диярлек мөстәкыйльлек бирелә. Укыту процессының төп методы булып «эзләнү» методы кулланыла башлый. Бу метод белән укыту күбесенчә төрле экскурсияләр, лаборатор эшләр, конференцияләр, диспутлар формасында алып барыла. Укучылар үзләре тема сайлап, төрле чараларга мөстәкыйль әзерләнәләр. Мондый мөстәкыйль эшчәнлек нигезендә укучылар уку әсбаплары, фәнни әдәбият белән эшләү күнекмәләренә өйрәнәләр. Яңа метод, бер яктан, укучыларны үзлекләреннән эшләргә өйрәтсә, икенче яктан, укытучының ролен киметә. Әлеге чараларда укытучы читтән күзәтеп тора, кирәк булса, киңәш биреп торучы булып кына кала.

«Дальтон-план» методы егерменче елларда педагоглар тарафыннан дөрес метод дип танылган һәм киң кулланылышта булган. Мәсәлән, М.Корбангалиев география дәресендә ерак төбәкләрне һәм ерак илләрне өйрәнү темасын үткәндә түбәндәгечә эшләргә тәкъдим итә: «Балаларга бер эш бирелә. Алар шул эшне эшләргә план төзиләр. Эшне үтәгәндә хезмәтне билгеләү әсасында коллектив рәвештә үтиләр. Бу вакытта аларга китап, газет, мәкалә, харита (карта) һәм башкалар кебек ярдәмлекләр бирелә һәм алар шулар буенча әзер-

---

[107] Вәлеева Ф.С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевның татар телен укыту методик системасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 47 б.

[108] Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы. – Казан: Ихлас, 2012. – 70 б.

[109] Шунда ук. – 69–70 б.

ләнеп бирелгән эшне үзлекләреннән башкаралар. Хисап бирү җыелышларында аларның һәрберсенең эше тыңлана һәм шуннан соң уртак бер рәсем (картина) килеп чыга. Программаның «Хәзерге заманның зур мәмләкәтләре һәм аларның колонияләре» дигән бүлеген шул юл белән үтәргә мөмкин. Менә бу сөйләгәннәребездән 4 нче уку елының җәгърафия материалларын үткәндә «Дальтон-план» буенча үтәү уңайлы булачагы үзеннән-үзе күренеп тора»[110].

Ләкин әлеге система укытучының ролен төшерүгә, укытуның шәхсилек принцибын бозуга, күп укучыларның тырыш, кызыксынучан иптәше «артына качуына» китереп чыгара[111].

Укыту комплекс системасы нигезендә алып барылган очракта, фән аерым бер предмет буларак түгел, ә башка предметлар белән берлектә, бирелгән теманы ачыклар өчен кулланыла. Мәсәлән, әдәбият фәне теге яки бу һөнәрне үзләштерүдә иллюстрация ролен үтәүче итеп кенә тәкъдим ителә. Укыту «лаборатор-бригада методы» белән алып барыла. Бу методка нигезләнеп язылган татар әдәбиятын укыту программаларында[112] әдәбият җәмгыятьне өйрәнү фәненең бер өлеше буларак кына бирелә, ягъни иҗтимагый теманы өйрәнгәндә әдәбият иллюстратив материал булып кына хезмәт итә. Әдәбият фәненә мондый мөнәсәбәт әдәби әсәрләр белән индивидуаль эшләү, үз фикереңне җиткерү кебек алымнарны арткы планга куя.

Комплекс системасын куллану балаларга тиешле дәрәҗәдә белем бирүне булдыра алмый. Күп очракта укытучылар комплекс системасын куллана белмиләр. Көчле укытучы программалардан заман таләп иткән кирәкле материалны сайлап ала алса да, күпчелек укытучыларга мондый сәләт бирелми. Нәтиҗәдә укучылар тиешле белем ала алмыйлар.

1923/24 уку елыннан авылларда җидееллык колхоз яшьләре мәктәпләре (ШКМ) оештырыла. Әлеге мәктәпләрдә укыту планнарына гомуми дәресләр белән бергә агрономия, бакчачылык, умартачылык һ.б. авыл-хуҗалыгында кирәкле һөнәрләрнең нигезләре би-

---

110 Корбангалиев М., Исхаков Х. Җәгърафия дәреслеге. – Казан: Татиздат, ТССР, 1925. – 5 б.

111 Шакиров Р.В. Казанская педагогическая школа во второй половине XX в. – Казань: Изд-во «Матбугат йорты», 1999. – С. 40.

112 Программалар. Казан педагогия техникумының беренче курслары өчен / Төз. Х.Бәдигый. – Казан, 1925. – 73 б.; Программалар. Өч еллык крестьян мәктәпләре өчен / Төз. М.Фазлуллин. – Казан, 1926. – 73 б.; Икенче баскыч татар һәм башкорт мәктәпләре өчен / Төз. В.Хангильдин, С.Ямалиев. – Казан, 1926. – 36 б.

релә. Укыту программалары ике юнәлеш буенча төзелә: беренчесе – җир эшкәртү, икенчесе – терлекчелек. Ә эшче районнарда һәм шәһәрләрдә фабрика-завод җидееллыклары ачыла. Аларның укыту программаларында физика, химия, математика фәннәрен җитештерүгә бәйләп укыту карала. Программалары химия җитештерүе, механик җитештерү, агач эшкәртү һәм җепсел матдәләрне эшкәртү юнәлешләрендә төзелә[113]. Бу мәктәпләр өчен программалар төзү эше шулай ук Академик үзәккә йөкләнә.

1927 елдан колхоз яшьләре мәктәпләре сигезьеллык итеп үзгәртелә. Коллективлаштыру сәясәте башлангач, колхоз яшьләренең кичке мәктәпләре оештырыла башлый. Аларга I баскыч мәктәпләренең II классын тәмамлаучылар кабул ителә, ә уку вакыты 2 ел була.

1927 елда МХК яңа программалар төзеп чыгара. Бу программалар барлык СССР мәктәпләре өчен дә бердәм дәүләт программалары була. Алар буенча укучы белергә тиешле белем һәм күнекмә минимумнары күрсәтелә, ә мәктәп җитәкчеләре дәүләт алдында аларның үтәлеше өчен җавап тоталар[114].

Алда санап үтелгән методлар шул елларда эшләгән укытучылар тарафыннан да уңай кабул ителми[115]. ВКП(б) ҮКның 1932 елның 25 августы карары нигезендә лаборатор-бригада методы гамәлдән чыгарыла[116]. Әлеге карарда «укытуның бер методы да камил һәм төп метод була алмый», диелә. Укытуның төрле методларын кулланып, һәр укучы да катнаша ала торган дәрес алып барырга тәкъдим ителә[117].

20–30 елларда татар мәгарифенә йогынты ясаган мәсьәләләрнең берсе – татар язуының ике тапкыр үзгәреш кичерүе, ягъни гарәп язуының латинга, ә соңга таба кириллицага күчерелүе.

Галимнәр фикеренчә, гарәп язуын латин графикасына күчерү фикере татар зыялылары арасында, җәдитчелек күренеше буларак,

---

[113] Академический центр Татарии: 1920-е годы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – С. 38.

[114] Фасхутдинова Е.Н. Учительство Казанской губернии / ТАССР в 1918 – начале 1930-х годов (по архивным документам): дис. ... канд. ист. наук. – Казань, 2008. – С.48–53.

[115] Сәхәбетдинов М. Ул еллар истәлеге // Совет мәктәбе. – 1967. – №11. – 55–56 б.

[116] Муртазина Л.Р. Педагогический анализ деятельности ликбезов (на примере Республики Татарстан). – Казань: Печатный двор, 2002. – С. 80.

[117] Гибатдинов М.М. Преподавание истории татарского народа и Татарстана в общеобразовательной школе: история и современность. – Казань: Алма-Лит, 2003. – С. 52–53.

гасыр башында ук туа. Октябрь революциясеннән соң, 1919, 1920, 1924 елларда, татарларның язуын һәм орфографиясен үзгәртү мәсьәләсенә кагылышлы бик күп конференцияләр, корылтайлар уздырыла. Ләкин латинга күчү буенча карар кабул ителми. Моның урынына гарәп язуын камилләштерү өстендә эшлиләр[118].

Республикада татар алфавитын латинлаштыру 1926 елның февраль аенда Бакуда уздырылган Беренче тюркология съездында карала. Әлеге мәсьәлә буенча делегатлар икегә бүленә. Ш.Усманов, С.Атнагулов һәм Ф.Сәйфиләр яналифны кертүне тизләтүне таләп итәләр. Ә Г.Ибраһимов һәм Г.Шәрәфләр әлеге мәсьәләдә ашыкмаска чакыралар, чөнки гарәп графикасын үзгәртү татар халкының күп гасырлардан бирле җыелып килгән язма мирасын бер мизгел эчендә юкка чыгаруга китерәчәк дип саныйлар[119]. Алга таба латин графикасына каршы чыгучылар «милләтчелектә» гаепләнәләр.

Күп кенә татар зыялыларының яналифка күчүгә каршы булуларына карамастан, 1927 елда яналиф рәсми рәвештә татар алфавиты буларак кабул ителә. Яңа алфавит белән укытуга күчү техникумнарга, II баскыч мәктәпләргә, МХК оештырган татар теле укытучыларын хәзерләү курсларына 1927/28 уку елыннан[120], ә татар телендә белем бирүче башлангыч мәктәпләргә 1928/29 уку елыннан[121] кертелә башлый. Башлангыч мәктәпләрдә укыту беренче елларда гарәп

---

[118] Языковая политика в Республике Татарстан: Документы и материалы: 20–30-е гг. // Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар: 20–30 нчы еллар / Төз. З.Г. Гарипова, Ф.Ф. Исламов, К.М. Миннуллин. – Казань: Магариф, 1998. – С. 8.

[119] История татарского народа (XX – начало XXI вв.): учеб. пособие для 11 кл. сред. общеобразоват. шк. с рус. яз. обучения (профильный уровень) / А.Г. Галлямова, М.М. Гибатдинов, А.Ш. Кабирова. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 49.

[120] Постановление ЦИК и СНК ТССР от 3 августа 1927 г. // Языковая политика в Республике Татарстан: Документы и материалы: 20–30-е гг. // Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар: 20–30 нчы еллар / Төз. З.Г. Гарипова, Ф.Ф. Исламов, К.М. Миннуллин. – Казань: Магариф, 1998. – С. 172–173.

[121] Постановление ЦИК и СНК ТССР «О мероприятиях по введению латинского шрифта татарской письменности» от 8 февраля 1928 г. // Языковая политика в Республике Татарстан: Документы и материалы: 20–30-е гг. // Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар: 20–30 нчы еллар / Төз. З.Г. Гарипова, Ф.Ф. Исламов, К.М. Миннуллин. – Казань: Магариф, 1998. – С. 173–174.

алфавиты белән параллель рәвештә алып барыла. Латинга күчү процессы 1931 елда тәмамлана[122].

1930 елның 25 июлендә 1930/31 уку елыннан СССР территориясендә гомуми мәҗбүри белем бирүне кертү турында карар чыга. Карар политехник белем бирүгә, укытуны җитештерүчән хезмәт белән бәйләп баруга тагын да нык басым ясый. Нәтиҗәдә, шәһәрдәге барлык мәктәпләр, ШКМ һәм авылдагы күпчелек мәктәпләр фабрика-завод оешмаларына, колхоз һәм совхозларга, МТСларга беркетеләләр.

1930 елда Мәскәүдә уздырылган I Бөтенроссия политехник съезды политехник белем бирү буенча күптөрле тәкъдимнәр белән чыга. Алар арасында югарыда әйтелгән чаралардан тыш, укыту программаларына җитештерү турында курслар кертү, җитештерүчән хезмәт буенча остаханәләр һәм лабораторияләр ачу һ.б. була.

Һәр дәресне җитештерүчән хезмәт белән бәйләп алып бару төп бурыч булып тора. Мәсәлән, география дәресендә хезмәт турында бүлек бөтен курсның иң мөһим бүлекләреннән санала. Аны укытканда, экскурсия һәм тикшеренүләрдән тыш, җитештерүчән хезмәт белән дә бәйләргә тәкъдим ителә. Һәрбер мәктәпнең үз җире булырга тиеш; бу җирдә балалар җир эшләре белән танышалар, үзләре ул эшләрне башкаралар. Бу очракта мәктәпнең халык өчен файдасы зур булачак[123]. Мәсәлән, 1918 елда Казан шәһәренең Мещанская урамында ачылган И.М.Гаспринский исемендәге мәктәп соңрак I һәм II баскыч җидееллык тәҗрибә-үрнәк мәктәбе итеп үзгәртелә. Анда, беренчеләрдән булып, политехник белем бирү кертелә, слесарьлык, балта эше, кисү-тегү, оек бәйләү остаханәләре ачыла, кооперация предметы укытыла. Мәктәп янында җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчасы булган тәҗрибә участогы оештырыла. Анда укучылар үзләренең биология, хезмәт дәресләрендә алган белемнәрен ныгыталар, хезмәт тәрбиясе алалар[124].

---

[122] Языковая политика в Республике Татарстан: Документы и материалы: 20–30-е гг. // Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар: 20–30 нчы еллар / Төз. З.Г. Гарипова, Ф.Ф. Исламов, К.М. Миннуллин. – Казань: Магариф, 1998. – С. 8.

[123] Корбангалиев М., Исхаков Х. Җәгърафия дәреслеге. – Казан: Татиздат, ТССР, 1925. – 6 б.

[124] Мортазина Л.Р. Казанда И.М.Гаспринский исемендәге мәктәп // Крымское историческое обозрение. – 2015. – № 2. – 330–331 б.



*Казандагы И.Гаспринский исемендәге мәктәпнең укытучылары һәм укучылары. 1920 ел*

Егерменче еллар ахырына таба илдәге сәясәт әкренләп үзгәрә башлый. Үзгәрешләр мәгариф өлкәсенә дә үтеп керә. Октябрь революциясеннән соң мәктәп системасында үткәрелгән күптөрле тәҗрибәләр үзләренең тискәре нәтиҗәләрен күрсәтә башлыйлар. Мәктәпнең системасыз, төпле булмаган белем биргәнлеге ачыклана. Җитештерүчән хезмәтнең югарыда санап үтелгән чаралары тәгълимати яктан кызыклы булып тоелсалар да, гамәли яктан мәктәпнең ролен, белем бирүнең сыйфатын төшерүгә китерә. Күп очракта укучылар хезмәтен тиешсез куллану очраклары күзәтелә.

Нәтиҗәдә, 1931 елда ВКП(б) ҮКның мәктәпнең барлык кимчелекләрен күрсәткән «Башлангыч һәм урта мәктәп турында»гы карары дөнья күрә. Карар нигезендә мәктәп өстеннән дәүләт тикшерүе көчәя. 1932 елның 1 гыйнварында системага салынган белем бирүгә нигезләнелгән яңа укыту программаларына күчү башлана. Карарда коллективлык идеяләренә зур игътибар бирелә. Социалистик ярышларда актив катнашуга басым ясала. Хәрби-патриотик, дингә каршы тәрбия чаралары пропагандалана. Хезмәт укытуның максаты түгел, ә белем бирү чарасы гына икәнлеге ассызыклана. Хезмәт дәресләрен укыту өчен мәктәптә остаханәләр, эш бүлмәләре булдыру тәкъдим ителә.

30 нчы елларда дәреслекләр өстән билгеләнгән кешеләр тарафыннан төзелә, күбрәк авторлар коллективына өстенлек бирелә. 1931 елның 20 декабрендә узган дәреслекләр мәсьәләсенә багыш-

ланган конференциядә элекке дәреслекләрнең төп кимчелекләре итеп: дәреслекләрдә агымдагы сәяси моментларның йомшак бирелүе; аларның тел ягыннан яхшы эшләнмәгән, балалар өчен авыр аңлаешлы булулары күрсәтелә. Татарстан тарафыннан чыгарылган дәреслекләр СССРның татарлар яшәгән почмакларының һәркайсында кулланылу сәбәпле, Татарстанда төзелә торган дәреслекләр Татарстан шартларына гына карап төзелмичә, бәлки Урал, Донбас һәм Түбән Идел буйларында яшәүче татарлар өчен дә яраклы итеп эшләнергә тиеш диелә[125].

Ләкин 1930 елларның беренче яртысында дөнья күргән карарлар нигезендә өлкә һәм милләт үзенчәлекләренә карамыйча, илдәге бөтен мәктәпләрнең укыту барышын бердәйләштерү процессы башлана. 1933 елдан ВКП(б) ҮКның «Башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен дәреслекләр турында»гы карары нигезендә СССР территориясендә һәр предмет буенча МХК тарафыннан расланган бердәм мәҗбүри дәреслекләр буенча гына укытырга рөхсәт ителә. 20–30 еллар башында киң таралган «эш китаплары» һәм «сибелмә» дәреслекләр кулланыштан алына. Шул вакыттан алып татар мәктәпләрендә фәкать хөкүмәт тәкъдим иткән, күпчелек очракта рус телендәге дәреслекләрнең тәрҗемәләре генә кулланыла башлый. Бу бигрәк тә математика, физика, химия дәреслекләренә кагыла. Үзгәрешләрне МХК раслаган очракта гына кертергә мөмкин була. Ләкин 1935 елдан мондый мөмкинлек тә бетерелә. Барлык мәсьәләләр ВКП(б) ҮК яки СССР ХКС тарафыннан хәл ителә. Төбәкләргә үзлекләреннән дәреслекләр чыгару тыела. Һәр эш бердәм стандарт нигезендә башкарыла. Хәтта дәреслекләрнең тышлыклары, күләме һәм шрифтлары бердәм стандартка туры килергә тиеш була. 30–40 елларда укыту системасында эзләнү методы бөтенләй юкка чыгарыла. Укучының ялгыш фикер әйтүен булдырмас өчен, дәрестә проблемалы мәсьәләләр куелмаска тиеш була. Шулай итеп, 30–40 елларда укучыларның мөстәкыйль эшчәнлекләре, активлыкларын үстерү кискен рәвештә кими. Һәм мәктәп тормышында мондый халәт 50 еллар ахырына кадәр дәвам итә.

1933/34 уку елы башындагы август киңәшмәсе материаллары да үзенең яңа таләпләре белән алдагы еллардан нык аерылып тора. Беренче тапкыр укытучыдан дәреснең җентекле планы һәм конспекты сорала. Укытучыга дәрескә әзерләнү буенча 12 пункттан торган

[125] Татарстан МХК һәм Татиздат чыгарган дәреслекләр конференциясе материаллары. – Казан: Татиздат, 1932. – 4 б.

кагыйдәләр чыгарыла. Дәресне ничек алып бару турында күрсәтмәләр бирелә һәм дәрес бары тик шуның нигезендә генә алып барылырга тиеш була. Әлеге материалларда укучының мөстәкыйль эшчәнлеге, эзләнү методы турында бер генә сүз дә әйтелми. Мәктәпнең барлык эшчәнлеге, шул исәптән укыту методикасы да, бердәм стандартларга яраклаштырыла[126]. Үзәкләштерү процессы мәктәп җитәкчелеген дә әйләнеп узмый. 1934 елдан мәктәп җитәкчеләре директорлар дип йөртеләләр. Һәр директор, хәтта бик кечкенә авыл мәктәбе җитәкчесе дә, Мәскәүдә раслана.

Тәкъдим ителгән дәрес планы акрынлап бердәм формага кертелә һәм традицион дәресне хәтерләтә башлый. Әлеге форманың үтәлеше инспектор тарафыннан тикшерелеп тора. Әлбәттә укытучы дәресләрдә үз методларын да куллана ала, ләкин бу бер-ике дәрестән ерак китми. Гадәттә дәрес тәкъдим ителгән бер үк формада бара: дәрес башында укучыларның өй эшләрен тикшерү, укытучы тарафыннан яңа теманы аңлату, яңа теманы ныгыту һәм өй эше бирү.

1934 елдан ил күләмендә бердәм гомуми белем бирү системасы төзелә. Аның нигезендә башлангыч (4 еллык), тулы булмаган урта (7 ел) һәм урта (10 ел) мәктәпләр оеша.

Бердәм мәктәп челтәрен төзүдә 1935 елның 3 сентябрь карары зур роль уйный. Ул уку елының башлану һәм тәмамлану вакытларын, көнлек дәрес санын, балаларны мәктәпкә кабул итү тәртибен, белемнәрне бәяләүнең 5 баллы системасын һ.б. кабул итә.

Утызынчы еллар ахырына таба хезмәт тәрбиясенә караш үзгәрә. Белем бирүне фәнни нигездә алып бару максаты куелган гомуми белем бирү мәктәпләреннән хезмәт дәресләре алып ташлана. 1937 елда мәктәп яны остаханәләре һәм эш бүлмәләре ябыла[127].

Татар мәктәпләрендә укытуны ана телендә алып бару белән беррәттән, милли мәгариф өлкәсендә берничә гасырдан бирле борчыган мәсьәләләрнең берсе булган татар мәктәпләрендә рус теле укыту мәсьәләсе бу дәвердә дә үзенең актуальлеген югалтмый. ДГС программалары нигезендә татар мәктәпләренең икенче уку елыннан рус теле дәресләрен предмет буларак мәктәп программасына кертү тәкъдим ителсә[128], 1938 елда чыккан ВКП(б) ҮК һәм СССР ХМС

---

[126] Материалы к августовской учительской конференции 1933–34 года. – Казань, 1933. – С. 8–11.

[127] Солтанбеков Б. Киң колач белән социализм төзү чорында Татарстан мәктәпләре // Мәгариф. – 1967. – № 4. – 7 б.

[128] Тутаев М.З. Развитие народного образования в Татарии (1917–1940 гг.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – С. 60–61.

карары милли республикаларда һәм өлкәләрдә рус телен укытуны мәҗбүри итеп куя.

Йомгак ясап әйткәндә, бу чор татар мәгарифенең гомумроссия дәүләт мәгарифе составына кертелгән, милли мәктәпләр киң таралыш алган һәм тел сәясәте мәсьәләләренә иң күп игътибар бирелгән чор. Ләкин алга таба идеологик басым һәм интернационализм идеяләренең көчәюе нәтиҗәсендә илдә бердәйләштерү һәм бердәмләштерү процесслары башлана, милли үзенчәлекләрне яктыртуга мөмкинлекләр тарая.

### 1.4. Педагогик кадрлар хәзерләү мәсьәләсе

Октябрь революциясеннән соң мәгариф өлкәсендәге мөһим мәсьәләләрнең берсе булып татар мәктәпләре өчен педагогик кадрлар әзерләү тора.

Әлбәттә, совет власте урнашуның беренче елларында татар мәктәпләрендә милли мәктәп-мәдрәсәләрне тәмамлаган мөгаллим һәм мөгаллимәләр укыта. Моннан тыш, кайбер милли уку йортлары укытучылар хәзерләү семинарияләре һәм институтлары итеп үзгәртелә. Аларның укыту программаларыннан дини фәннәр алынып, «социализм тарихы», «Совет дәүләтенең төп законнары», «социология» кебек идеологик характердагы фәннәр кертелә[129]. 1896 елда ачылган Л.Хөсәения мәктәбе 1917/18 уку елында татар хатын-кыз укытучылар семинариясе буларак эшли башлый[130]. Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе нигезендә Халык мәгарифенең татар институты (ТИНО) оештырыла[131] һ.б. Шулай ук ҮБК һәм ХКСның 1936 ел 10 апрель карары нигезендә Л.Хөсәения мәктәбен тәмамлаган укытучыларга башлангыч мәктәп укытучысы хокукы бирелә[132].

---

[129] Мингазов Р. Становление и развитие системы естественнонаучного образования в татарской национальной педагогике. Научно-методическое пособие для учителей, аспирантов и исследователей. Кн.1. – Казань: Дом печати, 2001. – С. 87.

[130] Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / Төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. – Казан: Җыен, 2012. – 330 б.

[131] Гибатдинов М.М. Преподавание истории татарского народа и Татарстана в общеобразовательной школе: история и современность. – Казань: Алма-Лит, 2003. – С. 38.

[132] Ләбибә Хөсәенова тарафыннан ачылган беренче татар кызлар мәктәбе. Отдел рукописей и редких книг Научной библиотеки им. Н.И.Лобачевского КФУ, ф. 2391, ед. хр. 1, л. 23.

СССР МС һәм ВКП(б) ҮКның 1948 ел 10 февраль карары нигезендә Совет хакимияте тарафыннан революциягә кадәр эшләп килгән тагын кайбер милли уку йортлары педагогик училищеларга тиңләштереләләр, аларны тәмамлаучыларның педагогик хокуклары танылa. Бу исемлеккә Казан шәһәрендәге «Мөхәммәдия» һәм «Касыймия», Уфадагы «Галия» һәм Госмания», Оренбургтагы «Хөсәения», Троицктагы «Рәсүлия», Иж-Бубыйдагы «Бубый» мәдрәсәләре керә[133].

Ләкин «Динне дәүләттән һәм мәктәпне диннән аеру турындагы» декрет нигезендә дини мәктәп укытучыларының бер өлеше мәктәп һәм укыту эшеннән читләштереләләр. Нәтиҗәдә, татар мәктәпләрендә эшләргә укытучылар җитми. Яңа таләпләр буенча, укытучылар тиешле дөньяви белем бирү осталыгыннан тыш, яшь буынга заман таләпләренә туры килерлек тәрбия бирергә, яңа төр мәктәпләр оештыра һәм яңа җәмгыять, ягъни коммунистик идеяләргә корылган совет җәмгыяте, төзи алырга тиеш булалар. Шулай итеп, мәгариф системасы алдына элеккеге укытучыларны яңадан укыту, белемнәрен күтәрү һәм яңа педагогик кадрлар хәзерләү бурычы килеп баса.

Совет хакимиятенең беренче елларында хөкүмәт вәкилләре һәм укытучы кадрлар арасында төрле аңлашмаучанлыклар килеп чыга. Беренчедән, укытучыларның күпчелеге мәгариф өлкәсендә булган яңарышларны кабул итә алмый. Мәсәлән, ир һәм кыз балаларның бергә укулары, укыту программаларыннан дини фәннәрне алу һ.б. Ләкин алга таба әлеге үзгәрешләрне танырга мәҗбүр булалар. Икенчедән, яңа хөкүмәт вәкилләре укытучы кадрларны, иң беренче чиратта, халыкны агитацияләүдә, яңа социаль җәмгыять төзү идеяләрен таратуда үзләренең ярдәмчеләре итеп күрәләр. Укытучылар исә, үзләре дә әлеге идеяләр белән тиешле дәрәҗәдә хәбәрдар булмаганлыктан, хөкүмәт органнарының ышанычын тулысынча аклый алмыйлар. Шуңа күрә укытучыларны контрреволюцион эшчәнлектә, профессиональ дәрәҗәсенә туры килмәүдә гаепләүләр арта. Әлеге сәбәпләр аркасында укытучылар саны тагын да кими[134].

Хөкүмәт тарафыннан педагогик кадрлар хәзерләү эше параллель рәвештә берничә юнәлештә алып барыла. Бу конференцияләр, съездлар, семинарлар уздыру, төрле төрдәге курслар оештыру, урта һәм югары педагогик белем бирүне җәелдерү һ.б.

---

[133] Гимазова Р.А. Просветительская деятельность Нигъматуллиных-Буби (конец XIX – начало XX вв.). – Казань: Печатный двор, 2004. – С. 56–57.

[134] Фасхутдинова Е.Н. Учительство Казанской губернии / ТАССР в 1918 – начале 1930-х годов (по архивным документам): дис. … канд. ист. наук. – Казань, 2008. – С. 21–29.

Урта һәм югары белемле яңа укытучылар хәзерләп чыгару билгеле бер вакыт дәвамлыгы таләп иткәнлектән, беренче елларда күптөрле кыска вакытлы курсларга өстенлек бирелә. Алар укытучыларның җәйге яллары вакытында төрле шәһәрләрдә, өяз, кантон үзәкләрендә оештырылалар. Аларда лекция укырга педтехникумнарда һәм югары уку йортларында эшләгән шул заманның күренекле шәхесләре чакырыла. Мәсәлән, Минзәлә өязендә оештырылган шундый курсларда С.Камал, В.Хангильдин һәм башкалар укыта[135]. Шулай ук өч айлык, алты айлык курслар да оештырыла.

1919 елда РСФСР ХМК тарафыннан берьеллык укытучылар курслары ачу турында карар чыга[136]. Аның нигезендә курска 17 яше тулган яшьләр кабул ителә. Алардан бернинди дә диплом һәм аттестатлар да таләп ителми, бары әңгәмә нигезендә гомуми белем дәрәҗәләре генә ачыклана. Мондый курслар нинди дә булса аерым юнәлеш буенча ачыла. Мәсәлән, Арчада мөселман педагогия курслары, Пановка авылында мәктәптән тыш белем бирү буенча кыска вакытлы курслар[137] һ.б.

Мәгариф системасында яңа мәктәпкәчә тәрбия челтәре булдырылгач, аларны белемле тәрбиячеләр белән тәэмин итү зарурлыгы туа. Тәрбиячеләр хәзерләү буенча беренче курслар Югары хатын-кызлар курслары каршында оеша. Анда I баскыч мәктәпләреннән яшь укытучылар җибәрелә. 1919–20 елларда татар һәм башка рус булмаган милләт вәкилләреннән тәрбиячеләр хәзерләү буенча Казанда алты айлык, Чистай, Спас, Чабаксар, Зөя өязләрендә өч айлык курслар ачыла[138]. Алга таба да тәрбиячеләр хәзерләү башлыча кыска вакытлы курслар аша алып барыла.

1922 елдан Академик үзәк тарафыннан Казан, Чистай һәм Алабуга шәһәрләрендә 3 айлык җәйге педагогия курслары булдырыла.

1923 елның гыйнвар аенда Казанда узган I баскыч мәктәп укытучылары конференциясе укытучыларның белем дәрәҗәләре түбән

---

[135] Культурная революция в Татарии (1917–1937 гг.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – С. 113.

[136] «Положение о временных годичных курсах для подготовки учителей для единой трудовой школы».

[137] Фасхутдинова Е.Н. Учительство Казанской губернии / ТАССР в 1918 – начале 1930-х годов (по архивным документам): дис. … канд. ист. наук. – Казань, 2008. – С. 151.

[138] Корнеева М.С. Очерки по истории общественного дошкольного воспитания в ТАССР (1917–1941 гг.): автореф. дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 1960. – С. 8.

булганны күрсәтә. Моңа кадәр эшләп килгән җәйге курсларда төп игътибар сәяси күзаллауны арттыруга бирелеп, педагогик эш йомшак куелган булуны таный. Нәтиҗәдә шул елдан җәйге курсларга конкрет таләпләр куела башлый. Академик үзәк тарафыннан тыңлаучылар өчен анкеталар, укыту планнары төзелә. Академик үзәк оештырган курсларның Казан шәһәрендәгесе – үзәк, ә Чистай һәм Алабугадагылары[139] берләшкән курслар дип санала башлыйлар. Курсларга иң актив һәм көчле укытучылар чакырыла. Чөнки алар киләчәктә урыннарда инструктор ролен үтәргә, үзләре конференцияләр, съездлар үткәреп, калган укытучылар арасында аңлату-агарту эше алып барырга тиеш булалар. Курсларда укыту 6 юнәлеш буенча алып барыла: политграмота, педагогика, туган тел, математика, табигать һәм мәдәният, туган як. Курска килгән һәрбер кеше анкета тутыра. Бу анкета буенча тыңлаучыларның социаль хәле, шул ук вакытта аларның гомуми белем дәрәҗәләре, эш тәҗрибәләре, әлеге курсларга куйган теләкләре ачыклана. Анкета җавапларыннан һәм белем дәрәҗәләреннән чыгып, тыңлаучылар 3 төркемгә бүленә[140]. Лекцияләр татар һәм рус телләрендә укыла. Курсларның төп максаты, бер яктан, эш мәктәпләренең төп идеяләрен җиткерү, укыту методларын аңлату, укытучыларның гомуми белемнәрен күтәрү булса, икенче яктан, педагогик кадрларның сәяси күзаллауларын яңа заман таләп иткән юнәлештә үзгәртү һәм сәяси белемнәрен арттыруны максат итә. Академик үзәк оештырган җәйге курслар 1929 елга кадәр дәвам итә.

Академик үзәк тарафыннан укытучыларның белемнәрен күтәрү максаты белән кышкы (ике атналык) курслар, конференцияләр, түгәрәкләр, семинарлар оештырыла. Моннан тыш, Политпросвет оештырган I баскыч мәктәп, ШКМ, югары төр мәктәп укытучылары өчен һ.б. курслар да эшләп килә.

Алга таба да укытучылар җитешмәү сәбәпле Мамадышта (1922), Бөгелмәдә (1924), Арчада (1925) икееллык татар педагогия курслары ачыла. Аларда укытучылар хәзерләүнең төп формасы итеп берьеллык һәм алты айлык практик курслары алына.

Шул чор галимнәренең мондый кыска вакытлы курсларга карата карашлары төрлечә була. Кайберләре аларны яклап чыга. Мә-

---

[139] Чистай шәһәрендәге курсларга Чистай, Бөгелмә, Спасс, Тәтеш һәм Буа, ә Алабуга шәһәрендәге курсларга Чаллы, Алабуга, Минзәлә, Әгерҗе һәм Мамадыш кантоннарыннан укытучылар килә.

[140] Академический центр Татарии: 1920-е годы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – С.40–45.

сәләп, Л.Җәләй, үзенең «Укытучыларга курслар кирәкме?»[141] дигән мәкаләсендә татар укытучыларының курсларга теләп килүләрен әйтә. Автор язуынча, бу елларда рус галимнәре арасында кыска вакытлы курсларга караганда конференцияләр уңайлырак дигән фикерләр була. Алар уйлавынча, конференцияләр ярдәмендә укытучылар үзлекләреннән эшләргә, иҗат итәргә өйрәнәләр, шуның нәтиҗәсендә аларның тикшеренү, эзләнү көчләре арта, конференцияләр укытучыларга алга барырга ярдәм итә, дип уйлыйлар. Ел әйләнәсе мондый конференцияләрдә йөргән укытучыларның 90%ы яңадан курсларга барырга сорап мөрәҗәгать итүләрен белдерә. «Конференцияләр әле укытучыларның бөтен сорауларына да җавап бирә алмыйлар», – ди автор. Ул монда конференцияләрне генә гаепле итеп калдырмый, ә татар укытучысын әйләндереп алган мохитне дә гаепле дип саный. Чөнки «әле урыннарда методик бюролар тиешле дәрәҗәдә эшләми, укытучыларның педагогика-методика фәннәре буенча белемнәре аз, татарлар арасында педагогика юлларын күрсәтә торган вакытлы матбугат юк дәрәҗәсендә». Курсларда укытучылар үзләрен борчыган сорауларга җавап табарга, ялгышларын төзәтергә, үзлекләреннән хәзерләнергә, үз тәҗрибәләре белән уртаклашырга өйрәнергә тиешләр, дигән фикердә тора.

Автор тәрбия ягыннан караганда да әлеге курсларга зур өстенлек бирә. Совет власте елларындагы иң актуаль мәсьәләләренең берсе булып дингә каршы тәрбия мәсьәләсе тора. Л.Җәләй бу турыда: «Хәзерге вакытта татар авылларын кайната торган мәсьәлә – «дин укыту» мәсьәләсе. Бездә әлегә дингә каршы көрәш мәсьәләсе аз эшләнгән, шунлыктан татар укытучыларын бу фронтка хәзерләргә тиешлебез», – ди.

Ә Г.Хәбиб башка төрлерәк фикердә тора. Ул кыска вакытлы курсларны тулысынча инкарь итмәсә дә, «ни төп белем ягыннан, ни тәгълим-тәрбия ягыннан, психология әсасларыннан (нигезләреннән – *З.А.*) хәбәрдар булмаган курсантлар өчен түгел, ә бәлки кирәкле белем һәм әсаслардан тәмам хәбәрдар кешеләргә тәгълим-тәрбия бабындагы (бүлегендәге, мәсьәләсендәге – *З.А.*) яңа агым, яңа фикерләрне ирештерү, аларның тулмаган кайбер якларын тутыру, тәҗрибә вакытында шөбһәләнгән мәсьәләләрен хәл итү шикелле эшләр өчен генә булырга тиеш»[142], – ди. Ә укытучылар хәзерләү

---

[141] Җәләй Л. Укытучылар курслары кирәкме? // Мәгариф. – 1926. – № 8. – 83–85 б.

[142] Хәбиб Г. Укытучылар хәзерләү мәсьәләсе // Мәгариф. – 1921. – № 8–9. – 82 б.

өчен ике төрле педагогия уку йортлары ачарга тәкъдим итә. Беренчесе – I баскыч мәктәп укытучылары өчен 2–3 еллык тәгълим-тәрбия курслары, икенчесе – II баскыч мәктәп укытучылары өчен 3–4 еллык тәгълим-тәрбия институтлары[143].

Әлбәттә, курслар укытучыларга әллә ни зур белем бирә алмасалар да, яңа төр мәктәпләрнең төп максат-бурычларын җиткерүдә, яңа методик алымнарны куллану ысулларын аңлатуда нык булышлык иткәннәр, совет хөкүмәте урнашуның нәкъ менә беренче елларында бик актуаль булганнар.

Укытучыларның белемнәрен арттыруда вакытлы курслар һәм башка төрле чаралар күпмедер дәрәҗәдә ярдәм итсәләр дә, бердәм эш планнары булмаганлыктан, бер-берсе белән хәбәрләшеп эш итмәгәнлектән, мәгарифнең барлык өлкәләренә дә тиешле дәрәҗәдә игътибар җитеп бетми. Нәтиҗәдә, өстәмә педагогик белем бирү буенча үзәкләштерелгән оешма төзү фикере туа. Әлеге оешма булып, 1928 елда Бөтенроссия мәгариф хезмәткәрләренең белемен күтәрү институтының бер бүлеге буларак, Казанда Укытучыларның белемнәрен күтәрү буенча татар институты ачыла. 1932 елдан ул Татарстан халык мәгарифе кадрларының белемен күтәрү институты, ә 1939 елдан Татарстан укытучылары белемен күтәрү институты (ТУБКИ) итеп үзгәртелә. Әлеге институт педагогик кадрлар белән беррәттән мәгариф эшчеләре өчен дә курслар оештыра.

Милли кадрлар хәзерләү буенча хөкүмәт тарафыннан кыска вакытлы курслар белән беррәттән махсус педагогик уку йортлары да оештырыла башлый.

Революциягә кадәр эшләп килгән кайбер уку йортлары яңа таләпләргә туры китерелеп үзгәртеләләр. Вакытлы хөкүмәтнең 1917 ел 14 июнь карары нигезендә КТУШ та 1 июльдән Татар укытучылар семинариясе итеп үзгәртелә[144]. 1921 елда семинария нигезендә дүрт (татар, чуваш, рус, керәшен) аерым педагогия техникумнары төзелгәч, 1922 елның язынннан әлеге уку йорты К.Насыйри исемендәге татар педагогия техникумы дип аталып йөртелә башлый. Техникумда төрле елларда И.М. Казаков, Х.Г. Рафиков, З. Нигъмәтуллин һ.б. җитәкчелек итә. Техникумның утырыш материалларыннан күренгәнчә, ул ТАССР өчен генә түгел, ә СССРның татарлар яшәгән барлык өлкәләре өчен дә татар укытучылары хәзерләүче бердәнбер уку йорты булып торган. Техникумда укулар физика-математика, биология-география, иҗтима-

[143] Шунда ук.

[144] Национальный архив Республики Татарстан, ф. 142, оп.1, д. 485, л.29.

гый-тарихи, җитештерү, педагогия юнәлешләре буенча алып барылган. 20 нче елларда татар теле һәм әдәбиятын Г. Ш. Габдрәхимов, Х. Бәдигый, М. А. Фазлуллиннар укыткан. М. А. Фазлуллин шул ук вакытта татар әдәбияты буенча түгәрәк тә алып барган[145]. Техникумда башлангыч мәктәп укытучылары, тәрбиячеләр, физкультура һәм чит тел укытучылары хәзерләнгән[146].

Үзгәртелү процессы 1863 елда ачылган керәшен татарлары өчен укытучылар хәзерләү мәктәбенә дә кагыла. 1918 елда ул Керәшен укытучылар семинариясе, ә 1922 елда Керәшен педагогия техникумы итеп үзгәртелә. Аның мөдире вазыйфасын 1918 елдан В.Горохов башкара. Ләкин әлеге уку йорты илдә башланган берләштерү сәясәте нәтиҗәсендә 1930 елда ябыла[147].

1918–1919 елларда укытучылар семинарияләре тагын Чистай, Тәтеш һәм Алабугада ачыла. Аларда уку вакыты биш ел була. Әлеге уку йортларында төп игътибар педагогика укытуга һәм практикага бирелә. Семинариядә укулар беренче өч елда II баскыч эш мәктәпләре программасы буенча, ә соңгы ике елда педагогик юнәлештә алып барыла. Ләкин әлеге семинарияләр дә туган телдә уку әсбаплары, шулай ук укытучы кадрлар җитешмәү сәбәпле тиешле дәрәҗәдә татар мәктәпләренә укытучылар әзерләп өлгертә алмыйлар. Семинарияләрнең укыту вакытларының шактый озак булуы да әлеге эшнең бик акрын баруына китерә. Ул илдә укытучыларга көннәнкөн артып торган ихтыяҗны канәгатьләндерә алмый. Шунлыктан укытучылар әзерләү буенча яңа төр уку йортлары кирәк була. Нәтиҗәдә, 1919–1920 уку елыннан семинарияләр өчьеллык педагогия курслары, 1921 елдан (җидееллык мәктәпләр базасында дүртьеллык укыту вакыты белән) педагогия техникумнары итеп үзгәртеләләр.

1919 елга Казан губернасындагы 6 шәһәрдә өчьеллык татар педагогия курслары ачыла, шуларның берсе катнаш типта була[148]. Әлеге уку йортларына 15 яше тулган һәм икенче баскыч мәктәпләре

---

[145] Ахтямова А.В. Преподавание на татарском языке и татарского языка в 1920-е гг. // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015. – С. 62–63.

[146] Гобәйдуллин Ә. Махсус педагогик урта белем бирү // Мәгариф. – 1967. – № 10. – 15 б.

[147] Кириллова З. XX гасыр башында керәшеннәр // Татар халкының педагогик фикерен һәм мәгариф тарихын өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2011. – 250–258 б.

[148] Арчада, Алабугада, Казанда, Мамадышта,Чистайда, Тәтештә – рус-татар.

күләмендә урта белеме булган барлык яшьләр кабул ителә. Беренче һәм икенче курсларда гомуми белем бирелә, ә өченче курста педагогика, төрле фәннәрнең методикалары өйрәнелә һәм укучылар мәктәптә практика узалар.

Татар педагогия техникумнарында укыту татар телендә алып барылырга тиеш була. Ләкин 20 нче елларда республикада коренизация кампаниясе киң җәелүгә карамастан, белем бирүне татар телендә алып баруның күп кенә кыенлыклары килеп чыга. Беренчедән, татар телендә уку әсбаплары җитешми. Икенчедән, барлык татар техникумнары өчен бердәм килешенгән укыту планнары һәм программалары булмый. Өченчедән, техникум укытучыларының күпчелеген рус укытучылары тәшкил итә. Мәсәлән: К.Насыйри исемендәге татар педагогия техникумында 1923/24 уку елында 24 укытучының 8е генә татар була. Бу татар балалары өчен, бигрәк тә беренче елны, тел ягыннан зур кыенлыклар тудыра. Шул сәбәпле техникумның 1924 елның 2 сентябрь карары буенча хәзерлек курсларына керү имтиханнарын татар телендә уздыру раслана. Шул елны хәзерлек курсында математика фәнен укыту өчен техникумга З.Нигъмәтуллин чакырыла. Алабуга техникумында татар телендә укыту тагын да кыенрак хәлдә була. Анда төп фәннәр – физика, математика, химия, педология, табигать белеме – рус телендә, ә калган фәннәр рус телендәге фәнни әдәбият кулланып, татар телендә алып барыла[149].

Татар педагогия техникумнарында татар телендә укытуның начар куелышы техникум җитәкчеләрен генә түгел, ә анда укыткан татар укытучыларын да нык борчый. Мәсәлән, Казан педагогия техникумы укытучысы Максудов үзенең чыгышында фәннәрне татар телендә укыту белән беррәттән, телне чит сүзләрдән чистартырга кирәклеген ассызыклый. Аның фикеренчә, техникумда кулланылган тел ни татар теле түгел, ни рус теле түгел, ә ниндидер бер болганчык. Әйтергә кирәк, алга таба техникум җитәкчеләре белем бирүдә татар телен куллануга нык игътибар биргәннәр. Чөнки 1928 елның февраль документлары буенча, белемнең 90%ы туган телдә бирелә, диелә[150].

Хөкүмәт тарафыннан педагогик кадрлар хәзерләү буенча күп эшләр эшләнсә дә, мәктәпләрне педагогик кадрлар белән тәэмин итү ихтыяҗы елдан-ел арта бара. Куелган планнар, мәҗбүри башлангыч

[149] Ахтямова А.В. Преподавание на татарском языке и татарского языка в 1920-е гг. // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2015. – С. 63–65.

[150] Шунда ук. – С. 65.

һәм урта белем бирүне кертү мәктәпләрдәге балалар санын һәм мәктәпләр санын тагын да арттыра. 1932 елның 25 август карары нигезендә укытуда төгәл генә бер метод куллану бетерелә. Укытучы төрле методлар кулланып, үз фәнен эзлекле рәвештә укучыларга җиткерергә тиеш була. Бу карар, бер яктан, укытучының дәрәҗәсе күтәрелүгә этәргеч бирсә, икенче яктан, укытучыдан тиешле белем таләп итә. Нәтиҗәдә, укытучыларга һәрдаим белем дәрәҗәләрен күтәреп торырга кирәк була.

Укытучыларга ихтыяҗны киметү максатында II баскыч мәктәпләрендә өлкән сыйныф укучыларына махсус фәннәр укытып, мәктәпне тәмамлаганда укытучы, китапханәче белгечлекләре алып чыгу мөмкинлеге тудырыла. Мәсәлән, хәзерге Арча педагогия көллиятенең тарихы тугызъеллык урта мәктәпкә барып тоташа. 1926 елда анда педагогия сыйныфлары ачыла, ә 1930 елда ул Арча агропедтехникумы, 1937 елдан башлангыч сыйныф укытучылары хәзерләүче Арча педагогия училищесы итеп үзгәртелә[151]. Бу елдан барлык педагогия техникумнары да училищелар итеп үзгәртеләләр.

1930 елда Бөгелмәдә педагогия техникумы ачыла. Педагогия техникумнары укучылары, укыту эшеннән тыш хуҗалыкның төрле тармакларында эшли алырга хәзерлекле булып чыгарга тиеш булалар, шунлыктан алар агрономия, терлекчелек, бакчачылык һәм умартачылык буенча практика үтәләр, остаханәләрдә агач эше белән шөгыльләнәләр.

30 еллар башында мәктәпне политехникалаштыру эше көчәйтелү сәбәпле, педтехникумнарда яңа бүлекләр барлыкка килә. Мәсәлән, Чистай педтехникумында төрле төр уку йортлары өчен, шул исәптән фабрика-завод һәм колхоз яшьләре мәктәпләре өчен дә, хезмәт укытучылары, Алабуга педтехникумында китапханәчеләр хәзерләү буенча бүлекләр ачыла.

Балалар бакчалары өчен тәрбиячеләр хәзерләү эше дә актив алып барыла. 1935/36 уку елыннан Бөгелмә шәһәрендә мәктәпкәчә тәрбия бирү буенча беренче педагогик техникум ачыла. Икенче шундый техникум 1936/37 уку елыннан Чистайда эшли башлый. 1936 елда Казан, Чистай, Буа һәм Бөгелмә педагогия училищеларында тәрбиячеләр хәзерләү өчен читтән торып уку бүлекләре тудырыла[152].

---

[151] Татарская энциклопедия: В 5 т. / Гл. ред. М.Х.Хасанов, отв. ред. Г.С.Сабирзянов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. – Т.1: А-В. – С. 185.

[152] Корнеева М.С. Очерки по истории общественного дошкольного воспитания в ТАССР (1917–1941 гг.): авторефер. дис. ... канд. пед. наук, – Казань, 1960. – С.16.

Укытучылар хәзерләүнең югарыда санап үтелгән юллары белән параллель рәвештә югары белемле кадрлар булдыру эше дә алып барыла.

1918 елның май аенда Мәскәүдә узган укытучылар институтлары вәкилләренең Бөтенроссия съезды яңа педагогия институтлары ачу мәсьәләсен карый. Съездда кабул ителгән карар нигезендә институтларны, беренче чиратта, университет булган шәһәрләрдә ачу күздә тотыла, уку вакыты дүрт ел итеп билгеләнә[153]. Шуның нәтиҗәсендә, 1876 елдан бирле эшләп килгән Казан укытучылар институты нигезендә 1918 елдан Казан педагогия институты (КПИ) булдырыла. Бу вакытта институтта мәктәпкәчә тәрбия, беренче һәм икенче баскыч эш мәктәпләре укытучылары, хезмәт буенча инструкторлар, мәктәптән тыш белем бирү хезмәткәрләре хәзерләү (1921 елда ябыла) бүлекләре була.

Институтта гомуми фәннәрдән тыш, һәрбер бүлек өчен үзенчәлекле булган махсус фәннәр дә өйрәнелә. Әйтик, мәктәпкәчә бүлектә – балалар гигиенасы, психология, рәсем, музыка, җыр; мәктәп укытучылары хәзерләү бүлекләрендә аерым фәннәр һәм аларны укыту методикасы курслары уздырыла. Авыл хуҗалыгы теориясенә һәм практикасына, машина белеме нигезләренә, электротехникага зур игътибар бирелә. Барлык студентлар өчен дә остаханәләрдә, өйрәнү-тәҗрибә хуҗалыкларында һәм фермаларда җитештерүчән хезмәттә катнашу карала[154].

Институтта югары квалификацияле белгечләр күп булганлыктан, КПИга Мәскәү һәм Петроград педагогия институтлары белән беррәттән, РСФСР территориясендәге педагогия институтлары өчен вуз профессорлары һәм укытучылары хәзерләү бурычы йөкләнә. Шул сәбәпле КПИ 1919 елдан Халык мәгарифе югары институты итеп үзгәртелә[155]. 1921 елдан янәдән Казан педагогия институты исеме белән йөртелә башлый.

1919 елның 30 декабрендә булып үткән МХК карарлары нигезендә рус булмаган халыкларга илдәге барлык педагогия уку йортларына чикләүсез керү хокукы бирелүгә карамастан, беренче чорда КПИда татарлар бик аз була. Мәсәлән: 1921 елда барлык укучы-

[153] Литвин А., Солтанбеков Б. Казан педагогия институтының беренче адымнары // Мәгариф. – 1967. – №10. – 11 б.

[154] Шунда ук. – 12 б.

[155] КГПИ / Сост. А.Л.Литвин; отв. ред. М.З.Закиев. – Казань, 1970. – С. 4.

ларның 3%ы[156], ә 1922 елда бирелгән 120 гаризаның 10 сы гына татарлардан була[157]. Татар һәм башка милләт яшьләре күбесенчә техникум һәм рабфакларга килгәнлектән, укуларын тәмамлагач, аларны институтка тарту планлаштырыла. Шул рәвешле бу кимчелекне бетерү күздә тотыла[158].

1922 елдан Идел буе өлкәләренең икътисади хәлләре бераз алга китү сәбәпле, II баскыч мәктәпләренең саны арта. Нәтиҗәдә, уку йортларына югары белемле укытучылар җитешми. Шунлыктан, 1922 елның 22 августында РСФСР ХМКты КПИ нигезендә ТАССР һәм Идел буенда яшәгән төрле милләт вәкилләре өчен югары квалификацияле укытучылар хәзерләү максаты белән югары педагогик уку йорты төзү турында карар чыгара. КПИ Көнчыгыш педагогия институты дип үзгәртелә. Институт составына педагогия институты, Шәрык академиясе[159] һәм Казан университетының иҗтимагый фәннәр факультеты кертелә. Институт нигездә II баскыч мәктәпләр, эшче факультетлар, техникумнар, крестьян яшьләре һәм ФЗӨ мәктәпләре өчен укытучылар һәм туган якны өйрәнү хезмәткәрләре әзерләп чыгара.

Шул ук елны институтның башлангыч мәктәпләр өчен укытучылар хәзерли торган бүлеге ябыла, чөнки хәзерлек курслары базасында педагогия техникумы ачыла. Әлеге бүлек тулысы белән шунда күчерелә[160].

КПИ ачылганда көнчыгышны өйрәнү, физика-математика, биология-география, тел-тарих[161], 1924–25 уку елыннан иҗтимагый-икътисади, әдәбият-лингвистика, чуваш, милли-лингвистика, музей-этнография (1927 елдан ябыла), ә 1927 елдан иҗтимагый-икътисади, рус теле һәм әдәбияты, физика-техника, табигать белеме, татар теле һәм мәдәнияте, чуваш теле һәм мәдәнияте, мари теле һәм мәдәнияте,

---

[156] Шунда ук. – С. 6.

[157] Мөхетдинов Н. Көнчыгыш педагогия институтының милли бүлекләрен ныгыту турында // Мәгариф. – 1926. – № 8. – 8 б.

[158] Литвин А., Солтанбеков Б. Казан педагогия институтының беренче адымнары // Мәгариф. – 1967. – №10. – 13 б.

[159] Шәрык академиясе – 1920 елда Казанда Төньяк-көнчыгыш археология һәм этнография институты җирлегендә оештырыла. Анда тарих-археология, этнография, тел һәм әдәбият (төрек-татар һәм фин-угыр телләре, әдәбиятлары), социаль-икътисади бүлекләр була. Академия каршында татарлар өчен әзерлек мәктәбе эшли.

[160] Литвин А., Солтанбеков Б. Казан педагогия институтының беренче адымнары // Мәгариф. – 1967. – №10. –13 б.

[161] КГПИ / Сост. А.Л. Литвин, отв. ред. М.З. Закиев. – Казань, 1970. – С. 7.

удмурт теле һәм мәдәнияте бүлекләре була[162]. 20–30 елларда КПИда тарихчы Г. Гобәйдуллин, тел белгече Г. Шәрәф, Җ. Вәлиди, М. Фазлуллин, әдәбиятчылардан Г. Нигъмәти, Г. Рәхим, Г. Сәгъди, математик Н. Йосыпов, методист М. Корбангалиев һ.б. белем бирә.

Югары уку йортларына татарларның аз керүе татар галимнәрен бик борчый. Бу уңайдан 1926 елда Н. Мөхетдиновның «Көнчыгыш педагогия институтының милли бүлекләрен ныгыту турында» дигән мәкаләсе басылып чыга[163]. 1924–1926 елларда КПИда эшләгәнлектән, ул әлеге мәсьәлә белән яхшы таныш була һәм институтның Көнчыгышны өйрәнү бүлегендә татарларның аз булуына борчылып яза. Төп сәбәпләренең берсе итеп автор бүлекнең алга куйган төгәл максаты булмауны һәм институтның гомуми эшеннән аерым яшәвен күрсәтә. Шулай ук мәгариф комиссариаты тарафыннан татар эшчеләренә зур сорау булуга карамастан, кайбер белгечлекләр укучыларда кызыксыну уятмый. Мәсәлән, музей-этнография бүлеге студентлары киләчәктә эшләргә җирлек күрмибез, дип ул бүлекне тормышка яраклырак бер бүлеккә әйләндерүне сорап күмәк гариза бирәләр. Нәтиҗәдә, бу бүлек табигать белеме бүлеге итеп үзгәртелә.

Институтта татар студентларының саны аз булуга карамастан, махсус татар теле бүлеге ачыла. Башка бүлекләрдә предметларны татар телендә укыту тәҗрибәсе кертелә. Дәресләр ике төркемгә бүлеп алып барыла: бер укытучы татар студентлары өчен генә лекция укый, икенчесе – барлык студентлар өчен дә. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәк, 20 елларда күпсанлы карарлар нигезендә[164], югары уку йортларында татар телен укыту мәҗбүри итеп куелса да, чынлыкта бу бары Көнчыгыш институтында гына тормышка ашырыла, институтта мәҗбүри рәвештә татар теле укытыла[165].

[162] Татарская энциклопедия: В 5 т. / Гл. ред. М.Х. Хасанов, отв. ред. Г.С. Сабирзянов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. – Т.1: А-В. – С. 635.

[163] Мөхетдинов Н. Көнчыгыш педагогия институтының милли бүлекләрен ныгыту турында // Мәгариф. – 1926. – № 8. – 6–9 б.

[164] 1922 елның 8 маендагы ТҮБК карарында югары уку йортларында татар теле укыту кирәклеге билгеләнә, ә шул ук елның 21 декабрендәге инструкциядә инде татар теле өйрәнүнең мәҗбүри икәнлеге ассызыклана. 1926 елның 25 июнендә Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе тарафыннан бирелгән белешмәдә дә урта һәм югары уку йортларында татар теле укытуның мәҗбүри булу фикере кабатлана. (Кириллова З.Н. Югары уку... – 172 б.)

[165] Кириллова З.Н. Югары уку йортларында татар телен укыту (XX гасырның 20–30 нчы еллар тәҗрибәсе) // Языки России и стран ближнего зарубежья как иностранные: преподавание и изучение: материалы Междунар. науч.-

1930–31 елларда КПИның башка милләт мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү бүлекләре нигезендә Чабаксарда, Йошкар-Олада, Ижевскта педагогика институтлары оештырыла. Шуның нәтиҗәсендә институт – Татар педагогия институты дип үзгәртелә. Институт алдына илдәге барлык татар мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү бурычы куела.

1930 елда КПИда югары белемле тәрбиячеләр булдыруны күз алдында тоткан мәктәпкәчә тәрбия бүлеге ачыла. Беренче бишьеллык нәтиҗәләре буенча Татарстанда 488 югары белемле тәрбияче исәпләнә[166].

Революциядән соңгы елларда Россиянең төрле төбәкләрендә яшәүче рус булмаган милләт вәкилләре өчен дә ана телендә белем бирүче бердәм эш мәктәпләре ачыла, алар өчен педагогик кадрлар хәзерләү эше башланып китә.

РСФСРның күп кенә шәһәрләрендә милли мәктәпләргә укытучылар хәзерләү өчен махсус педагогия техникумнары ачыла. 1922–1923 елларда Татарстаннан читтә яшәүче татарлар өчен дүрт педагогия техникумы эшли. Татар контингенты булган урыннарда рус техникумнарында татар бүлекләре оештырыла. Ләкин болар гына татар мәктәпләренең укытучыларга булган ихтыяҗын канәгатьләндерми. Шуңа күрә яңа уку йортлары ачу мәсьәләсе күтәрелә. Нәтиҗәдә чит өлкәләрдә татар педагогия техникумнарының саны 9 га җитә (Екатеринбург (Свердловск), Оренбург, Әстерхан, Саратов, Пенза, Түбән Новгород (Горький), Мәскәү, Томск һәм Троицк педтехникумнары). 1927 елда әлеге техникумнар 2050 татар укытучысы хәзерләп чыгара. Бу сан чит төбәкләрдә укытучыларга булган ихтыяҗның 33%ын гына канәгатьләндерә[167]. Шунлыктан өстәмә рәвештә Уфада, Мәскәүдә, Саратов һ.б. шәһәрләрдә кыска вакытлы курслар ачыла. Бу курсларда төп игътибар татар теле белән татар әдәбиятын укытуга бирелә.

---

практ. конф. (28–29 ноября 2013 г.) = Чит тел буларак Россия һәм якын чит илләр телләре: укыту һәм өйрәнү: Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (28–29 ноябрь, 2013 ел). – Казан: Казан университеты, 2013. – 171–172 б.

[166] Корнеева М.С. Очерки по истории общественного дошкольного воспитания в ТАССР (1917–1941 гг.): авторефер. дис. ... канд. пед. наук, – Казань, 1960. – С. 14.

[167] Галиев Р. Беренче адымнар // Мәгариф. – 1974. – № 4. – 58 б.



*Свердловск татар-башкорт педтехникумы укытучылары һәм укучылары. 1930 нчы еллар*

30 елларда Төмән татар педагогия училищесы оеша. Тиздән ул Тубыл шәһәренә күчерелә. Тубыл педагогия училищесы Бөек Ватан сугышы елларында да эшли. Ул укытучылар хәзерләп кенә калмый, ә Төмән өлкәсендә татар милли мәдәниятен өйрәнүче һәм халыкка таратучы үзәк булып та тора. Үзенең эшләү дәверендә училище 1500 башлангыч мәктәп укытучысы хәзерләп чыгара[168].

Шулай ук милли педагогик кадрлар хәзерләүдә һәм белемнәрен арттыруда югары уку йортлары каршында оешкан рабфакларның, вакытлы матбугатның («Мәгариф», «Эш», «Кызыл Армия», «Эшче»), 1932 елдан уздырыла башлаган укытучыларның август конференцияләренең, методик бюроларның һ.б. әһәмияте зур була.

---

[168] Сайфуллина Ф.С. Историческая роль ТГПИ им. Д.И.Менделеева в подготовке национальных педагогических кадров и сохранении культуры татарского народа // Материалы XVII Всероссийской научно-практической конференции «Менделеевские чтения, посвященные 100-летию Тобольского учительского института «Образование и культура как фактор развития региона» (23–24 ноября 2016 г.). – Тобольск: ТГПИ им. Д.И.Менделеева, 2016. – С.5–10.

Хөкүмәт тарафыннан укытучылар хәзерләү буенча күп эшләр эшләнсә дә, татар мәктәпләренә югары квалификацияле укытучылар җитешми. Мәсәлән: Татарстанда башлангыч, тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләрнең 1934/35 уку елындагы эшләренә йомгак ясаганда укытучыларның белем дәрәҗәләре түбән булуы искәртеп үтелә. Бигрәк тә татар һәм башка милләт укытучыларының белем күрсәткечләре түбән булуы ассызыклана. 30 нче еллар башына ТАССР-да барлык башлангыч мәктәп укытучыларының 16,9%ы, урта мәктәп укытучыларының 38,6% гына махсус педагогик (педвуз яки педтехникум) белемле була[169], ә татар мәктәпләрендәге башлангыч сыйныф укытучыларының 82%ы урта белемгә дә ия булмый.

Татарстанда сугыш башланганчы укытучылар хәзерләү белән 10 педагогия училищесы һәм Казан педагогия институты шөгыльләнә. Училищелар башлангыч мәктәп, ә институт халык мәгарифенең барлык өлкәләре өчен укытучылар хәзерли. Укытучыларның белемнәрен күтәрү буенча эш алып баручы төп оешма булып ТУБКИ исәпләнә.

1941 елда Казан педучилищесы Алабугага күчерелә. Бу техникум 3 юнәлеш буенча эшли: башлангыч мәктәп укытучылары, китапханәчеләр һәм мәктәпкәчә тәрбия хезмәткәрләре хәзерләү.

Сугыштан соңгы елларда кайбер педагогия училищеларында татар төркемнәре берләштерелә, ә кайбер училищелар гомумән ябыла. Мәсәлән, 1947 елда Тәтеш педагогия училищесының татар бүлеге Арча училищесына күчерелә, ә 1955–1957 еллар аралыгында Мамадыш, Алабуга, Бөгелмә, Куйбышев училищелары ябыла. Андагы укытучылар башка педучилищеларга күчерелә. Нәтиҗәдә 1956–1957 уку елына республикада бары 4 педагогия училищесы кала, аларның берсе читтән торып укыту, берсе мәктәпкәчә тәрбиячеләр хәзерләү буенча профильләштерелгән педучилище була.

Педагогия училищелары челтәре киму нәтиҗәдә республикада алдагы елларда башлангыч класс укытучылары җитмәүгә китерә.

Татар мәктәпләренә укытучылар хәзерләү эше башка төбәкләрдә дә алып барыла. 1950 елда Төмән институтында ике еллык рус-татар теле һәм әдәбиятлары укытучылары хәзерләү факультеты ачыла. Соңрак ул Тубыл педагогия институтына күчерелә. Анда татар мәктәпләренә укытучылар хәзерләүче ике бүлек эшли: татар һәм рус-татар бүлекләре.

[169] Фасхутдинова Е.Н. Учительство Казанской губернии / ТАССР в 1918 – начале 1930-х годов (по архивным документам): дис. … канд. ист. наук. – Казань, 2008. – С. 169.

Тубыл институтында беренче тапкыр ачылган татар теле һәм әдәбияты кафедрасына эшкә Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген, Казан педагогия институтын тәмамлаган яшь белгечләр җибәрелә. Алар арасында бүгенге көннең танылган галимнәре Ф.М. Хатыйпов, Г.Ф. Саттаров, А.Г.Әхмәдуллин һ.б. да була[170].

## 1.5. Татар телендә югары белем бирү (1920–1930 еллар)

Революциядән соң беренче елларда Татарстанда үткәрелгән тел сәясәте югары мәктәптә укытуга да сизелерлек үзгәрешләр кертә. Татарстан республикасының дәүләт теле итеп танылган татар теле, рус теле белән беррәттән, югары уку йортларына үтеп керә, институтларны «татарлаштыру» дигән юнәлеш барлыкка килә.

Иң беренче чиратта ул татар яшьләрен укырга һәм татар педагогларын эшкә алу аша алып барыла. Татар телен мәҗбүри предмет буларак укытуга килгәндә, институтларда кире кагылмаса да, чын мәгънәсендә бары тик Казан педагогия институтында гына тормышка аша. Башка вузлар бу эшкә тулаем кушылып китә алмыйлар. 1927 елда, сметалар кыскару аркасында, КПИда да татар телен мәҗбүри рәвештә укыту туктатыла, ләкин җирле яки үзәк бюджетның булышлыгы ярдәмендә татар теленә өйрәтү дәвам иткән дип фаразлана[171].

Татар үзәк башкарма комитетының (ТҮБК) 1928 елның 8 май карарында югары уку йортларында татар теле укытуның кирәклеге ассызыклана. Шул ук вакытта предмет буенча имтихан билгеләнмәү сәбәпле, ул тулысынча хәл ителми. Кайбер уку йортларында, мәсәлән, КПИда, диплом алу өчен зачет тапшыру мәҗбүри итеп куелганнан соң, вәзгыять беркадәр үзгәрә[172]. Башка югары уку йортлары махсус курс буларак татар телен мәҗбүри-ихтыяри укыта[173].

---

[170] Сайфуллина Ф.С. Историческая роль ТГПИ им. Д.И.Менделеева в подготовке национальных педагогических кадров и сохранение культуры татарского народа // Материалы XVII Всероссийской научно-практической конференции «Менделеевские чтения, посвященные 100-летию Тобольского учительского института «Образование и культура как фактор развития региона» (23–24 ноября 2016 г.). – Тобольск: ТГПИ им. Д.И.Менделеева, 2016. – С. 5–10.

[171] Кириллова З.Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20–30 нчы еллар). – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 72 б.

[172] Шунда ук. – 72 б.

[173] Татарстан республикасында тел сәясәте. Документлар һәм материаллар (20–30 нчы еллар). – Казан: Мәгариф, 1998. – 126 б.

Ике дәүләт телендә һөнәри эшчәнлек алып барырлык кадрлар әзерләү эшенә башка милләт вәкилләре дә җәлеп ителә. Моның өчен аларны татар теленә өйрәтү, югары уку йортларын тәмамлаучылардан татар телендә камил сөйләшә белүләрен таләп итү шарт итеп куела[174]. Әмма ике телне белгән өчен түләү мәсьәләсе хәл ителмәү сәбәпле, 20 елларның уртасына ул эш тулысынча тормышка ашмый кала[175].

Бу елларда югары уку йортларында татар булмаганнарга татар телен укыту проблемаларын камилләштерү өстендә күп эшләнә, аның методик системасы формалаша. КДУ галиме М.Корбангалиев бу проблеманы нәзари яктан да, гамәли яктан да хәл итүгә зур өлеш кертә. Татар булмаганнарга татар теле укытуны гамәлгә ашыру юлларын билгеләгәндә Корбангалиев сүз запасын арттыруга гына нигезләнеп калмыйча, ишетү, күрү, җанлы сөйләшүгә игътибар итәргә кирәклекле ассызыклый[176]. Галимнең югары уку йортлары студентлары өчен «Татар теле дәреслеге» (беренче басмасы 1931 елда дөнья күрә)[177] татар теленең фонетикасы һәм грамматикасы буенча тулы мәгълүмат һәм матур әдәбияттан үрнәкләр бирелүе белән үзенчәлекле. М.Корбангалиев татар телен читтән торып өйрәнүчеләр өчен дәреслекләр язуда да зур эш башкара[178].

Татарларны югары уку йортларына әзерләү буенча оештырылган махсус рабфаклар күп уку йортлары каршында ачыла (30 еллар башында аларның саны 11 була). Татарлар арасында рабфакта укучылар саны шактый югары – 35–40% тирәсе була. Ләкин аларның барысы да югары уку йортларына керә алмый[179]. Хезмәт эшчәнлегендә татар телен файдалана алырлык белгечләр әзерләү мәсьәләсе 20 еллар урталарында да актуальлеген югалтмый. Көнчыгыш педагогия институтында югары типтагы татар мәктәпләрендә татар телендә укыта алырлык укытучы-кадрлар әзерләү, шулай ук рабфаклар аша татар-

---

[174] Шунда ук. – 30 б.

[175] Шунда ук. – 86 б.

[176] Исламов Ф.Ф. Мәгърифәт, әдәбият һәм тарих сукмаклары буйлап. – Казан: Печатный двор, 2002. – 102 б.

[177] Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен (техникум, рабфак, ВУЗ һәм ВТУЗлар өчен). – Казан: Татагосиздат, 1934. – 253 б.

[178] Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкаларга татар телен читтән торып өйрәнү өчен. Кис. 1 – Казан: Татгосиздат, 1941. – 244 б.

[179] Сыченкова А., Козлова О. «В отношении коренизации вуза сделан значительный шаг вперед»: политика коренизации в вузах ТАССР в годы первых пятилеток // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2016. – № 3/4. – С. 93.

ларны күбрәк уздыру бурычы йөкләнә[180]. Техник белгечлекләр буенча белгечләр әзерләүнең озак вакытка сузылуын истә тотып, алар өчен кыска вакытлы курслар оештыру (аларның күбесе татар телен тормышка ашыру курслары буларак үткәреләләр) карала[181].

Мәсьәләнең икенче ягы татар телендә югары белем бирү, ягъни фәннәрне татарча укытуга карый. Казан вузлары арасында татарча укыту эшенә беренчеләрдән булып Политехник институт алына (1922 елда төзелеш фәннәре ике телдә укытыла башлый). Татарлар өчен укырга кергәндә уңайлы шартлар тудырыла, керү имтиханнарын туган телдә тапшыру мөмкинлеге бирелә. Аерым предметлар (математика, физика, төзелеш материаллары һ.б.) татарча укытыла[182]. КПИда да махсус татар төркемнәре оештырылуы мәгълүм. Дәресләр ике төркемгә бүленеп, берсендә татар студентлары, икенчесендә татар телен белмәүчеләр укытыла, аерым укытучылар билгеләнә[183].

Коренизация сәясәтенең вузлар эшчәнлегенә йогынтысы зур була. 1930 еллар башында, ВКП(б) ӨКның «Вузларда укытуны коренизацияләүне ныгыту һәм киңәйтү» турындагы карарыннан соң бу мәсьәләгә игътибар тагын да арта. Югары уку йортларында коренизация татар студентларының санын арттыру, татар телен белгән укытучылар белән тәэмин итү, уку-укыту әсбаплары һәм фәнни атамалар булдыру юнәлешләрендә алып барыла. Барлык студентлар санының 40%ын татар милләтеннән булганнар тәшкил итәргә тиеш була. 1935 елда әлеге сан 25%ны тәшкил итә, татарларның саны бигрәк тә Казан медицина институтында һәм Татар педагогия институтында югары була[184].

Политехник институт базасында Коммуналь төзелеш институты ачылганнан соң, татарча белем бирү эше тагын да киңрәк җәелә: 1931 елда төзелеш факультетында 10 нчы (татар) төркеме ачыла,

---

[180] Тезисы доклада Шаймарданова о деятельности Комиссии по реализации татарского языка // Осуществление политики коренизации в Татарстане в документах. 1920–1930 гг. / Авт.-сост. З.Г.Гарипова. – Казань: ИИ АН РТ, 2009. – С. 29.

[181] Шунда ук. – 30 б.

[182] Мортазина Л. Татар телендә югары белем бирүнең кайбер мәсьәләләре // Фән һәм тел. – 2010. – №2. – 46 б.

[183] Кириллова З.Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20–30 нчы еллар). – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 71 б.

[184] Сыченкова А., Козлова О. «В отношении коренизации вуза сделан значительный шаг вперед»: политика коренизации в вузах ТАССР в годы первых пятилеток // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2016. – № 3/4. – С. 95.

татар телендә укыту буенча махсус кабинет булдырыла. 30 нчы еллар азагына кадәр геодезия, теоретик механика, югары математика, төзелеш материалары буенча уку әсбаплары языла. Эшне оештыруда татар теле кабинеты мөдире В.Н.Хангильдин, архитектура кафедрасы доценты Ф.М.Хәкимов, геодезия кафедрасы доценты З.С.Богданов, теоретик механика кафедрасы доценты Х.М.Мөштәри, төзелеш конструкцияләре доценты И.Г.Сафин һ.б. зур эш башкара. 30 нчы елларда Казан фельдшер-акушерлар мәктәбендә татар телендә кеше анатомиясе һәм физиологиясе буенча дәресләр алып барылуы мәгълүм[185].


*Х.Мөштәри*

Техник вузларда «институтларны татарлаштыру» өчен җаваплы кешеләр билгеләнә, мәсьәләнең фәнни-методик нигезләрен булдыру өстендә эш алып барыла[186]. Авыл хуҗалыгы институтында әлеге эш белән техник фәннәр кандидаты Нәҗип Максудов шөгыльләнүе мәгълүм. Н.Г. Максудов бер үк вакытта бу мәсьәләне тормышка ашыруның гамәли ягына да үзеннән өлеш кертә, авыл хуҗалыгын механикалаштыру буенча татар телендә дистәләгән китап язып бастыра. Алар озак еллар буена вузларда дәреслек буларак файдаланыла[187].

Совет властеның беренче елларында – сәяси нигездә татар мәгарифенең меңнәрчә еллык тәҗрибәсе кире кагылып, яңа совет системасын булдыру чорында дөнья күргән дәреслекләрнең күпчелегенең (икътисади география, медицина һ.б.) рус авторларыннан тәрҗемә итеп язылуы билгеле. Егерменче елларның икенче яртысында татар атамаларын булдыру, татар теленең фәнни нигезләрен булдыруга омтылыш барлыкка килү белән яңача уку әсбаплары да күренә башлый. Татар телендә фән нигезләрен чагылдырырлык атамалар булдыру мәсьәләсе 1925 елның 17 сентябрендә үткәрелгән Гыйльми үзәк президиумы утырышында карала (бу эшкә җаваплы итеп

[185] Габбасова М. Ибраһим Вәлидов турында // Фән һәм тел. – 2010. – № 2. – 10 б.

[186] Гали Х., Вәлиев Х. ВУЗ һәм техникумнарда дәрес бирүне татарлаштыру турында // Кызыл Татарстан. – 1931. – 30 октябрь;

[187] Максудов Н. Авыл хуҗалыгы машиналары: Вузлар һәм техникумнар өчен уку китабы. – Казан: Татгосиздат, 1932. – 191 б.; Максудов Н. Автомобильләр (Шоферлар хәзерләү курсларында укыту өчен ярдәмлек китап). – Казан: Татгосиздат, 1936. – 312 б. һ.б.

Г.Шнаси билгеләнә). Дәреслекләр язуда тәҗемәдән фәнни нигездә файдалануны күздә тотып, Татарстан Мәгариф комиссариатында тәрҗемә секторы ачыла. Аның җитәкчесе итеп билгеләнгән Г.Максудов үзе дә математика буенча күп кенә дәреслекләр авторы буларак таныла[188]. Бер үк вакытта ул татар телендә югары мәктәпне булдыруның теоретик нигезләрен эшләүгә дә өлеш керткән шәхес буларак билгеле[189].

Эшнең нәтиҗәсе буларак, 1927 елда инде 15 меңгә якын татарча атама эшләнүе, татар теленең гыйлем теленә әверелүе турында нәтиҗә ясала[190].

30 еллар башына төгәл, математика һәм табигать фәннәрен татарча укыту буенча тәҗрибә туплана. Бу вакытта М.И. Әлмөхәммәтовның сызма геометрия[191], И.А.Алексеевның математика буенча татар телендә язылган дәреслекләре[192], З.Х. Нигъмәтуллинның аналитик геометрия һ.б. дәреслекләр[193] дөнья күрә. Нигездә рус авторларыннан тәрҗемә дәреслекләр булсалар да, аларның татар телендә белем бирүгә йогынтылары шактый.

---

[188] Максудов Г. Туры сызыклы тригонометрия (Өчпочмаклар белеме). – Казан: Татиздат, 1926. – 342 б.

[189] Максудов Г. Ана телендә гали мәктәпләр // Мәгариф. – 1921. – № 1–2. – 74–78 б.; Максудов Г. Татарча фәнни истилахлар // Мәгариф. – 1921. – № 5–6. – 31–32 б.; Гали Х., Вәлиев Х. ВУЗ һәм техникумнарда дәрес бирүне татарлаштыру турында // Кызыл Татарстан. – 1931. – 30 октябрь.

[190] Шәмсетдинова Р.Р. Габдулла Сабир улы Ибраһимов-Шнаси – танылган галим һәм терминолог (тууына 125 ел тулуга багышлана) // Татар халкының педагогик фикерен өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре. – Казан: ТИ, 2011. – 248 б.

[191] Әлмөхәммәтов М.И. Сызма геометрия: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Татиздат, 1932. – 163 б.; Әлмөхәммәтов М.И. Зурлар өчен математика. 2 кисәктә. – Казан: Татиздат, 1932. – Кис. 1. – 114 б.; Кис. 2. – 154 б.

[192] Алексеев И.А. Математика дәресләре. Партия мәктәбенә һәм татар коммунистик университетына хәзерләнүчеләр өчен. – Казан: Татгосиздат, 1930. – 20 б.; Алексеев И.А. Математика. Элементар курс. – Казан: Татгосиздат, 1931. – 55 б.; Алексеев И., Бакиров Г., Биширов М. Математика. Дәреслек. – Казан: Татгосиздат, 1933. – 287 б.; Алексеев И.А. Югары математика нигезләре. Укытучылар, читтән торып укучылар һәм югары математиканы үзлекләреннән өйрәнүчеләр өчен. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 855 б.

[193] Нигъмәтуллин З.Х. Аналитик геометрия. ВУЗ һәм ВТУЗлар өчен дәреслек. 1 кис. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 265 б.; Фәйзи Г., Сафин М., Сәгъди Җ. Кыскача биология. Югары мәктәп һәм күтәренке типтагы техникумнар өчен. – Казан: Татиздат, 1932.



М.Әлмөхәммәтов



Г.Шнаси

Фәнни терминология булдыру һәм вузлар өчен татар дәреслекләре төзүдә Н.Максудовның эшчәнлеге игътибарга лаек. Аның авыл хуҗалыгын механикалаштыру һәм агрономия нигезләрен яктырткан дәреслекләре татар телендә югары белем бирү юнәлешен тормышка ашыруда зур өлеш кертә. Терминологик аппарат эшләнеше ягыннан аларны бик үк камил дип булмый, әлбәттә. Чөнки атамаларның байтагы турыдан-туры рус теленнән алып кулланылган. Шулай да, аларны уңышлы һәм урынлы кулланып, дөрес әйләнешкә кертеп, Максудов татар телендә техник атамалар булдыру өстендә эшләгән галим буларак тарихка кереп калды. Алар бүген дә бу өлкәдә кыйммәтле материал булып торалар.

С.М.Корбангалиевнең 1926 елда басылып чыккан химия дәреслеге дә шундый әсбаплар рәтендә[194]. Анда гарәп теленнән кергән химия терминнары урынына кайбер элементларның беренче тапкыр татар телендәге исемнәре тәкъдим ителә, атамалар ике телдә – рус һәм татар телләрендә бирелә. Бу дәреслектә Академүзәк тарафыннан эшләнгән терминнар кулланыла, әмма алар бик үк камил булмау сәбәпле, татарча атамаларны эзләү эше дәвам иттерелә. 1931 елда Г.Вәлитовның вузлар һәм техникумнар өчен дәреслекләр төзү коллективы тарафыннан расланган «Химия терминнары» хезмәте басылып чыга. Ул атамалар эшләнеше ягыннан системалы кулланма булуы белән беренче басма исәпләнелә.

[194] Мифтахова Н.Ш. Химия буенча татар телендәге беренче китаплар турында // Фәнни Татарстан. – 2005. – № 3/4. – 12 б.

Кайбер фәннәр буенча югары уку йортлары студентлары өчен язылган дәреслекләрнең булмавы сәбәпле урта-һөнәри уку йортлары, аерым алганда медицина техникумнары, өчен язылган дәреслекләр югары белем бирү системасы өчен дә яраклы дип табыла. Бу дәреслекләр медицина вузларында укучы өлгермәүче укучыларга тәкъдим ителә[195]. Алар арасында Г.Шнаси, С.Корбангалиев дәреслекләре[196], профессор Ә.Г.Терегуловның гигиена буенча язылган дәреслекләре[197] бар. Бу дәреслекләр рус теленнән ирекле тәрҗемә итеп язылган, әмма терминнарны бирүдә рус атамалары белән беррәттән татар сүзләрен бирү (җәя эчендә русча тәрҗемәләре белән) зур урын алган. Гомумән алганда, 20–30 нчы елларда татар студентларын рабфак һәм вузларга кабул итү арта, әзерлек төркемнәре өчен курслар оештырыла.



*Ә.Терегулов*

30 нчы еллар азагында илдә башланган Сталинның милли сәясәте, массакүләм репрессияләр татар мәгарифе үсешенә, аерым алганда югары уку йортларында татарча белем бирүгә, тискәре йогынты ясый: дәреслекләр чыгу туктатыла, күп атаклы педагоглар укыту эшеннән читләштерелә. Татар телендә югары белем бирү юнәлеше көн кадагыннан төшеп кала.

---

[195] Кириллова З.Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20–30 нчы еллаар). – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 43 б.

[196] Шнаси Г. Мохтасар химия. Кис. 1. – Казан: Юл, 1910. – 172 б.; Кис. 2. – Оренбург: Вакыт, 1912. – 106 б.; Мөштәри Х., Шнаси Г. Физика. Рабфаклар, II баскыч мәктәпләр, техникумнар һәм партия мәктәпләре өчен дәреслек: Үзлегеннән укучылар өчен ярдәмлек. Кис. 1. Механика, сыеклык, газлар. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1929. – 168 б.; Кис. 2. Молекулалар гипотезасы, җылылык, магнетизм, электрик. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1929. – 248 б.; Кис. 3. Тавыш, яктылык, гомумән тирбәнү хәрәкәте һәм радио. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1929. – 208 б.

[197] Терегулов Ә.Г. Гигиена (Хыйфзе сиххәт): Тәрбия-тәгълим техникумнары, гомуми урта мәктәпләр өчен дәреслек итеп төзелде. – Казан: Татар. матб. нәшр. комб., 1926. – 328 б.; Терегулов Ә.Г. Гигиена (Макушин, Крафт һ.б. буенча). – Казан: Татиздат, 1928. – 292 б.

## 2. Совет мәгарифе: татарлаштырудан үзәкләштерүгә таба (1938–1958)

Совет хөкүмәтенең егерменче еллар ахырында башлаган милләтләрне берләштерү, ил белән идарәне үзәкләштерү сәясәте сугыш алды елларына тагын да көчәя. Октябрь революциясеннән соң дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелгән татар теленең кулланылыш даирәсе бик нык тарая. 30 нчы елларның икенче яртысында рус теле дәүләт тарафыннан тормышның барлык өлкәләрендә дә киң кулланышка кертелә. Шулай ук мәгариф системасында да рус теленең ролен үстерү буенча эш алып барыла. 1938 елның 13 мартында кабул ителгән карар[198] моның ачык мисалы. Әлеге карар нигезендә, 1938 елның 1 сентябреннән милли мәктәпләрнең 2 сыйныфыннан мәҗбүри рәвештә рус телен укыту кертелә һәм аны укытуга сәгатьләр саны арттырыла. Барлык төр педагогия уку йортларында да мәҗбүри рәвештә рус теле укыла башлый.

Бөек Ватан сугышы елларында да рус телен өйрәтүгә нык басым ясала. Мәсәлән, 1943 елның гыйнвар аенда милли мәктәпләрдә рус телен укыту буенча укытучыларның һәм методистларның төбәкара конференцияләре уза. Конференциядә рус теле укытуның сыйфаты түбән булуы ачыклана. Бу кимчелекне бетерү өчен яңа программалар һәм дәреслекләр булдыру, укытучыларның белем дәрәҗәләрен күтәрү, методик эшне яхшырту һ.б. кирәк дип табыла[199]. Шул максаттан чыгып, 1946 елда Казан һәм Алабуга педагогия институтларында татар мәктәпләре өчен рус теле һәм әдәбияты укытучыларын хәзерләү буенча бүлекләр оештырыла. Ә 1951/52 уку елыннан татар мәктәпләрендә рус теле 1 нче сыйныфтан ук укытыла башлый.

---

[198] Постановление СНК СССР, ЦК ВКП(б) от 13.03.1938 N 324 «Об обязательном изучении русского языка в школах национальных республик и областей».

[199] Постановление Коллегии Наркомпроса РСФСР об итогах межобластного совещания учителей и методистов по вопросам преподавания русского языка в нерусских школах, проведенного в январе 1943 г. в гор. Казани // Культурное строительство в Татарии 1941–1970. Документы и материалы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. – С. 44–46.

Утызынчы еллар ахырында татар укучыларын рус теленә өйрәтү мәсьәләләре белән актив рәвештә М.Корбангалиев[200] һәм Р.Газизов[201] шөгыльләнәләр. Аларның җиңелдән авырга принцибын кулланып, татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүгә багышланган дәреслекләре берничә дистә еллар дәвамында төзәтмәләр кертелеп бастырылып килә. Р.С.Газизов тәкъдиме белән «Совет мәктәбе» журналында татар мәктәпләрендә рус телен өйрәнүгә багышланган махсус бүлек ачыла[202].

Хөкүмәт милләтләрне берләштерүнең, халыкларның мәгарифен һәм мәдәниятен интернациональләштерүнең төп юлын милли халыкларның алфавитын рус графикасына нигезләнгән алфавитка күчерүдә күрә. Нәтиҗәдә, 1938 елга илдәге 50 милләтнең язуы кириллицага күчерелә[203].

Әлеге сәясәт кысаларында 10 ел да кулланылышта булмаган латин алфавитын да кириллицага күчерү мәсьәләсе күтәрелә. 1939 елның 2 гыйнварында биш кеше катнашында уздырылган бюро утырышында «яшерен» грифы белән латин алфавитын кириллицага күчерү мәсьәләләре турында карар кабул ителә. Татар телендә кулланылачак алфавит һәм орфография кагыйдәләре буенча берничә проект тикшерелә (М.Фазлуллин, М.Корбангалиев, Ш.Рамазанов)[204]. М.Корбангалиев тарафыннан тәкъдим ителгән проектта татар теленең үзенчәлекле 6 авазына туры китереп ә, ө, ү, җ, ң, һ хәрефләре кертелә. Ш.Рамазанов проекты [w] авазын язу кайгыйдәләре белән генә аерылып тора. Нәтиҗәдә, Ш.Рамазанов проекты татар алфавиты буларак раслана[205]. ТАССР Югары Советы Президиумы Указы

---

[200] Курбангалиев М. Учебник русского языка для татарской начальной школы. – Казань: Татгосиздат, 1939. – 104 с.; Курбангалиев М. Учебник русского языка. 5-е издание. – Казань: Татгосиздат, 1942. – 138 с. һ.б.

[201] Газизов Р. Опыт практической сравнительной грамматики русского языка: Пособие для татарской средней и неполной средней школы. Ч.1. –Казань: Татгосиздат, 1939. – 277 с.; Русский язык: Учебник для 4-го класса татарской начальной школы. – Казань: Татгосиздат, 1947. – 271 с. һ.б.

[202] Шәкүрова М.М. Татар теле укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). – Казан: Ислах, 2012. – 74 б.

[203] Шамсутдинов Д.З. Татарская национальная школа ТАССР в конце 1950-х – 1970-х гг.: дис. ... канд. ист. наук. – Казань, 2014. – С. 30.

[204] Курбатов Х. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 104–105 б.

[205] Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Хәтер, 2001. – 43 б.

белән 1939 елның 5 маенда татар алфавиты кириллицага күчерелә. Яңа алфавит һәм орфографиягә күчүнең вакытын 1939–1940 еллар дип билгелиләр. Барлык мәктәп, техникум һәм югары уку йортларында яңа алфавит белән укыту 1939/40 уку елыннан башлана. Зурларны яңа алфавитка өйрәтү курслары 1939 елның 1 сентябреннән ачыла. Башка төрле курслар, матбугат һәм оешмалар яңа алфавитка 1940 елның 1 гыйнварыннан күчә[206].

Яңа алфавитта татар теленең барлык үзенчәлекләре дә исәпкә алынып бетми. Бу мәсьәлә кабаттан 1940 елның 5–9 июлендә Татарстан МХК белән Татарстан Тел һәм әдәбият фәнни-тикшеренү институты үткәргән грамматика һәм орфография фәнни конференциясендә карала һәм ТАССР Югары Советы Президиумының 1941 елның 10 гыйнвар карары белән яңа төзәтмәләр кертелә. Анда кайбер аныклаулар кабул ителсә дә, к-г хәрефләре, w фонемасы өчен аерым билге күрсәтелми[207]. Алдагы елларда да, милли телләргә игътибар киму сәбәпле, әлеге мәсьәлә чишелмичә кала килә. Гомумән, сугыш һәм сугыштан соңгы еллардагы тормыш авырлыгы, шәхес культы идарәчеләренең милли проблемаларга бәйле мәсьәләләрне иреккә куймаулары сәбәпле татар теленең дәрәҗәсе төшә, XX гасырның 60 нчы елларына кадәр татар теленә өйрәтү проблемаларына игътибар аз була[208].

Татар язуының ике мәртәбә үзгәрүе татар халкы мәгарифенә һәм мәдәниятенә тискәре йогынты ясый. Кириллицада укып үскән буын өчен күп гасырлар буе тупланып киленгән татар язма мирасы билгесез булып кала, барлык таләпләргә туры китереп гарәп һәм латин графикасында төзелгән дәреслекләр, кулланмалар, хрестоматияләр кулланыштан алына.

Сугыш башлану белән, илдәге тормышның барлык өлкәләре сугыш кирәгенә яраклаштырып үзгәртелә. 1941 елның җәеннән Татарстанга сугыш барган җирләрдә яшәгән кешеләр, күренекле галимнәр, язучылар эвакуацияләнә, куркыныч янаган сәнәгать оешмалары, завод-фабрикалар, фәнни институтлар күчерелә. Татарстан ӨК карары нигезендә эвакуацияләнгән балалар республиканың рус мәктәпләренә беркетеләләр. Төрле сәбәпләр аркасында рус мәктәп-

---

[206] Курбатов Х. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. – 105 б.

[207] Шунда ук. – 106–108 б.

[208] Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Хәтер, 2001. – 43 б.

ләренә урнаштыру мөмкин булмаган очракта, алар өчен татар мәктәпләрендә рус сыйныфлары ачыла[209].

Белем бирү оешмаларының эше дә тамырдан үзгәрә. Мәктәпләрнең күпчелеге эвакуацияләнгән оешмаларга тапшырыла яисә госпитальләр итеп файдалануга бирелә. Биналар җитешмәү сәбәпле, балалар 3 сменага бүленеп укырга мәҗбүр булалар, еш кына клуб, мәдәният йортларында шөгыльләнергә туры килә[210]. Ягулык булмау аркасында, укулар күп очракта җылытылмый торган биналарда үткәрелә, уку кирәк-яракларына зур кытлык туа, балалар еш авырый. Әлеге сәбәпләр аркасында, күп кенә балалар укуларын ташлыйлар. Чит авылларга йөреп укый торган балалар яшәргә интернат, кияргә кием булмау аркасында да укуларын ташларга мәҗбүр булалар. Нәтиҗәдә, мәктәптә укучы балаларның саны сугыш башлануның беренче өч елында бик нык кими. Шәһәр җирләрендәге тулы булмаган һәм урта мәктәпләрдә начар укыган укучыларны ФЗӨ һәм башка һөнәри уку йортларына күчерү дә мәктәптәге балалар санының кимүенә китерә. Республика буенча 1941 елда барлыгы 8 меңгә якын мәктәп яшендәге бала мәктәпкә йөрми[211].

Авыр шартларга карамастан, сугыш елларында Татарстанда татар мәктәпләренең саны арта. 1940/41 уку елында республикада 1641 татар мәктәбе булса, 1944/45 уку елында аларның саны 1791гә җитә[212]. Бу күренеш башлангыч мәктәпләрнең саны арту белән аңлатыла.

Сугыш башлану белән рәсми күрсәтмәләргә туры китерелеп, укыту планнары һәм программалары үзгәртелә. Кайбер фәннәрнең эчтәлегенә дә үзгәрешләр кертелә. Балаларда патриотизм хисе тәрбияләүгә нык басым ясала. Бу бигрәк тә тарих һәм әдәбият дәресләре, политинформация сәгатьләре аша алып барыла.

---

209 Культурное строительство в Татарии 1941–1970. Документы и материалы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. – С. 33–34.

210 Нам жить и помнить. Татарская АССР в годы Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.) / А.Ш. Кабирова, Е.Г. Кривоножкина, А.С. Бушуев; Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ. – Казань: Фолиант, 2016. – С. 184.

211 Кәбирова А.Ш. Ватан сугышы елларында – мәгариф // Мәгариф. – 1999. – № 11. – 75 б.

212 Евграфова О.Г. Деятельность ТИУУ в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. // Казанский педагогический журнал. – 2010. – № 2. – С. 164.



*Казанның 34 нче мәктәп укучылары гимнастика вакытында. 1944/45 уку елы*

Әдәбият дәресләрендә укучыларны совет патриотизмы рухында тәрбияләү мәсьәләләренә игътибарны тагын да көчәйтү кирәклегенә басым ясала. География дәресләрендә топографияне өйрәнүгә, физикадан элемтә һәм сигнализация чараларына, химиядән агулаучы матдәләр һәм аларга каршы көрәш чараларына һ.б. күбрәк урын бирелә. Тарих дәресләрендә 1812 елгы – Ватан, 1918–1920 еллардагы гражданнар сугышларын өйрәнүгә сәгатьләр саны арттырыла[213]. Ләкин татар халкы һәм ТАССР тарихы өйрәнелми. Гомумән, 40–50 еллардагы бердәм укыту программаларында милли тарихны өйрәнүгә сәгатьләр бөтенләй бирелми. Бу чорда татар халкы тарихы буенча мәгълүматларны бары әдәбият курсыннан гына алу мөмкин була[214].

Укучыларга хәрби-физик тәрбия бирүгә игътибар көчәя. 1941/42 уку елы башында гамәлгә кергән махсус карарлар нигезендә физкультура һәм хәрби эш дәресләре берләштерелеп, хәрби хәзерлек дәресләре дип йөртелә башлыйлар. Балаларның физиологик үзенчәлекләре

[213] Гыйльманов Җ. Сугыш елларында Татарстан мәктәпләре // Совет мәктәбе. – 1975. – № 5. – 12–15 б.

[214] Гибатдинов М.М. Преподавание истории татарского народа и Татарстана в общеобразовательной школе: история и современность. – Казань: Алма-Лит, 2003. – С. 56.

физик һәм хезмәт тәрбиясе бирүдә, хәрби хәзерлек дәресләрен алып барганда кыенлыклар тудыра дип, СССР ХКСы 1943 елның 16 июленнән тулы булмаган урта һәм урта мәктәпләрдә малайларны һәм кызларны аерым укыту турындагы карарны кабул итә. Укучыларны җенесләре буенча бүлеп укыту белем бирү процессын максатчан итеп оештырырга мөмкинлек бирә. Малайлар сафта йөрергә, төз атырга өйрәнә, кызлар исә санитария, гигиена буенча белем ала, телеграфчы, радист, сандружина хезмәткәре булырга әзерләнә[215].

Сугыш елларында ТУБКИ ТАССР ХМК белән берлектә укыту-тәрбия эшләрен хәрби юнәлештә оештыру юлларын, методларын күрсәтеп, РОНО җитәкчеләре һәм мәктәп директорлары белән җыелышлар уздыра, инспекторларга һәм укытучыларга семинарлар, курслар оештыра. 1941 елның көзеннән хәрби эш укытучылары өчен кыска вакытлы курслар уздырыла башлый[216].

Сугыш елларында мәктәпләрдә укытучылар җитешмәве тагын да ныграк сизелә башлый. Бу бер өлеш укытучыларның сугышка китүләре, ә бер өлеше башка эшкә күчерелү белән аңлатыла. Шуның өстенә педагогия уку йортларын бетереп чыгучылар саны да кими. МХКның 1941 елгы белдерүенә караганда, күп районнарда укытучылар җитмәү нык сизелә, ә эшләүче укытучыларга чиктән тыш күп дәресләр үткәрергә туры килә. Шуның белән бәйле рәвештә, Казан, Алабуга, Тәтеш, Мамадыш, Аксубайда рус һәм татар башлангыч мәктәпләре өчен укытучылар хәзерләү буенча өч айлык курслар оештырыла.

Ир-егет укытучыларның фронтка алынуы сәбәпле сугыш елларында мәктәптә хатын-кыз укытучыларның саны нык арта. Мәсәлән, 1943 елда Татарстан мәгариф учреждениеләрендә эшләүче барлык хезмәткәрләрнең 87%ы хатын-кызлар була. Сугыш ахырына (яраланып кайтучы солдатлар исәбенә) хатын-кыз укытучылар саны бераз кими, шулай да ул 74% тәшкил итә.

Галимнәрнең дә эш юнәлеше үзгәрә. Алар оборона өчен кирәкле өлкәләрне өйрәнәләр, төрле ачышлар ясыйлар. Бу елларда актив рәвештә хезмәт куйган татар галимнәреннән химик Г. Камайны, медиклар Ә. Терегуловны, Ф. Мөхәммәдъяровны, Г. Әхмәдуллинны, авыл хуҗалыгы өлкәсендә Х. Байчурованы, Ш. Вәлиевны, төбәктәге

---

[215] Кәбирова А.Ш. Ватан сугышы елларында – мәгариф // Мәгариф. – 1999. – № 11. – 76 б.

[216] Евграфова О.Г. Деятельность ТИУУ в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. // Казанский педагогический журнал. – 2010. – №2. – С.161.

нефть ятмаларын тикшерүчеләрдән Б. Йосыповны, Ф. Байбурова һ.б.ны атап үтәргә мөмкин.

Сугыш башлануның беренче елларында, халыкның патриотик рухын күтәрү максатыннан, илдә урнашкан идеологик басым бераз йомшара төшә. Дәүләт җитәкчеләренә социалистик системага туры килмәгән өстәмә чараларга таянырга туры килә. Дингә каршы пропаганда алып бару туктатыла, язучыларга ирекле иҗат итү мөмкинлеге ачыла, халыкларның милли рухын күтәрү максатыннан тарихта калган милли геройларның образларын тергезергә рөхсәт бирелә. Мәсәлән, татарларга Алтын Урда тарихына мөрәҗәгать итәргә, Урта гасырларда куәтле татар дәүләтләре булган вакытларны искә төшерергә, дошманнарга каршы батырларча көрәшкән милли геройлар образларын кайтарырга мөмкинлекләр туа.

Хөкүмәт тарафыннан төрле милләтләргә бирелгән ташламалар озак бармый, сугыш барышында җиңүләр күренә башлау белән дәүләт сәясәте кире элеккеге хәленә кайта. Алай гына да түгел, милли үзенчәлекләргә караган мәсьәләләргә мөнәсәбәт тагын да кырыслаша. 1944 елның август аенда «Татарстан партия оешмасында массакүләм сәяси, идеологик эшнең торышы һәм аны яктырту чаралары турында» карар кабул ителә. Бу карар, гомумән алганда, татар тарихын язганда аерым тарихчылар һәм әдәбиятчылар тарафыннан җибәрелгән милли характердагы хата һәм ялгышларны бетерүне, барлык алдынгылыкны рус халкы һәм Россия дәүләте роленә кайтарып калдыруны таләп итә. Халык дастаны «Идегәй» Алтын Урда чорын дөрес күрсәтми торган реакцион эчтәлекле әсәр дип бәяләнә. Казан ханлыгын «руслар яулап алуы» Рус дәүләте белән «кушылу» дип аңлатыла, аның татарлар өчен уңай әһәмияткә ия вакыйга булуы ассызыклана. Август карары нигезендә күп кенә мәгариф оешмаларының эш юнәлешләре үзгәртелә.

Әлеге карар нигезендә, ТАССР ӨК ныңТатарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтын (ТӘһСИ) җентекләп тикшерә һәм шул елның октябрь аенда ӨКның «Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты эшендәге хаталар һәм җитешсезлекләр турында» карар чыгара. Карарда Институт Татарстан тарихын язу буенча йөкләнгән бурычларны үтәмәгән, диелә. Институтның кайбер хезмәткәрләре милләтчелектә, интернационализм принципларыннан читләшүдә гаепләнә. Алга таба фәнни тикшеренүләр алып бару буенча юнәлешләр билгеләнә, нинди темаларны

күбрәк яктыртырга, кайсы шәхесләрнең эшчәнлегенә игътибар итәргә кирәклеге күрсәтелә[217].

Шулай итеп, август карары нигезендә татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча булган барлык тикшеренүләр җитди күзәтү астына алына, тарих партия дөрес дип тапкан күзлектән чыгып кына яктыртылырга тиеш була, татар әдәбиятында тарихи темаларны язуга цензура куела.

ВКП(б) ҮКның август карарыннан башланган идеологик басым ТӘһСИ галимнәренең 8 сыйныф укучылары өчен төзелгән татар әдәбиятыннан дәреслек-хрестоматиягә дә кагыла. Л.Җәләй авторлыгындагы дәреслек 1948 һәм 1952 елларда кискен тәнкыйть ителә. ӨК тарафыннан дәреслектә Мәүлә Колый, Габдрәхим Утыз Имәни, Габделҗәббар Кандалый кебек авторларга артык югары бәя бирелгән, татар халкы мәдәнияте тарихында исламның һәм суфичылыкның тискәре йогынтысы ачылмаган, җәдитчелек хәрәкәтенә дөрес бәя бирелмәгән, халык өчен зарарлы әсәрләр кертелгән, татар әдәбиятына рус әдәбияты тәэсире йомшак яктыртылган дигән карар чыга[218].

Әлеге дәреслек 1953 елда М.Гайнуллин һәм Х.Ярми авторлыгында астында яңадан бастырыла. Хәзер инде ул чор таләпләренә туры китерелеп төзелә. Идеологик караш дәреслекнең һәр җөмләсендә чагылыш таба, В.Ленин һәм И.Сталинның әдәбият турындагы «аеруча әһәмиятле фикерләре» һәрдаим калкытып куела. Шулай да, татар әдәби тәнкыйтенә нигез салучы булып, элеккечә, Г.Тукай исеме атала. Эчтәлеге татар халкының авыз иҗатына, XIX йөзнең татар әдәбиятына, татар драматургиясенең беренче үрнәкләренә, Заһир Бигиев белән Закир Һади иҗатларын ачуга нигезләнә. Шул ук вакытта рус язучыларының әсәрләре дә тәкъдим ителә[219].

Бу чорда ТӘһСИ галимнәре, аерым алганда әдәбиятчылары, дәреслекләр төзү эшен әйдәп баручылар була. Әлеге өлкәдә актив эшләүчеләр булып М.Гайнуллин, Х.Хәйри, Х.Ярми (алар 5 нче сый-

---

[217] Постановление «Об ошибках и недостатках в работе Татарского научно-исследовательского института языка, литературы и истории» // Ислам в татарском мире: история и современность (Материалы международного симпозиума, Казань 29 апреля – 1 мая 1996 г.). – Казань, 1997. – С. 338.

[218] Постановление от 18.01.1952 г. «Об ошибках в учебнике литературы для 8 класса татарских средних школ» // Ислам в татарском мире: история и современность (Материалы международного симпозиума, Казань 29 апреля – 1 мая 1996 г.). – Казань, 1997. – С. 361–364.

[219] Хәсәнова Ф.Ф. ТӘһСИ галимнәре дәреслек яза, яки әдәбият укытуны программалаштыру // Фәнни Татарстан. – 2014. – № 4. – 145–146 б.

ныфтан башлап әдәбият дәреслекләре яза), Х.Гали, Х.Хисмәтуллин, Г.Кашшаф торалар[220].

Элеккеге еллардан аермалы буларак, илленче елларда татар әдәбияты программаларына тарихи жанрдагы, мәсәлән, гражданнар сугышы чорын чагылдырган, Февраль һәм Октябрь революцияләре елларындагы сыйнфый каршылыкларны сурәтләгән, революция каһарманнарына мәхәббәт тойгысы тәрбияләүне күз алдында тоткан, милли азатлык һәм халыклар дуслыгы темаларын яктырткан әсәрләр кертелә[221]. Күренгәнчә, тарихи темалар балаларга патриотик тәрбия бирү максатыннан чыгып сайланылган.



*Сәйфуллин Г. Әлифба. 1953 ел*

40–50 елларда, гомумән, укытучы алдына балаларда Туган илгә мәхәббәт, совет патриотизмы тәрбияләү бурычы куела. Ул дәресне белем бирү генә түгел, тиешле тәрбия йогынтысы ясарлык итеп тә үткәрергә тиеш була. Патриотизм тәрбиясе бирүгә, бигрәк тә тарих, география, табигать белеме, туган тел дәресләре булышлык итә. Башлангыч сыйныфларда Ә.Исхакның «Мактан илем», К.Нәҗминең «Казанга кайту», М.Максудның «Москвага дан җыры», Г.Кутуйның «Сталинга сәлам», Ә.Ерикәйнең «Сталинград» әсәрләре, ә югарырак сыйныфларда Г.Бәшировның «Намус» әсәре, М.Әмирнең «Агыйдел» повесте, Г.Тукайның «Китмибез» шигырьләре балаларда совет патриотизмы тәрбияләү өчен яхшы материал булып тора дип санала[222].

Бу елларда шулай ук интернационализм, халыклар дуслыгы хисләре тәрбияләүгә зур урын бирелә. Ләкин интернационализм аның классик бирелешендә, төрле милләт халыкларының дуслыгында, аларның хезмәттәшлегендә түгел, ә Россия территориясендә яшә-

---

[220] Кашшаф Г. Татар совет әдәбияты. X класс өчен дәреслек. – Казан: Таткнигоиздат, 1955. – 282 б.; XX йөз башында татар әдәбияты / Г.Хәлит, Х.Хисмәтуллин, Б.Гыйззәт. – Казан: Матур әдәбият редакциясе, 1954. – 386 б. һ.б.

[221] Зарипова А.М. Татар әдәбияты дәресләрендә тарихи эчтәлекле әсәрләр укыту методикасы: тарихы һәм үсеш баскычлары. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 69–70 б.

[222] Замов К. Балаларда совет патриотизмы тәрбияләү мәсьәләсенә карата // Совет мәктәбе. – 1951. – № 5. – 11–13 б.

гән халыкларны рус милләте кысаларына кертү юнәлешендә алып барыла. Ягъни бу чорда да «интернационализм» лозунгы астында уздырылган руслаштыру сәясәте дәвам итә.

Күренгәнчә, совет хөкүмәте төрле юллар белән совет дәүләтенең, коммунистлар партиясенең, совет кешесенең абруен күтәргә, балаларда патриотизм, «интернационализм» хисләре, революцияләргә кадәр булган чорга тискәре караш тәрбияләргә омтылган.

Илленче еллар уртасында ил күләмендә, шул исәптән Татарстанда да, милли мәктәпләрнең саны кими. Әгәр 1949/50 уку елында Татарстанда 258,3 мең укучы белән 1749 татар мәктәбе булса, 1956/57 уку елына 127220 бала белән 1474 мәктәп кала[223]. Шулай ук башка төбәкләрдә дә татар мәктәпләрен кыскарту процессы бара. Мәсәлән, бу чорда Казахстанда бер генә татар мәктәбе дә калмый. Бу, беренче чиратта, милли телләрнең куллану өлкәләре таралю, хөкүмәт тарафыннан милли үзенчәлекләргә игътибар кимү, «интернациональләштерү» сәясәтенең киң җәелүе белән аңлатыла. Уку-укыту эшләре үзәктән килгән бердәм карарлар нигезендә алып барыла, мәктәп программаларыннан туган якны өйрәнү дәресләре алына. Милли мәктәпләрдә күбесенчә түбән сыйфатлы тәрҗемә дәреслекләр кулланыла. Татарстанда татар теленнән һәм әдәбиятыннан өлгергәнлек аттестатына куела торган чыгарылыш имтиханы бетерелә. Милли мәктәпләр шулай ук матди яктан да начар тәэмин ителәләр. Мәсәлән, шәһәрләрдә күпчелек татар мәктәпләре авария хәлендәге биналарда урнашкан була. Татар мәктәпләренең күбесендә, бигрәк тә авыл җирләрендә, квалификацияле укытучылар җитешми. Бу сәбәпләр милли мәктәпләрнең дәрәҗәсе төшүгә китерә.

Югары уку йортларына укырга кергәндә дә татар балалары өчен өстәмә кыенлыклар тудырыла. Керү имтиханнары рус телендә уза, һәм алар татар телендә белем алган балаларның үзенчәлекләрен исәпкә алмыйлар. Татарлар югары уку йортларына кергән очракта да, күбрәк төрле квоталар буенча, рус балалары кызыксынмаган, авыл хуҗалыгы яки милли төркемнәр булган педагогия өлкәсенә баралар[224]. Мәсәлән, 1957 елда КДУның беренче курсына 173 татар

---

[223] Шамсутдинов Д.З. Татарская национальная школа ТАССР в конце 1950-х – 1970-е гг.: дис. … канд. ист. наук. – Казань, 1914. – С. 45.

[224] Шунда ук. – С. 46.

алына, тик аларның 27се генә татар мәктәбен тәмамлаган, аларның да 24 е – татар теле бүлегенә алынучылар була[225].

Татар теленең һәрьяклап кысылуы һәм хөкүмәт башлыкларының рус халкын һәм рус телен өстен куюлары нәтиҗәсендә ата-аналарның күпчелеге туган телне камил белүнең киләчәге юк дип санап, балаларын рус мәктәпләренә яки милли мәктәпләрдә ачылган рус сыйныфларына бирергә омтыла. Әлеге күренеш шәһәр җирләрендә генә түгел, ә авыл һәм эшче поселокларында да киң тарала[226].

Сугыштан соңгы елларда татарларга рус телен, телнең аерым бүлекләрен укыту методикасы фәнни яктан ныклап өйрәнелә башлый[227].

Р.С.Газизов бу чорда рус теле укыту методикасы буенча иң актив эшләгән авторларның берсе. Ул М.Ш.Субаева, И.И.Назаров З.Г.Максудовалар һ.б. белән берлектә рус теленнән яңа дәреслекләр төзеп бастыра[228]. V–X сыйныфлар өчен рус теле һәм әдәбияты дәреслекләре яңадан карап чыгыла, сыйныфтан тыш уку өчен русча китаплар сериясе, русча-татарча сүзлек, I–V сыйныфлар өчен сүзлек

---

[225] Галлямова А.Г. «Почему же бояться своего родного языка?» (Из стенограммы заседания бюро Татарского обкома КПСС 28 апреля 1958 г.) // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2013. – № 1/2. – С. 69.

[226] Шунда ук. – С. 70.

[227] Газизов Р. Опыт практической сравнительной грамматики русского языка: Пособие для татарской средней и неполной средней школы. Ч.1. – Казань: Татгосиздат, 1939. – 277 с.; Чистяков В.М. Основы методики русского языка в нерусских школах. – Рига: Латгосиздат, 1949. – 580 с.; Бакеева Н.З. О преподавании русского глагола в V–VII классах татарской школы. – Казань: Татгосиздат, 1951. – 136 с.; Субаева М.Ш. Обучение русскому ударению в татарской школе. – Казань: Таткнигоиздат, 1956. – 62 с.; Гарифьянова Р.Б. Причастие русского языка в VI классе татарской школы. – Казань: Таткнигоиздат, 1957. – 11 с. һ.б.

[228] Газизов Р.С. Учебник для начальных татарских школ: Для 2-го класса (соавтор – Чистяков В.М.). – Казань: Татгосиздат, 1946. – 215 с.; Газизов Р.С. Учебник русского языка для татарских школ: Синтаксис: для 6–7 классов (соавторы – Назаров И.И.; Максудова З.А.). – Казань: Татгосиздат, 1951. – 200 с.; Максудова З.Г. Книга для чтения по русскому языку. Для татарской школы. Ч. 3. Для 7 класса. – Казань: Татгосиздат, 1948. – 417 с.; Максудова З.Г. Учебник русского языка. Ч. 2. Синтаксис для 7 класса татарской семилетней и средней школы (соавторы – Газизов Р.С., Назаров И.). – Казань: Таткнигоиздат, 1958. – 147 с. һ.б.

минимумы, грамматик таблицалар бастырып чыгарыла, методик кулланмалар[229] әзерләнә.

50 еллар уртасыннан илдә идарә үзгәргәч, демократия чаткылары күренә башлый. Шул елларда татар җәмгатьчелеге Татарстанның статусын, татар теленең дәрәҗәсен күтәрүгә омтылыш ясый. Республикада татар теленең куелышы белән канәгать булмаган татар зыялылары татар әдәбияты һәм мәдәнияте үсешенә ясалма киртәләр тудырылу, аңа партия һәм хөкүмәт вәкилләре тарафыннан тиешле игътибар булмау, татар мәктәпләренең саны кимү, татар теленең кимсетелүе турында борчылып, 1954 елның ноябрь аенда КПСС ҮКна хат юллыйлар. Бу кимчелекләрне авторлар Татарстанның статусы түбән булу белән аңлаталар. Шундый зур һәм бай республика автономияле генә түгел, ә союздаш булырга хокуклы дип саныйлар. Үзенең хокукларыннан мәхрүм булган татар халкы туган телен тиешенчә файдалана алмый: татар мәктәпләренең санын арттыра һәм фәнни кадрлар хәзерли алмый, диләр[230]. Ләкин КПССның ӨК беренче секретаре З.И.Моратов, милләтчелектә гаепләнүдән куркып, милли мәктәпләр турындагы мәсьәләне кузгатмый[231]. Шулай итеп, татар мәктәбенең язмышы тагын үзгәрешсез кала.

1957 елда Мәскәүдә Татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы уңышлы гына үтә. Әлеге чарадан соң татар зыялылары татар теленең һәм бөтен милли мәдәниятнең дәрәҗәсен күтәрүгә тагын бер омтылыш ясый. Бу юлы республикада татар теленең дәрәҗәсе түбән булуы өлкә җитәкчеләре тарафыннан да таныла. Республикада тел сәясәтенең торышы С.Д. Игнатьев җитәкчелеккә килгәннән соң үзгәрә башлый: гарәп-фарсы алынмаларын татар теленә кайтару буенча терминологик комиссия төзелә, татар мәдәнияте өлкәсендә аерым казанышлар өчен Г.Тукай исемендәге бүләк булдырыла, мәктәптән тыш тәрбия эшләрен татар телендә оештыру буенча чаралар комплексы кабул ителә һ.б.

С.Д.Игнатьев мөрәҗәгате буенча республикада татар теле торышын өйрәнү буенча КПСС ҮКның фән, мәктәп һәм мәдәният

---

[229] «I классларда рус теленнән сөйләм телен үстерү дәресләре», «Татар мәктәпләренең II классы рус теле дәреслеге белән эшләү буенча методик күрсәтмәләр», «Татар мәктәпләренең VI классында рус теле дәресләре» һ.б.

[230] Фасеев К. Вспоминая прошедшее. – Казань: Изд-во Казанского ун-та, 1999. – С. 36–39.

[231] Галлямова А.Г. «Почему же бояться своего родного языка?» (Из стенограммы заседания бюро Татарского обкома КПСС 28 апреля 1958 г.) // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2013. – № 1/2. – С. 69.

бүлеге мөдире урынбасары В.Н.Дербинов җитәкчелегендә комиссия төзелә. Комиссия мәсьәләне һәрьяклап өйрәнгәннән соң, 1958 елның апрелендә узган ӨК җыелышында эш нәтиҗәләрен җиткерә. В.Н.Дербинов кичекмәстән республика күләмендә татар телен һәм әдәбиятын укытуның дәрәҗәсен күтәрергә, татар мәктәпләренең матди-техник һәм укыту-методик базаларын, укытучылар составын яхшыртырга кирәклеген дәлилли, абитуриентлар теләге белән вузлар һәм техникумнарга керү имтиханнарын татар телендә оештыру, милли мәктәп мәсьәләләрен фәнни яктан өйрәнү кирәклеген ассызыклый. Хәзерге күзлектән чыгып карасак, В.Н.Дербиновның тәкъдимнәре милли белем бирү системасын үстерү концепциясе сыйфатында китерелгән дияргә мөмкин[232].

В.Н.Дербинов чыгышы КПСС ӨК пленумының «Татар гомуми белем бирү мәктәпләрендә эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында»гы (1958, май) карарына нигез булып тора. Карарда татар телен һәм мәдәниятен торгызу, татар балаларының белем дәрәҗәләрен күтәрүгә басым ясала. Татар мәктәпләрендә рус телен укыту түбән дәрәҗәдә булганлыктан, бу мәсьәләгә аеруча зур игътибар бирелә.

Карарда мәктәпләрне югары квалификацияле рус теле укытучылары белән тәэмин итү, уку-укыту планнарын, программаларын, дәреслекләрен камилләштерү, рус теле дәресләрендә күбрәк практик күнегүләргә һәм сөйләм телен үстерүгә игътибарны арттыру, 5–7 нче сыйныфларда рус телен укытуга сәгатьләр санын арттыру максаты белән татар мәктәпләрендә чит телне 8 нче сыйныфтан гына укыта башлау кирәк дип табыла. Татар балаларында русча сүзлек байлыгын һәм сөйләм телен яхшырту теләге белән татар мәктәпләренең 8–10 нчы сыйныфларында физика, математика, химия кебек фәннәрне рус телен яхшы белгән, югары квалификацияле укытучылар тарафыннан рус телендә алып бару тәкъдим ителә.

Татар телен һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын арттыру өчен балаларда татар теленә карата хөрмәт һәм кызыксыну уятырга, татар әдәбиятыннан өлгергәнлек аттестатына куела торган чыгарылыш имтиханын торгызырга, татар теленнән һәм әдәбиятыннан укыту планнарын һәм программаларын камилләштерергә, мәктәпләрне югары белемле татар теле укытучылары белән тәэмин итәргә, рус мәктәпләрендә һәм рус сыйныфларында белем алган татар балаларына татар теле һәм әдәбияты дәресләре укытуны кертергә кирәк, диелә[233].

---

[232] Шунда ук. – С. 70.

[233] Документы актуальные и сейчас. О статусе татарского языка по документам 50-х гг. // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1996. – № 1/2. – С. 108–115.

Илленче еллар ахырына Татарстан республикасындагы милли проблемаларны ачыклау буенча үткәрелгән чаралар милли сәясәтне үзгәртү, татар теленең статусын күтәрү кирәклеген билгели алсалар да, алар тормышка ашырылмый кала. Май пленумы карары Мәскәү басымы белән дөрес түгел һәм анда җитди кимчелекләр җибәрелгән дип табыла. Бу кимчелекләр түбәндәгеләрдән гыйбарәт: татар ата-аналарын балаларын рус мәктәпләренә бирүдә гаепләү; татар мәктәпләрендә рус сыйныфларын ачуны дөрес түгел дип санау; халык мәгарифе органнарының һәм югары белем бирү оешмалары җитәкчеләренең барлык югары уку йортларында, рус мәктәпләрендә һәм катнаш сыйныфларда татар балалары өчен татар телен һәм әдәбиятын укытуны торгызу һәм алардан имтихан кертү[234].

Шулай итеп, татар телен һәм татар мәдәниятен торгызуга юнәлдерелгән күтәрелеш «интернационализм» идеяләре басымы белән бастырыла. Әлеге күтәрелеш тарафдарлары милләтчелектә гаепләнә.

Гомумән, 30 елларның урталарында илдә башланган сәяси вәзгыять бу чорда тагын да кискенләшә, мәгариф өлкәсендә төп игътибар рус теленә юнәлтелә, татар теленең дәрәҗәсе төшә, татар мәктәпләренең саны кими һәм алар башлыча авыл җирләрендә генә саклanып кала, татар мәгарифе идеологик киртәләр эченә кертелә.

## 3. Бердәм совет халкы төзү чорында татар мәгарифе (1958–1989)

1958–1989 елларда татар педагогик фикерендә җитди үзгәрешләр күзәтелмәсә дә, гомумән мәгариф системасында яңарышлар шактый була. Алар Республикадагы мәктәпкәчә тәрбия, гомуми белем, һөнәри-техник, махсус урта белем һәм югары мәктәп системасында чагылыш таба.

1958 елның декабрендә СССР Югары Советы сессиясе илдә урта белем бирү системасын үзгәртеп кору турында закон кабул итә. «СССРда мәктәпнең тормыш белән бәйләнешен ныгыту һәм халык мәгарифе системасын тагын да үстерү турында»гы закон кабул ителгәннән соң, совет мәктәбе тарихында яңа чор ачыла. Мәгълүм булганча, бу закон укытуны җитештерүчән хезмәт («тормыш») бе-

[234] Семен Игнатьев: как главу Татарии наказали за татарский язык [Электронный ресурс]. URL: http://www.business-gazeta.ru/article/136816

лән тыгыз бәйләп баруны күздә тота. Гомуми белем мәктәпләрендә политехник белем бирү, укытуны тормыш белән бәйләү, укучыларны практик хезмәткә хәзерләү төп бурыч итеп куела. Ил күләмендә сигезьеллык мәҗбүри укытуга күчерү эше башлана. Әлеге закон ата-аналарга балаларын үзләре сайлаган телдә укыту хокукын бирә.

Үз чиратында, партиянең халык мәгарифе мәсьәләләренә кагылышлы күрсәтмәсен тормышка ашырып, Татарстан АССР Югары Советының мәктәпләрне җидееллык укытудан сигезьеллык мәҗбүри укытуга күчерү турындагы карары дөнья күрә[235].

Указ нигезендә урта белемне кичке гомуми урта белем, политехника мәктәпләрендә, техникумнарда һәм башка махсус урта уку йортларында алырга мөмкин була. Үткәрелгән чаралар укучыларның ихтыяҗларын асылда исәпкә алмый. Нәтиҗәдә, урта мәктәпне тәмамлаучы үсмерләрнең күпчелеге алынган һөнәрләре буенча эшкә урнашырга теләми. Шул рәвешле, 1966 елдан мәктәптә һөнәри белгечләр әзерләү туктатыла, унберьеллык мәктәп унъеллык итеп үзгәртелә[236].



*Татар мәктәбе укучысы Л.Әхмәрова. Казан, 1954 ел*

1970 елда «Гомуми урта белем мәктәбе уставы» дөнья күрә. Уставта СССРда гомуми урта белем мәктәбенең бердәм, хезмәт, политехника мәктәбе булып торуы, аның төп бурычлары билгеләнә[237]. КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар советы «Яшьләргә гомуми урта белем бирүгә күчүне тәгәлләү һәм гомуми урта белем мәктәбен тагын да үстерү турында»гы (20 июнь, 1972) карарында мәҗбүри гомуми урта белем бирүгә күчүне 1975 елда тәгәлләү бурычын куя.

Гәрчә дәүләтнең рәсми сәясәте азчылык милләтләрнең мәдәни үсешен таныса да, гамәлдә төп игътибар җәмгыятьтә идеологик бердәмлеккә ирешү, рус теле нигезендә «бердәм совет халкын» барлык-

[235] ТАССРның бишенче чакырылыш Верховный Советының икенче сессиясе. Карар. Татарстан АССРда мәктәпнең тормыш белән элемтәсен ныгыту һәм халык мәгарифен тагын да үстерү турында. – Казан, 1959. – 5 б.

[236] Шакиров Р.В. Казанская педагогическая школа во второй половине XX века. – Казань, 1999. – С. 138.

[237] Гомуми урта белем мәктәбе уставы. – Казан, 1971. – 40 б.

ка китерүгә юнәлдерелгән була. 1950 елларның икенче яртысы – 1960 елларда совет мәктәбе системасының үзенчәлеге – мәктәпләрнең милли йөзе югалуда. Балаларны ана телендә укыту мөмкинлеге сакланса да, милли мәктәпләр, анда укучы балалар саны елдан-ел кими бара. Республиканың башкаласы Казанда татар мәктәпләренең абруе төшә бару 50 нче еллар башыннан ук күзәтелә. Мисал өчен, сугыштан соңгы елларда Казан шәһәрендә 12 татар мәктәбе эшләсә, 1960 еллар уртасында – 5, ә 1980 еллар башына бары 2 татар мәктәбе сакланып кала[238]. 1957/58 уку елында Татарстандагы татар балаларының 70, ә башкалада 16,8%ы гына ана телендә белем ала. Татар мәктәпләрендә дә рус сыйныфлары ачыла, аерым фәннәр рус телендә укытыла башлый. РСФСР составына кергән барлык республикаларда милли мәктәпләрнең язмышы шул ук хәлдә. Тубылдагы бердәнбер татар мәктәбе дә үзенең милли йөзен югалта: 1961 елдан укыту рус мәктәбе программасы буенча алып барыла башлый[239]. Милли мәктәпләрнең әһәмияте кимү сәбәпле, татар педагогик кадрларын хәзерләүгә ихтыяҗ кими. Тубыл педагогия институтының 1959 елда татар, 1965 елда рус-татар бүлеге ябыла. Әгәр 1951 елда Төмән өлкәсендә 152 татар мәктәбе булса, 1990 елда бары тик 93 кенә кала[240] (укучы балалар саны 37%ка кими). 1968 елда Оренбугта уку-укыту татар телендә алып барылган соңгы татар мәктәбе ябыла[241]. 1969 елның июнь азагында Ульяновск шәһәрендә бердәнбер сакланып калган милли мәктәп – 27 нче номерлы сигезьеллык мәктәпнең дә эшчәнлеге туктатыла[242]. Илленче елларда Башкортстанда 1200 татар мәктәбе булса, сиксәненче еллар башына аларның саны

---

[238] Шамсутдинов Д.З. Татарская национальная школа ТАССР в конце 1950-х – 1970-е гг.: дис. … канд. ист. наук. – Казань, 1914. – С. 60; Шамсутдинов Д.З., Шайдуллин Р.В. Татарская национальная школа в СССР в конце 1950-х – начале 1960-х гг. // Симбирский научный вестник. – 2012. – № 1(7). – С. 91.

[239] Хисаметдинова Г.С. Этнообразовательная политика советского государства в 1920–1960-е гг. и состояние национальных школ сибирских татар // Сибирский сборник. – Казань: ЯЗ, 2011. – С. 104.

[240] Шунда ук. – С. 103, 105.

[241] Федорова А.В. Народы Южного Урала: этнический взгляд на историю. – [Электрон. ресурс]. URL: http://artlib.osu.ru/web/books/fedorova/ book0302.pdf (дата обращения 29.06.2017).

[242] Садыкова Р.К. Роль татарских меценатов второй половины XIX – начала XX века в развитии национального образования города Симбирска // Симбирский научный вестник. – 2016. – № 1 (23). – С. 183.

алты мәртәбә кыскара[243]. Бу елларда ил күләмендә махсус урта уку йортларындагы татар төркемнәре ябыла. Югары һәм махсус урта уку йортларына керү имтиханнары рәсми рәвештә рус телендә генә үткәрелә.

Ни өчен татар ата-аналарының игътибарын рус мәктәпләре җәлеп иткән? Ни өчен татар мәктәпләренең югары сыйныф укучылары күп кенә фәннәр буенча рус телендә белем алган соң? Моның сәбәпләре берничә булырга мөмкин.

Баласына гыйлем-тәрбияне туган телендә бирү теләге ата-аналарның күбесендә булса да, балаларына «якты киләчәк», «яңа үрләр яулауларын» теләп, алар балаларын рус мәктәбенә бирәләр. Рус мәктәпләренә бирүләренең төп сәбәбе: балаларының югары уку йортларында укый алырлык дәрәҗәдә рус телен өйрәнүләре. Татар яшьләренең рус телен белмәү яисә начар белүләре югары һәм урта белем алуга рус теле буенча киртә куя. Әйтик, 1947 елда мәктәпне тәмамлаучыларның якынча 18%ы рус теленнән имтихан тапшыра алмау сәбәпле, югары уку йортларына керә алмаган[244]. Шунлыктан, милли татар мәктәпләре, анда укучы балалар саны шактый кими. Әгәр 1947/48 уку елында республикадагы татар балаларының 95%ы ана телендә белем алса, 1957/58 уку елында бу сан 70%ка кадәр түбәнәя. 1958 елга Казанда бары ике генә татар мәктәбе сакланып кала[245]. Димәк, сугыштан соңгы 1945/46 уку елы белән чагыштырганда, аларның башкаладагы саны 8 мәртәбә кыскара.

Укытучы кадрларны хәзерләүгә игътибар азая, туган телләрдә дәреслекләр, методик ярдәмлекләр, әдәби китап бастыру кими, милли мәктәпләрнең күпчелеге иске, ягъни 30–40 нчы елларда нәшер ителгән әсбаплар кулланырга мәҗбүр була[246]. Әлеге кимчелекләр белем бирүнең сыйфатына тискәре йогынты ясый.

---

[243] Сибәгатов Р.Г. Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 85 б.

[244] Галлямова А.Г. Кризис национальной самоидентификации татар в 40–70-е гг. XX в. // Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность (материалы Международной тюркологической конференции, проходившей 9–13 июня 1992 г. в г. Казань). Т. 3. – М., 1997. – С. 97.

[245] Хаплехамитов Р.Б. Национальная интеллигенция и проблемы образования (1944–1960 гг.) // Казанский педагогический журнал. – 2006. – № 5. – С. 51.

[246] Шамсутдинов Д.З., Шайдуллин Р.В. Особенности развития татарской национальной школы в ТАССР в 50–60-е годы XX века // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. – 2012. – Т. 154, кн. 3.– С. 99.

Татар теле һәм әдәбиятын укытуның сыйфаты түбән дәрәҗәдә була. Татар булмаганнарга татар телен өйрәтү мәсьәләсенә игътибар бирелми. 60 нчы еллар башында Р.С.Газизовның «Татарский язык» китабы дөнья күрә. Дәреслек татар һәм рус телләрен чагыштыруга нигезләнеп төзелгән. Дәреслектә теоретик материал махсус күнегүләрдәге мисаллар белән дәлилләнеп бара. Галимнәр фикеренчә, дәреслек грамматик яктан көчле булса да, татарча сөйләшергә өйрәтүгә барып җитә алмый. Шулай да, 70 нче елларга хәтле Р.С.Газизовның бу китабы шул чорда татар теленә өйрәнүгә багышланган бердәнбер дәреслек буларак яшәп килә[247].

Бер яктан, башка милли мәктәпләрнең уку планнары белән чагыштырганда, татар теле һәм әдәбияты фәненә бирелгән сәгатьләр саны беренче урында тора. Татар мәктәпләренең гамәлдәге уку планында ана телен һәм әдәбиятын өйрәнүгә 17,1% урын, ягъни ун ел буена 1732 сәгать вакыт бирелә. Мәсәлән, ана телен һәм әдәбиятны өйрәнүгә башкорт мәктәбендә 1716 сәгать, чуваш мәктәбендә – 1635 сәгать, мари мәктәбендә – 1551 сәгать, мордва мәктәбендә – 1468 сәгать карала[248]. ТАССР Мәгариф министрлыгы тарафыннан татар мәктәпләрендә ана теле һәм әдәбиятын укытуның торышын тикшерү нәтиҗәләрендә, бу өлкәдә җитди кимчелекләр булганлыгы ачыктан-ачык әйтелә. Методик аспекттан караганда, татар теле һәм әдәбияты дәресләренең түбән дәрәҗәсе, түгәрәкләрнең кәгазьдә генә күрсәтелүе, әдәби темага фикер алышулар, язучылар белән очрашулар үткәрелмәү, китапханәләрнең күпчелегенең татар әдәби китапларына ярлы булуы төп җитешсез яклар булып санала. Моннан тыш, бердәм тел режимы үтәлмәгәнлеге дә ачыклана. Мәсәлән, шигарьләр (лозунглар), белдерүләр, кабинет исемнәре һ.б. рус телендә генә язылган, ә укытучылар, шул исәптән татар теле белгечләре дә, татар әдәби теле нормаларын игътибарга алмаган очраклар билгеләнә[249]. ТАССР Мәгариф министрлыгы каршындагы Халык мәгарифе советы 1958/59 уку елыннан башлап, 10 нчы сыйныфта татар әдәбиятыннан өлгергәнлек аттестатына язма имтихан алуны яңадан кертү зарурлыгын ассызыклый. Шунысы күренеп тора: методик әсбапларга мохтаҗлык үсү белән, һичшиксез, бу өлкәдә ярдәм итәргә ти-

[247] Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Хәтер, 2001. – 44 б.

[248] Республика мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укытуның торышы турында (Татарстан АССР Мәгариф министрлыгы каршындагы Халык мәгарифе советының 1958 ел 14 нче март карары). – Казан, 1958. – 3 б.

[249] Шунда ук. – 5–7 б.

ешле фәнни-тикшеренү үзәген оештыру мәсьәләсе, бигрәк тә укытуның эчтәлеген гомумиләштерү шартларында, кискенләшә.

Татар милли мәктәбе тарихында тирән эз калдырган оешмаларның берсе – 1961 елда Казанда оештырылган РСФСР Педагогик фәннәр академиясе милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институтының Татарстан филиалы татар мәгариф үсешенә өлеш кертә. Аның беренче мөдире итеп милли мәктәпләрдә рус теле укыту методикасы өлкәсендә эшләүче иң зур белгечләрнең берсе Л.З. Шакирова билгеләнә, ә 1963 елның апреленнән 1984 елга кадәр бу вазифаны Г.А. Жданова башкара. Филиал эшчәнлегенең төп юнәлеше милли мәктәпкә караган гомуми педагогик мәсьәләләрне һәм татар мәктәпләрендә рус һәм ана телләрен, әдәбиятларын укытуның эчтәлеген һәм методикасын билгеләүдән, республикадагы мәгариф һәм фәнни-педагогик учреждениеләргә, методистларга ярдәм итүдән гыйбарәт була. Биредә укыту барышында ана һәм рус телләренең үзара йогынтысы мәсьәләләре дә тикшерелә. Әлеге фәнни оешманың хасияте, әлбәттә, аның мәктәпләр белән тыгыз бәйләнешенә нигезләнүендә.



*Г.Жданова*

XX гасырның 60 нчы елларында мәктәп мәгарифенең төп проблемасы – тормышның мәктәптән аерылганлыгында, чыгарылыш сыйныф укучыларының практик эшчәнлеккә әзерлексез булуында чагылыш таба. Бу чорда яңадан кертелгән «җәмгыять белеме» предметы әлеге кимчелекләрне хәл итәргә тиеш була.

1956 елда уздырылган XX съезд Сталинның шәхес культыннан арыну процессына этәргеч бирә. Илдә демократик үзгәрешләр башлана. Әдәбиятта, рәсем сәнгатендә, скульптурада совет чынбарлыгының каршылыкларын дөрес чагылдыручы әсәрләр дөнья күрә башлый. Бу, үз чиратында, яшь буында коммунистик идеалларга һәм КПСС эшчәнлегенә карата шик тудыра. Яшьләр арасында партиянең идеологик нигезләрен ныгыту җәмгыять белеме фәненә йөкләтелә. КПСС БК курсның төп бурычлырын «кешелек тарихы практикасында укучыларга марксистик-ленинчыл идеяләрнең өстенлеген, социалистик төзелешнең һәм коммунистик идеологиянең капи-

талистик төзелеш һәм буржуаз идеологиядән өстенлеген күрсәтүе» дип билгели[250].

Өч еллык эксперименттан соң, 1962/63 уку елының икенче яртысыннан урта мәктәпләрнең чыгарылыш сыйныфында җәмгыять белеме курсы укытыла башлый. Башта ул «Политик белем нигезләре» дип йөртелә.

Җәмгыять белеме курсын укыту совет чынбарлыгын якыннан торып күзәтүдә, үсеп килүче яшь буынга коммунистик тәрбия бирүдә зур роль уйнарга тиеш була. Бу фәнне җирле материалларга, укучылар производствода өйрәнә торган теге яки бу оешма, район, шәһәр, республика тормышына бәйләп укытуның аеруча әһәмиятле булуы ассызыклана.

Җәмгыять белеме фәненең формалашуы илдә барган процесслар белән тыгыз бәйләнгән, шунлыктан реаль чынбарлык шартларында эш иткән укытучылар әлеге фәнне укытуның тормыш, коммунистик төзелеш практикасы белән бәйлелеген ассызыклыйлар. Укыту-тәрбиядә конференцияләр, диспутлар, атаклы шәхесләр, предприятиеләр, оешмалар җитәкчеләре белән очрашу һәм дәресләрне турыдан-туры предприятиеләрдә алып баруга игътибар бирелә. Әмма җәмгыять белеме дәресләре нигездә сөйләү һәм лекция методы белән алып барыла. Моннан тыш, укытучылар КПСС съездлары материалларына зур игътибар бирәләр. Алар фикеренчә, чорның иң әһәмиятле документлары булган бу материаллар яшь буынга дөньяга фәнни караш, коммунизм эшенә бирелгәнлек, Ватаныбызга һәм героик совет халкына мәхәббәт тәрбияләргә ярдәм итә[251].

Илнең сәяси тормышындагы барлык үзгәрешләр җәмгыять белеме курсына да турыдан-туры тәэсир иткән. Утыз ел эчендә «Җәмгыять белеме» дәреслегенең 23 өстәмә басмасы дөнья күрә.

1968/69 уку елы программасында беренче тапкыр проблемага карата тулы караш булдыру максаты белән системалы рәвештә өйрәнү өчен сораулар кертелә. Мәсәлән, тарихи материализм бүлегендә программа нәсел, ыруг, халык, милләт кебек халыклар уртаклыгының тарихи формаларын җентекле өйрәнүне күздә тота. Моны өйрәнү укучыларның тарихи белемнәрен гомумиләштерергә, кеше-

[250] Вопросы идеологической работы: Сборник важнейших решений КПСС (1954–1961 годы). – М.: Госполитиздат, 1961. – С. 231.

[251] Абдуллина Д. Җәмгыять белеме дәресләрендә документлар белән эшләү // Совет мәктәбе. – 1968. – № 4. – 41–43 б.; Хәмитов Г. Тарих һәм җәмгыять белеме дәресләрендә КПССның XXIII съезды материалларыннан файдалану // Совет мәктәбе. – 1966. – № 8. – 48–52 б.

лек җәмгыятенең төп этапларының формалашуын күрсәтергә мөмкинлек бирә. «Милләт» төшенчәсен ачыклаганда кешеләр уртаклыгының тарихи юл, территория, тел уртаклыгы, бердәм психология, гореф-гадәтләр, җитештерү берлеге нәтиҗәсендә формалашуын күздә тотарга кирәклегенә басым ясала[252].

Җәмгыять белеме программасына төп үзгәрешләр 1977 елда кабул ителгән яңа Конституциядән соң кертелә. 1978 елгы дәреслектә совет кешеләренең аерым гражданлык хокуклары да күрсәтелә[253].

Җәмгыять белеме дәресләрендә җирле материалларны файдалану 60 нчы еллар урталарында әлеге фән мәктәпнең уку планына кертелгәннән соң башланып китә. Җирле материал куллану укытучыдан үз белемнәрен артыруны, дәрес методикасы өстендә өстәмә махсус эш алып баруны таләп итә. Әмма бу эш нәтиҗәсез калмый. Ул укучыларда тирән һәм нык белемнәр, күзәтүчәнлекне, фикерләүне үстерә. Ләкин чынлыкта җирле материал «коммунизмның якты идеалларын» ачыкларга тиеш була. Мәктәп краеведениесе төбәкнең география, табигать, этнография, икътисад мәгълүматларына корылган була. Тарихи краеведениегә бик аз урын бирелә. Ул авыл, шәһәр, район турында тарихи мәгълүматлар белән чикләнә, әлеге курста республика тарихын өйрәнү каралмый.

1965 елның май аенда КПСС ҮК тарафыннан «Мәктәпләрдә тарих укыту тәртибендә үзгәртүләр» турындагы карар чыга. Аның нигезендә яңа программалар эшләнелә. Яңа программалар нигезендә укучыларны туган якның төп тарихи вакыйгалары, геройлары һәм данлыклы кешеләре белән таныштыру карала.

1960–1980 елларда чыккан ТАССР тарихы дәреслекләрендә республика тарихы буенча материалның бик нык кыскартылып бирелүе күзәтелә, тарихи вакыйгаларга объектив бәяләмәләр бирелми. Мәсәлән, Казан ханлыгының Идел Болгарының варисы булуына басым ясала, Алтын Урда белән бәйләнеше яктыртылмый; 1445 елда нигез салынган нәсел, Болгар кенәзе Алибәйдән аермалы буларак, «Алтын Урданың килмешәк ханнары» династиясе итеп күрсәтелә.

Дәреслекләрдә бары тик рус чыганаклары гына бирелә. Патшаның көчләп чукындыру сәясәтенә карамастан, Урта Иделнең Рус дәүләтенә кушылуы прогрессив күренеш буларак карала.

---

[252] Щепров С.В. Особенности преподавания обществоведения в 1968/69 учебном году // Преподавание истории в школе. – 1968. – № 5. – С. 65.

[253] Суходеев В.В. Очередное издание учебника «Обществоведение» // Преподавание истории в школе. – 1978. – № 4 – С. 35–36.

Әлеге курста милли тарих түгел, ә республика белән чикләнгән төбәк тарихы гына өйрәнелә, Алтын Урда, Себер, Әстерхан, Кырым ханлыклары һ.б. бөтенләй каралмый. Әмма кыскартылган һәм идеологияләштерелгән булуга карамастан, «ТАССР тарихы» курсы укучыларга туган як тарихы турында гомуми белемнәр алырга мөмкинлек бирә һәм XX гасыр ахырында мөстәкыйль «Татарстан һәм татар халкы тарихы» курсы барлыкка килүгә нигез була.

Татар педагоглары да җәмгыять белемен укытканда җирле материалларга, татар халкының алдынгы иҗтимагый фикере тарихына таянуга зур әһәмият бирәләр (Г. Хәмитов, Я. Мәннәпов)[254]. Ф. Солтанов «Җәмгыять белеме дәресләрендә әдәби мирастан файдалану» исемле мәкаләсендә бу максатта татар халкының Г.Тукай, Ф. Әмирхан, М.Гафури, Г.Ибраһимов кебек күренекле вәкилләренең иҗтимагый фикергә караган хезмәтләреннән киң файдалану юлларын күрсәтә (мәсәлән, «Дөнья һәм аны танып белү турындагы философик карашлар» дигән бүлекне өйрәнгәндә Г.Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» әсәреннән файдалану һ.б.)[255].

М.Абдрахманов иҗтимагый фәннәрне укыту процессында халык традицияләренә игътибар итүне ассызыклый. Үзенең югары уку йортлары өчен басылган «Диалектик материализм» исемле оригиналь дәреслегендә аерым татар шагыйрьләренең һәм әдипләренең теге яки бу темага караган фикерләрен күрсәтә. «Инкярны инкяр итү» темасын өйрәнгәндә, мәсәлән, рус һәм татар халыклары арасындагы дуслыкның хезмәт нигезендә туып, тарих буенча килүен күрсәтеп, Г.Тукай шигырен китерә:

Һич бетәрме тарихи бу бергәлек?
Без туган бер җепкә бергә теркәлеп.

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез[256].

---

[254] Мәннәпов Я. Җәмгыять белеме курсында СССРның экономик политикасы // Совет мәктәбе. – 1985. – № 3. – 38–40 б.; Хәмитов Г. Җәмгыять белемен съезд материалларына бәйләп укыту // Совет мәктәбе. – 1986. – № 6. – 35–36 б.

[255] Солтанов Ф. Җәмгыять белеме дәресләрендә әдәби мирастан файдалану // Совет мәктәбе. – 1978. – № 9. – 50–52 б.

[256] Абдрахманов М. Диалектик материализм. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 94 б.

60 нчы еллардан 80 нче еллар урталарына кадәр гуманитар фәннәрдә, шул исәптән җәмгыять белемендә дә, җирле материалларны куллану укучыларны коммунистик рухта тәрбияләү чарасы булып тора.



*М.Абдрахманов*

1985 елдан совет мәктәбендә укыту һәм җәмгыять белеменең эчтәлеген тамырдан үзгәртеп коруга бәйләнгән яңа этап башлана. Ил җитәкчелеге җәмгыятьне «социализмны камилләштерү» нигезендә үзгәртеп коруны игълан итә. Яңа шартлар фәнни эзләнү эшен алып баруга мөмкинлекләр ача. Җәмгыять белеме проблемалары спектры, шул исәптән җәмгыять белеме дәреслеге буенча да, дискуссияләр башланып китә. Укытучылар уку китабыннан канәгатьсезлекләрен, шул ук вакытта укучы шәхесенә юнәлдерелгән китап белән эш итәргә таләкләрен белдерәләр.

Яңа «тематик планлаштыру» җәмгыять белеме укытуда җитди үзгәрешләргә башлангыч була. Төрле темаларда шәхес һәм җәмгыятьнең үзара мөнәсәбәтләрен, җәмгыятьнең шәхескә карата таләпләрен ачу, яшьләрнең кызыксынуларын уятучы актуаль сорауларны яктыртуга (яшәеш образы, эшчеләрнең реаль табышлары, массакүләм мәдәният, көнкүреш, буш вакыт, сүз иреге, тәнкыйть һәм үзүзеңне тәнкыйтьләү, кадрлар сәясәте, үзгәртеп коруның революцион характеры һ.б.) зур әһәмият бирелә[257].

Тематик планлаштыру укыту методларында да чагылыш таба. Аңлату-иллюстратив методыннан, укучыларның мөстәкыйль актив оештыру эшенә басым ясала.

1988 елда кабул ителгән программа беренче тапкыр укытучыларга җирле материалларны объектив рәвештә, социализмның якты идеалларын чагылдырмыйча, җәмгыятьтәге барлык каршылыкларны, кыенлыкларны күрсәтеп куллану мөмкинлекләрен тудыра[258].

---

[257] Обществоведение: Тематическое планирование курса для средней общеобразовательной школы и средних специальных учебных заведений. – М.: Госиздат, 1986. – С. 8–9.

[258] Программа по обществоведению для средних учебных заведений // Преподавание истории в школе. – 1988. – № 1. – С. 15–31.

Җәмгыять белеме курсының эчтәлеген яңарту идеяләре җәмгыятьтә тирән үзгәрешләр шартларында конкретлаша. Үзгәртеп кору кризисы сәяси көрәшне кискенләштерә. Конституциянең КПСС ролен билгеләүче 6 нчы маддәсе бетерелә, иҗтимагый оешмаларның тәэсире көчәя, СССР таркала. Бу шартларда элеккеге «Җәмгыять» белеме курсы уку планыннан алына. 1990/91 уку елында аны «Марксистик җәмгыятькә кереш» курсы белән алыштыру укытучылар һәм ата-аналар тарафыннан яклау тапмый. Илдә барган демократик тенденцияләр 1991 елның гыйнвар аеннан мәктәп системасыннан элеккеге программаларны һәм марксистик-ленинчыл уку китапларын алуга китерә. Әмма демократияләштерү шартларында шәхес ихтыяҗларына җавап бирерлек җәмгыять белеме курсы кирәклеге заманның ачык мәсьәләсе булып кала.

Шулай итеп, узган гасырның урталарында дәреснең нәтиҗәлелеген күтәрү юлларын эзләү совет җәмгыятендә көнүзәк мәсьәләгә әверелә. Галимнәр методиканың дөреслеген өлгергәнлек аттестаты алуга ирешкән балалар саны белән генә билгеләүне таныргa мәҗбүр булалар. Фән-техника казанышлары шартларында мәктәп алдында балаларның иҗади мөстәкыйльлеген, фикерләү дәрәҗәсен, белем алуга сәләтен үстерү бурычлары куела, яңа дидактик ысуллар куллану таләп ителә.

Фәнни тәҗрибәгә нигезләнгән сынаулы дәресләр илнең төрле төбәкләрендә үткәрелә, ләкин нәкъ менә Казан шәһәре ил күләмендәге фәнни-тикшеренү эшләренең үзәгенә әверелә. Биредә профессор И.Т.Огородников җитәкчелегендә Мәскәү галимнәре тарафыннан фәнни-тикшеренү эшләре башланып китә.

Укучыларның танып белү активлыгын һәм иҗади мөстәкыйльлеген үстерү алымнарының нигезен түбәндәге кагыйдәләр тәшкил итә:

1. Укыту-тәрбия процессының барлык этапларында да укытуны тормыш белән, укучыларның үз хезмәтләре белән бәйләп алып бару;

2. Укучыларның логик фикер йөртүләрен үстерүдә зарури шарт буларак, дәрестә эзләнүле, проблемалы ситуация (хәл, торыш) тудыру;

3. Укучыларның дәрестәге мөстәкыйль эшләрен аларның танып белү мөстәкыйльлеген үстерү чарасы итеп оештыру, төрле дидактик һәм укыту-техник чаралардан файдалану;

4. Укыту-тәрбия процессының барлык этапларында да һәр балага аерым игътибар итү;

5. Сыйныфтан тыш һәм мәктәптән тыш эшләр оештырганда, тәрбия чаралары ярдәмендә укучыларның танып белүгә сәләтләрен һәм омтылышларын үстерү, аларның уку һәм практик күнекмәләрен формалаштыру[259].



*Арча районы Ташкичү сигезьеллык мәктәбе бакчасында көзге уңыш җыю. 1966 ел*

Мәгълүм ки, проблемалы укыту яңа педагогик күренеш түгел. Мәсәлән, проблемалы укыту элементлары Сократның эвристик әңгәмәләрендә чагылдырыла. Балаларны мөстәкыйль иҗади эшчәнлеккә тарту фикере Ж.Ж.Руссо, И.Г.Песталоци, Ф.А.Дистервег эшкәртмәләрендә дә күрергә мөмкин.

Проблемалы укытуда, исеменнән үк күренгәнчә, укучы үзе уку проблемасын хәл итүдә катнаша[260]. Проблемалы укытуның нигезен

---

[259] Мәхмүтов М.И. Мәктәптә мөстәкыйльлек тәрбияләү (Укучыларның танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген укутуны тормыш белән бәйләү нигезендә үстерү). – Казан, 1964. – 19–20 б.

[260] Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогика: педагогик уку йортлары, көллиятләр, гимназияләр, лицейлар өчен уку әсбабы. – Казан, 1998. – 91 б.

укытучы тарафыннан булдырылган системалы рәвештә һәм алдан ук уйланган проблемалы ситуацияләр тәшкил итә[261]. Димәк, М.И.Мәхмүтов фикеренчә, «проблемалы уку – проблемалы ситуация шартларында укытучы аңлатмасын кабул итү, проблемалы ситуацияләрне мөстәкыйль (яки укытучы ярдәмендә) анализлау һәм проблемаларны тәгъбир итү һәм аларны (логик һәм интуитив) фараз кылу, шуларны нигезләү һәм исбатлау ярдәмендә чишү, шулай ук чишелешнең дөреслеген тикшерү юлы белән укучыларның белемнәрне һәм гамәл ысулларын үзләштерү буенча уку – танып белү эшчәнлеге ул»[262].

1960 елларда татар телендә укучылар саны үсә баруын дәлилләп, М.И. Мәхмүтов түбәндәге мәгълүматларны китерә. 1962 елда татар мәктәбендә 149 мең, 1972 – 211,5 мең укучы туплана (42% ка үсә). Шунысы әһәмияткә ия, 70 нче еллар башында Татарстанда барлыгы 2670 гомуми белем мәктәбе һәм урта уку йортлары исәпләнә. Аларда рус телендә белем алучыларның саны 416 мең (өчтән бер өлешенең татар милләтеннән), татар телендә – 214 мең, башка телләрдә – 26 мең кеше тәшкил итә[263]. Тик 80 нче еллар башына татар мәктәбенең челтәре элекке хәятенә кайтуын күрәбез. Бу вакытта республиканың 1045 татар һәм рус-татар мәктәбендә 150 мең укучы укый[264].

Ватанны саклау – совет кешесенең беренчел бурычы икәнлеген тирәнтен төшендерү гаять әһәмиятле тәрбияви мәсьәләгә әверелә. Яшүсмерләргә совет патриотизмының Ватанны, туган якны яратудан тыш, Коммунистлар партиясенә, Совет хакимиятенә мәхәббәтне дә үз эченә алганын инандыру максаты куела. Хәрби-патриотик тәрбия, иң беренче чиратта, дәрестә башкарыла. Шулай ук политинформацияләр, сугыш ветераннары белән очрашулар, истәлекле даталарны билгеләп үтү, «Аҗаган», «Бөркеткәй» уеннары кебек чаралар да актив кулланыла.

Алтмышынчы елларда интернациональ тәрбия, коммунистик тәрбия системасының зарури бер өлеше буларак, җитди игътибар таләп итә. Интернациональ тәрбиягә мөнәсәбәтле нәзари мәсьәләләр Советлар Союзының күпмилләтле булуыннан һәм тышкы сәяси эшчәнлегенең үзенчәлегеннән чыгып билгеләнә. КПСС программа-

[261] Махмутов М.И. Вопросы организации проблемного обучения (Методическое пособие). – Казань, 1972. – С. 6.

[262] Мәхмүтов М.И. Мәктәптә проблемалы укытуны оештыру. Укытучылар өчен дидактик ярдәмлек. – Казан, 1980. – 27 б.

[263] Махмутов М.И. Некоторые вопросы развития татарской школы // Вопросы обучения и воспитания в татарской школе. – Казань, 1975. – С. 19–20.

[264] Низамов Р. Халык мәгарифе офыклары // Совет мәктәбе. – 1980. – № 6. – 5 б.

сында пролетар интернационализм һәм социалистик патриотизмны үстерү бурычы ассызыклана[265]. Шулай итеп, өйрәнелә торган дәвердә укыту һәм тәрбия эше процесслары (уку программалары, дәреслекләр, пионер, комсомол оешмаларының эшчәнлеге) сыйнфый идея белән сугарылган була.

М.И. Мәхмүтов интернациональ тәрбия – ул укучыларда халыкара пролетар бердәмлекнең, зур һәм вак халыкларның милли хокукларын һәм мөстәкыйльлекләрен тирән ихтирам итүнең кирәклегенә ышану, барлык раса һәм милләт халыкларына дуслык хисе тәрбияләү, дип тәгъбир итә[266]. Автор, КПСС программасына нигезләнеп, яшьләрне пролетар интернационализм рухында тәрбияләргә өнди. «Пролетар интернационализм дигәннән без барлык халыкларның милли бәйсезлеген, дуслыгын, үзара хезмәттәшлеген, аларның гаделсез сугышларга каршы, тынычлык һәм төрле иҗтимагый стройлы дәүләтләрнең үзара тыныч яшәүләре өчен көрәшен аңлыйбыз»[267].


*М.Мәхмүтов*

Мәктәптә интернациональ тәрбия, башлыча, ике аспекттан чыгып карала. Беренчедән, Советлар Союзы халыкларының башка илләрдә яшәүче халыкларга дусларча карашын формалаштыру, пролетар бердәмлек хисләре тәрбияләү. Икенчедән, СССРдагы барлык милләтләр арасындагы дустанә мөнәсәбәтне ныгыту.

Интернациональ рухта тәрбияләүнең төп юнәлешләре түбәндәгедән гыйбарәт.

1. Үсеп килүче яшь буынны дәресләрдә халыклар дуслыгының гүзәл үрнәкләре белән таныштыру. Бигрәк тә тарих, чит тел, география, әдәбият, музыка предметларын укыту процессында мондый мөмкинлекләр киң була. Матур әдәбиятның, көчле иҗтимагый тәрбия чарасы буларак, халыклар арасында тугандаш мөгамәлә туды-

[265] Коммунистическая партия Советского Союза в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК (1898–1986). Т. 10. – 1961–1965. – М., 1986. – С. 169.

[266] Мәхмүтов М.И. Татар теле һәм әдәбиятын укыту процессында укучыларга коммунистик тәрбия бирү // Совет мәктәбе. – 1965. – № 2. – 5 б.

[267] Тайчинов М. Яшь буынны совет патриотизмы һәм пролетар интернационализм рухында тәрбиялик // Совет мәктәбе. – 1973. – № 9. – 24 б.

руда тәэсире аеруча күзәтелә. Галимнәр халык авыз иҗаты (әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, бәетләр, җырлар) һәм әдәби әсәрләрне интернациональ тәрбия бирүдә файдалану мөмкинлекләренең уңышлы мисалларын матбугат битләрендә, яисә җыентыкларда мәкаләләр бастырып, кызыксынучан укучыны кыйммәтле мәгълүмат белән һәрдаим таныштырып торалар[268].

2. Халыкара дуслык хисен сыйныфтан тыш чаралар аша үстерү (әдәби иртәләр, тематик кичәләр уздыру, экскурсияләргә бару, альбомнар төзү һ.б.). Туган төбәккә, туган телгә мәхәббәт хисе тәрбияләүдә мондый чараларның роле гаҗәеп зур.

3. Хәрби-патриотик һәм интернациональ тәрбиянең бер формасы буларак, Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 20 ел тулу уңаеннан әзерләнгән чаралар барышында, эзтабарларның җәелдергән эшчәнлеге. Нәтиҗәдә, мәктәпләрдә экспонатларга бай музейлар да барлыкка килә[269]. 60 нчы елларда партия тарафыннан дәүләт органнарына музейларның эшчәнлеген яхшырту буенча йөкләмәләр бирелә[270]. КПСС Үзәк Комитетның «Хезмәт ияләрен коммунистик тәрбияләүдә музейларның ролен күтәрү турындагы карарында» (1964) тәрбия эшендә музейларның тоткан урыны билгеләнә[271].

4. Интернациональ дуслык клубларын оештыру (ИДК). ИДКлары Мәскәүдә VI Бөтендөнья яшьләр фестивале уздырылганнан соң (1957), илленче еллар азагында барлыкка килә башлый. Татарстан АССР мәктәпләрендә дә ИДКның нәтиҗәле эшләве билгеле. Мисал өчен, Яр Чаллы шәһәрендәге 15 нче мәктәптә инглиз теле укытучысы С.Новоселова җитәкчелегендә оештырылган ИДКны атап узарга мөмкин. Клубта «Дуслык почтамты», «СССР халыклары», «Полит-

---

[268] Исламов Ф.Ф. Татар әдәбияты дәресләрендә интернациональ тәрбия // Совет мәктәбе. – 1964. – № 12. – 30–35 б.; Мәхмүтов М.И. Татар теле һәм әдәбиятын укыту процессында укучыларга коммунистик тәрбия бирү // Совет мәктәбе. – 1965. – № 2. – 5–9 б.; Исламов Ф. Татар әдәбиятын укытканда интернациональ тәрбия (5–8 класслар). – Казан, 1968. – 176 б.; Шул ук. Татар әдәбиятын өйрәнү процессында интернациональ тәрбия мәсьәләләре // Вопросы обучения и воспитания в татарской школе. – Казань, 1975. – С. 192–205.

[269] Владимиров В.И. Школьные музеи и преподавание регионального компонента // Преподавание истории в школе. – 2000. – № 2. – С. 65.

[270] Постановление ЦК КПСС о повышении роли музеев в коммунистическом воспитании трудящихся (12 мая 1964 г.) / Коммунистическая партия Советского Союза в резолюциях и решениях съездов, конференций и пленумов ЦК (1898–1986). Т. 10. – 1961–1965. – М., 1986. – С. 416–417.

[271] Сафиуллина К.З. Укучыларга патриотик тәрбия бирү. – Казан, 1984. – 51 б.

информаторлар» секцияләре эшли. Клуб әгъзаларының актив булуы хакында аларның Никарагуа балаларына уенчыклар һәм уку әсбаплары җыеп, коралланууга каршы үзләренең нәфрәт сүзләрен язып, НАТОның штаб-квартирасына йөзләрчә открытка җибәрүләре, СССРның төрле почмакларында үткәрелгән фестивальләрдә катнашулары һ.б. сөйли[272]. Монан тыш, оешма эшчәнлеге кысаларында Татарстан тарихы һәм мәдәнияте өйрәнелә.

Мәктәпнең тормыш белән элемтәсен ныгыту, укучыларда хезмәт күнекмәләре тәрбияләү мәсьәләләре дә яңача яктыртуны таләп итә. ТАССР Мәгариф министрлыгының Дәреслекләр бүлеге татар башлангыч мәктәпләре өчен хезмәткә өйрәтү программасын хәзерли[273]. Анда укучы балаларга ныклы гомуми белем бирү белән бергә, укучыларны җәмгыятькә файдалы җитештерүчән хезмәткә хәзерләү бурычы да куела. Яшүсмерләргә хезмәт тәрбиясе бирүнең мөмкинлекләре күпкырлы. Укучы балалар колхоз тормышында, мәктәп яны яшелчә үстерү эшендә актив катнашалар, төрле белгечлекләрне үзләштерәләр. Мәктәпләрдә тере табигать почмагы, яшь умартачылар түгәрәге оештыру киң таралыш ала.



*Я.Ханбиков*

Бу чорда татар педагогикасы тарихын өйрәнүгә дә игътибар ителә. Татар мәгарифе үсешенең төрле дәверләре Ханбиков Я.И., Горохов В.М. хезмәтләрендә чагылыш таба[274].

Йомгаклап, түбәндәге нәтиҗәләрне ясарга мөмкин.

Бу елларда укучы баларга гомуми белем бирү белән бергә, яшь буынны тормышка әзерлекле, совет җәмгыятенә файдалы җитештерүчән хезмәткә хәзерләү юнәлеше билгеләнә. Белем бирү өлкәсендә, заман таләпләренә яраклашып, рус теленә өстенлек би-

---

[272] Степанов М. Интернациональ дуслык клубы – тәрбия үзәге // Совет мәктәбе. – 1983. – № 1. – 6–7 б.

[273] Карагыз: I–IV классларда хезмәткә өйрәтү һәм җәмгыятькә файдалы хезмәт // Совет мәктәбе. – 1959. – № 10. – 30–54 б.

[274] Ханбиков Я.И. История педагогики татарского народа. – Казань, 1975. – 162 с.; Горохов В.М. Педагогика тарихыннан очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 124 б.

релә. Ләкин татар милли мәгариф системасында, җитди кыенлыкларга карамастан, сизелерлек нәтиҗәләр күзәтелә. Педагогик тикшеренүләрнең аерым тармагын милли мәктәпләрдә рус теле, ана теле һәм әдәбиятларын укыту методикасын эшкәртү тәшкил итә.

Илленче еллар азагыннан башлап, республикадагы алдынгы укытучыларның һәм галимнәрнең эзләнүләрендә төп игътибар укучыларның дәрестә мөстәкыйль эшләүләрен көчәйтүгә, аларның фикер йөртү активлыгын үстерүгә юнәлтелгән була. Бу өлкәдә билгеле галим-педагог М.И.Мәхмүтовның проблемалы укыту турындагы хезмәтләре бүгенге көндә дә үз әһәмиятен югалтмыйлар. Укыту-тәрбия процессына яңа ысуллар һәм технологияләр үтеп керүе белән беррәттән, мәктәпләрнең матди нигезен ныгытуга юнәлтелгән эзлекле чаралар да кулланыла.

Хәрби-патриотик һәм интернациональ тәрбия совет чорында «иҗтимагый заказ» булып кабул ителсә дә, аның нигезен гуманистик идея тәшкил итә. Ә гуманлы мөнәсәбәтләр, мәгълүм булганча, әхлак мөнәсәбәтләре системасына керә. Балаларда җаваплылык, шәхеснең кешелек сыйфатларына хөрмәт хисләрен үстерү, аларны хезмәт сөючән итеп һәм оптимистик рухта тәрбияләү – совет педагогикасының төп казанышы.

# VI. XX ГАСЫР АХЫРЫ – XXI ГАСЫР БАШЫНДА ТАТАР ПЕДАГОГИК ФИКЕРЕ

## 1. Татар мәгарифе үсеше (1990–2005)

1985 елдан соңгы чор иҗтимагый-сәяси һәм социаль-икътисади өлкәләрдә барган катлаулы үзгәрешләр белән билгеләнә. «Үзгәртеп кору» чорына хас булган төп үзенчәлекләр – җәмгыятьне демократияләштерү, СССР таркалу, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының суверенлыгы турындагы декларацияләр, ТР Конституциясе (1992) кабул ителү һ.б. рухи яңарышка һәм милли үзаң күтәрелүгә тәэсир итә. Илдә барган хәлиткеч үзгзәрешләр җәмгыять үсешенең бер өлеше булган мәгариф үсешендә дә чагылыш таба. Гомумдәүләт милли мәгариф системасы таркала: РФдә гомумроссия милли мәгарифе белән идарә итү системасы бетерелә, Россия халыклары телләрендә укыту-методик әдәбият (дәреслек, кулланмалар) белән тәэмин итү механизмы җимерелә. Милли мәгарифне оештыру вәкаләтләре төбәкләрнең үзләренә тапшырыла. Шулай итеп, милли мәгарифләрне яңа этапка күтәрү ихтыяҗы туа. Бу чорда татар мәгарифе Татарстанның дәүләт сәясәтендәге иң төп юнәлешләрнең берсенә әверелә.

80 нче еллар азагында Казан шәһәрендәге 200 ләп мәктәпнең бары тик икесе генә татар мәктәбе булу (аның берсе – республика күләмендәге интернат-мәктәп), республиканың башка шәһәрләрендә һәм авылларында күп мәктәпләрнең русча укытуга күчүе (бу чорда татар мәктәпләренең гомуми саны 1000нән артмый; шәһәрдәге татар балаларының бары тик 3%ы гына туган телләрендә белем ала), Россия төбәкләрендәге татар мәктәпләренең нигездә рус телендә белем һәм тәрбия бирүләре (чит өлкәләрдәге татар авылларында мәктәпләрдә татар һәм рус телләрендә белем бирүче сыйныфлар ачылу һәм күпчелекнең рус сыйныфларына өстенлек бирүе) яшь буынның ана теленнән, милли мәдәнияттән читләшүенә сәбәп була. Бу исә татар

теленең кулланылыш даирәсе кимүгә китерә. Гомумән алганда, әлеге чорда туган телләрдә белем бирүче мәктәпләр Россиядә, татарлардан тыш, якутларда, чувашларда, башкортларда гына сакланып кала, һәм ул нигездә авыл шартларында күзәтелә. Мәсәлән, 90 нчы еллар башында Удмуртия башкаласы Ижевск шәһәрендә удмурт теле укытылган бер генә милли мәктәп тә булмый, халыкның 1/3 өлеше генә туган телен белә[1]. Шундый ук хәл башка милли республикаларда да күзәтелә.

Яңа вәзгыять торгынлык чоры кичерүче милли мәгариф системасын торгызу мәҗбүрилеген таләп итә. Милли мәгарифне сыйфат ягыннан тамырдан яңартмый торып, алга таба үсешкә ирешү мөмкин түгеллеге ачыклана. Татарстан Республикасында дөнья күргән мәгариф һәм телләр турындагы законнар, татар һәм рус телләренең дәүләт телләре итеп игълан ителүе бу юлда беренче карарларның берсе[2]. Гомумән алганда, телләр турындагы законнар, Татарстаннан тыш тагын кайбер милли республикаларда, мәсәлән, Башкортстанда һәм Якутиядә, кабул ителә. Аның нигезендә әлеге республикада яшәүчеләр, рус теле белән беррәттән, әлеге төбәкнең дәүләт телен дә өйрәнергә тиеш була. «Мәгариф турындагы» закон мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләре буларак белем бирүнең гуманистик, халыкчан-милли характерда булуын, гомумкешелек кыйммәтләренә, шәхеснең ирекле үсешенә өстенлек бирүне, белем бирүне тормыш һәм милли-мәдәни традицияләр белән бәйләп алып бару, туган телдә белем алу хокукын билгели. Республикада күзәтелгән икетеллелек (билингвизм) мәгариф үсешендә дә чагылыш таба. Гомумән алганда, билингваль белем бирү Россиядә яисә Татарстанда гына түгел, дөнья тәҗрибәсендә дә шактый киң таралган күренеш. Европада, аерым алганда, Бельгиядә, мәсәлән, барлык мәктәпләрдә укыту теле буларак француз теле белән беррәттән фламанд теле файдаланыла. Бу очракта дәүләт сәясәте туган телдә укытуны шәхеснең туган телне төрле өлкәләрдә файда-

[1] Власова Т.А. Образовательный потенциал школы с этнокультурным компонентом на примере национальной школы г. Ижевска // Вестник Удмуртского университета. – 2013. – Вып. 1. – С. 53.

[2] Закон Республики Татарстан от 19 октября 1993 года № 1982-XII «Об образовании» // Ведомости Верховного Совета Татарстана. – 1993. – № 10; Закон Республики Татарстан от 8 июля 1992 года «О языках народов Республики Татарстан» // Ведомости Верховного Совета Татарстана. – 1992. – № 6.

лану хокукы булудан бигрәк (ата-аналар француз теленә өстенлек бирә), фламанд җәмгыятенең телен саклау хокукы буларак карый.

Татар мәгарифе мәсьәләләренә игътибар арту, беренче чиратта, халык, иҗтимагый хәрәкәт вәкилләренең эшчәнлегендә күзәтелә. Бөтентатар иҗтимагый үзәге (БТИҮ) тарафдарлары, татар мәгарифе тарихында беренче тапкыр буларак, белем бирү һәм тәрбияне гаилә тәрбиясеннән башлап, югары уку йортлары белән тәмамланган өзлексез белем бирү бердәм системасы буларак күрә. Бу елларда мәгариф системасы үсеше иң беренче чиратта татар теленең статусын, кулланылыш даирәсен күтәрүгә омтылышта һәм уку-укытуны ана телендә алып баруда чагылыш таба. Милли мәгариф үсешендәге иң югары нокта буларак татар халкы мәнфәгатьләренә җавап бирүче, аның киләчәген, фән, тел үсешен тәэмин итәчәк төп уку йорты – Милли университет (Татар милли университеты, Татар университеты) төзү карала. 1990 елда Милли университет төзү турындагы резолюция кабул ителә, дистә ел дәвамында төрле авторлар тарафыннан аның үсеш концепцияләре эшләнә (Гайфуллин В.Г., Әмирханов Р.У., Гарданов Х, Ялалов Ф.Г.). Әмма Россия мәгариф законы нигезендә югары белем бары тик рус телендә генә алып барылу сәбәпле, идея тормышка ашмый кала.

1992 елда оешкан Бөтентатар «Мәгариф» ассоциациясе татар милли мәктәпләрен булдыру, милли кадрлар әзерләү, татарча дәреслек һәм уку-укыту кулланмалары бастыру һ.б. мәсьәләләрне хәл итү буенча зур эш башкара. Ассоциация тарафдарлары милли мәгариф системасын Россиянең татарлар яшәгән барлык төбәкләрендә җәелдерү максатын куялар.

Бу елларда Татарстаннан читтә яшәгән татарлар өчен үз туган телләрендә белем алу хокукы тормышка ашырыла башлый. 1989 елда, мәсәлән, Тубылда Татар мәдәнияте үзәге төзелә, педагогия училищесы каршында татар бүлеге ачыла, 1990–1991 елларда Д.И.Менделеев исемендәге ТДПИның филология факультетында татар бүлеге оештырыла. Университетларның һәм педагогия институтларының филология факультетлары каршында татар бүлекләре татарлар яшәгән башка өлкәләрдә дә барлыкка килә (Төмән, Уфа, Бөре, Стәрлетамак, Ижевск һ.б.), Чуваш дәүләт университетының Батыр филиалында 1998 елда «Татар теле һәм әдәбияты» белгечлеге буенча студентлар кабул ителә башлый. Бу республикада гына түгел, төбәкләрдә дә милли мәктәпләр оешу һәм аларны педагогик кадрлар белән тәэмин итү ихтыяҗы барлыкка килү белән билгеләнә. Казан университетында Татар филологиясе, тарихы һәм шәрык телләре

факультеты оештырылу татар телен һәм әдәбиятын, тарихын өйрәнүдә һәм укытуда, гомумән татар мәгарифен үстерүдә зур әһәмияткә ия факторларның берсе була.



*М.Лотфуллин*

Иҗтимагый оешмалар белән беррәттән, фәнни даирәләрдә дә милли мәгариф мәсьәләләре тирәнтен өйрәнелә башлый (Гайфуллин В.Г., Ялалов Ф.Г., Харисов Ф.Ф., Лотфуллин М.В. һ.б.).

ТРның «Латин графикасы нигезендә татар алфавитын торгызу турында» законы (1999) кабул ителү милли мәгариф системасы үсешендә дә сизелерлек үзгәрешләр китереп чыгара. Яңа алфавит нигезендә укый-язарга өйрәтү буенча дәреслекләр һәм уку кулланмалары, аның методологик нигезләрен яктырткан фәнни хезмәтләр дөнья күрә (Хаков В.Х., Курбатов Х., Вәгыйзов С.Г. һ.б.), латин алфавитын гамәлгә кертү буенча мәктәпләрдә эксперименталь эш алып барыла. Әмма федераль законга үзгәрешләр кертелү сәбәпле, бу эш туктатыла.

Бу чорда татар мәктәбе һәм аның асылын билгеләү буенча берничә юнәлеш билгеләнә. Беренче юнәлеш тарафдарлары татар мәктәбен татарларны татар теленә өйрәтүдәге төп буын буларак күрә. Алар фикеренчә, татар мәктәбе – ул рус мәктәбенең татар телле варианты, ана телендә белем һәм тәрбия бирүче татар унитар мәктәбе. Татар галимнәре милли мәгарифне РФ мәгариф стретегиясе нигезендә эшләүче Татарстан Мәгариф министрлыгы кысаларында күрәләр (Гарданов Х., Гайфуллин В.Г. һ.б.). Икенче юнәлешне яклаучылар (Әмирханов И., Ягъфәров Р.) татар мәгарифе РФ мәгариф системасына бәйле булмаган, мөстәкыйль бер система һәм ул халык кулында булырга, аерым мәктәп, коллективлар инициативасы белән оешырга тиеш санйлар. Әмма һәркайсы татар мәктәбен билгеләүче төп фактор итеп укучыларны туган тел мохитендә, гасырлар дәвамында тупланган мәдәни һәм тарихи кыйммәтләр, педагогик тәҗрибә нигезендә тәрбияләү һәм белем бирүне саныйлар. Бу фикерләр татар педагоглары һәм галимнәренең хезмәтләрендә, татар мәгарифенең үсеш концепцияләрендә (Ягъфәров Р., Гайфуллин В.Г., Әмирханов И. һ.б.), доктриналарда (ТР ФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих инсти-

туты галимнәре тарафыннан эшләнгән «ТРда белем-тәрбия системалары үсеше милли доктринасы» һ.б.) чагылыш таба.

Милли мәгариф системасын торгызудагы үзгәрешләр иң түбән баскыч булган мәктәпкәчә яшьтәге тәрбия йортларыннан башланып китә. Татар балалар бакчалары, гадәти бакчаларда татар төркемнәре ачыла, татар телендә тәрбия бирү, балаларга татар мәдәнияте, тарихы буенча мәгълүмат бирү мәсьәләсе өлешчә хәл ителә, татар мәдәниятенә багышланган махсус почмаклар һәм музейлар булдырыла. 90 нчы еллар башында татар балалар бакчаларын методик яктан тәэмин итү мәсьәләсе дә берникадәр хәл ителә: милли тәрбия бирү буенча методик кулланмалар, төрле җыентыклар басылып чыга (Шәрәфетдинов З.Т., Юсупов Ф.Ю., Борһанова Р.Г., Закирова К.В. һ.б.).

Ана телендә белем һәм тәрбия бирүче урта мәктәпләр (90 нчы еллар ахырында Казан шәһәрендә генә 42 татар мәктәбе ачыла; 1997 елда республикада барлыгы 1256 татар мәктәбе була[3]), гимназияләр (1997 елда аларның саны 91 гә җитә[4]), катнаш мәктәпләр (рус-татар), рус мәктәпләрендә татар төркемнәре, рус телле балалар өчен милли тәрбиягә нигезләнгән махсус (этнокомпонентлы) сыйныфлар барлыкка килә, мәҗбүри предмет буларак татар теле кертелә. 1989 елда ТАССР Министрлар Советы тарафыннан «Халык мәгарифе системасында ана теле һәм әдәбиятының торышы һәм аны яхшырту турында»гы карар кабул ителүнең бу мәсьәләне хәл итүдә йогынтысы зур була. Шулай итеп, дәүләт теле буларак танылган татар теле республиканың барлык мәктәпләрендә дә мәҗбүри предмет буларак кертелә. 1997–1998 уку елында 97% укучы татар телен предмет буларак өйрәнә. Гомумән алганда, бу еллар Татарстанда башка милләтләр мәгарифендә дә шактый алга китеш еллары була: 55,7% чуваш, 65,3% удмурт, 43,2% мари, 6,95% мордва, 2,9% башкорт һәм 73% еврей балалары үз туган телләрендә белем ала, ана телләрен предмет буларак өйрәнә[5].

Милли мәгариф проблемасы Европа илләрендә дә актуаль. Бердәм мәгариф системасы булмаган, һәр провинция үз белем бирү программасы нигезендә эшләгән Канадада, мәсәлән, мәктәпләр төбәк һәм аның тарихын, мәдәни мирасын, традицияләрен өйрәнү ягыннан шактый аерылып тора, чөнки һәрбер уку йорты җирле мәдәни шарт-

---

[3] Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – С. 60.

[4] Шунда ук. – С. 64.

[5] Туктамышов Н.К., Салехова Л.Л. Возникновение и развитие образования в Татарстане // Казанский педагогический журнал. – 2010. – № 2. – С. 175.

ларга яраклаштырылган укыту планын үзе әзерли. Белем бирүдә төрле милләтләрнең мәнфәгатьләрен кайгырту билингваль программаларга нигезләнеп, бикультуралы сыйныфлар ачу аша алып барыла. Милли телләрне торгызу һәм саклауны максат иткән әлеге система рәсми телләрне өйрәнүгә нигез һәм ярдәмче булып тора.

90 нчы елларда Россиядә чит илләр, аерым алганда, АКШ, Германия үрнәгендә, Дәүләт белем бирү стандартлары әзерләнә һәм кертелә. Ул өч компонентны – федераль, региональ (төбәк) һәм мәктәп өлешен үз эченә ала. Милли-төбәк компоненты (МТК) Россия халыкларының милли мәгарифләрен үстерүдә шактый зур роль уйный. МТК нигезендә Татастанда аерым фән буларак татар халкы һәм Татарстан тарихы, Татарстан географиясе укытыла башлый, укыту методикалары булдырыла (Фәхретдинов Р.Р., Солтанбеков Б., Тайсин Ә.В. һ.б.), балаларга милли тәрбия бирүдә яңа мөмкинлекләр ачыла. Укытучылар гомумроссия күләмендә кабул ителгән стандартлардан тыш татар тарихы, мәдәнияте, төбәкне өйрәнү буенча, гомумән татар халкы турында өстәмә материалларга да мөрәҗәгать итә башлыйлар. Татар теле, әдәбияты, татар тарихы, Татарстан географиясеннән тыш, милли-төбәк компонентын башка предметларны укытуда (мәсәлән, астрономия, физика, химия һ.б. дәресләрендә татар халык авыз иҗаты үрнәкләрен, Татарстан һәм татар галимнәренең ачышларын, хезмәт, технология, рәсем дәресләрендә татар һөнәрчелек үрнәкләре – чигү, күн эшкәртү, музыкада татар композиторлары иҗатына мөрәҗәгать итү һ.б.) куллану мөмкинлеге ачыла. Болар барысы да балаларда милли үзаң тәрбияләү максатын тормышка ашыруга ярдәм итә. МТКның тулысынча республика карамагында булуы да зур әһәмияткә ия.

1993 елда База уку план (БУП) кертелү дә белем бирү эчтәлегенә вариатив өлешне – милли, төбәк яисә җирле үзенчәлекләрне һәм традицияләрне, укучыларның кызыксынуларын һәм сәләтләрен искә алу мөмкинлеген арттыра. Шул ук вакытта мәктәпләргә үзләренә теге яки бу программаны, дәреслекне сайлау, төбәк һәм мәктәп компоненты хисабына шул төбәктә әзерләнгән һәм экспертлар тарафыннан бәяләнгән вариатив программалар һәм кулланмалар кертү хокукын бирә. 90 нчы елларда мәгариф өлкәсендәге сәясәт федераль программалар белән беррәттән, җирле мәгариф системасының үсешен һәм социаль-икътисади үсеш дәрәҗәләрен искә алган региональ (төбәк) һәм муниципаль программалар булдыру мөмкинлеген бирә. Нәтиҗәдә гомумроссия һәм төбәк, шулай ук аерым авторлар тарафыннан язылган, берләштерелгән (интеграцияләнгән) һәм бер генә

предметка караган дәреслекләр барлыкка килә. Укытучыларның төбәк материаллары белән кызыксынулары, аларны укыту барышына кертү теләге теге яки бу мәктәпнең үзенчәлекләрен яктырткан кулланмалар нәшер ителүгә китерә.

2007 елда МТК бетерелә, 2009 елда РФнең «Мәгариф турындагы» законы кабул ителгәннән соң, яңа буын Федераль дәүләт белем бирү стандартлары әзерләнә башлый.

Бу еллар Россиянең татарлар яшәгән башка төбәкләрендә дә татар мәктәпләренең торгызылуы, яңа типтагы мәктәпләр ачылу (гимназияләр), татар телендә һәм татар телен предмет буларак укытуга әһәмият арту белән бәйле. Мари-Эл, Чувашстан һ.б. кайбер республикаларда татар мәктәпләре торгызыла, күп өлкәләрдә тик ана теле һәм әдәбияты гына укытыла. Мәсәлән, Төмән өлкәсендә 1990 елда 93 мәктәптә татар теле укытылса, 1995 елда аларның саны 119 га җитә[6].

90 нчы еллар мәгариф өлкәсендә башка төбәк һәм илләр белән бәйләнешләрне ныгыту чоры да. Мәсәлән, 1999 елда Татарстан Республикасы һәм Россиянең 23 төбәге һәм татарлар яшәгән БДБ илләре (Азәрбайҗан, Казахстанның Караганда, Семипалатинск өлкәләре) белән килешүләр төзелә. Аның нигезендә әлеге төбәкләргә татар телендә укыту-методик кулланмалар, дәреслек һәм башка әсбаплар белән өлешчә тәэмин итү, урыннарда татар теле укытучылары әзерләү яки укытучы кадрлар белән ярдәм итү карала.



*1 нче татар гимназиясенең гарәп теле укытучысы Р.Сафин дәрес вакытында. Түбән Кама, 1994 ел*

[6] Национальная школа сибирских татар. Хрестоматия. Т. 3. – Тюмень: Вектор Бук, 2005. – С. 167, 168.

90 нчы еллар башы татар теле һәм әдәбиятын укытуга яңача караш формалашу белән тарихка кереп кала. Яңа шартларга туры китереп язылган күпсанлы дәреслекләр дөнья күрә. Татарларны, рус телле укучыларны татар теленә өйрәтү буенча яңа методикалар эшләнә, шулар нигезендә альтернатив программалар һәм дәреслекләр дөнья күрә (мәсәлән, рус телле укучыларга татар телен укыту буенча Сафиуллина Ф.С., Литвинов И.Л, Харисов Ф.Ф., Харисова Ч.М., Хәйдарова Р.З., татар мәктәбендә әдәбият укыту буенча Яхин А.Г., Әхмәдуллин А.Г. дәреслекләре һ.б.). Грамматика кагыйдәләрен нигез итеп алган традицион методикалардан аермалы булган, укучыларның сөйләм телен үстерүгә нигезләнгән юнәлешкә игътибар арта (Әсәдуллин А.Ш.). Балаларны чит телләргә өйрәтүдә ана теленә нигезләнүнең нәтиҗәлелеге раслана (Хисамова В.Н., Ибатуллина Л.Х., һ.б. хезмәтләре). Бер үк вакытта чит телләрне өйрәтүдә турыдан-туры элемтәләр юлы (чит ил дәреслекләрен куллану, шул илләрдән белгечләр чакырту, кайбер фәннәрне чит телдә укыту) тәҗрибәсе дә киң җәелә.

90 нчы елларда Татарстанда мәгариф үсеше икетеллелек (билингвизм) белән турыдан-туры бәйле. Ике дәүләт теле булу, ике телдә аралашу ихтыяҗы нигезендә барлыкка килгән икетеллелек татар телен туган тел һәм дәүләт теле буларак өйрәнүнең нигезен тәшкил итә. Ул татар телен укыту методикаларын эшләүдә һәм, гомумән, уку йортларында уку-укыту процессын оештыруда төп принцип буларак алына. Чит телләр укытуга игътибар арту полилингваль (күптелле) белем бирү мәҗбүрилеген раслый.

Урта һөнәри белем бирү системасына да яңалыклар кертелә: татар телендә белем бирүче төркемнәр ачыла, предмет буларак татар теле укытыла башлый.

Милли мәктәпнең яңа бер тибы буларак барлыкка килгән татар-төрек лицейлары (1996 елда республикада 7 татар-төрек лицее ачыла) үз алларына төрек һәм Көнбатыш белем бирү системалары тәҗрибәләренә таянып, бер үк вакытта ана телен, рус һәм берничә чит телне камил белгән, дөньяга үзенең ныклы карашы булган яшь буын тәрбияләү максатын куялар. Татар яшьләренә Төркия һ.б. чит илләрнең югары уку йортларында белем алу мөмкинлеге ачыла.

Бу еллар чит ил педагогикасының алдынгы тәҗрибәсенә игътибар арту, укыту һәм тәрбиядә үзара хезмәттәшлек урнаштыру чоры буларак тарихка кереп кала. Аерым алганда, чит телләр үзләштерүдә башка илләр тәҗрибәсенә таяну, дәреслек һәм укыту методикаларын файдалану, фәнни мәктәпләр белән килешүләр төзү (мәсәлән, Ка-

зандагы 9 нчы мәктәп белән Лондондагы Блэкхейс колледжы, 9 нчы гимназия белән Фантенебл шәһәре (Франция) колледжы арасында һ.б.), башка предметларны чит телләрдә укыту (Казанның 155 татар-инглиз гимназиясе һ.б.) күзәтелә. Чит илләр педагогик системаларына – Вальдорф, М.Монтессори, С.Френе методикаларына таянып эшләгән мәктәп һәм мәктәпкәчә оешмалар барлыкка килә.

Мәктәпләрдә һөнәри юнәлешләргә өстенлек бирелә. Профильле яңа төр уку йортларында, шулай ук профильле сыйныфларда табигать фәннәре, физика-математика, гуманитар (чит телләргә басым белән), икътисади, эстетик һ.б. юнәлешләр буенча белем бирелә. Мәктәпләр белән вузлар арасында хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм итү буенча килешүләр төзелә, югары уку йортлары укытучылары эксперименталь программалар нигезендә мәктәпләргә килеп укыта.

Һәрбер мәктәптә һәм урта һөнәри белем бирү йортында татар теле укытыла башлау нәтиҗәсендә күпләп педагогик кадрлар әзерләү ихтыяҗы туа. Шул максатны күздә тотып, югары гуманитар белемле белгечләрдән татар теле укытучылары әзерләнә (КДУда, Казан дәүләт педагогия институтында (КДПИ), ТУБКИда махсус факультетлар ачыла).

Югары уку йортларындагы үзгәрешләр, иң беренче чиратта, алар алдына милли кадрлар әзерләү максаты куелу белән билгеләнә. Бу юнәлештә беренче адым киләчәктә Милли университетка база буларак каралган Татар дәүләт гуманитар институты ачылу белән билгеләнә (2005 елда ул ТДГПУ составына кертелә). Икенче юнәлеш – югары уку йортларында ике дәүләт телендә югары белемле белгечләр әзерләү мәсьәләсе. 1993 елда Татарстан югары уку йортлары ректорлар советы каршында татар телендә укыту мәсьәләләре буенча методик совет оеша. Күп вузларда татар телендә укытуны гамәлгә ашыру буенча эшче төркемнәр барлыкка килә. Татар мәгарифе тарихында беренче тапкыр буларак, «Татар телендә югары белем бирү концепциясе» (авторлары Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә., Нарбеков А.И.) әзерләнә һәм кабул ителә. Күп югары уку йортларында татар төркемнәре ачыла, аларда татар телендә белем бирелә, ике дәүләт телендә һөнәри эшчәнлек алып бара алырлык белгечләр әзерләнә башлый. Татар телендә дәреслекләр, методик әсбаплар дөнья күрә, техник һәм төгәл фәннәр буенча (механика, физика, химия, сызма геометрия һ.б.) фәнни терминология булдырыла, гуманитар һәм социаль фәннәр буенча вуз дәреслекләре дөнья күрә. Югары уку йортларында (нигездә Татар гуманитар институтында һәм педагогика университетында) барлык фәннәр буенча татарча белем бирә алучы мөгаллимнәр әзерләү мәсьәләсе хәл ителә.

Шулай итеп, бу чорда татар телендә югары белем мәсьәләсен күтәрү һәм тормышка ашырырга омтылу татар педагогик фикере үсешен билгеләүче төп юнәлешләрнең берсенә әверелә.

XX гасыр азагы – дини белем һәм тәрбия өлкәсендә дә зур алгарыш чоры. Ул исламның әхлакый кыйммәтләренә игътибар арту, яшь буынны шул кыйммәтләр нигезендә тәрбияләү омтылышы барлыкка килү белән билгеләнә. Дини мәгариф системасы үсешенең чагылышы булган күпсанлы мәдрәсәләр торгызылу (Ислам дине кабул ителүнең 1000 еллыгы, Мөхәммәдия һ.б.), югары дини уку йортлары (Россия ислам университеты) барлыкка килү, дини белем бирүнең концепциясен булдыру өстендә эшләү, уку-укыту процессының методик яктан тәэмин ителеше мәсьәләләре – болар барысы да шушы чор татар педагогик фикере үсешендә чагылыш тапкан мәсьәләләр.

Әлеге чорда татар педагогикасының үсеш тенденцияләрен чагылдырган юнәлешләрнең тагын берсе – җәмгыятьтә барган демократияләштерү күренешләре нәтиҗәсендә татар халкының үз асылына, тарихына, күп гасырлар буена тупланып килгән, әмма соңгы 60–70 ел эчендә онытылу, югалу дәрәҗәсенә җиткән милли кыйммәтләренә әйләнеп кайту, педагогик мирасны барлау һәм яңача күзлектән чыгып өйрәнү. Халык педагогикасы һәм этнопедагогика мәсьәләләренә игътибар арту, буыннан-буынга күчеп камилләшкән педагогик белемнәрне, халык өйрәтүләрен, тәрбия тәҗрибәсен өр-яңа күзлектән чыгып өйрәнү һәм хәзерге педагогик процесста файдалану мөмкинлеген барлау иң актуаль юнәлешләрнең берсенә әверелә.

Гуманлаштыру һәм гуманитарлаштыру, ягъни шәхескә, аның рухи дөньясына мөрәҗәгать итү, белем һәм тәрбия бирү барышында укучыларның фикерләү сәләтләрен үстерү, үстерелешле укытуга игътибар арту, фәнни яктан нигезләнгән яңа педагогик технологияләр булдыру, компьютерлаштыру һәм аларны уку-укыту барышында куллану кебек юнәлешләр татар педагогик фикере үсешендә зур урын алып тора. Тәрбия бирүдә традицион тармаклар белән беррәттән, яңа юнәлешләр барлыкка килә – милли йолалар һәм гореф-гадәтләр, халык традицияләре нигезендә экологик, икътисади тәрбия бирү, ислам кыйммәтләре нигезендә тәрбия бирү, тәрбия бирүдә милли сәнгать чараларын файдалану һ.б.

Татар мәгарифе проблемаларын, аерым алганда, татар телен һәм әдәбиятын, милли мәктәпләрдә рус телен, татар тарихын укытуны һәм аларның методикасын, тәрбия теориясен, татар мәгарифе тарихын һ.б. актуаль мәсьәләләрне өйрәнүдә РСФСР Педагогик фәннәр академиясе Милли мәктәпләр фәнни-тикшерену институтының

Татарстан филиалы ябылганнан соң барлыкка килгән Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгенең роле зур. ТФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты каршында ачылган әлеге бүлектә татар теле һәм әдәбияты, рус теле, татар тарихы буенча дәреслекләр һәм методик әсбаплар әзерләнә. Төрле елларда биредә Я.И.Ханбиков, А.Ш.Әсәдуллин, Ш.Ш.Җәләлиев, Ф.М.Солтанов, Ф.Ф.Исламов, Т.Ә.Биктимирова һ.б. күренекле галимнәр хезмәт куя.




*Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге. 2000 нчы еллар башы*

90 нчы еллар ахыры – XXI гасыр башы милли мәгариф үсешендә беркадәр чигенеш чоры буларак билгеле. Бу елларда татар мәктәпләренең, татар телендә белем алырга теләүчеләрнең саны кимү күзәтелә (1996/97 уку елында республикада 1256 татар мәктәбе булса, 2000/01 елда ул 1214 тәшкил итә)[7]. Ул, беренче чиратта, дәреслекләр һәм камил методика булмау сәбәпле татар телендә укытуның сыйфаты тиешенчә югарылыкка күтәрелмәү, ана телендә югары белем алу мөмкинлекләре чикле булу белән билгеләнә.

Гомумән алганда, 1990–2005 елларда татар педагогик фикере үсешенең иң төп юнәлешләренең берсе булган татар мәгарифе, бер

---

[7] Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – С. 64.

яктан, милли юнәлештә үсеш алса, икенче яктан, гомумроссия һәм бөтендөнья педагогик процессының гомуми үсеш тенденцияләренә (гуманлашу һәм гуманитарлашу, Болонья процессына кушылу һ.б.) нигезләнә. Шул сәбәпле анда татар халкының тәрбия һәм белем бирүдә гасырлар буе тупланып килгән милли үзенчәлекләре һәм традицияләре белән беррәттән, Россия һәм дөнья күләмендә урнашкан педагогик үсеш закончалыклары да чагылыш таба.

## 1.1. Татар мәгарифе үсеше концепцияләре

Әлеге чор РФдә дә, шулай ук милли республикаларда да, аерым алганда, ТРда, мәгариф үсешенең максатчан юлларын билгеләү, эзләнүләр дәвере булып кереп калды. Бу чорда татар милли мәгарифен торгызу, аны милли таләпләргә һәм шул ук вакытта заман шартларына туры килерлек система итеп төзү ихтыяҗы нигезендә күпсанлы концепцияләр һәм доктриналар (1990 елларда концепцияләр, 2000 еллар башыннан доктрина дип атала башладылар[8]) барлыкка килә.

Татар мәгарифе үсешенең нигезен һәм юлларын билгеләгән беренче концептуаль документларның барлыкка килүе Татарстандагы иҗтимагый хәрәкәт тарафдарларының эшчәнлеге белән бәйле. Татар иҗтимагый үзәге (ТИҮ) татар теленең статусын күтәрү, белем һәм тәрбияне татар телендә алып бару, һәрбер мәктәптә татар телен укыту, татар мәктәпләрендә, дәүләт телләреннән тыш, чит тел буларак гарәп һәм фарсы телләрен укыту, балалар бакчаларында туган телдә тәрбия бирү, урта һәм югары һөнәри уку йортларында татар теле һәм әдәбиятын укытуның нигезле методикасын булдыру һ.б. бурычларны милли мәктәпне торгызуда иң әһәмиятлеләре дип саный[9].

1990 еллар башында ТИҮ тарафыннан тәкъдим ителгән милли мәгариф концепцияләренә конкурста да әлеге таләпләр нигез шартлар буларак куела. 20 дән артык проект арасыннан И.Әмирханов тарафыннан әзерләнгән документ яхшы дип табыла, алга таба концепция әзерләү эше аңа тапшырыла. 1991 елда И.Әмирханов, Р.Ягъфәров, Х.Гарданов, Р.Ногманов һ.б. авторлыгында «Мәгариф» оешмасы һәм ТР Мәгариф министрлыгының уртак проекты – «Татар

---

[8] Гайфуллин В. Мәгариф реформалары һәм модернизациясе // Мәгариф. – 2002. – № 11. – 4 б.

[9] Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – С. 29.

мәгарифе үсеше концепциясе» әзерләнә[10]. Соңрак, ТРда «Мәгариф турындагы» законның яңа варианты кабул ителгәннән соң, концепция проекты яңартыла, өстәмәләр һәм кайбер төзәтмәләр белән кабат нәшер ителә[11].

Әлеге концепция сәяси һәм хокукый яктан ТР Конституциясенә һәм Дәүләт суверенитеты турындагы декларациягә нигезләнә. Ул татар мәгарифен белем һәм тәрбия бирүдә дәүләт һәм халык тәҗрибәсенә, шулай ук дөнья күләмендәге казанышларга таянган күп баскычлы бердәм белем бирү системасы итеп карый. Концепция татар милләтен дөнья цивилизациясе дәрәҗәсенә күтәрүне, татар мәгарифен Татарстанда гына түгел, Россия күләмендә дә (татарлар яшәгән өлкәләрдә) торгызуны максат итә. Концепция белем һәм тәрбия бирүне туган телдә алып баруны күздә тота; авторларның фикере буенча, ул татар милләтенең киләчәген тәэмин итәргә сәләтле күп баскычлы дәүләти мәгариф системасы булырга тиеш[12]. Концепция Россия мәгариф концепциясенә каршы килми, чөнки анда да туган телдә белем бирү мөмкинлеге карала. Шул ук вакытта Татарстан мәгариф концепциясендә билгеләнгән һәр баскычта да туган телдә укыту таләбе Россия концепциясе тарафыннан тулаем яклана алмый: Россия законнары буенча туган телдә белем һәм тәрбия бирү бары тик төп гомуми белем бирү системасында гына мөмкин. Барлык башка баскычларда (тулы урта белем, югары мәктәп һ.б.) укыту бары тик рус телендә генә алып барылырга мөмкин.

«Татарстан Республикасында милли мәгарифнең концептуаль нигезләре»[13] исеме астында дөнья күргән чираттагы концепция татар мәгарифен генә түгел, ә республикада яшәгән башка милләтләрнең дә мәгарифен үстерүне күздә тотып эшләнгән. Әлеге проектта «милли мәгариф» төшенчәсе, моңа кадәрге концепцияләрдән аермалы буларак, киңрәк мәгънәдә кулланыла – «республика халкының һәрбер этник төркемен» карый. Бу документ Татарстанда яшәүче төрле милләт вәкилләре өчен милли мәгариф концепцияләрен булдыру өчен нигез буларак тәкъдим ителә. Шул рәвешчә, аерым концепция һәм аны тормышка ашыру буенча программалар барлыкка килә, соңгылары аерым

---

[10] Концепция развития татарского просвещения // Шәһри Казан. – 1991. – 15 март.

[11] Татар мәгарифен үстерү концепциясе // Мәгърифәт. – 1997. – 27 август.

[12] Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – С. 33.

[13] Концептуальные основы национального просвещения Республики Татарстан // Мәгърифәт. – 2000. – 19 февраль.

мәктәпләрдә (рус, татар, чуваш, мари, удмурт, мордва) эксперимент буларак кертелә[14]. Гомумән алганда, 2000 еллардан соң милли мәгариф дип Россиядә яшәүче барлык милләтләр, шул исәптән рус милләтенең, мәгарифе күзаллана башлый, ул илкүләм (федераль) дәрәҗәдәге категориягә әверелә. «Милли мәгариф» төшенчәсе яңа эчтәлектә беренче тапкыр РФ мәгариф доктринасында искә алына[15]. Европа академик традицияләре нигезендә дә «милли мәгариф» төшенчәсе астында дәүләт мәктәпләре системасын карау кабул ителгән[16].

«Татарстан Республикасында милли мәгарифнең концептуаль нигезләре» концепциясе буенча милли мәгариф үсешендә биш баскыч булырга тиеш: гаилә, урта гомуми белем, урта һөнәри, югары һөнәри һәм фәнни мәктәпләр. Ул укучыларның шәхси үзенчәлекләрен һәм мөмкинлекләрен, сәләтләрен һәм кызыксынуларын искә алган хәлдә һөнәри юнәлешләргә караган мәктәпләр – гуманитар, төгәл фәннәр, табигать фәннәре, гамәли-техник, спорт-техник, мәдәни-белем бирү, музыкаль профильдәге, шулай ук һөнәри (школа ремесел), фермер мәктәпләрен һ.б. булдыру мәсьәләсен карый. Концепция мәктәп советы карары буенча башка төр мәктәпләр оештыру мөмкинлеген дә кире какмый. Ул элементар, стандарт һәм югары (катлаулы) типтагы программалар куллану, шулай ук индивидуаль һәм төркемле программалар төзү мөмкинлеген дә күздә тота.

1996 елда Милли мәҗлеснең 2 чакырылышында тәкъдим ителгән, И.Әмирханов тарафыннан әзерләнгән «Татар мәктәбенең тәгълимати һәм гамәли нигезләре» проекты, моңарчы искә алынган концепцияләрдән аермалы буларак, дәүләттән аерым, мөстәкыйль татар милли мәгариф системасын төзүне күздә тота. Ул, автор фикеренчә, баланың ана карыннан алып, шәхес буларак формалашканга кадәр булган чорны үз эченә алырга тиеш[17], Шәрык һәм төрки дөнья, ислам кыйммәтләренә таянырга, шул ук вакытта Европа тәҗрибәсен дә искә алырга тиеш[18]. Милли мәгарифнең үзенчәлекләрен

[14] Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – С. 33.

[15] Национальная доктрина образования в Российской Федерации // Мәгариф. – 2000. – № 3. – 5–7 б.

[16] Власова Т.А. Образовательный потенциал школы с этнокультурным компонентом на примере национальной школы г. Ижевска // Вестник Удмуртского университета. – 2013. – Вып. 1. – С. 49.

[17] Әмирхан И. Татар фәлсәфәсе һәм милли мәгариф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 157 б.

[18] Шунда ук. – 168 б.

тулаем чагылдыруына карамастан, шәхси мәктәпләр, дәүләти булмаган система булдыруны («ул тулаем халык кулында булырга, түбәннән, аерым мәктәп яки коллективлар инициативасы белән оешырга тиеш; шул ук вакытта төрле юнәлешләрдәге һәм төрле баскычка караган милли мәктәпләр дәүләт карамагында да булырга мөмкин»[19]) максат иткән, эчтәлеге белән РФ законнарына каршы килмәгән бу концепция тәҗрибәсе соңыннан Татарстанда берничә шәхси мәктәп төзүдә файдаланылды.



*И.Әмирханов*

ТРда яшәүче барлык милләтләрнең мәгарифен үстерүгә юнәлдерелгән 2000 нче елгы концепциядә И.Әмирханов тәкъдим иткән проекттагы фикерләрнең шактые чагылыш таба. «Милли мәктәп, – диелә анда, – рухи-дөньяви мәктәп, ул этномәдәни тамырларга таяна, мәгърифәтнең рухи яктылыгында үсеш ала. Ул карыннан алып, этносоциаль һәм рухи-дөньяви шәхес формалашканга кадәрге чорны үз эченә ала»[20]. Әлеге концепцияләрдә «мәктәп бары тик милли булганда гына үзенең белем һәм тәрбия бирү функцияләрен үти ала» диелә. Күп галимнәр, аерым алганда М.Мәхмүтов, әлеге формулировкадагы «бары тик» сүзенә кискен каршы чыга. «Бу очракта бик күп халыкларның тәҗрибәсен үз эченә алган татар фәнни-педагогик мәктәпләрне кая куярга?!» – дип яза ул[21].

«Татарстан Республикасында белем һәм тәрбия бирү системалары үсешенең милли доктринасы» исеме астында дөнья күргән чираттагы концепция ТФА Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәге тарафыннан әзерләнә[22]. Ул фәнни яктан шактый әзерлекле, нигезле булуы, проблемага глобаль яктан якын килүе белән аерылып тора.

---

[19] Шунда ук. – 157–158 б.

[20] Концептуальные основы национального просвещения Республики Татарстан // Мәгърифәт. – 2000. – 19 февраль.

[21] Мәхмүтов М. Мәктәпләребезнең үсеш юнәлешләре // Мәгариф. – 1996. – № 2. – 5 б.

[22] Национальная доктрина развития образовательно-воспитательных систем в Республике Татарстан. – Казань, 1999.

Документның барлыкка килүе республикада белем-тәрбия системалары реформаларының беренче этабы тәмамланып, икенче, хәлиткеч этапка күчү мәҗбүрилеге ачыкланган чор белән бәйле. Әлбәттә, алдагы концепцияләр тарафыннан куелган таләпләр нигездә тормышка аша алмады (татар телендә югары мәктәп яралгы хәлендә калды, мәгариф өлкәсендә татар теле тулаем урнаша алмады һ.б.). Шуңа күрә проблемага карата яңача, заманча караш булдыру мөһим була. Милли тойгылар, аерым шәхесләрнең (педагогларның) инициативасына нигезләнгән беренче этаптан соң дәүләт яклавына һәм ярдәменә таяну мөмкинлеге булган чаралар эзләү мәҗбүрилеге ачыклана.

Доктрина илдәге һәм республикадагы вәзгыятьне күздә тотып, мәгариф мәсьәләләрен нәзари һәм гамәли өйрәнүгә юнәлдерелгән тикшеренүләргә, башка республикалар һәм илләрдәге мәгариф реформалары тәҗрибәсенә һәм Татарстан халыкларының милли традицияләренә нигезләнеп эшләнә[23]. Ул мәгариф өлкәсендә дәүләт сәясәтенә генә түгел, суверен республика халыкларының идеалларына, максат һәм кыйммәтләренә дә таяна[24]. Доктрина өзлексез белем бирүнең ачык, үсештәге һәм яраклашучан системасын булдыруны максат итә. Ул, авторларның билгеләвенчә, республиканың XXI гасыр таләпләренә җавап бирә ала торган заманча, милләтләрнең алга таба үсешен тәэмин итәрлек, халыкның төп (база) белемнәргә ия булуына ярдәм итәрлек, икътисади яктан тотрыклы мәгариф системасына нигез булырга тиеш[25].

2000 елда РФдә мәгариф өлкәсендә законнар системасын камилләштерүнең төп юнәлешләрен күрсәткән, мәгариф үсеше программаларына нигез буларак тәкъдим ителгән Россия мәгариф доктринасы дөнья күрә[26]. Ул аерым төбәкләргә милли-төбәк компонентын һәм Россия доктринасын исәпкә алган документлар нигезендә

---

[23] Муртазина Л.Р. Сравнительный анализ основных концепций реформирования образования в РТ // Сборник материалов итоговых конференций Центра истории и теории национального образования 2004–2005 гг. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2006. – С. 60.

[24] Национальная доктрина развития образовательно-воспитательных систем в Республике Татарстан. – Казань, 1999. – С. 3.

[25] Шунда ук.

[26] Национальная доктрина образования в Российской Федерации // Мәгариф. – 2000. – № 3. – С. 5–7.

үз доктриналарын төзү мөмкинлеген бирә[27]. Шундый концепцияләрнең берсе – Чувашстан Республикасында милли мәктәп үсеше концепциясе[28]. Ул республикада яшәүче барлык милләтләр – чувашлар, руслар, татарлар, мордвалар һ.б. өчен мәктәпләр һәм аларда туган телләрдә һәм туган телләрне укыту мөмкинлеген карый. Концепциядә күрсәтелгәнчә, бу чорда Чувашстандагы татар мәктәпләренең 1–5 нче сыйныфларында балалар туган телләрендә белем ала, мәктәпкәчә балалар оешмаларында туган телдә белем һәм тәрбия бирелә[29]. Шулай итеп, 2000 нче елларда Россиянең татарлар яшәгән төбәкләрендә туган телдә белем алу мөмкинлеге шул республикаларның концептуаль документлары нигезендә раслана.

Гомумән алганда, бу чорда дөнья күргән мәгариф үсеше концепцияләрендә уртак һәм аермалы яклар бар. Бердәм белем бирү киңлеген булдыруга юнәлдерелгән Россия документларына нигезләнгән хәлдә, Татарстан концепцияләре мәгариф өлкәсендә ирешелгән уңай тәҗрибәне, республикада яшәүче милләтләрнең мәнфәгатьләрен истә тоту, аларның мәдәниятен һәм үзенчәлекләрен саклауга юнәлдерелә. Шунысын ассызыклау мөһим: Россия мәгариф доктринасы милли мәгарифләргә карата декларатив характерга ия. Анда милли мәгарифләр үсеше кире кагылмый, ләкин шул ук вакытта аларның эшчәнлеген тормышка ашыру механизмнары күрсәтелми (мисал өчен, туган телдә белем алу хокукы раслана, тик туган телләрдә дәреслекләр булдыру, укытучылар әзерләү механизмы бирелми). Татар мәгарифе үсеше концепцияләрендә, киресенчә, күбрәк механизмнар тәкъдим ителә.

2000 еллардан соң дөнья күргән документлар гомумкешелек кыйммәтләренә таянган, бөтендөнья мәдәни-мәгариф киңлегенә омтылган, шул ук вакытта үз милли үзенчәлекләрен, бөтенлеген саклаган, үз милләтенең рухи һәм мәдәни мирасына таянган хәлдә укучыларга интернациональ тәрбия бирүне максат иткән милли мәгариф төзүне максат итә.

---

[27] Валиев М.Х. Общее и особенное в образовательных доктринах России и Татарстана // Национальная школа и актуальные проблемы национального образования. – Казань: Институт истории АН РТ, 2001. – С. 10.

[28] О концепции национальной школы Чувашской Республики в современной системе обучения и воспитания. URL: http//docs.cntd.ru/document /473600782

[29] Шунда ук.

## 1.2. Мәктәпкәчә тәрбия

Тәрбиядә иң мөһим һәм хәлиткеч чорларның берсе – мәктәпкә кадәрге чор. Бу чорда бала әйләнә-тирә, төп кешелек кыйммәтләре белән таныша. Әлбәттә, тәрбия, иң беренче чиратта, гаиләдән башлана. Бик борынгы заманнардан ук татар гаиләсендә тәрбия халкыбызның күп гасырлык тәҗрибәсенә таянып, традиция һәм гореф-гадәтләргә нигезләнеп алып барылган. Татар гаиләсендә ата-ана, әби-баба сүзе, олылар үрнәге зур әһәмияткә ия булган. Бу традиция совет елларында да сакланып калган. 90 нчы елларда милли күтәрелеш чорында гаилә тәрбиясенә игътибар тагын да арта. Инде онытыла барган кайбер гореф-гадәтләрне торгызу, ата-аналарны балаларын милли традицияләребез нигезендә тәрбияләүнең юлларын һәм эчтәлеген өйрәткән әсбаплар һәм кулланмалар нәшер ителә башлый.

Мәктәпкәчә тәрбиядәге икенче мөһим фактор булып балалар бакчалары тора. Билгеле булганча, 90 нчы еллар башында моңа кадәр бары тик авылларда гына сакланып калган татар балалар бакчалары ТР шәһәрләрендә дә барлыкка килә. Махсус татар балалар бакчалары белән беррәттән, гадәти оешмаларда татар телендә тәрбия эшләрен алып баручы төркемнәр ачыла. Мәгариф өлкәсендә барган үзгәрешләр мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирүне оештыру белән беррәттән, аның эчтәлегендә дә чагылыш таба, ата-аналарга үз балаларына нинди телдә тәрбия һәм белем бирүне, бакчаларның төрен (гадәти яки мөселман һ.б.), баланың иҗади һәм акыл үсешенә ярдәм итәрлек түгәрәкләрне сайлау мөмкинлеге бирелә.

90 нчы еллар, бер яктан, балалар бакчалары челтәренең күпмедер дәрәҗәдә кимүе (нигездә демографик һәм иктисади шартларга бәйле рәвештә) белән билгеләнсә, икенче яктан караганда, сыйфат, эчтәлек ягыннан баюы белән характерлана. Бу чор балалар бакчалары системасы, шулай ук татар балалар бакчалары үсешендә дә, вариативлык, ягъни төрле төрдәге һәм типтагы учреждениеләр (катнаш төрдәге, үсеш үзәкләре, прогимназияләр, башлангыч мәктәп – балалар бакчасы, иртә үсеш (2 айдан – 3 яшькәчә), өлкәннәр өчен (5–7 яшь) һ.б.) барлыкка килү, балаларга белем һәм тәрбия бирүдә яңа метод һәм алымнар, инновацион технологияләр куллану мөмкинлеге булдырылу белән билгеләнә. Телләр өйрәтү, сәнгати һ.б. юнәлештә эшләүче бакчалар, балалар бакчаларына йөрмәүче нәниләр өчен мәктәпкә әзерләү төркемнәре, кече яшьтәге балалар өчен кыска вакытка исәпләнгән, якшәмбе төркемнәре һ.б. оештырылу

шулай ук әлеге чорның үзенчәлеге булып тора. 90 нчы еллар ахыры балалар бакчаларының хокукый-оештыру ягыннан үзгәрешләр кичерүе белән билгеләнә, яңа форма – автоном бакчаларга күчә башлау күзәтелә. Шулай ук, республикада демографик хәлнең яхшыра баруы белән, дәүләти булмаган, хосусый балалар бакчалары һәм аларның төре буларак гаилә бакчалары барлыкка килә.

Балалар бакчаларында инновацион технологияләр куллану – әлеге чорга хас үзенчәлекләрнең берсе («Физик үсеш», «2100 ел мәктәбе», «Балачак», экологик тәрбия, ТРИЗ технологиясе («Уйлап табу мәсьәләләрен чишү теориясе»), В.Н.Мещерякова, Р.К.Шәехова методикалары, пиктограммалар[30] һ.б.). Татар балалар бакчалары, моннан тыш, ана телендә белем һәм тәрбия бирү, татар халкының милли гореф-гадәтләре, йола һәм бәйрәмнәре нигезендә тәрбияләү, татар тарихын, мәдәниятен, әдәбиятын һ.б. өйрәтүгә игътибарны юнәлтә.

ТР Мәгариф министрлыгының 1991 елгы «Мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләрендә татар телен өйрәнүне яхшырту чаралары турындагы» боерыгы нигезендә татар теле дәүләт теле буларак өйрәтелә башлый. Бу чорда Татарстанда татар балаларының 75% тан артыграгы ана телендә белем һәм тәрбия бирүче балалар бакчаларына йөри (чагыштыру өчен: Россиядә барлык рус балалары ана телләрендә тәрбияләнсә, башка республикаларда, аерым алганда, Чувашстан Республикасында, бу чорда чуваш балаларының 35%ы милли балалар бакчаларына йөри, бер мәктәпкәчә белем бирү оешмасында белем һәм тәрбия рус, чуваш һәм татар телләрендә, 8 балалар бакчасында (207 бала) татар телендә бирелә[31]).

Билгеле булганча, милли үзаң тәрбияләүнең төп шарты – ул гаилә тәрбиясе һәм милли мохит. Милли мохит тудыруда балалар бакчаларының роле зур. Милли горурлык хисе, милли үзаң тәрбияләү татар халкы тарихы, мәдәнияте үрнәкләре белән таныштыру, халыкның күп гасырлык әхлак тәрбиясе тәҗрибәсенә һәм халык педагогикасына нигезләнү бу чорда татар балалар бакчаларының төп бурычларыннан берсе булып санала[32]. Милли тәрбия бирүдә яңа форма һәм чаралар билгеләнә, татар халкының тарихына, гореф-гадәтләренә һәм йолаларына, милли бәйрәмнәргә игътибар арта. Алар

[30] Шәехова Р. Иҗади уеннан – укуга. – Казан, 1999. – 91 б.; Шаехова Р.К. Играя – учимся творить. – Казань, 1997. – 40 с.

[31] О концепции национальной школы Чувашской Республики в современной системе обучения и воспитания. URL: http//docs.cntd.ru/document/473600782

[32] Мәктәпкәчә тәрбия: Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү. – Казан: Школа, 1998. – 15 б.

татар балаларын тәрбияләүдә иң төп чараларның берсенә әверелә. Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга әхлак тәрбиясе бирүнең методик нигезләре Р.Низамов, К.Закирова, Р.Кадыйрова, В.Казыйханов[33] хезмәтләрендә чагылыш таба.



К.Закирова

Уеннар, зәвык тәрбиясе милли тәрбия бирүдә төп чаралар буларак файдаланыла. Бу елларда дөнья күргән балалар өчен музыкаль әсәрләр җыентыклары[34], бәйрәм һәм кичә сценарийлары[35], хрестоматияләр беренче чиратта милли үзаң тәрбияләүне күздә тота. Иң беренче әсбапларның берсе – «Гөлбакча» җыентыгының авторлары билгеләвенчә, «Хрестоматиядән файдаланганда балаларның яшь үзенчәлекләрен, акыл һәм зиһен үсешендәге этапларны истә тотып эшләргә кирәк. Тәрбияче балаларның акыл эшчәнлеген тагын да үстерү һәм камилләштерү буенча системалы эш алып барырга тиеш»[36]. Кулланма бу максатларны тормышка ашырырга мөмкинлек бирә, әмма коммунистик идеологиядән арынып бетә алмау әле сизелә (В.И.Ленин һәм аның тормышы турында текстлар күп).

Милли тәрбияне тормышка ашыру чарасы буларак каралган гореф-гадәтләр, милли йолалар, фольклор үрнәкләрен тәкъдим итүдә сакчыл караш булдыру мөһим. 90 нчы елларда басылып чыккан кайбер әсбапларда бу принцип искә алынмый. Мәсәлән, «Раушан көзге» җыентыгында урта төркем өчен тәкъдим ителгән «Идегәй» дастаны

[33] Низамов Р., Закирова К. Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәплелек тәрбияләү // Мәгариф. – 2005. – № 9. – 42–44 б.; № 10. – 43–45 б.; Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә. Әхлак нигезе – матур гадәт (Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү): Методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2004. – 383 б.; Казыйханов В. Иман дәресләре. – Яр Чаллы: ӨПББИ, 1997. – 80 б.; Әхлак дәресләре: Укытучылар, сыйныф җитәкчеләре, тәрбиячеләр өчен дәрес эшкәртмәләре. – Яр Чаллы: ӨПББИ, 2001. – 239 б. һ.б.

[34] Ишниязова З.Л., Вафина Т.В. Балалар бакчасында музыка дәресләре уздыру өчен хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1999; Сабирова С.М. Җырлыйк, уйныйк, нәниләр. – Чаллы, 1994 һ.б.

[35] Балачак бәйрәмнәре (Тамаша үрнәкләре) / Төз. С.Сәүбанова. – Казан, 1999. – 58 б.

[36] Гөлбакча: Балалар бакчалары өчен хрестоматия / Төз. Ф.Ю.Юсупов, З.Ф.Камалова, Р.А.Борһанова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 255 б.

(3–10 битләр), «Сак-сок бәете»нең (11–13 битләр) текстлары мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен яраклаштырылмаган, шул сәбәпле, милли үзаң тәрбияләүдә көчле чара буларак уйланылсалар да, чынлыкта аларны тәрбия процессында файдалану мөмкинлеге чикле була.

Әлеге чорда милли уеннарны кайтару, аларны тәрбия барышында куллануга багышланган әсбаплар күп дөнья күрә. Р.Ягъфәров, беренчеләрдән булып, татар балалар фольклорын һәм шуның бер өлеше буларак уеннарны фәнни яктан өйрәнә һәм шул эшнең нәтиҗәсе буларак, татар балалар бакчалары өчен махсус хрестоматияләр тәкъдим итә. Моңарчы татар балалар бакчалары тәрбиячеләре Н.Исәнбәт китапларына нигезләнеп эшләсә, хәзер бу өлкәдә сайлау мөмкинлеге тудырыла[37].

Соңгы елларда басылып чыккан уен җыентыкларының авторлары уеннарга карата куелган максат һәм мөмкинлекләрнең төрлелегенә игътибар итәләр. К.В.Закирова, мәсәлән, уеннарны балаларны рухи яктан бай, физик яктан сәламәт итеп үстерү юлларының берсе һәм иң әһәмиятлесе, тәрбияче өчен балаларны яхшырак аңлау, аларга якынаю, аларда эстетик тойгылар тәрбияләү чарасы дип саный: «Хәрәкәтләрнең төгәллеге, уенның сүзләрен сәнгатьле итеп әйтү, баланың төрле образлар башкаруы – болар барысы да балаларда канәгатьләнү хисләре уята, матурлыкны аңларга ярдәм итә. Уен вакытында туган шатлыклы кичерешләр уенны көчле тәрбия чарасына әверелдерә»[38].

М.Кашапова исә уеннарга иң беренче чиратта сөйләм телен үстерү чарасы итеп карый, сүзле, дидактик, үстерелешле уеннарны сөйләм телен үстерү шөгыльләрендә үзләштерелгән белемнәрне ныгыту чарасы буларак тәкъдим итә[39].

З.М.Маһиярова мәктәпкәчә яшьтәге балаларда иң мөһим әхлакый сыйфатлар иң беренче чиратта уеннар аша тәрбияләнә дип саный. Бу максаттан ул язучы һәм шагыйрьләребезнең әхлакый

---

[37] Кәҗә-мәкәрҗә: Балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен кулланма / Төз. Р.Ягъфәров. – Казан: Мәгариф, 1994. – 109 б.; Ал кирәк, гөл кирәк: Укытучылар һәм балалар бакчалары тәрбиячеләре өчен кулланма / Төз. Р.Ягъфәров. – Казан: Мәгариф, 1995. – 125 б.; Алтын кашык: Такмаклар, уеннар... / Төз. Р.Ягъфәров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 111 б. һ.б.

[38] Закирова К.В. Уйный-уйный үсәбез (Балалар бакчасында уеннар): Балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма). – Казан: Мәгариф, 2005. – 3 б.

[39] Кашапова М. Иң татлы тел – туган тел: Балалар бакчасында сөйләм үстерү буенча методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2004. – 4 б.

эчтәлектәге әсәрләрен сәхнәләштереп уйнарга тәкъдим итә. Шулай ук халык уеннарын туган телне өйрәнү, бәйләнешле сөйләм үстерү, тәрбияче үткәргән шөгыльләрнең кызыклы булуына ирешү өчен дә файдаланырга мөмкин дип саный[40]. С.Х.Айдарова уеннар аша татар телен өйрәтү юлларын күрсәтә.[41]

Татар телен өйрәтүдә иң төп мәсьәләләрнең берсе булып укыту барышын методик әсбаплар белән тәэмин итү тора. Совет чорында, аерым алганда 1960–1985 елларда, татар балалар бакчалары өчен язылган методик әдәбиятның гомуми саны дистәдән артмый. 90 нчы еллар башында Р.А.Борһанова, Ф.Ю.Юсупов, К.Закирова, З.Т.Шәрәфетдинов, М.Ф.Кашапова һ.б. авторлыгында татар балалар бакчалары өчен программалар, милли тәрбия, телләргә өйрәтү, балалар бакчаларында эшне оештыру, планлаштыру буенча методик әсбаплар, хрестоматияләр төзелә.

Озак еллар дәвамында бердәм Мәскәү программаларын кулланып килгән татар балалар бакчаларында бу елларда һәр бакчага, һәр тәрбиячегә программа сайлау, төп бурычларны үзгәртмәгән хәлдә аны үзенә кирәгенчә яраклаштыру яисә үзе төзү мөмкинлеге бирелә. Махсус татар бакчалары өчен язылган һәм шул чордагы вәзгыятьне күз алдында тотып төзелгән программалар дөнья күрсә дә[42], беренче чорда төп, нигез документ буларак Мәскәү тарафыннан тәкъдим ителгән программалар хезмәт итә. 1994 елда бу программа татар теленә тәрҗемә ителеп һәм беркадәр тулыландырылып нәшер ителә[43]. Анда, оригиналдан аермалы буларак, сөйләм телен үстерүгә зур игътибар бирелгән, өстәмә рәвештә татар язучыларының әдәби әсәрләре һәм халык авыз иҗаты үрнәкләре, музыка тәрбиясе бирүдә татар композиторларының балалар өчен язган әсәрләре тәкъдим ителә. Авторлар тәрбия эше «үз туган халкыңның мәдәниятеннән – тирәндә яшәүче халыклар, алар аша – дөнья мәдәниятенә» дигән принципка нигезләнергә тиеш дип санийлар. Әмма, белгечләрнең билгеләвенчә, программага өстәлгән милли компонент бик аз, үз

---

[40] Маһиярова З. Балаларда әхлак сыйфатлары тәрбияләү // Мәгариф. – 1997. – № 12. – 86–87 б.

[41] Айдарова С.Х. К знаниям через игру. – Казань: ТГГИ, 1998. – 116 с.

[42] Татар балалар бакчалары өчен программа / Ред. Ф.Ю.Юсупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 120 б.; Балалар бакчаларында тәрбия һәм белем бирү программасы / Төз. К.В.Закирова, Р.А.Борһанова. – Казан: Хәтер, 2000. – 192 б.

[43] Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / Төз. һәм тәрҗ. Ф.Ю.Юсупов, Р.А.Борһанова, Р.Н.Ярмиева һ.б. – Чаллы: КамАЗ, 1994.

милли мәдәниятен белүче һәм аны өйрәнүне дәвам итүче шәхес формалаштыруны тәэмин итәрлек дәрәҗәдә түгел[44]. Программа «мәктәпкәчә тәрбия буенча дәүләт һәм республика стандартларын, педагогика һәм психология өлкәсендәге казанышларны, хәзерге заман таләпләрен искә алып, үзгәртелеп һәм тулылыландырылып язылуы»[45] белән аерылып тора.

Моңа кадәрге программаның төп кимчелеге – аның тәрбия һәм белем бирү эшендә укыту-дисциплинар модельне куллануында иде, ягъни анда төп максат булып балаларны мәктәптә укырга әзерләү, белем һәм күнекмәләр бирү торды. Ә соңгы программада исә беренче чиратта баланың шәхес буларак үсешенә, аның шәхси үзенчәлекләренә нигезләнеп, сәләтләрен ачу, шуны тагын да үстерү өчен билгеле бер юнәлеш бирүгә игътибар ителә.

Рус теленә өйрәтү А.Ш.Әсәдуллин[46], Р.А.Борһанова программалары[47] нигезендә алып барыла. Татар теле программалары ике юнәлешне – туган тел буларак һәм рус телле балаларга тел өйрәтүне искә алып эшләнә. Татарларга туган телне өйрәтү программаларының[48] яңа иҗтимагый һәм икътисади шартларга, вәзгыятькә туры килмәве сәбәпле, яңа программалар әзерләнә[49]. Бу чорның тагын бер үзенчәлеге – иҗат мөмкинлегенең киңәюе. 90 нчы еллар азагында аерым тәрбиячеләрнең эш тәҗрибәләренә нигезләнеп иҗат ителгән программалар да шактый дөнья күрә[50].

---

[44] Һадиуллин И.Г. Хәзерге мәктәпкәчә тәрбия системасында милли-мәдәни юнәлеш // Мәктәпкәчә тәрбия: Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү. – Казан: Школа,1998. – 5 б.

[45] Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / Төз. К.В.Закирова, Р.А.Борһанова. – Казан: Хәтер, 2000. – 4 б.

[46] Асадуллин А.Ш. Программа по русскому языку для татарских детских садов // Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы / Төз. һәм тәрҗ. Ф.Ю.Юсупов, Р.А.Борһанова, Р.Н.Ярмиева һ.б. – Чаллы: КамАЗ, 1994. – 64–93 б.

[47] Бурганова Р.А. Программы по обучению русскому языку. – Казань: Хәтер, 2000.

[48] Балалар бакчасы өчен ана теле программасы // Совет мәктәбе. – 1986. – № 10. – 46–52 б.; № 11. – 48–54 б.; № 12. – 42–45 б.

[49] Тәрбия эшләре рус телендә алып барыла торган балалар бакчалары өчен татар теле программасы / Төз. Р.А.Борһанова, Ф.Ф.Юсупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991; Балалар бакчасында татар теле өйрәтү программасы / Төз. Р.А.Борһанова, Ф.Ф.Юсупов. – Казан: Школа, 2004.

[50] Муллаәхмәтова Е. Рус телле балаларны татар теленә өйрәтү (программа) // Фән һәм мәктәп. – 1999. – № 7–8. – 202–206 б.; № 11–12. – 117–120 б. һ.б.

Татар теле барлык балаларга да өйрәтелә башлау белән, сөйләм әдәбенә игътибар арта. Бу проблема М.Ф.Кашапованың хезмәтләрендә чагылыш таба.[51] Ләкин татар теленә өйрәтүгә бик аз вакыт каралу, шөгыльләрнең атнага өч тапкыр 15 әр минут дәвамында гына алып барылуы балаларның телне тиешле дәрәҗәдә өйрәнүенә булышлык итә алмый. Шуңа күрә башка шөгыльләрне туган (татар) телдә алып бару зур әһәмияткә ия була. Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру, музыка тәрбиясе бирү, сынлы сәнгать буенча татарча әсбаплар шул максатны да күздә тотып эшләнә[52], аларны төзүдә тәрбиячеләр үзләре дә катнаша.

Зәвык, сәнгать тәрбиясе милли тәрбия бирүдә иң көчле чараларның берсе буларак файдаланыла. Шөгыльләр, бәйрәм кичәләре уздырганда татар көйләренә, музыкаль фольклорга, татар композиторларының әсәрләренә игътибар арта. Программаларда моңа кадәр дә күпмедер күләмдә татар композиторларының музыкаль әсәрләрен өйрәнү чагылыш таба иде[53], хәзер исә татар көйләреннән генә торган махсус җыентыклар һәм аларны тәрбия барышында дөрес һәм нәтиҗәле куллануга багышланган методик кулланмалар нәшер ителә[54].

Милли мәдәният белән кызыксыну арту белән аны дөрес итеп балаларга җиткерүнең төрле юлларын эзләү күзәтелә. Моңа кадәр нигездә Мәскәү методистлары тарафыннан тәкъдим ителгән әсбаплардан файдаланылса, яңа вәзгыятьтә төп урын татар халкы мәдәниятен өйрәнү, үзләштерүгә бирелә, МТК үз эченә алган әсбаплар дөнья күрә[55]. Мавыктыргыч итеп, җиңел телдә, нәниләрнең яшь һәм

---

[51] Кашапова М.Ф. Балалар бакчасында сөйләм телен үстерү программасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 62 б.; Иң татлы тел – туган тел: Балалар бакчасында сөйләм үстерү буенча методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2004. – 447 б.

[52] Борһанова Р. Татар халкының мәдәнияте белән таныштыру // Мәгариф. – 1994. – № 8. – 32–54 б.; Шәйхетдинова З., Шәйхетдинов Ф., Камалова З. Балалар бакчасында музыкаль тәрбия бирү программасы // Совет мәктәбе. – 1989. – № 8. – 50–53 б.; № 9. – 47–50 б.; №10. – 46–48 б. һ.б.

[53] Татар балалар бакчалары өчен программа / Ред. Ф.Ю.Юсупов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 120 б.

[54] Музыка әлифбасы / Ред. А.Ә.Тәхәвиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 90 б.; Балалар бакчаларында музыкадан файдаланып иртәнге гимнастика / Төз. С.М.Пискунова, М.Р.Сафин. – Казан: Таң-Заря, 1999. – 48 б.; Сабирова С.М. Җырлыйк, уйныйк, нәниләр. – Чаллы, 1994. – 86 б. һ.б.

[55] Сергеева Н. (Нурзия). Татар сынлы сәнгате: Өстәмә белем бирү программасы һәм методик кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1999. – 55 б.; Сергеева Н. Әбиемнең сандыгы: Тәрбиячеләр, укытучылар өчен кулланма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 32 б.; Сергеева Н. Татар чигүе = Татарская вышивка. – Казан: Мәгариф, 2005. – 45 с.

психологик үзенчәлекләрен истә тотып язылган, төсле рәсемнәр, кечкенә шигырьләр белән тулыландырылган мондый кулланмаларда татар киемнәре, бизәнү әйберләре, нәфис керамика, милли чигү һ.б. буенча мәгълүмат тупланган, аппликация, әвәләү, чигү кебек эш алымнары аша татар сәнгатен өйрәтүнең милли мәдәниятебезне саклап калуда иң әһәмиятле юлларның берсе булуы ассызыклана. Татар халык сәнгатенең тәрбияви роле башка авторларның хезмәтләрендә дә чагылыш таба[56].

Рус телле балаларга татар телен өйрәтүдә нигездә А.Ш.Әсәдуллин, С.Г.Вагыйзов[57] алымнарына өстенлек бирелә. Ана телен белмәгән татар балалары белән шөгыльләнүче тәрбиячеләргә атап язылган «Татар теле өйрәнә нәниләр» китабының төп максаты – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак фадаланырга әзерләү. Авторлар төп методик принцип буларак бик гадидән катлаулыракка таба бару, кабатлау-төшендерү алымнарын ешрак куллануны һәм рус теле белән чагыштырып өйрәтүне тәкъдим итәләр.

Бу чорда балалар бакчаларында татар телен чит тел буларак өйрәтү буенча методикалар эшләнә. Шундыйларның берсе – Р.Шаехова тәкъдим иткән аваз бәйләнешләре (охшашлыклары) методы (метод звуковых ассоциаций). Ул туган телдә чит телдәге сүзгә охшаш сүзләр эзләүдән һәм шул сүзләргә охшатып чит сүзләрне истә калдырудан гыйбарәт. Бу эшне автор балалар өчен кызыклы, гадәти булмаган формалар, экияти образлар аша алып барырга тәкъдим итә. Яңа сүз өйрәткәндә аны бигрәк тә ассызыклап, интонация белән әйтү, шул рәвешле баланың игътибарын әлеге сүзгә юнәлтү, аны кабатлау һәм дөрес әйтелешен өйрәтү мөһим. Автор моңа кадәр белгән яки истә калдырылган материал аша яңа сүзне өйрәтү бер үк вакытта тәрбиячегә уңайлы, шул эшкә баланың үзен тарту эш барышы белән идарә итәргә мөмкинлекләр тудыра дип саный.[58]

Әлеге чорның тагын бер үзенчәлеге – татар балаларының сөйләмдәге кимчелекләрен төзәтү (логопедия) эшен туган телдә алып бару мөмкинлеге тудырылу. Моңа кадәр ул рус телендә алып барылды, татар телендәге махсус авазларны дөрес әйтергә өйрәтү ка-

---

[56] Бурганова Р.А. Татарский орнамент в изобразительной деятельности: Пособие для воспитателей детских садов. – Казань: ИПКРО РТ, 2002. – С. 4.

[57] Вагыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Башлангыч сыйныфларда татар теле методикасы. – Казан: Мәгариф, 1993. – 415 б.

[58] Шаехова Р. Эффективность использования метода звуковых ассоциаций в обучении детей татарскому языку // Мәгариф. – 2002. – № 9. – С. 39–40.

ралмаган иде. 90 нчы елларда әзерләнгән кулланмалар[59] әлеге проблеманы хәл итүгә юнәлдерелгән.

Мәктәпкәчә тәрбия, бигрәк тә татар балалар бакчалары өлкәсендә фәнни эзләнү эшләре педагогиканың башка тармаклары белән чагыштырганда сүлпәнрәк бара. Бу чорда татар балалар бакчаларында белем һәм тәрбия бирүне оештыруга багышланган хезмәтләрдән М.Ф.Кашапова, Р.К.Шәехова[60] хезмәтләрен атарга мөмкин. Аларда татар телен өйрәтү, сөйләм үстерүнең дидактик шартлары, уен эшчәнлегендә нәниләрнең иҗади сәләтләрен үстерү һ.б. мәсьәләләренә игътибар ителә. Шулай ук мәктәпкәчә тәрбия мәсьәләләре, аның тарихы, балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрдә үзаң тәрбияләү һ.б. мәсьәләләргә багышланган эзләнүләр дә билгеле[61].

Гомумән алганда, 1990–2005 елларда мәктәпкәчә яшьтәге балаларга милли тәрбия бирүдә гаилә беренче урында торса, икенче, шулай ук мөһим факторларның берсе булып татар мәктәпкәчә тәрбия оешмалары тора. Соңгыларының күпләп барлыкка килүе һәм урнашуы, милли рухта, милли нигездә, халкыбызның гореф-гадәтләре, йола һәм традицияләре нигезендә тәрбия алып барулары, нәниләрне ТР дәүләт телләренә өйрәтүдә башкарган эшчәнлеге әлеге чорның төп үзенчәлеге булып торса, 2005 елга илдә, РФ мәгариф системасында барган үзгәрешләргә бәйле рәвештә, милли тәрбиягә игътибарның беркадәр кимүе, татар балалар бакчалары һәм төркемнәренең эчтәлеге үзгәрүе (чын мәгънәсендә татар төркемнәре азаю, нигездә авыл шартларында калу, тәрбия һәм белем бирүнең нигездә рус телендә алып барылуы) күзәтелә.

---

[59] Камаева Р.З. Дөрес сөйләшик: Мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләмендәге кимчелекләрне төзәтү һәм бәйләнешле сөйләм үстерү буенча методик ярдәмлек. – Казан: Школа, 2004. – 184 б.; Хөснуллина Э. Белем ачкычы – сүз: Сөйләмендә кимчелекләре булган мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләү өчен биремнәр җыентыгы. – Түбән Кама: ӨПББИ, 2007. – 118 б.

[60] Кашапова М.Ф. Дидактические условия организации словарной работы по татарскому языку с детьми старшего дошкольного и младшего школьного возраста: дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 2005. – 268 с.; Шаехова Р.К. Педагогические условия и критерии развития творческих способностей дошкольников в игровой деятельности: автореф. дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 1999. – 24 с.; Шәехова Р. Иҗади уеннан – укуга. – Казан, 1999. – 91 б. һ.б.

[61] Мардашова Р.С. Становление и развитие дошкольного образования в Татарстане (1872–1941). – Казань: КГПУ, 2004. – 272 с.; Хаертдинова Р.М. Путешествие в прошлое: Программа ознакомления детей старшего дошкольного возраста с историей и культурой Татарстана. – Н.Челны: НГПИ, 2006 һ.б.

## 1.3. Гомуми белем бирү мәсьәләләре

Россия күләмендә һәм Татарстанда барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр татар мәгарифенең төп буынын тәшкил иткән урта мәктәп системасында аеруча тулы чагылыш таба. Бу, инде билгеле булганча, әлеге чорда татар мәктәпләренең саны арту, аларның эчтәлеге үзгәрү белән характерлана.

90 нчы еллар башында Мәгариф турындагы закон нигезендә Россиядә милли мәгариф проблемаларын хәл итү вәкаләте тулысынча төбәкләргә тапшырыла. РСФСР мәгариф министрлыгында милли мәктәпләр бүлеге бетерелә, Милли мәктәпләр фәнни-тикшеренү институты, аның урыннардагы бүлекләре, шул исәптән Татарстан филиалы, ябыла.

Совет чорында кайбер РСФСРдагы милли республикаларда, әйтик, Удмуртиядә, милли мәктәпләр бөтенләй булмый. Ижевск шәһәрендә, мәсәлән, бер генә мәктәптә дә удмурт теле укытылмый[62]. Шундый ук вәзгыять башка республикаларда да күзәтелә. 80 нче еллар ахырында РСФСРда татарлар һәм башкортлар 11, тува һәм якутлар 7–9 сыйныф күләмендә үз туган телләрендә белем ала, башка милли телләрдә укыту башлангыч сыйныфларда гына саклана. Гомумән алганда, 1980 елларда рус булмаган халыкларның бары тик 9%ы гына милли мәктәпләрдә белем ала. 1994 елда татар, башкорт һәм якутларда 11 еллык милли мәктәпләр барлыкка килә[63].

Татар телле мәктәпләргә килгәндә, алар совет чорында Россия төбәкләрендәге татар авылларында, аерым алганда, Башкортстан, Чувашстан, Мари республикаларында сакланып кала. 90 нчы елларда ил күләмендә татар мәктәпләренең саны арту күзәтелә. 2000 елда, мәсәлән, Чувашстандагы рус милләтеннән булмаган барлык укучыларның 45%ы туган телләрендә (шул исәптән татар телендә) белем ала, татар мәктәбенең 1–5 нче сыйныфларында белем һәм тәрбия ана телендә алып барыла[64].

---

[62] Власова Т.А. Образовательный потенциал школы с этнокультурным компонентом на примере национальной школы г. Ижевска // Вестник Удмуртского университета. – 2013. – Вып. 1. – С. 53.

[63] Ахиезер А. Культурные основы этнических конфликтов // Общественные науки и современность. – 1994. – № 4. – С. 121.

[64] О концепции национальной школы Чувашской Республики в современной системе обучения и воспитания. URL: http//docs.cntd.ru/document/473600782

Совет чорында милли мәктәп дип татар (яисә башка милләтләр) телендә белем һәм тәрбия бирүче мәктәпләрне атау кабул ителә. Төп критерий булып аларның предметларны туган телдә укытулары тора. 90 нчы еллар башында «милли мәктәп» төшенчәсенең эчтәлеге киңәя. Әлеге мәктәпнең төп билгеләре булып түбәндәгеләр тора:

– укыту-тәрбия процессы укучыларның һәм алар яши торган төбәкнең милли үзенчәлекләрен исәпкә алып оештырыла;

– укыту-тәрбия чаралары, мәктәптәге үзара аралашу, эш кәгазьләре туган телдә алып барыла;

– укучы шәхесе туган тел, милли тирәлек, әдәбият, мәдәният, тарих, гореф-гадәтләр һ.б. милли факторлар йогынтысында формалаша;

– туган телдән тыш, дәүләт һәм халыкара аралашу телләре дә нигезле итеп өйрәнелә. Анда тәрбия шәхеснең халыкара, милләтара бәйләнеш, милли төбәк шартларында яшәргә хәзерлеген күз алдында тотып оештырыла»[65].

«Милли мәктәп»нең эчтәлеген күзаллауда әлеге карашлардан аермалы булган өченче юнәлеш – аны мөстәкыйль, дәүләт карамагында булмаган аерым структура буларак күрү һәм оештыру омтылышына нигезләнә. Әлеге юнәлешнең тарафдары Илдус Әмирханов «татар милли мәктәбен» күп баскычлы мөстәкыйль татар мәгарифенең бер буыны буларак күрә һәм аны халык кулында булырга тиеш дип саный[66]. Ләкин бу очракта республиканың мөстәкыйль булуы төп шартларның берсе булырга тиеш[67]. Галимнең фикеренчә, бары тик өченче төр мәктәпләр генә чын мәгънәсендә милли мәктәпләр дип аталырга хаклы, алдагы ике төр мәктәпләрне татар мәктәбе дип атау дөреслеккә туры килә, һәм унитар мәктәп, хәтта татар телендә белем һәм милли рухта тәрбия биреп, милли гореф-гадәтләр, мәдәният, халык педагогикасына нигезләнсә дә, чын мәгънәсендә милли мәктәп була алмый[68]. Шул ук фикер Р.В.Шакиров хезмәтләрендә дә урын ала[69]. Совет чорында авыл шартларында яшәп килгән мәктәпләрне милли мәктәпләр дип атау киң таралса да,

---

[65] Низамов А.М. Милли мәктәп: тәрбия нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2005. – 5 б.

[66] Әмирхан И. Татар фәлсәфәсе һәм милли мәгариф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 123 б.

[67] Шунда ук. – 6 б.

[68] Шунда ук. – 129 б.

[69] Шакиров Р.В. Казанская педагогическая школа во второй половине XX века. – Казань, 1999. – С. 401.

алар чынлыкта туган телдә белем бирүче гадәти гомумбелем мәктәпләре генә, дип яза ул[70].

Бу елларда татар мәктәбенең асылын тар мәгънәдә аңлау еш күзәтелә. Бу очракта татар мәктәбе һәм гомумән татар мәгарифе тел, берникадәр дәрәҗәдә мәдәният мәсьәләләренә генә кайтып кала, эчтәлеге белән этник була.

Милли мәктәпнең төп билгесе итеп нигездә татар телендә укыту карала[71]. Туган телне саклауда мәктәпнең роле, һичшиксез, зур. Әгәр дә тел мәктәптә кулланылмаса, мәктәптәге укыту теле (бу очракта рус теле) өйдә аралашуда да кулланыла башлый, һәм, шулай итеп, әкренләп туган телне алыштыра. Оксфорд галимнәре Т.Л.Маккарти, Т. Скутнаб-Кангас һәм О.Н.Магга билгеләп үткәнчә, «югалу алдында торган телне бер мәктәп кенә коткарып кала алмый, әмма аны берничә буын эчендә, мөстәкыйль рәвештә диярлек, бетерә ала»[72]. Менә шуңа күрә дә туган телдә белем һәм тәрбияне оештыруның әһәмияте зур.

Бу елларда милли мәктәптә тәрбия бирүнең эчтәлеге түбәндәге юнәлешләрдән торырга тиеш дип фаразлана:

- Укучыларны кешелек җәмгыятенең мораль нигезләре булган гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыру, аларның асылын аңлату, таныту.
- Укучыларда җәмгыятьтә мөнәсәбәт нормалары булган гомумкешелек сыйфатларын формалаштыру.
- Укучыларда милләт буларак яшәүнең төп шарты булган милли үзаң формалаштыру.
- Укучыларның үз милләтенә хас уңай сыйфатларга ия булуы[73].

Шул ук вакытта, әлбәттә, тәрбия бирүнең нигезе – халык педагогикасы булырга тиешлеге ассызыклана[74].

---

[70] Шунда ук.

[71] Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – С. 3.

[72] Цитата бу китап буенча бирелә: Галимҗанов Ә.Ф. Төгәл фәннәрне татарча укыту – зарурилык // Татар телендә югары белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар). – Казан: КДАТУ, 2017. – 56 б.

[73] Низамов А.М. Милли мәктәп: тәрбия нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2005. – 7–8 б.

[74] Шунда ук. – 9 б.




*Казан шәһәренең 2 нче интернат-лицей укучылары*

Әлеге чорда тәрбия бирүдә халык тәҗрибәсе һәм ислам кыйммәтләрен куллану, рухи, югары әхлакый сыйфатлар булдыру белән беррәттән, экологик, икътисади тәрбиягә, сәламәт яшәү рәвешен алга сөрүгә зур игътибар бирелә[75], алар аерым мәктәпләрнең эш юнәлешләрендә чагылыш таба.

Урта белем бирүнең эчтәлеге Россия мәгариф министрлыгы тарафыннан каралган гомуми документлар нигезендә оештырыла. Ләкин аны беркадәр үзгәртү һәм яраклаштыру мөмкинлеге саклана. Беренче чорда Дәүләт белем бирү стандартлары буенча федераль эчтәлек белән беррәттән, МТК һәм мәктәп компоненты каралу Татарстан мәктәпләрендә Татарстан һәм татар тарихын, Татарстан географиясен укыту, шулай ук башка предметларны, аерым алганда, җәмгыять белеме, физика, химия, технология, музыка һәм рәсем дә-

[75] Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 1997. – 175 б.; Җәләлиев Ш.Ш. Милли тәрбия нигезләре (исламдагы һәм татар халык педагогикасындагы рухи-әхлакый потенциал – милли тәрбиянең нигезе). – Казан: Алма-Лит, 2003. – 174 б.; Казыйханов В., Шәрипов Ә. Әхлак белеме. – Яр Чаллы: ИНПО, 1997. – 104 б.; Гайсин И.Т. Эколого-нравственное воспитание учащихся. – Казань: КГПУ, 1999. – 164 с. һ.б.

ресләрендә татар халкы һәм төбәк материалын файдалану мөмкинлеген бирә. Милли компонент булган База уку планы (БУП) кабул ителү белем бирү эчтәлегенә вариатив өлешне – милли, төбәк яисә җирле үзенчәлекләрне һәм традицияләрне кертүгә ярдәм итә. 2000 нче еллар башында Татарстан мәктәпләрендә «Ватанны өйрәнү», «Казанны өйрәнү», «Яшь татарстанлылар» кебек федераль һәм республика программалары нигезендә тәрбия буенча авторлык программалары төзелә.

Татар мәктәбен үстерүдә татар телендә язылган оригиналь дәреслекләрнең роле, һичшиксез, зур. Бу нисбәттән В.Гайфуллин һәм Р.Исламшин тарафыннан 7–11 нче сыйныфлар өчен язылган физика дәреслекләрен атарга мөмкин. Алар – совет чорының беренче елларында язылган Х.Мөштәри дәреслегеннән соң физика буенча татар телендә беренче һәм бердәнбер дәреслекләр булып тора.

Урта мәктәптә Татарстан географиясен укыту бу чорда Әнвәр Тайсин тарафыннан язылган дәреслекләр нигезендә алып барыла. Укучыларны илнең бер өлеше буларак республика, төбәк географиясе, климаты, казылма байлыклары һ.б. белән таныштыруда, туган якның киләчәге өчен җаваплылык тәрбияләүдә, экологиясен саклауда һ.б. әлеге әсбапларның роле, һичшиксез, зур була[76].



В.Гайфуллин

Башка предметларны укытканда җирле материаллардан, фольклор үрнәкләреннән, Татарстан галимнәренең тәҗрибәсенннән файдалану шулай ук әлеге чорга хас үзенчәлекләрнең берсе. Мисал өчен, физика, математика яки астрономия укытканда халык авыз иҗаты әсәрләрен[77], химия дәресләрендә милли-төбәк компонентын[78]

---

[76] Тайсин Ә.С., Сәүбанова Л.И. Урта мәктәптә Татарстан географиясен укыту: методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2003. – 3–4 б.

[77] Сабирова Ф. Ай булмаса, йолдыз бар: Методик кулланма. – Яр Чаллы, 1995. – 68 б., Сабирова Ф. Идел суы илле батман (Математика дәресләрендә фольклор әсәрләрен файдалану) // Мәгариф. – 1997. – № 5. – 63–65 б.

файдалануның шактый уңышлы икәнлеге раслана. Бу, әйтик, 8 нче сыйныфта укучыларны матдә һәм җисем, физик һәм химик күренеш төшенчәләре белән таныштырганда халык әйтемнәрен файдалану, республикада химия белән бәйле һөнәрчелек тармаклары белән таныштырганда халкыбызның борынгыдан килгән һөнәрләре турында (Болгар илендә чуен, тимер кою, алтын-көмештән әйберләр, савыт-саба ясау, кырып бизәү (граверлау), чүкү һ.б. ысулларны кулланып бизәнү әйберләре җитештерү, чүлмәкчелек һ.б.) мәгълүмат бирү, укучыларның белемнәрен баету белән беррәттән, милли тәрбия бирүдә дә зур әһәмияткә ия[79].

Республикада «Милли мәктәптә рус теле» һәм «Туган тел» максатчан программалары төзелә. 1988–89 уку елыннан рус мәктәпләрендә татар милләтеннән булган укучылар туган телләрен өйрәнсә, башкалар өчен «Туган як мәдәнияте, әдәбияты һәм тарихы» дигән яңа предмет кертелә.

СССР Халык мәгарифе дәүләт комитетының 254 нче боерыгы (1990 ел, 16 апрель) иҗтимагый фәннәрне укытуның эчтәлегендә, методларында һәм мәктәпнең укыту планында ролен билгеләүдә борылыш этап була. Боерык нигезендә урта (8–11 нче сыйныфлар) һәм махсус урта мәктәпләрдә, шулай ук урта һөнәри белем бирү йортларында «Кеше һәм җәмгыять» дигән яңа курс кертелә. Әлеге курс элек укытылып килгән «Җәмгыять белеме», «Совет дәүләте һәм хокукы нигезләре» һәм «Гаилә тормышы этикасы һәм психологиясе» фәннәрен алмаштыра. Моннан тыш, уку йортларына иҗтимагый фәннәрнең программаларына төбәк һәм һөнәри үзенчәлекләрне, укучыларның кызыксынуларын һәм ихтыяҗларын исәпкә алган махсус курслар кертү һәм имтихан бирү формаларын билгеләү мөмкинлеге карала.

Яңа курсны гамәлгә кертү эксперимент 4 вариант программа нигезендә тәкъдим ителә (Б.Г. Мещеряков һәм А.Т. Кинкулькин; В.С. Овчинников; Р.А. Арцишевский; Л.Н. Боголюбов), аларны сайлау мөмкинлеге бирелә.

Курсның эчтәлеге һәм концепциясе яңа булуы сәбәпле, укытучыдан элеге курсны укытуга алдан ук әзерләнү таләп ителә. Шуны искә алып, Татарстан укытучылар белемен күтәрү институтының иҗтимагый фәннәр кафедрасы каршында «Кеше һәм җәмгыять» кур-

---

[78] Хәлиуллин Р. Химия дәресләрендә халык авыз иҗаты // Мәгариф. – 1996. – № 7. – 40–42 б.; Хәлиуллин Р. Химияне укытуда милли-төбәк компонентлары системасы // Мәгариф. – 2001. – № 4. – 80–81 б. һ.б.

[79] Хәлиуллин Р. Химияне укытуда милли-төбәк компонентлары системасы // Мәгариф. – 2001. – № 4. – 80–81 б.

сын укыту буенча фәнни-методик совет оештырыла: республиканың төрле шәһәр һәм районнарында, тарих һәм җәмгыять белеме укытучыларының район (шәһәр) методик берләшмәләрендә укытучылар белән яңа курсның эчтәлеге буенча консультацияләр уздырыла.

Иҗтимагый фәннәрне укытканда укытучы программаны җирле материаллар белән тулыландырырга, ягъни анда милли-төбәк үзенчәлекләрен киң чагылдырырга тиеш. Флера Зыятдинова «Яңа уку елында иҗтимагый фәннәрне укыту» мәкаләсендә төрле темаларны үткәндә өстәмә җирле мәгълүматларны файдаланырга тәкъдим итә. Төп игътибарны милләтләр һәм милли мөнәсәбәт темасына бирергә өнди, укучыларга татар һәм рус халкының тарихи үсеш процессында бер-берсенә йогынтысын һәм үзара мөнәсәбәтләрен җиткерү кирәклеген белдерә. Кулланышта йөри торган «Татар-монгол игосы (изүе)» дигән төшенчәнең бик шартлы булуын күрсәтеп, күренекле рус фәлсәфәчесе Н.А. Бердяевның: «Рус чиркәве тарихында иң әйбәт чор – татар игосы периоды; ул вакыт чиркәүнең рухи яктан иң бәйсез чагы була, анда социаль элемент була», – дигән фикерен китерергә тәкъдим итә.

Әлеге теманы өйрәнгәндә ул Ә.Кәримуллинның «Татарлар: исемебез һәм җисемебез», А.Авторхановның «Империя Кремля: советский тип колониализма», А.Хәлимнең «Книги печали или записки аборигена» исемле чыганакларын кулланырга тәкъдим итә[80].

1992 елның гыйнварыннан 11 нче сыйныфларда җәмгыять белеме «Кеше һәм җәмгыять» дигән курсның икенче бүлеге белән алмаштырыла. Ул «Хәзерге цивилизация нигезләре» дип атала. Л.Н. Боголюбов җитәкчелегендә тәкъдим ителгән программада үзәк урынны хәзерге цивилизациянең төп кыйммәте булган икътисади мөнәсәбәтләрне көйләүнең товар-акча, базар механизмы системасы, хокукый дәүләт һәм гражданнар җәмгыяте принципларына нигезләнгән сәяси мөнәсәбәтләр, кешелек җәмгыяте өчен гомуми булган әхлакый кыйммәтләр, халыкара мөнәсәбәтләрнең яңа принциплары, төрле дәүләт һәм халыкларның мәдәни-рухи кыйммәтләре кебек мәсьәләләр алып тора. «Хәзерге цивилизация нигезләрен» өйрәнү курсы берничә ел дәвам итә. 8–9 нчы сыйныфларда исә «Кеше һәм җәмгыять» дигән интегратив курсны өйрәнү укытучы, мәктәп администрациясе советы карары нигезендә гамәлгә ашырыла. Шул максатлардан чыгып,

[80] Зыятдинова Ф. Яңа уку елында иҗтимагый фәннәрне укыту // Мәгариф. – 1992. – № 5. – 40–44 б.

ТУБКИның иҗтимагый фәннәр кафедрасы 8–9 нчы сыйныфлар өчен «Кеше һәм җәмгыять» курсы буенча үз программасын тәкъдим итә.

Яңа курс кертү җәмгыять белеме укытуның эчтәлеген төптән үзгәртә. Әгәр элек курсның нигезен хакимлек итүче партиянең идеологиясе тәшкил итсә, сыйнфый каршылыклар идеясе, ике социаль-икътисади системаның капма-каршы торуы хас булса, яңа курс гомумкеше, милли, дәүләти, шәхси ихтыяҗлар диалектикасын чагылдыра.

XX гасырның 90 нчы елларында федераль программа белән берлектә, социаль-икътисади, мәдәни һәм җирле мәгариф системалары үзенчәлекләрен исәпкә алган региональ һәм муниципаль программалар барлыкка килә, төрле (гомумроссия, төбәк, автор һ.б) уку әсбаплары нәшер ителә, гореф-гадәтләр, әхлак кыйммәтләре төрлелеге күп программаларның нигезен тәшкил итә. Әлеге программаларга нигезләнгән курслар эчтәлеге, идея юнәлеше, материалның сыйфаты буенча шактый аерылып торалар.

1993 елда мәктәптә башланган яңа реформалар нигезендә тарихи-иҗтимагый белем бирү линияле структурадан концентрлыга үзгәртелә, Базис уку планы эшләнелә һәм кертелә. Шулай ук мөһим адымнарның берсе булып күчү чорына тарих һәм иҗтимагый фәннәр үсеше стратегиясе (1994 ел 28 декабрь) эшләнү тора[81].

Беренче концентрда иҗтимагый фәннәр «Җәмгыять белеменә кереш», «Кеше һәм җәмгыять», «Гражданлык белеме» кебек интегратив, «Хокук һәм сәясәт», «Икътисадка кереш», «Кеше дөньясы» кебек аерым модульле курслардан гыйбарәт була.

Икенче концентрда «Җәмгыять белеменә кереш», «Кеше һәм җәмгыять» кебек интегратив һәм социаль фәлсәфәгә, социологиягә, икътисади теориягә, политологиягә, хокук һ.б белемнергә кагылышлы модульле курслар карала[82].

Татарстан республикасында БУП буенча җәмгыять төзелеше белән таныштыруны күздә тоткан «Кеше һәм җәмгыять», «Хәзерге цивилизация нигезләре», «Хәзерге заман дөньясы» һәм «Җәмгыять белеменә кереш» курслары укытыла. Моннан тыш, мәктәпкә укучыларны җәмгыятьнең иҗтимагый-сәяси, икътисади һәм рухи даирә-

---

[81] О стратегии развития исторического и обществоведческого образования в общеобразовательных учреждениях // Преподавание истории в школе. – 1995. – № 3. – С. 53–55.

[82] Асмолов А.Г. О переходе на новую структуру исторического и обществоведческого образования // Преподавание истории в школе. – 1993. – № 4. – С. 45–46.

ләре белән таныштыра торган фәннәрне дә укытырга мөмкин була (мәсәлән, «Менеджмент һәм маркетинг», «Диннәр тарихы» һ.б.)[83].

Яңа стандартлар буенча бер юнәлеш буларак төбәкләрнең ихтыяҗларын исәпкә алган параллель һәм профиль дәреслекләр һәм программалар әзерләү карала. Бу, үз чиратында, мәктәптәге иҗтимагый фәннәрнең тоталитар идеологияле монополиясеннән фикерләр төрлелеге (плюрализм) идеологиясенә күчүне аңлата. Ул патриотизм, гражданлык хисе, милли үзаң, Россия халыкларының тарихи һәм мәдәни мирасына ихтирам тәрбияләүгә юнәлдерелгән була[84].

XX гасырның 90 нчы елларында милли тарих, мәдәни мирас белән массакүләм кызыксыну туа. СССР таркалгач, берничә ел укытылмаган «Татарстан һәм татар халкы тарихы» (1993/1994 уку елыннан) фәне укытыла башлый. Яңа структурага күчүгә бәйле рәвештә, тарихны өйрәнү буенча кереш курсны үзләштерү башлангыч мәктәптә үк гамәлгә ашырылырга тиеш дип исәпләнә, моның өчен татар теле һәм әдәбияты дәреслекләрен дә файдалану күздә тотыла. Материал сайлаганда укучыларны күбрәк үз халкының тарихына бәйле вакыйгалар белән кызыксындырырга тәкъдим ителә. Дәреслекләрдән тыш, Г.М.Дәүләтшинның «Татарстан тарихыннан хикәяләр» исемле ярдәмлегеннән файдалану мөмкинлеге була. Ләкин «Татарстан һәм татар халкы» курсы төп мәктәптә генә кертелә. Соңрак ул 10–11 нче сыйныфларда да өйрәнелә башлый, аерым фән буларак кертелә. Аның буенча имтихан сайлау мөмкинлеге дә була.

Бу курсны системалы укыту, 8 нче сыйныфтан башлап, түбәндәгечә оештырыла:

8 нче сыйныф – туган як тарихы (борынгы заманнан алып XVI гасыр уртасына кадәр);

9 нчы сыйныф – XVI гасырның икенче яртысыннан башлап, XVIII гасырны кертеп;

10–11 нче сыйныф – XIX–XX гасырлар.

Татарстан Республикасында вариатив белем бирү 1994/95 уку елыннан башланып китә. Моның нәтиҗәсендә Татарстанда иҗтимагый фәннәр түбәндәгечә өйрәнелә башлый: «Укучыларга хокук турында» (8 нче сыйныф), «Икътисад нигезләре» (9 нчы сыйныф); «Кеше һәм җәмгыять», «Җәмгыять белеменә кереш» һ.б. (10–11 нче

[83] Фокеева И.М. Иҗтимагый фәннәрне укыту // Мәгариф. – 1994. – № 5. – 42 б.

[84] О стратегии развития исторического и обществоведческого образования в общеобразовательных учреждениях // Преподавание истории в школе. – 1995. – № 3. – С. 53–55.

сыйныфлар)[85]. Укытучы фәннәрне укыткан вакытта программаны сайлау, җирле материаллар кертү ягъни милли-төбәк үзенчәлекләрен куллану мөмкинлекләренә ия була. Җәмгыять белеменең милли-төбәк эчтәлеген формалаштыруга, аның эффектив юлларын ачыклауга Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты хезмәткәрләре зур көч куя (В.И. Пискарев, И.М. Фокеева). В.И. Пискарев «Җәмгыять белеме»нең милли-төбәк эчтәлеген билгеләп, аны системалы принцип нигезендә кертергә тәкъдим итә. Милли-төбәк һәм федераль компонент тулы системаны тәшкил иткән вариант авторга иң кулай һәм продуктив юл буларак күрелә.

Тарих һәм җәмгыять белеме укытучыларының белемнәрен камилләштерү уңаеннан Мәгарифне үстерү институты тарафыннан «Методология, теория һәм мәктәптәге тарих һәм иҗтимагый фәннәр методикасы проблемалары» исемле белем бирү программасы эшләнелә һәм укыту процессына кертелә.

Төп гомум белем бирү эчтәлеге мәҗбүри минимумының вакытлы таләпләре (1998) нигезендә җәмгыять белеме һәм тарих буенча үрнәк программалар һәм төп мәктәп укучылары өчен таләпләр эшләнелә. Программалар иҗтимагый фәннәргә якынча бирелгән сәгатьләр санын һәм 10–15% уку вакытын төбәк компоненты эчтәлегенә бирүне билгели. Үрнәк программалар укытучыларның автор программаларын, уку планнарын эшләү ориентиры булып тора[86], укытучыга иҗади эшләү шартларын, мөстәкыйль рәвештә укыту формаларын һәм методларын сайлау мөмкинлекләрен тудыра.

Дөнья цивилизациясендә лаеклы урын алыр өчен милли тарихка объектив караш булдыру проблемасы татар халкы өчен аеруча актуаль. Әлеге курсны кертү Татарстан һәм татар халкы тарихын өйрәнүне яңа дәрәҗәгә күтәрә. Моңа хәтле өйрәнелмәгән чорларны яктырткан дәреслекләр һәм методик әсбаплар чыга башлый (Шәмси С., Измайлов И. «Рассказы по истории Волжской Булгарии»; Давлетшин Г., Хузин Ф., Измайлов И. «Рассказы по истории Татарстана»; Фахрутдинов Р. «История татарского народа и Татарстана»; Мифтахов З., Мухаммадиева Д. «История Татарстана и татарского народа»; Синицына К. «История Татарстана и татарского народа» һ.б.). Аерым фән буларак уку планына кертелүе татар халкының зур тарихын тулы һәм җентекле

[85] Фокеева И.М. Изучение в новом учебном году истории и общественных дисциплин // Магариф. – 1996. – № 9. – С. 43–44.

[86] О преподавании курсов истории и обществознания в общеобразовательных учреждениях Российской Федерации в 1999/2000 учебном году: Методические письма // Магариф. – 1999. – № 8. – С. 10–15.

өйрәнүгә булышлык итә. Элек татар халкының бозылып күрсәтелгән тарихи битләрен хакыйкый күзлектән күрсәтү мөмкинлеге туа.

1990–2000 елларда «Татарстан һәм татар халкы» дип аталган мөстәкыйль курсның булуы зур әһәмияткә ия була, чөнки Россия тарихы курсында татар халкы һәм башка РФ милләтләре (руслардан башка) өйрәнелми диярлек. «Россия тарихы» һәм «Ватан тарихы» курслары Россия дәүләтчелегенең формалашуына юнәлдерелгән, татар халкы тарихына караган вакыйгалар күп очракта берьяклы яктыртыла.

XXI гасыр башында аерым авторлар тарафыннан Россия халыкларының милли ихтыяҗларын канәгатьләндерү уңаеннан «Россия халыклары һәм дәүләт тарихы» курсын кертү карала. Бу федераль дәреслекләр чыгу элеккегеләр белән чагыштырганда зур адым була. Ләкин бу китапның эчтәлеге аның исеменә һәм кереш өлешендә билгеләнгән максатларга туры килми, Россия халыкларының милли тарихы бик сай (аз) бирелә. Шулай да бу елларда федераль дәреслекләргә элек каралмаган темалар кертелә башлый: «Төрки халыклар һәм аларның безнең ил территориясендәге дәүләтләре», «XIII–XIV гасырда Алтын Урда», «Казан һәм Кырым ханлыклары оешу» һ.б.[87] «Россия халыклары һәм дәүләте тарихы» курслары программалары һәм дәреслекләре, кайбер кимчелекләренә карамастан, башка федераль дәреслекләрдән уңай яклары белән аерылып тора. Әмма Татарстан мәктәпләрендә алар киң таралыш тапмый. Бу чорның төп максаты булып мөстәкыйль «Татарстан һәм татар халкы тарихы» курсын саклап калу була.

1999/2000 уку елында Татарстанда яңа БУПның инвариатив өлешнең үрнәк уку планында җәмгыять белеме түбәндәгечә укытыла:

- 9 нчы сыйныфта «Хокук белеме нигезләре» (атнага 1 сәгать);
- 10 нчы сыйныфта «Икътисад» (атнага 1 сәгать);
- 11 нче сыйныфта «Кеше һәм җәмгыять» (атнага 1 сәгать).

Моннан тыш, «Икътисад»ны үрнәк уку планының (мәктәп компоненты) вариатив өлеше нигезендә өстәмә рәвештә укыту мөмкинлеге бирелә. Моннан тыш, ТР Мәгариф министрлыгы бу елдан Татарстан территориясендә «Хокук белеме һәм икътисад нигезләре» дәресләре эчендә «Кулланучылар белеме нигезләре» курсын кертүне тәкъдим итә[88].

---

[87] Данилов А.А., Данилов Д.Д. Российская история с древнейших времен до начала XVI в. – М., 1999. – С. 20.

[88] О преподавании курсов истории и обществознания в общеобразовательных учреждениях Российской Федерации в 1999/2000 учебном году: Методические письма // Магариф. – 1999. – № 8. – С.10–15.

1999 елда гомумбелем мәктәбендә иҗтимагый фәннәр концепциясе эшләнелә. Әлеге документ иҗтимагый фәннәр һәм тарих белеме арасындагы аерымлыкларны, җәмгыять белеме фәненең максатларын, мәктәп, уку планындагы ролен, структурасын һәм эчтәлеген билгели.

Бердәм белем бирү пространствосын саклау, җәмгыять белеменнән мәҗбүри минимумны тәэмин итү һәм шулай ук милли-төбәк компонентын кертүне оптимизацияләү зарурилыгы Татарстан Республикасында иҗтимагый фәннәр өлкәсендә урнашкан системаны яңадан карап чыгуны таләп итә. Шунлыктан Татарстанда 2000/2001 уку елында уку материалын бирүдә шактый үзгәрешләр килеп чыга. Мәсәлән, 8 нче сыйныфта РФ Базис планы нигезендә «Татарстан тарихы» фәне урынына «Җәмгыять белеме» курсы кертелә; 9 нчы сыйныфтагы «Хокук белеме нигезләре» һәм 10 нчы сыйныфтагы «Икътисад» курслары эчтәлеге «Җәмгыять белеме» фәне эчендә өйрәнелә башлый. Шулай итеп, 2000 елдан алып Татарстанда моңа хәтле укытылган төрле иҗтимагый фәннәр урынына интегратив «Җәмгыять белеме» курсы кертелә[89]. Сәяси һәм икътисади белемнәрнең актуальлеге һәм кирәклеген билгеләп, Татарстанда «Җәмгыять белеме» курсы эчтәлегенә «Кулланучылар белеме нигезләре» (11 сәгатькә исәпләнгән) һәм «Правовые и экономические основы занятости населения и предпринимательства» (20 сәгать) курсларын кертү тәкъдим ителә[90]. Әлеге курслар Татарстан мәктәпләрендә 1999 уку елыннан алып берничә ел укытыла. 2002 елда Татарстанда «Мой выбор» исемле курс кертелә. Әлеге курсның төп идеясе – кеше сайлау хокукына ия һәм аның өчен үзе җавап тота. Мәгълүмат белән эш итәргә, социаль ситуацияләргә анализ бирергә һәм укучыларның тормыш ихтыяҗларын канәгатьләндерергә исәпләнгән әлеге курс җәмгыять белеме эчтәлегендә өйрәнелергә тиеш була[91]. Татарстандагы татар мәктәпләрендә 2000 елга кадәр һәм моннан соң укытылган иҗтимагый фәннәр буенча дәреслекләр рус вариантының татар теленә турыдан туры тәрҗемәсе булып тора. Әмма алар рәтендә

[89] Об изучении истории и обществознания в общеобразовательных учреждениях Республики Татарстан в 2000/2001 учебном году // Магариф. – 2000. – № 7. – С. 67–69.

[90] К вопросу о преподавании обществоведческих дисциплин в общеобразовательных учреждениях РТ // Магариф. – 2001. – № 1. – С. 73–74.

[91] Об изучении истории и обществоведческих дисциплин в общеобразовательных учреждениях РТ в 2003/2004 учебном году // Магариф. – 2003. – № 7. – С. 54–55.

милли-төбәк компоненты буларак һәм ТР мәгариф министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән «Хокук белеме нигезләре: Татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен уку ярдәмлеге» (К.Ф.Әмиров һәм Р.Г.Әмирова) китабын билгеләп үтәргә кирәк. Әлеге уку әсбабы хокук блогында республиканың аерым статусы һәм дәүләт төзелеше белән таныштыруда зур ярдәм бирә.

Гомумән алганда, бу дәвердә иҗтимагый фәннәрне укытуда милли эчтәлекне кертү мөмкинлекләре булдырыла. Әмма алар күбесенчә укытучы инициативасына бәйле була. Җәмгыять белемен укыту тулысынча федераль дәреслекләр һәм үрнәк программалар нигезендә алып барылса, Татарстан һәм татар халкы тарихы нигездә региональ дәреслекләр буенча укытыла.

Әлеге чорда татар теле һәм әдәбиятын укытуда шактый зур, хәлиткеч үзгәрешләр күзәтелә. Бу, беренчедән, татар телен укытуның даирәсе киңәю белән аңлатыла. Татар телен мәҗбүри предмет буларак гомуми белем бирү оешмаларында укыта башлау төрле категория укучылар өчен (татар мәктәпләре; рус мәктәпләрендә татар; рус мәктәпләрендә рус; башка мәктәпләрдә рус төркемнәре, төрле типтагы һәм эчтәлектәге программалар, методикалар һәм дәреслекләр төзү мәсьәләсен куя.

Татар теленнән теоретик материалны аңлаешлы итеп җиткерү белән беррәттән, укучыларда телгә карата кызыксыну уяту һәм дөрес итеп сөйләшергә, укырга һәм язарга, фикерләргә өйрәтү – татар теле дәресләренең төп максаты шуннан гыйбарәт. Шуңа бәйле рәвештә татар теле дәреслекләре дә укучыларны сөйләмне дөрес төзеп, әдәби тел нормаларына туры китереп, телдән һәм язма рәвештә башкаларга җиткерә белергә өйрәтергә тиеш була. Әлеге таләпләргә җавап биргән дәреслек һәм методикалар булдыруга юнәлдерелгән эшчәнлек бу чорда педагогик фикер үсешендәге төп юнәлешләрнең берсенә әверелә.

90 нчы елларның башында татар телен чит тел буларак укыту методикасын эшләү буенча эзләнүләр алып барыла. Бу өлкәдә аеруча Ф. Сафиуллина эшчәнлеген ассызыклап үтү мөһим. Ул рус телле укучылар өчен татар теле дәреслекләре әзерләп бастыра, методик әсбаплар һәм күпсанлы сүзлекләр төзи.



Ф.Сафиуллина

Беренче чорда төзелгән дәреслек һәм методикаларның күбрәк лингвистик компетенциягә, ягъни телнең грамматик төзелешен, кагыйдәләрне өйрәнүгә юнәлдерелгән булуы рус телле укучыларның телне үзләштерүләрендә кыенлыклар тудыра. Катлаулы грамматик конструкцияләрне истә калдыруга омтылып, практик сөйләмгә игътибар аз бирелү – бу дәреслекләрнең төп кимчелеге әнә шуннан гыйбарәт. Лингвистик яссылыкны тулаем (хәтта кирәгеннән артык) чагылдыруга омтылган татар теле дәреслекләре методик яктан чит тел өйрәтүгә карата заманча күзаллауларга туры килми. Шул сәбәпле алар, чит тел дәреслеге булудан бигрәк, туган тел дәреслекләренә якынрак торалар.



*И.Литвинов*

Рус телле укучыларга татар телен өйрәтү буенча укытучылар һәм галимнәр тарафыннан уңышлы дип табылган дәреслекләр арасында И.Литвиновның башлангыч мәктәп өчен язылган дәреслекләре бар. Методик яктан алар татар телен чит тел буларак өйрәтүгә нигезләнә. Авторның төп максаты – укучыларны көндәлек тормышка караган темаларга һәм гап-гади һөнәри тематикага әңгәмә алып барырга өйрәтү. И.Литвинов фикеренчә, чит телдәге сөйләмне куллану өчен, 1,8–2 мең сүз үзләштерергә кирәк. Мәктәп курсында 2,5 мең сүзне истә калдырырга мөмкин. Иң кирәкле булган әлеге сүзләрне җентекләп өйрәнү мөһим, шулай булганда гына аларны көнкүрештә җиңел кулланырга була. Шуңа күрә дәреслекләрдә лексикографик минимум бик җентекләп сайлап алынган булырга тиеш. Әлеге сүзләр һәм текстлар дәресләрдә кабатланып килергә, ныгытылырга тиешләр. Яңа сүзләр кертүне укытучы бик уйлап, алдан ук хәл итәргә тиеш[92]. Кызганычка каршы, күп дәреслекләрдә әлеге таләпләр үтәлми. И.Литвиновның «Уку, бигрәк тә язу – татар телен өйрәнүдә төп максат түгел, бәлки сөйләм телен үзләштерүдә чара гына» дигән фикере дә мәктәптә беренче чиратта сөйләмгә өйрәтергә кирәклекне раслый. Чөнки бу чорда мөмкин булган иң югары дәрәҗә – ул катлаулы булмаган көндәлек аралашу теленә ирешү[93].

[92] Литвинов И. Рус телле укучылар өчен татар теле дәреслеге: ул нинди булырга тиеш? // Мәгариф. – 1998. – № 4. – 94 б.

[93] Шунда ук. – 95 б.

Шулай итеп, И.Литвинов дәреслекләрендә төп игътибар коммуникатив компетенциянең төп өлешләреннән берсе булган сөйләм теленә өйрәтүгә бирелә.

2000 еллардан башлап укытуда коммуникатив технологиягә өстенлек бирүнең максатка ярашлы икәнлеге башка авторлар тарафыннан да раслана. Бу фикер бигрәк тә А.Әсәдуллин хезмәтләрендә чагылыш таба. Аның карашынча, әлегә кадәр кулланылган методикалар һәм дәреслекләр нигездә татар теленең кагыйдәләрен, закончалыкларын өйрәтүгә юнәлдерелгән. «Ике дистә ел дәвамында рус телле укучыларның татар телен өйрәнә алмаулары безнең аларны татар сөйләменә түгел, ә татар теленә өйрәтүебездә. Укырга, язарга, грамматик кагыйдәләргә өйрәтәбез, ләкин тере татар сөйләменә – татар телендә сөйләшкәнне аңларга, диалоглар төзергә, текстка таянмый гына бәйләнешле сөйләм төзергә өйрәтмибез. Дәреслек белән генә эшләп, без балаларны беркайчан да татар сөйләменә өйрәтә алмаячакбыз. Сүзләр, кагыйдәләр өйрәнеп, текстлар укып кына сөйләм эшчәнлегенә кушылу мөмкин түгел»[94]. Галим рус телле укучыларга татар телен укытуның җанлы сөйләмгә нигезләнгән булырга, телгә күнектерүнең 3–4 яшьлек вакыттан башланырга тиешлеге турында яза. Шул ук вакытта әлегәчә методик яктан уйланылган камил системаның булмавын да уңышсызлыкларның төп сәбәбе итеп күрә: «Бар нәрсәгә өйрәтәбез: укырга да, язарга да, татар теленең грамматикасына да; ләкин рус балаларын беренче чиратта татарча сөйләшергә өйрәтергә кирәклеген онытабыз»[95].



*А.Әсәдуллин*

Бу чорда рус телле балаларга татар телен өйрәтүдә шулай ук Ф.Ю.Йосыпов, Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова, Р.Р.Җамалетдинов, К.С.Фәтхуллова, Р.З.Хәйдәрова, Р.Р.Нигъмәтуллиналарның дәреслек һәм әсбаплары кулланыла.

---

[94] Асадуллин А.Ш. Методическое руководство к пособиям «Татарская речь» для 5–11 классов русских школ. – Казань: Алма-Лит, 2004. – С. 4.

[95] Асадуллин А.Ш. Актуальные вопросы преподавания татарского языка в русскоязычной аудитории // Национальная школа и актуальные проблемы обучения. – Казань: Мастер Лайн, 2001. – С. 15.

Россия төбәкләрендәге татар мәктәпләре һәм татар балаларына татар телен өйрәтүдә нигездә Татарстан мәктәпләре өчен чыгарылган дәреслекләр кулланыла. Ләкин һәр төбәкнең үз милли мәгариф сәясәтен үткәрүе сәбәпле, төрле республикаларда татар теленнән үз дәреслекләрен әзерләү мәсьәләсе куела. Татарстан дәреслекләренең республика шартларына яраклаштырып язылуы (җирле материалга нигезләнүе), төбәкләрдә яшәүче татарлар тормышын аз яктыртуы яисә бөтенләй яктыртмаулары алардан файдалану мөмкинлекләрен чикли. Башкортстанда яшәүче татарлар өчен язылган дәреслекләр шул нигездә төзелә[96].

Татар әдәбиятын укытудагы үзгәрешләр, беренче чиратта, әдәбиятның эчтәлеге үзгәрү белән билгеләнә: укучыларга тәкъдим ителгән әдәбият исемлеге яңартыла, коммунистик рухта язылган әдәби әсәрләр дәреслекләрдән алына, алар урынына совет чорында буржуаз язучылар буларак танылган һәм иҗатларын өйрәнү тыелган әдипләрнең әсәрләре (мәсәлән, Гаяз Исхакый) кертелә. Бу чорда озак еллар дәвамында кулланылган традицион дәреслекләрдән тыш (А.Әхмәдуллин, Ф.Галимуллин. М.Мәһдиев, М.Гайнуллин һ.б.), альтернатив программа һәм дәреслекләр барлыкка килә. Шул рәвешле, 90 нчы елларда урта мәктәптә татар әдәбиятын укытуда программа һәм дәреслек сайлап алу мөмкинлеге барлыкка килә. Татар әдәбиятын укытуда үстерелешле методиканы нигез итеп алган А.Яхин дәреслекләре гомумән татар әдәбиятын укытуның төп максатларыннан тыш, укучыларның уйлау, фикерләү дәрәҗәләрен үстерүгә юнәлдерелә. Моңарчы дөнья күргән дәреслекләрдән аермалы буларак, А.Яхин методикасы буенча эшләгән укытучы дәреслек материалын сөйләми, ул укучы белән әңгәмә кора, уку проблемасын ачуга корылган сораулар ярдәмендә аның эшчәнлегенә юнәлеш бирә; укучы әсәргә анализ ясый, фикерен исбат итәргә, нәтиҗә ясарга өйрәнә, 8 нче сыйныфтан башлап дәрестә иҗат белән шөгыльләнә[97]. Шулай итеп, укучының иҗади мөмкинлекләрен, фикерләү дәрәҗәсен, фикер-омтылышларын, һәм, иң мөһиме – үз сүзен әйтә алуы, фикере хәтта гомум кабул ителгән стереотиплардан беркадәр аерылган очракта да укытучы һәм иптәшләренең яклавын табу яисә үз фикерен яклау мөмкинлеген тудыра. Бу исә аның ирек-

[96] Гафурова Ф., Сәлимгәрәева Б. Татар теле: 2 нче сыйныф: Башкортстанның дүртъеллык башлангыч мәктәпләре өчен дәреслек. – Уфа: Китап, 2002. – 120 б. һ.б.

[97] Яхин А. 5–11 класслар өчен татар әдәбияты программасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 3 б.

ле шәхес буларак формалашуына ярдәм итә. А.Яхин методикасының төп әһәмияте, беренче чиратта, мөгаен, шуның белән билгеләнәдер.

Бу чорда рус мәктәпләрендә белем алучы татар балалары өчен әдәбият дәреслекләре әзерләнә[98]. Икенче бер үзенчәлек татар әдәбиятын укытуда яңа юнәлеш белән бәйле: 2000 нче еллар башында рус телле укучыларга татар әдәбияты укытыла башлый[99].

Бу елларда милли-төбәк компонентын куллану төбәкләрдә иҗат иткән язучы һәм шагыйрьләр иҗатына игътибар артуга китерә. Татарстан төбәкләрендәге әдипләрнең тормышын һәм иҗатын яктырткан методик кулланмалар, дәрес эшкәртмәләре күпләп дөнья күрә, шул рәвешле, билгеле булган, атаклы әдипләр белән беррәттән, шул төбәктән чыккан язучы һәм шагыйрьләрне дә өйрәнү мөмкинлеге тудырыла.

Бу юнәлеш Россиянең татарлар яшәгән башка төбәкләрендә дә үсеш ала. Мәсәлән, Башкортстанда, Себердә мәктәп укучыларына җирле әдәбиятны өйрәтү буенча методик һәм уку кулланмалары нәшер ителә. Мисал өчен, Себер төбәге татарларының әдәби мирасын яктырткан китаплар шундыйлардан[100].

Урта мәктәптә музыка укыту буенча үзгәрешләр музыка буенча берничә вариант программа булдыру, аларга милли композиторларның иҗатын яктырту бурычы йөкләнү белән билгеләнә. Татар мәктәпләре һәм гимназияләренең 1–8 нче сыйныфлар өчен тәкъдим ителгән яңа программада, хрестоматияләрдә татар музыкасы, фольклор әсәрләренә зур урын бирелә[101]. Бу чор шулай ук Татарстанда махсус татар музыка мәктәпләре ачылу белән дә тарихка кереп калды.

---

[98] Галимуллин Ф., Мифтиева Ф., Гыйләҗев И. Татар әдәбияты: Рус урта гомуми мәктәпләренең 6 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1999. – 206 б.

[99] Хәбибуллина З., Фәрдиева Х., Хуҗиәхмәтов Ә. Татар әдәбияты: Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 8 сыйныфы өчен дәреслек. – Казан: Мәгариф, 2005. – 206 б.; Рус телендә урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбиятыннан программалар: 1–11 нче сыйныфлар / Төзүче-авторлары: Ф.Галимуллин, З.Хәбибуллина, Х.Фәрдиева. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011.

[100] Хәбибуллина Л. Туган як әдәбияты. 5–11 нче класс укучылары өчен уку кулланмасы: ике кисәктә. – Төмән: ТДУ, 2002.

[101] Бакиева Н.В., Халитова Н.Х. Музыка дәресләре өчен хрестоматия: 1 нче класс. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 93 б.; Бакиева Н.В., Җиһаншина М.Ф., Халитова Н.Х., Кадыйров И.Ш. Татар мәктәпләре, гимназияләре өчен музыка программасы һәм дәрес эшкәртмәләре (1–8). – Казан: Мәгариф, 1997. – 143 б.; Кадыйров И.Ш. Музыка дәресләре өчен хрестоматия (4 нче класс). – Казан: Мәгариф, 1998. – 99 б. һ.б.

## 1.4. Татар телендә һөнәри белем бирү мәсьәләләре

Татар мәгариф системасын булдыруның иң төп шарты һәм төп максаты – татар телендә һөнәри эшчәнлек алып бара торган белгечләр әзерләү, ягъни татар телен тулы күләмдә көндәлек аралашу чарасы буларак куллану мөмкинлеген булдыру. Моның өчен, әлбәттә, татар телендә белем бирә торган югары уку йортларының булуы шарт. Милли мәгариф системасының югарыгы буыны буларак каралган татарча белем бирүче урта һөнәри һәм югары уку йортлары башка буыннарның яшәве һәм үсүе өчен мәҗбүри булган шартларның иң әһәмиятлесе. Шул мәсьәләне хәл итми торып, татар мәгарифен тулы һәм өзлексез белем бирү системасы буларак күзаллау мөмкин түгел. Икенче яктан караганда, татар телен һөнәри, аеруча югары белем бирү, системасына кертеп җибәрү генә аның тулы яшәешен һәм сакланып калуын тәэмин итә ала. Бу чорда күп татар галимнәре милли югары мәктәпне булдыру һәм анда ана телендә эш алып барырлык югары квалификацияле белгечләр әзерләү – татар телен аның тарихына һәм асылына туры килгән дөнья югарылыгына күтәрү өчен генә түгел, ә гомумән телебезне саклап калу өчен бердәнбер юл дип саный[102]. Югары белемле белгечләрнең үз ана телләрендә аралаша һәм аны һөнәри эшчәнлекләрендә куллана алулары татар телен тергезү, саклау һәм үстерүгә бәя биреп бетергесез өлеш кертә[103]. Икетеллелек шартларында татар телен доминанта ролен үтәгән рус теле дәрәҗәсенә күтәрү өчен кирәкле булган шартлар арасында аның кулланылыш даирәсен киңәйтү, икътисади базасын (статусын) ныгыту (мәсәлән, дәүләт заказы), мәгариф һәм фән өлкәсендә кулланылуын һәм тәэсир көчен арттыру һ.б. бар[104]. Туган телдә югары һөнәри белем алу мөмкинлеге халыкның белем алуга хокукын тормышка ашыру белән беррәттән, татар

---

[102] Фәтхуллин В.Ш. Татар булыйк, дөя булмыйк // Мәшһүр татар галимнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 406 б.; Шакирҗанов Р.Ә. Татар телендә югары белем бирү концепциясендә «Фән һәм тел» журналының урыны // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998. – 51 б.

[103] Зәкиев М.З. Милли телне саклау – милләтне саклау ул // Татар телендә югары белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар). – Казан: КДАТУ, 2017. – 33 б.

[104] Туктамышов Н.К. Билингвизм в современном мире // Татар телендә югары белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар). – Казан: КДАТУ, 2017. – 45–46 б.

теленең кулланылыш даирәсе киңәюгә, аның стиле, логикасы, ассоциациясе һ.б. мөмкинлекләрен тагын да тулырак ачу мөмкинлеген бирә[105].

Бу чорда урта һөнәри белем бирү йортларында татарча укыту вузлар белән чагыштырганда иртәрәк башлана: 1987–1988 уку елында 9 урта һөнәри-техник уку йортында укыту һәм тәрбия эшләре татар телендә алып барыла[106]. 1989–90 уку елыннан республиканың барлык һөнәри-техник уку йортларында һәм техникумнарда, шул исәптән Казан музыка, педагогия көллиятләрендә, татар теле предмет буларак кертелә.

Татарстандагы педагогия көллиятләрендә татар мәктәпләре өчен башлангыч сыйныф, музыка укытучылары, балалар бакчалары тәрбиячеләре әзерләнә. 1989 елда Лениногорск педагогия көллиятендә татар мәктәпләре һәм балалар бакчалары өчен музыка укытучылары әзерләү бүлеге ачыла. Аерым предметлар буенча дәреслек һәм кулланмалар төзелә[107].

2000 нче еллар башында исә урта һөнәри белем бирү йортларында предметларны татарча укыту (татар телен һәм әдәбиятын укытудан тыш) шактый кими[108]. Төп сәбәпләр арасында татар телендә һөнәри урта белем бирүнең кануни базасы эшләнелмәү, укыту-методик әдәбият аз булу тора.

Татар телендә югары белем бирү 90 нчы елларда шактый зур үсеш ала һәм татар мәгарифенең иң әһәмиятле баскычына әверелә. Мәсьәләне хәл итү юнәлешендә ике юл тәкъдим ителә. Беренчесе – моңарчы булмаган яңа структура булдыру – татар милли югары уку йортын ачу һәм икенчесе – югары уку йортларында татарча белем бирүне торгызу. Төп бурыч буларак каралган беренче юнәлеш төрле сәбәпләр аркасында тормышка ашмый[109]. Дәүләти вузларда татарча укытуга килгәндә, әлеге юнәлешне татар мәгарифен система буларак торгызу омтылышын тормышка ашыру, татар мәгарифе һәм пе-

---

[105] Туктамышов Н.К., Салехова Л.Л. Возникновение и развитие образования в Татарстане // Казанский педагогический журнал. – 2010. – № 2. – С. 176.

[106] Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – С. 56.

[107] Гайнетдинов М.Л. Педагогика: Педагогия көллиятләре һәм училищелары өчен уку әсбабы. – Казан: Школа, 2005. – 148 б.

[108] 2004 елгы материаллар буенча урта һөнәри белем бирү өлкәсендә студентларның 4%ы гына ана телендә белем ала // ИА Татаринформ, 2004, 22 июнь.

[109] Бу турыда тулырак итеп алдагы бүлектә укырга мөмкин.

дагогик фикер үсешендәге иң тирән эз калдырган күренешләрнең берсе дияргә мөмкин.

Вузларда татар телендә укыту 1991 елда башланып китә. Казан төзүче-инженерлар институтының төзелеш факультетында беренчеләрдән булып татар телендә укыта торган төркемнәр төзелә, татар телендә белем бирерлек укытучылар әзерләү мәсьәләсен хәл итү, терминологик базаны булдыру, укыту барышын методик яктан тәэмин итү буенча эшләр башлана. Төп максат – ике дәүләт телен камил белгән һәм аларны һөнәри эшчәнлекләрендә файдалана алган белгечләр әзерләү. Вузның уставына рус теленнән тыш, белем бирү башка телләрдә дә алып барылырга мөмкин, дигән төзәтмә кертелә[110]. Әлеге документ нигезендә билингваль укыту кертелә, 72 дисциплинаның 22 сен татар телендә укыту оештырыла[111]. Бу эшнең башында торучы һәм укыту барышын нәзари-гамәли һәм методик яктан тәэмин итүгә иң зур өлеш керткән галимнәрнең берсе – В.Ш.Фәтхуллин. Ул гидравлика, төзелеш материаллары, корылма механикасы кебек төзелеш фәннәрен татар телендә укытуга нигез сала. Татарча белем бирүгә Кама политехник институты, Казан дәүләт педагогия институты (КДПИ), Казан авыл хуҗалыгы институты, соңрак КАИ, КХТИ, Казан медицина институты һ.б. вузлар кушыла. 2000 елның урталарына Кама политехник институтында, мәсәлән, 70% студент татар телендә белем ала[112].



*В.Фәтхуллин*

Татар телендә югары белем бирүнең кануни нигезләре беренче тапкыр 1993 елда Казан дәүләт авыл хуҗалыгы академиясе галимнәре тарафыннан эшләнә[113]. Концепция авторлары татар төркемендә белем алу өзлеклелеген тәэмин итү, өч телне дә камил үзләштергән белгечләр әзерләү бурычын куялар. Татар телендә югары белем би-

[110] Низамов А.М. Милли мәктәп: тәрбия нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2005. – 8 б.

[111] http://www.kgasu.ru/sved/structure/tat/

[112] Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае материаллары. – Казан: БТК, 2002. – 70 б.

[113] Юлдашев А.К. Безнең бурычлар // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998. – 38 б.

рүнең теоретик нигезләре Казан архитектура-төзелеш академиясе галимнәре Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә., Нарбеков А.И. тәкъдим иткән Концепция проектында[114] аеруча тулы чагылыш таба. Концепция татар халкының тулы мәгариф системасын булдыруга, аның иң әһәмиятле буынын – милли югары мәктәпне төзүгә һәм үстерүгә юнәлтелгән. Проект татар телен кеше эшчәнлегенең һәр өлкәсендә куллану зарурлыгына таяна.

Концепция авторлары фикеренчә, татар югары мәктәбе, гомумән югары уку йортларына карата куелган максатлардан тыш, милли яңарышны тәэмин итү, мәдәниятне һәм телне үстерү, дәүләтчелекне, читтә яшәүче милләттәшләр һәм ватандашлар белән элемтәләрне ныгыту белән дә шөгыльләнергә тиеш. Борынгыдан килгән традицияләрне, гореф-гадәтләрне саклау һәм үстерү югары белемне дә татар мохитендә һәм нигездә татар телендә алып баруны таләп итә[115]. Әмма шул ук вакытта икенче дәүләт теле булган рус телен камил белү, югары белем бирүнең дөньякүләм системасына кушылу, халыкара интеграция, көнкүрештә һәм һөнәри өлкәдә аралашу, мәгълүмати һәм идеяләр белән алмашуны тизләтү өчен тагын бер чит тел өйрәнүне, чит телләрне туган тел нигезендә өйрәтүне максат итеп ала[116].

Концепция авторлары ана телендә югары белем бирмәү, төгәл фәннәрне татарча укытмау телне зәгыйфьләндерә, фәннән аера дип саныйлар. Татар телендә югары белем бирү милли алгарышның нигезе генә булып калмыйча, кешелек дөньясы өчен дә зур файда китерергә тиеш, чөнки ул төрле фәннәрне татар теленең фәлсәфи системасы аша яңабаштан тикшереп чыгарга, аларның әһәмиятле өлешләрен сайлап алырга мөмкинлек бирәчәк, фәндә татар теленең фәлсәфи нигезләрен киңрәк кулланырга, үсеш-үзгәреш барган системаларны, хәрәкәт-динамиканы, технологик процессларны төгәлрәк өйрәнергә ярдәм итәчәк[117].

Концепциядә милли мәгариф өлкәсендәге дәүләт сәясәте принциплары да билгеләнә. Болар арасында ТР гражданнарының югары белемгә конституцион хокукларын тәэмин итү һәм яклау, югары белем бирү өлкәсендә физик һәм юридик затларның вәкаләтләрен һәм

---

[114] Татар телендә югары белем бирү концепциясе // Фән һәм тел. – 1999. – № 1. – 10–15 б.

[115] Шунда ук. – 10 б.

[116] Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә., Нарбеков А.И. Татар телендә югары белем бирү концепциясен төзү юлында // Языковая ситуация в Республике Татарстан: состояние и перспективы. – Казань, 1999. – 10 б.

[117] Шунда ук. – 11 б.

җаваплылыгын билгеләү һ.б. лар бар. Әлеге документны тормышка ашыру чаралары арасында югары белем бирүнең бербөтен системасын төрле һәм күп кимәлдә (фундаменталь, гуманитар, техник, һөнәри, ике һәм күп телдә белемне күтәрү, аспирантура, докторантура һ.б.) формалаштыру күздә тотыла.

Милли мәгариф системасы үсешенең иң мөһим баскычларының берсе буларак каралган һөнәри югары белем бирүдәге үзгәрешләр ике юнәлештә алып барыла – татар телендә белем бирү һәм татар телен укыту.

Әлеге чорда республикадагы дәүләти 21 югары уку йортын, татар телендә укыту мәсләгеннән чыгып, ике төргә бүлеп карарга мөмкин. Беренчеләре – электән ана телендә белгечләр әзерли торганнар (педагогия уку йортлары, дәүләт университеты, сәнгать академиясе), икенчеләре – җитештерүненең төрле тармаклары өчен белгечләр әзерләүче вузлар (архитектура-төзелеш, авыл хуҗалыгы, Кама политехника институты, техник һәм технология университетлары)[118].

Куелган максатлар һәм укыту мөмкинлекләреннән чыгып, фәннәрне татарча укыту ике юнәлештә алып барыла – гуманитар һәм техник, төгәл фәннәрне укыту. Бу чорда гуманитар циклга караган предметларны, мәсәлән, тарих, фәлсәфә, педагогика, культурология, нәфасәт, этика, психология кебек фәннәрне туган телдә укыту өчен шартлар җитәрлек тудырыла: татар телендә белем бирә алырлык белгечләр бар, терминологик база да нигездә эшләнгән. Югары уку йортларының татар төркемнәрендә, КДУ, КДПУның татар факультетларында фәннәрне татарча укыту тәҗрибәсенең булуы да моңа ярдәм итә (М.Абдрахмановның 1966 елда татар телендә «Диалектик материализм» дәреслеге дөнья күрә һ.б.). Заманча шартларда мондый предметларны туган тел һәм милли үзенчәлекләр аша алып баруның дөреслеген белгечләр дә таный[119]. Бу чорда культурология, фәлсәфә, нәфасәт һ.б. фәннәр буенча югары мәктәп дәреслекләре басылып чыга[120]. Әмма аларның күбесе тулы мәгънәсендә уку-укыту процессына барып ирешми.

---

[118] Фәтхуллин В. Техник фәннәрне татарча укыту һәм бердәм терминнар булдыру // Мәгариф. – 1997. – № 4. – 39–40 б.

[119] Соловьева Е.Г. Язык и национальная культура в духовном становлении будущего педагога // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998. – 45 б.

[120] Гыйззәтов К.Т. Философия: Кыскача философия тарихы. Философиянең нигез проблемалары. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 1 нче китап. – Казан: Мәгариф, 2002. – 448 б.; Гыйззәтов К.Т. Философия: Социаль фи-

90 нчы еллар – татар теле, әдәбияты һәм тарихы буенча югары белем бирү юнәлешендә күтәрелеш еллары буларак кереп кала. 1990 елда, татар тарихында беренче тапкыр буларак, КДУда татар филологиясе, тарихы һәм шәрык телләре факультеты оештырыла, Башкорт дәүләт педагогия институтында, КДПИ да, Самара, Ижевск педагогия институтында һәм Россиядәге башка югары уку йортларында татар филологиясе бүлекләре ачыла, димәк, төбәкләр өчен татар теле укытучылары әзерләү мәсьәләсе беркадәр хәл ителә. Татарстанда татар теле, әдәбияты, татар тарихы белән беррәттән, барлык башка предметлар буенча ана телендә белем алу мөмкинлеге тудырыла.

Бу чорда күп югары уку йортларында татар телендә белем бирү буенча махсус төркемнәр ачыла. Югары уку йортларына керүче һәр абитуриентка имтиханны үз теләге буенча ике дәүләт теленең берсендә тапшыру мөмкинлеге тудырыла.

Татар төркемнәре оешу белән аларда белем бирә алырлык педагогик кадрлар һәм укыту-методик базаны булдыру мәсьәләсе күтәрелә, программа, методик әсбаплар, дәреслекләр төзү эшенә керешелә. Казан авиация, төзелеш, авыл хуҗалыгы институтлары галимнәре үз белгечлекләре буенча татар телендә дәрес конспектлары, программалар язалар. Бу проблемаларны яктырткан махсус конференцияләр уздырыла.

1997 елда Казан дәүләт төзелеш-архитектура институты базасында татар телен фән теле буларак торгызуны максат иткән «Фән һәм тел» журналы чыга башлый. Журналда татар телендә югары белем бирүнең төрле аспектларына багышланган, фәннең төрле тармакларын яктырткан мәкаләләр дөнья күрә, төрле дисциплиналар буенча татар телендә басылып чыккан укыту-методик әсбаплар тәкъдим ителә. Бу басма бер үк вакытта татар теленең фән теле буларак мөмкинлекләрен күрсәтүне максат итә.

Һәрбер уку йортында татар телендә белем бирүнең максат һәм бурычлары, эш юнәлешләре билгеләнә, иң беренче чиратта укытучылар өчен татар теле курслары оештыру хәл ителә, методик һәм терминологик комиссияләр төзелә, татар телендә белем бирә алучы укытучы-галимнәр әзерләнә.

---

лософия. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 2 нче китап. – Казан: Мәгариф, 2003. – 407 б.; Гыйззәтов К.Т. Нәфасәт: нәфасәтнең нигез проблемалары. Кыскача нәфасәт тарихы. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 1 нче китап. – Казан: Мәгариф, 2004. – 495 б.; Гыйззәтов К.Т. Нәфасәт. Югары уку йортлары өчен дәреслек. 2 нче китап. – Казан: Мәгариф, 2006. – 479 б.

1997 елда ТР югары уку йортлары каршында вузара фәнни-методик совет төзелә. Бу оешманың төп максаты – татар телендә методик әдәбият булдыру һәм татар телендә фәнни терминнар әзерләү юнәлешендә эш алып бару. Татар дәүләт гуманитар-педагогика институты базасында Татар дәүләт университеты төзү перспективасы ачыла.

Татар югары белем бирү системасын урнаштыруның беренче чорын (1990 еллар) милли үзаң күтәрелгән, идеаллар чоры буларак тасвирларга мөмкин. Икенче чорда исә (1990 еллар урталары – 2005 еллар) Татарстанда милли мәгарифнең теоретик нигезләре барлыкка килә, аерым алганда: икетеллелеккәнигезләнгән милли мәгарифнең норматив-хокуки нигезләре булдырыла, гомумроссия белем стандартларының федераль һәм төбәк компонентларына кергән гуманитар предметларның эчтәлеге бер-берсенә яраклаштырыла, һәркемгә түләүсез туган телдә белем бирү дәүләт гарантияләрен тәэмин итү буенча оештыру-идарә механизмнары булдырыла, милли мәгариф кадрлары әзерләү, квалификацияләрен күтәрү системалары булдырыла. Бу хәл, әлбәттә, федераль хакимиятнең кайбер даирәләрендә канәгатьсезлек тудыра, алар милли мәгарифләр үсеше Россиянең бердәмлеген тарката, дигән фикерне үткәрәләр.

Бу елларда мәсьәләнең икенче ягы күтәрелә: барлык фәннәрне дә татар телендә укыту кирәкме һәм барлык уку йортларында да татарча укыту мәҗбүриме? Р.Йосыпов фикеренчә, мәсәлән, бу очракта төп шартлар искә алынырга тиеш: кадрлар әзерләнә торган белгечлекләр, фәннәр, укытучыларның белем дәрәҗәсе, методик әдәбият белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе. Бу яктан караганда, галим фикеренчә, татар телендә укыту беренче чиратта педагогик уку йортларында алып барылырга тиеш. Шулай ук гуманитар өлкәдә эшләүчеләр (мәдәният, әдәбият, сәхнә сәнгате, музыкаль иҗат белән шөгыльләнүчеләр) ике телдә дә укырга тиеш. Һөнәр эшчәнлеге медицина, почта, транспорт белән бәйле, ягъни күпсанлы халык белән эшләүне күздә тоткан белгечлекләр буенча белем алучыларга шулай ук ике телне дә камил белү мәслихәт[121]. Агросәнәгатьнең нигездә авыл шартларында тормышка ашырылуын исәпкә алганда, анда да татар һәм рус телләрендә белем бирү дөрес булыр. Техник уку йорт-

[121] Юсупов Р.А. Преподавание на татарском языке в педагогических вузах Республики Татарстан // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998. – 12 б.

ларына килгәндә, ул һәрбер техник уку йортында да татар телендә белем бирүнең максатка ярашлы булуына шик белдерә[122].

Н.К.Туктамышов исә дәүләт теленең берсендә белем алучы кеше аның икенчесен дә яхшы белергә тиеш, билингвизм югары уку йортын тәмамлаучының мөмкинлекләрен арттыра гына дип саный[123]. Галим фикеренчә, түбән курсларда татар телендә күбрәк фәннәрне укыту татар балалары өчен адаптация узарга ярдәм итә, туган телдә бирелгән материал яхшырак үзләштерелә.



Н.Туктамышов

Билингвизмны тормышка ашыруның төп шарты булып татар теленең фән теле буларак дәрәҗәсен күтәрү тора. Бу, беренче чиратта, татар телендә фәнни-тикшеренү эшләре алып барылырга тиеш дигәнне аңлата. Соңгысы татар телендә фәнни терминология булдыруга турыдан-туры бәйле. Бу чорда галимнәр татар теленең фән, бигрәк тә төгәл фәннәр теле буларак мөмкинлекләре зур булуга игътибар итәләр[124].

Фәнни атамалар булдыру, аларны әйләнешкә кертүдә иң уңышлы юлларның берсе – төрле фәннәр буенча икетелле терминологик сүзлекләр төзү. Татар телендә укыту мөмкинлеге ачылу белән бу эшкә һәрбер уку йортының үз белгечләре дә кушыла. Нәтиҗәдә техника, төгәл фәннәр буенча дистәләрчә сүзлек дөнья күрә. Әмма алардагы төрлелек (ул чорда күп авторлар татарча атама ясау белән мавыга) татар телен фән теле буларак формалашуына комачаулык итә. Терминнар мәсьәләсе, бер яктан, татар сүзләрен кире кайтару, аларга яңа мәгънә салу, яңа атамалар уйлап чыгару (мәсәлән, санак һ.б.), тәрҗемә итү белән барса, икенче яктан гарәп-фарсы атамалары, борынгы төрки сүзләрне кайтару белән билгеләнә. Нәтиҗәдә татар телендә язылган дәреслекләр арасында уку-укыту барышында

[122] Йосыпов Р. Югары белемне – ана телендә // Мәгариф. – 2002. – № 6. – 3 б.

[123] Туктамышов Н. Югары уку йортларында – икетеллелек // Мәгариф. – 2001. – № 1. – 43 б.

[124] Шакирҗанов Р.Ә. Татар теленең танып-белү алгоритмын фән һәм җәмгыятьне үстерү өчен куллану // Фән һәм тел. – 2002. – № 3. – 54 б.; Мөбарәкҗанов Г.М. Математика тамгалары һәм терминнары, барлыкка килү тарихы. – Казан: Фән, 2004. – 9–10 б.

куллану мөмкинлекләре чикле әсбаплар барлыкка килә. Шулай итеп, вузда укытыла торган һәрбер фән өлкәсенә карата татар фәнни-техник терминологиясен унификацияләү бурычы килеп баса. Мәсьәләне хәл итү юлы буларак аерым фәнни тармаклар буенча вузара, шулай ук һәрбер вузның үз эчендә эчке көчләр ярдәмендә татар телен камил белгән галимнәр катнашында махсус терминологик комиссияләр төзү тәкъдим ителә[125].

Татарча югары белем бирү юлга салыну белән, студентларны татар халкының һөнәри тәҗрибәсе белән киңрәк таныштыру мөмкинлеге ачыла. Мәсәлән, борынгыдан килгән төзелеш тарихын өйрәтү – шундыйларның берсе. «Татар халкының төзү тарихы бик борынгы заманнардан башлана. Бабаларыбыз ак таш, чәртәп таш, Европада беренче булып кирпеч, тимер, кадак һәм атламалар, агач арка һәм борыслар кулланганнар. Бина нигезләренә сейсмик ныклык өчен кирпеч яки балчык түшәмә җәелгән һ.б.»[126]. Ләкин элеге өлкәгә караган әдәбият булмау сәбәпле, онытыла барган шул бай төзүчелек мирасын студентларга җиткерүдә мөмкинлекләр чикле була. Татарча атамалар булдыру әлеге проблеманы хәл итүгә ярдәм итә. Төзелеш терминнарын кулланганда рус телендә кереп урнашкан атамалар белән беррәттән, татарча сүзләр (мәрмәр, чуен, сумала, дегет, чәртәп һ.б.) кулланышка кертелә.

Техник фәннәрне укытучы белгечләр исәпләвенчә, татар телендә терминнар мәсьәләсен хәл итүдә иң беренче чиратта туган телгә карата сак мөнәсәбәт, аның эчке мөмкинлекләрен ача алу, яңа сүзләр төзүдә татар теленең үз закончалыкларыннан һәм сүз байлыгыннан файдалану, чит телдән терминнар керткәндә аларны рус теленнән түгел, ә бәлки төп, оригинал телдәге мәгънәсеннән чыгып эш итү мәҗбүри[127], шул ук вакытта тәрҗемә ителгән атамаларның кыска һәм аңлаешлы булуы шарт[128]. Мәсьәләнең тагын бер ягы – атама-

---

[125] Шакирҗанов Р.Ә. Татар теленең танып-белү алгоритмын фән һәм җәмгыятьне үстерү өчен куллану // Фән һәм тел. – 2002. – № 3. – 54 б.; Мөбарәкҗанов Г.М. Математика тамгалары һәм терминнары, барлыкка килү тарихы. – Казан: Фән, 2004. – 21 б.

[126] Камалова З.А. Югары уку йортларында татар телендә укыту – телне саклап калуның төп шарты һәм мөмкинлеге // Татар телендә югары белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар). – Казан: КДАТУ, 2017. – 70–71 б.

[127] Ахметов Л.Г., Тимербаев Р.М. Из опыта преподавания технических дисциплин в вузе на татарском языке // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998. – 33 б.

[128] Габбасов Н.С. Математик анализ фәне өлкәсендә татар теле // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998. – 69 б.

лардагы төрлелектән котылу: фәнни термин кулланылышында өзлеклелек сакланырга тиеш (мәктәп, вуз, җитештерү һ.б. өлкәләрдә). Бу яктан караганда, 90 нчы елларда дөнья күргән бик күп дәреслек һәм методик әсбаплар әлеге таләпкә җавап бирә алмый.

Беренче чорда теге яки бу предмет буенча татарча дәреслек язу эшен һәрбер вуз үзе хәл итә. Бу исә әлеге әсбапларның бары тик бер уку йорты кысаларында гына файдаланылуына китерә, гомумкулланышка чыгу юлын тоткарлый. Нәтиҗәдә татар телендә төрле фәннәр буенча дәреслекләр язу эше билгеле бер тәртиптән азат булып, хаоска китерә. Мәсьәләне хәл итү юлы буларак, гомуми характердагы дәреслекләр төзү һәм бастыруны тәртипкә салу, үзәкләштерү, дәүләти координацион оешма тарафыннан җитәкчелек ителүе күреләә[129]. Ә махсус, бик тар белгечлекләр буенча бу эш вузларның үзләренә калдырыла. Мисал өчен, Казан архитектура һәм төзелеш академиясендә 1991–1998 елларда 70 тән артык төрле дәреслек-кулланмалар, сүзлекләр бастырып чыгарыла[130] һәм аларның күбесенең башка (мәсәлән, педагогик) уку йортларында да куллану мөмкинлеге билгеләнә[131]. Бу елларда техник һәм төгәл фәннәрне укыту буенча дәреслек һәм методик әсбаплар шактый әзерләнә, шулар арасында Р.Б.Сәлимов, Н.К.Туктамышовның «Математика» дәреслеген, С.Миңнулланың «Сызма геометрия»сен һ.б. атарга мөмкин.

ТРда телләр программасы[132] кабул ителү белән төрле фәннәр буенча татар телендә дәреслекләр бастыруны үзәкләштерелгән юл белән хәл итү мөмкинлеге ачыла. Яңа барлыкка килгән «Мәгариф» нәшриятендә бик күп тармаклар буенча татарча дәреслек һәм уку кулланмалары басыла.

---

[129] Юсупов Р.А. Преподавание на татарском языке в педагогических вузах Республики Татарстан // Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998. – 20 б.

[130] Шунда ук. – 43 б.

[131] Камалов А.З., Сиражетдинов Ф.Г. Теоретик механика. Статика: Уку кулланмасы. – Казан: КДТИ, 1992. – 130 б.; Даутов Г.Ю., Галимов Д.Г., Тимеркәев Б.А. Физика. Югары техник уку йортлары өчен дәреслек. 3 кисәктә. Кис. 1. – Казан: Мәгариф, 1999. – 288 б.; Кис. 2. – Казан, 2001. – 344 б.; Кис. 3. – Казан, 2002. – 336 б. һ.б.

[132] Закон РТ от 08.07.1992 N 1560-XII «О государственных языках Республики Татарстан и других языках в Республике Татарстан». URL: http://kitaphane.tatarstan.ru/legal_info/zrt/lang.htm

2004 елда Татарстанда 22 дәүләти вузның 15 ендә теге яки бу дәрәҗәдә татар телендә укыту оештырыла[133]. Тулаем татар телендә югары белем татар филологиясе факультетларында, өлешчә Казан университетының һәм Казан педагогика университетының филология, юридик һәм журналистика факультетларында, Казан консерваториясендә һәм Казан дәүләт сәнгать һәм мәдәният институтында, Казан архитектура-төзелеш университетында алып барыла. Татарстандагы кайбер вузларда аерым фәннәрне татарча укыта торган татар төркемнәре була.

90 нчы еллар башында ике яклы икелеттелек турында сүз алып барыла. Бу иң беренче чиратта, рус һәм татар телләрен бер үк дәрәҗәдә тормыш, яшәешнең төрле өлкәләренә кертү белән бәйле. Аның беренче адымнарын мәгариф системасында, бигрәк тә югары мәктәптә күрергә мөмкин. Татарстанда беренчеләрдән буларак, КДПИ ның барлык факультетларында да 64 сәгатьлек программа нигезендә[134] 1991–92 елларда ике яклы икетеллелек тормышка ашырыла башлый, яки рус теле белән бергә рус һәм башка милләт телләрендә сөйләшүче студентларга татар теле укытыла. Ә үз ана телен белгән татар студентларына татар теле 1988/89 уку елында ук кертелә.

Югары уку йортларында татар телен укытуның төп максаты – студентларны татар әдәби телен практик рәвештә куллануга хәзерләү. 90 нчы еллар урталарында барлык вузларда диярлек татар теле өйрәнелә, татар теле кафедралары ачыла[135].

Төп проблема – укыту методикасы. Вузларда татар телен предмет буларак укыту өч төрле категория студентларга – татар телен бик яхшы белүчеләргә, начар белүчеләргә һәм бөтенләй белмәүчеләргә белем бирүне күздә тота. Шуңа күрә бу төркемнәрдә укыту өчен өч төрле методика һәм шуның нигезендә программа, дәреслек һәм башка уку әсбаплары эшләнергә тиеш. Югары уку йортларында татар телен өйрәтү киләчәктә татар телендә югары техник белем бирү мәсьәләсен хәл итүгә бер адым булып тора, чөнки һәрбер уку йорты тел мәгълүматларын үз белгечлекләренә карап тәкъдим итәргә тиеш. Бу исә төрле уку йортларында аерым программа һәм дәрес-

---

[133] Мухарямова Л.М., Моренко И.Б., Петрова Р.Г., Салахатдинова Л.Н. Проблема доступности высшего образования для учащихся национальных школ: этносоциальные аспекты // Социологические исследования. – 2004. – № 3. – С. 58–66.

[134] Харисов Ф. Икетеллелек: студентлар татарча сөйләшә // Мәгариф. – 1998. – № 7. – 40 б.

[135] Вәлиев Р. Татар телен куллану даирәсе киңәя // Мәгариф. – 1998. – № 4. – 84 б.

лекләр тууга китерә. Бер яктан караганда бу үз-үзен аклый да кебек (һәр вузның үз үзенчәлекләре, терминнар базасы һ.б.). Әмма бердәм система буларак, үзәкләштереп укытуга килсәк, беркадәр кыенлыклар һәм каршылыклар тудыра.

Татар теле дәресләренең төп максаты – студентларны татар сөйләмен дөрес итеп аңларга (тыңлап аңлау), сөйләм процессында катнашырга (кара-каршы сөйләшү), билгеле бер темага сөйләү (монолог), дөрес итеп укырга, язарга һәм укыганны аңларга өйрәтү, күнекмәләр булдыру. Моннан соң дөнья күргән дәреслекләр дә шушы принципка нигезләнеп төзелә.

Татар телен өйрәтүдә иң еш кулланылган методларның берсе – татар телен чит телләргә өйрәтү методикасы нигезендә укыту[136]. Бу нигезгә корылган дәреслекләр (алар арасында электрон дәреслекләр дә бар) соңгы чорда бик күп уку йортларында дөнья күрде[137].

Шулай итеп, бу чорда (1990–2005) татар югары мәктәбен торгызу һәм аның эчтәлеген булдыруга игътибар зур була. Аның концептуаль нигезләре, бурыч һәм максатлары, үсеш юнәлешләре билгеләнә, берникадәр дәрәҗәдә укыту-методик базасы булдырыла, татар теленең фән теле буларак үсешенә нигез салына. Әмма төп максатлар (Милли университет төзү, Татар югары мәктәбенең концепциясен тормышка ашыру һ.б.) үтәлми. 2000 еллар башында, тел сәясәтендәге һәм, гомумән, мәгариф үсешендәге кискен үзгәрешләр сәбәпле (БДИның бары тик рус телендә генә алып барылуы, мәктәпләрдә русча укытуга күчү һ.б.), татар теленә карата мөнәсәбәт үзгәрә. Бу проблемалар югары мәктәп эшчәнлегенә дә йогынты ясый: татар төркемнәре азая, татар телендә язылган дәреслек һәм башка методик әсбапларның куланылыш даирәсе кими. Югары уку йортларында татарча укыту нигездә татар телен укытуга гына кайтып кала. Хәзерге вакытта татар телендә укыту бары тик өч кенә вузда – КФУда (татар теле белән бәйле белгечлекләрдә), КДМСУда (һәвәскәр театрлар җитәкчесе) һәм КДАТУда (төзелеш институтында) гына алып барыла.

---

[136] Салехова Н.Х., Максимова А.К., Харисова Ч.М. Интенсивное обучение татарскому языку. – Казань: Магариф, 1993.

[137] Харисов Ф., Харисова Г., Айдарова С. Татар теле читтелле аудиториядә. 2 кисәктә. – Казан, 2009.

## 1.5. Татар милли университетын төзү мәсьәләләре

Татар милли университетын (ТМУ) төзү фикере 90 нчы еллар башында татар милли иҗтимагый оешмалары һәм татар зыялылары тарафыннан күтәрелә, тиз арада гомуммилли идеягә әверелә[138]. Ул милли мохитлы, күп белгечлекләр буенча тирән белемнәр бирүче иң эре фәнни-методик үзәк буларак күзаллана (Ф.Мусин һ.б.)[139]. Шул ук вакытта милли университет гомумән бөтен дөнья буйлап таралган татар милләтенең интеллектуаль, фәнни, мәдәни һәм рухи мөмкинлекләрен саклау һәм үстерүне күздә тоткан эре структура, татарны өйрәнүнең координация үзәге буларак күз алдында тотыла (Р.Вәлиев).

Милли телләрдә эшләүче университет төшенчәсе, гомумән алганда, өр-яңа идея түгел. Әйтик, Бельгиядәге Гент университетында озак еллар латин, француз телләрендә белем биргәннән соң, 1930 елда илдә беренче тапкыр буларак нидерланд телендә укытыла башлый. Моңа кадәр рәсми дәүләт телләренең берсе буларак танылса да, нидерланд теле югары мәктәп системасында кулланылмый. Телнең үсеше өчен аның югары белем бирүдә файдаланылуы мөһим. Әлеге уку йортының максаты – туган телдә милли кадрлар әзерләү, ике телне камил белгән дәүләт хезмәткәрләре булдыру. 1993 елда нидерланд теле Фламанд регионында бердәнбер рәсми тел буларак таныла. Каталониядә дә испан теле белән беррәттән, каталан телендә белем бирә торган университетлар бар һ.б.

Гомумән алганда, 90 нчы елларда Татарстанда «милли университет» төшенчәсен аңлауда төрлелек яши. Бер төркем галимнәр аны дәүләт карамагында һәм дәүләт структурасы кысаларында яшәүче югары уку йорты дип карый. Сүз татар телендә югары белем бирү системасын төзү хакында бара. Бу очракта милли университет Россия белем бирү стандартларына нигезләнгән татар телле югары уку йорты (предметларны укытуны татар, төрек һәм инглиз телләрендә

[138] Ахметзянов М.И. Почему нам нужен татарский университет // Молодежь Татарстана. – 1995. – № 36; Бадюгин И. Язык – больше чем власть // Молодежь Татарстана. – 1995. – № 39; Әхмәтҗанов М. Милли университет нигә кирәк? // Татар иле. – 2002. – №11 (март); Әхмәдулла Ш. Милли университет кирәкме? Бик кирәк // Татар иле. – 2002. – № 41 (октябрь) һ.б.

[139] Мусин Ф. Татар мәгарифе: үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге // Шәһри Казан. – 2006. – 28 март.

алып бару) буларак күз алдында тотыла. Икенче бер төркем оештыручылар аны дәүләттән бәйсез булган, мөстәкыйль татар мәгарифенең үзәге булган университет итеп күрә (И.Әмирхан). Шул нигездә аның концепциясен төзүдә дә карашлар аерыла. «Милли университет» төшенчәсеннән тыш, «Татар дәүләт университеты», «Халыкара татар университеты» атамалары да тәкъдим ителә.

Милли университетның максатларын аңлауда карашлар аерыла. Бер төркем зыялылар аны югары интеллектка ия булган белгечләр әзерләүдә күрә, кемнәрдер беренче урынга милли аң тәрбияләүне, милли тәрбия бирүне куя, татар идеясенең тормышка ашу коралы буларак күрә. Заманча татар мәдәниятен булдыру һәм аны үстерү, яңа шартларда эшли алган яңа милли идарәи элита тәрбияләүне төп бурыч итеп күрү[140], Федератив дәүләт шартларында төбәкләрнең социаль-икътисади стратегиясен эшләргә һәм гамәлгә ашырырга сәләтле элиталы белгечләр әзерләп чыгару[141] аның төп бурычы булып санала. Иң беренче чиратта ул милли мәгариф системасының бербөтенлеген тәэмин итүче төп югары уку йорты булырга тиеш[142]. Кайбер галимнәр (И.А.Гыйләҗев) аны нигездә гуманитар юнәлештә булырга тиеш дип санаса, күпчелек (шул исәптән, Я.Г.Абдуллин да) универсаль уку йорты буларак, университет бөтен фәннәрне, шул исәптән физика-математика фәннәрен дә, техника-технология гыйлемен дә, табигать белемен дә үз эченә алырга, гуманитар фәннәрне әлегә билгеле булган татар гуманитар факультетларына караганда киңрәк колачларга тиеш дип саный[143]. Автор шулай ук югары технологияләр чорында цивилизация казанышларын милләт буларак үзләштерә алсын өчен барлык фәннәрне дә ана телендә үзләштерүне төп шартларның берсе буларак күрә[144].

Беренче тапкыр милли университет ачу мәсьәләсе 1991 елның 29 августында ТР Югары Советында күтәрелә. 1994 елда аны хәл итү буенча кайбер адымнар ясала, проблема белән иҗтимагый оеш-

[140] Исхаков Д.М. Татарский национальный университет (Основные принципы организации) // Звезда Поволжья. – 2005. – 21 июля.

[141] Гайфуллин В.Г. Татар университеты: ул нинди булыр? Милли югары мәктәпне яңарту концепциясе // Татарстан. – 2004. – № 1. – 43 б.

[142] Исхаков Д.М. Татарский национальный университет (Основные принципы организации) // Звезда Поволжья. – 2005. – 21 июля.

[143] Абдуллин Я.А. Милләт язмышы. – Казан: Фән, 1999. – 305 б.

[144] Шунда ук.

малар да шөгыльләнә[145]. 1993 елда Россия югары белем системасыннан бәйсез Татар милли университеты ачыла һәм иҗтимагый башлангычларда эшли башлый[146]. Кыска вакыт эчендә университет советы, кабул итү комиссиясе төзелә, биш факультет (техник-технологик, инженер-медицина, тарих-археология, дәүләт һәм хокук, финанс-икътисад) ачыла; укытучылар составы раслана. 1993 елның 20 сентябрендә татар халкы тарихында беренче милли университетта дәресләр башлана. 250 студент кабул ителә, 60тан артык лекция укыла. Дәресләр нигездә татар телендә алып барыла. Әмма университет озакламый эшләүдән туктый.

Милли университет мөстәкыйль, дәүләткә бәйләнеше булмаган уку йорты буларак күзаллана. 1994 елның 18–20 июлендә ТР Югары Советының XXVI сессиясендә «Татарстан Республикасында ТР халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы» кабул ителә. Программа буенча фикер алышулар вакытында Татар иҗтимагый үзәге вәкилләре тарафыннан «татар телендә белем бирә торган югары уку йорты» булдыру турындагы мәсьәлә күтәрелә. Әмма өстенлек «1995 елда татар милли дәүләт университеты» ачу турындагы тәкъдимгә (авторы Ф.Сафиуллин) бирелә[147]. Шулай итеп, 1994 елның 20 июлендә кабул ителгән «Татарстан Республикасында ТР халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча дәүләт программасы»нда 1995 елда Татар милли дәүләт университетын ачу турындагы фикер раслана. М.Сабиров җитәкчелегендә татар дәүләт университетын төзү буенча оештыру комитеты эшли башлый. Әмма шул ук елның декабрендә ул эшләүдән туктый. 1997 елда җыелган Бөтендөнья татар конгрессы 2000 елда Татар дәүләт милли университетын ачу турындагы карарны кабул итә[148]. Бу мәсьәлә БТКның III корылтаенда да (2003) көн тәртибенә куела.

---

[145] 1993 елның 5 мартында «Мәгариф» ассоциациясе президиумында Татар милли университетын төзү турында карар кабул ителә. РФ МСның 1993 елның 26 июнь № 597 карары (югары һөнәри белем бирү учреждениеләрен раслау турындагы положение) нигезендә татар милли югары уку йортын төзү мөмкинлеге ачыла. 12 августта «Мәгариф» ассоциациясенең дәүләти булмаган татар университеты ачу хокукын раслаучы лицензия бирелә.

[146] Әмирхан И. Эшне астан башларга кирәк, шунсыз милли мәгариф үсмәячәк // Шәһри Казан. – 1998. – 15 август.

[147] 244 халык депутатының 127 се яклап тавыш бирә (Сафиуллин Ф. Национальный университет // Звезда Поволжья. – 2008. – № 6 (7–13 февраль).

[148] Бөтендөнья татар конгрессы. – Казан: БТК, 1998. – 183 б.

ТМУ булдыру эшен тоткарларга сәбәп юк һәм алдагы бер-ике ел эчендә университет ачу бөтен татар халкының иң мөһим бурычы дип саналырга тиеш дип белдерелә[149]. Бу юлы идея яңа яңгыраш ала. ТМУ яшьләргә республикада һәм республикадан читтә татар телендә белем алу мөмкинлеген тудыру өчен татарлар яшәгән төбәкләрдә дистанцион (һәм) яки кампус юлы белән белем бирүне күздә тоткан фәнни-педагогик үзәк буларак күзаллана[150].

2000 елның март аенда ТР президентының «Татар дәүләт милли университеты турындагы» боерык проекты әзерләнә, аның нигезендә университет төзү буенча эш 2000/2001 уку елында башланып китәргә тиеш була, концепция булдыру эше Министрлар кабинеты белән Фәннәр академиясенә йөкләнә. Әмма ул концепция эшләнеп бетми.

Концепциянең нигезен эшләүдә төрле фикерләр очрый. Бер төркем галимнәр аны гомумән хәзерге Россия һәм чит илләр югары белем бирү системасы белән бәйләнештә эшләнергә тиеш дип саный (М.Мәхмүтов, Д.Шакирова). Р.С.Хәкимов фикеренчә, татар университеты дөнья стандарталарына юнәлдерелергә, халыкара университет булырга тиеш. «Халыкка ул дөньяның иң яхшы университетлары белән хезмәттәшлек иткән очракта гына кирәк булачак»[151]. Шушы ук фикер Ф.Сафиуллин хезмәтләрендә дә куәтләнә. Алардан аермалы буларак, И.Әмирханов татар милли югары мәктәбе чын мәгънәсендә милли (бу очракта «милли» төшенчәсе астында «дәүләти булмаган» мәгънәсе күзаллана) булырга тиешлеген ассызыклый. Галим дәүләттән тыш мәгариф системасын булдыру татар милләтенең үз дәүләтчелеге булмаган шартларда бигрәк тә мөһим дип саный[152].

Ф.Сафиуллин фикеренчә, татар университеты татар телен белгән һәм һәрбер белгечлек буенча татар, рус, инглиз телләрендә белем алырга теләгән һәркем өчен ачык булырга, шул ук вакытта тел билгесенә карап төрле төркемнәргә бүленеш булмаска тиеш. Беренче чорда 25–30 кешене 3 нче курска кабул итеп (КДУ һәм башка вузларның гуманитар факультетларыннан), студентлар санын 350–400 кә җиткерергә, бу эштә чит илләр тәҗрибәсеннән турыдан-туры

---

[149] Бөтендөнья татар конгрессының III корылтае материаллары. – Казан: БТК, 2003. – 187 б.

[150] Шунда ук. – 196 б.

[151] Хәким Р. Кем син, татар? // Хәким Р. Татар рухы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 131 б.

[152] Әмирхан И. Эшне астан башларга кирәк, шунсыз милли мәгариф үсмәячәк // Шәһри Казан. – 1998. – 15 август.

файдаланырга (белем алуны чит илләрдә, аерым алганда, Оксфордта дәвам итә алу мөмкинлеген тудырырга, кайбер предметларны татар телендә укытуны дәвам итү максаты белән укучылар белән бергә берничә укытучыны да җибәрергә) мөмкин. Шулай итеп, Ф.Сафиуллин ТДМУны хәтта Европа һәм дөньяда танылган югары уку йорты итү максатын тормышка ашырырга кирәк дигән фикерне үткәрә[153]. Шул ук вакытта университетны Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Тарих институты һ.б. гуманитар институтларны үз эченә алган көчле фәнни үзәк, башка уку йортларында һәм төбәкләрдә татарча укытуны җайга салуда ярдәм итүче зур методик үзәк итеп күрергә теләү дә күзәтелә. М.И.Мәхмүтов бу уку йортын булдыруда ике төр максатны аерып күрсәтә һәм шуннан чыгып аның юнәлешен билгеләргә мөмкин дип саный. Галим фикеренчә, әгәр татар университеты татар телен, аның фәнни терминологиясен үстерү үзәге буларак күз алдында тотылса, гуманитар институт та җитә; әгәр белемле татар зыялыларын әзерләүгә курс алынса, һичшиксез, студентларны табигать-математика, техник һәм мәгълүмати яктан әзерләүгә корылган киң профильле университет кирәк[154]. В.Гайфуллин аны милли гуманитар университет буларак күрә[155]. Шулай ук милли университетны Татарстан һәм татарлар яши торган төбәкләр өчен югары квалификацияле милли кадрлар әзерләү буенча укыту-фәнни үзәк булырлык Татар милли университеты итеп күрергә теләү фикере дә яшәп килде[156].

И.Әмирханов Татар милли университетында белем бирүдә ана телен куллану мәҗбүриятенә басым ясый. Әмма төрле фәннәрдән материалның аз булуы яки бөтенләй дә булмавы сәбәпле, башка телләрдән тәрҗемә иткәндә бу этапта (татар теле тулы мәгънәсендә фән теле булып әверелгәнчегә кадәр) мәгълүматның адекватлыгы югалу мөмкинлеген күздә тотып, татар теле белән беррәттән башка телләр дә кулланылырга тиеш дип саный. Аның фикеренчә, татар теленә тәрҗемә ителгән мәгълүмат иң беренче чиратта халыкның милли-рухи катламын искә алып эшләнергә тиеш; тәрҗемә хезмәт-

[153] Бу хакта сөйләшүләр 2000 елда хәтта Англиянең үзендә, Лордлар һәм общиналар палаталары каршында да күтәрелә, рәсми рәвештә хәл итү өчен тәкъдимнәр сорала. Әмма мәсьәлә хәл ителми кала.

[154] Зачем нам нужен татарский университет? // Республика Татарстан. – 2003. – 29 марта (№ 63–64).

[155] Гайфуллин В. Глобальләшү процессы һәм мәгариф системасы // Мәгариф. – 2004. – № 10. – 58 б.

[156] Бөтендөнья татар конгрессы. – Казан: БТК, 1998. – 88 б.

ләрнең барысы да бу таләпне үти алмый. Д.Исхаков университетта рәсми тел татар теле, икенче урында инглиз теле, өстәмә тел буларак (мәсәлән, кайбер махсус курсларны укытканда) рус теле кулланылырга тиеш дип саный[157]. Р.С.Хәкимов фикеренчә, укыту төркитатар телендә, урыс һәм инглиз телләрендә алып барылырга тиеш. «Татар телен төрки телләр грамматикасына яраштырып укытырга кирәк, чөнки, чынлыкта ул төрки телнең казах, үзбәк, төрек һ.б. кебек үк бер диалекты гына, диалектның атамалары мөстәкыйль телләргә әверелгән, әмма бу хәл мәсьәләнең асылын күрергә комачауламаска тиеш. Татарлар төрки дөньяда моннан йөз ел, ике йөз ел элек эшләгән кебек эшләргә тиешләр»[158]. Шулай ук беренче урынга рус телен, аннан соң татар һәм чит телдә укытуны тәкъдим итүчеләр дә бар. Бу юнәлеш тарафдарлары бары тик татарча гына укытуны берьяклы фикер дип карыйлар[159].

И.Әмирханов Татар милли университетын дини-дөньяви уку йорты, татар телле унитар уку йорты, ягъни рус унитар университетының татар телле калькасы түгел, ә татар милләтен кешелекнең гасырлар буе тупланып килгән кыйммәтләре-белемнәре нигезендә торгызу, аеру һәм формалаштыру үзәге булырга тиеш дип саный, Р.С.Хәкимов аның эшчәнлеген Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә күрә («академия институтлары яңа университетта үз кафедраларын ачарга тиеш. Моның белән ике мәсьәлә хәл ителә: университетның конкуренциягә сәләте бердән артачак, ә академиягә яңа сулыш өреләчәк, чөнки республика һәм татар халкы үсешенең конкрет мәсьәләләрен хәл итүгә катнашачак. Нәкъ менә шушы татар университеты киләчәктә татар халкы һәм республика өчен яңа идеяләрнең төп чыганагы була ала һәм булырга тиеш тә»[160]).

1995 елның 5 декабрендә Татар гуманитар институтын (ТГИ) булдыру буенча оештыру комитеты төзелә. Аны КДУ базасында төзү фикере әйтелә. Әмма ул кире кагыла. Гомумән алганда, ТГИ 1994 елгы дәүләт программасын кабул иткәндә милли университетның бер төре буларак тәкъдим ителгән татар телендә белем

---

[157] Исхаков Д.М. Татарский национальный университет (Основные принципы организации) // Звезда Поволжья. – 2005. – 21 июля.

[158] Хәким Р. Кем син, татар? // Хәким Р. Татар рухы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 386 б.

[159] Гилязов И. Обитель элиты (Интервью Г.Саттаровой) // Восточный экспресс. – 2005. – 21 июня.

[160] Хәким Р. Кем син, татар? // Хәким Р. Татар рухы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 132 б.

бирүче уку йорты була. Оештырган чорда ТГУ милли университетка (ТРның милли гуманитар университеты[161]) нигез буларак күз алдында тотыла. Шулай итеп, аны татар җәмәгатьчелегенең Татар дәүләт милли университеты төзү турындагы таләпләренә җавап буларак оештырылган уку йорты дип әйтергә мөмкин. Шуңа карамастан, Татар дәүләт университетын булдыру турындагы мәсьәлә 1999 елга кадәр көн кадагыннан төшми. Университет төзүнең соңгы срогы итеп 2000 ел билгеләнә, матди яктан беркадәр тәэмин ителә[162]. Карар Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан да яклау таба. БТКның II съезды резолюциясендә (1997 елның 29 августы) шулай ук Татар дәүләт университетын 2000 елга кадәр ачу бурычы куела[163]. Бары тик БТКның 2002 елның 29–30 августында узган III съездында гына милли университет ачу мәсьәләсе төшереп калдырыла һәм моннан соңгы съездларда башка күтәрелми.

Әмма киң җәмәгатьчелек татар университетын булдыру идеясен кире какмый. М.Мәхмүтов аны 2025 елга кадәр чорны күз алдында тотып төзелгән РФ милли доктринасы кысаларында карарга тәкъдим итә[164]. Университет ачуның кирәклеген ассызыклап, М.Мәхмүтов татар һәм Татарстан зыялыларын тәрбияләү максатында фикерле, акыллы татар яшьләрен, конкурс һәм олимпиадаларда җиңгән балаларга белем бирүне күрүен әйтә. 1996 елда Татар гуманитар институты ачыла. Киләчәктә татарның генерация үзәге буларак күзалланган Милли университетның башлангычы буларак каралган әлеге уку йортында гуманитар фәннәр буенча татар белгечләрен әзерләүгә зур көч куела. Дистә елга якын вакыт эчендә биредә татар теле һәм әдәбияты, тарих һәм чит телләр (инглиз, гарәп, төрек телләре) буенча студентлар укытыла, аларның күпчелеге татар мәгарифе белән бәйле өлкәләрдә хезмәт итә. Әмма 2005 елда ТГИ Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты белән кушыла, аерым уку йорты буларак яшәүдән туктый. Шулай итеп, Татар милли университетын төзүгә соңгы ышаныч һәм база юк ителә.

---

161 Гайфуллин В. Глобальләшү процессы һәм мәгариф системасы // Мәгариф. – 2004. – № 10. – 58 б.

162 8,7 млн. сум акча бүленеп бирелә («Республика Татарстан» газетасы, 1999, 18 ноябрь).

163 Сборник материалов II съезда ВКТ. – Казан: ВКТ, 1998. – С. 356–357.

164 Зачем нам нужен татарский университет? // Республика Татарстан. – 2003. – 29 марта (№ 63–64).

## 1.6. Дини мәгариф системасы

Совет чорында мөселманнар дини белемне бөтен Советлар Союзына бер булган Бохарадагы «Мир-араб» мәдрәсәсендә генә ала алганнар. 1920 нче елларда совет дәүләте тарафыннан ябылган әлеге мәдрәсә 1945 елда кабат үзенең эшчәнлеген башлап җибәрә. 1980 елларга кадәр Бохарада бары 8–9 шәкерт кенә белем алган, алар Үзәк Диния нәзарәте тарафыннан җибәрелгән булалар (Тәлгат Таҗетдин, Госман Исхакый һ.б.).

Әлбәттә, мондый хәл мөселманнарны канәгатьләндерми. Шуңа Идел Буе, Кавказ, Урта Азиядә ярым яшерен рәвештә дини укулар алып барылган. Шундый мөгаллимнәрнең берсе – Габделхак Саматов җитәкчелегендә Чистайда беренче мәдрәсә ачыла, шул ук мәчеттә ул имам да була. 1990 елда 20 кешедән торган шәкертләр төркеме җыела. Бер елдан соң Г.Саматовның Казанга күчүе сәбәпле, бу мәдрәсә башкалага күчә һәм Кабан арты мәчетендә эшчәнлеген дәвам итә.

1990 елдан башлап, беренчеләрдән булып, Казан югары мөселман мәдрәсәсе «Исламны кабул итүгә 1000 ел» исеме белән рәсми рәвештә теркәлә. Татарстанда барлыкка килгән икенче мөселман уку йорты – Яр Чаллы шәһәренең «Йолдыз» мәдрәсәсе. Идрис Галәветдин бу мәдрәсәнең беренче җитәкчесе була. 1990–91 уку елында мәдрәсә «Каенлык» дигән пионер лагеренда эшли башлый. Бу уку елында алтмышлап кеше белем ала, шәкертләрне Уфадагы Үзәк Диния нәзарәте җыя.

СССР таркалгач, элек җимерелгән мәчетләрне торгызу, яңа мәчет салу күренешләре бик тиз үсеш ала. Шуның белән бергә мәчетләргә, мөселман уку йортларына дини белемле мөгаллимнәрнең кирәклеге көнүзәк мәсьәләгә әйләнә. 1992 елның августында Татарстанда Диния Нәзарәте оештырыла. 1993 елның 20 августында Казанда Югары мөселман мәдрәсәсе «Мөхәммәдия» торгызыла. Ачылган көннән үк иң зур мөселман уку йортына әверелгән. Бу мәдрәсәдә беренчеләрдән булып хатын-кызлар өчен махсус бүлек, кичке һәм читтән торып укый торган бүлекләр ачыла. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: күп кенә мөселман уку йортлары юридик теркәлү узсалар да, эшләп китә алмыйлар. Мәсәлән, «Рамазан» мәчетендә югары мөселман уку йорты теркәлә. «Солтан» (Казан шәһәре) мәчете янындагы мәдрәсә дә берничә ел эшләп карый, әмма югары уку йорты буларак эшләп китә алмый. Аксубай, Түбән Кама,

Азнакай, Норлатта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең филиаллары теркәлә. Шулар арасында мөстәкыйль уку йорты буларак Норлат филиалы гына эшләп китә.



*Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе. 1990 нчы еллар*

90 нчы еллардан башлап Татарстан Диния нәзарәте тарафыннан һәм башка төбәкләрдәге иҗтимагый оешмалардан һәм мәдрәсәләрдән Төркиягә, Малайзиягә, Согут Гарәбстанына һәм башка гарәп илләренә шәкертләрне укырга җибәрү оештырыла.

1990 еллар ахырында барлык мөселман уку йортлары МДН юрисдикциясенә күчә. Бу чорда мәгариф системасы структурасында оптимизацияләү эшләре алып барыла. МДН мәдрәсәләрне берберсенә кушып зурайту юлын сайлый. ТР МДН мөфтие фәрманы белән 2000 елга Татарстанда дини уку йортларының төрле баскычтагы 8 мәдрәсәсе генә кала, шунда ук Россия ислам университеты, «Йолдыз», «Тәнзилә», «Ихлас», «Нуретдин», «Иман» мәдрәсәләрен кушу нәтиҗәсендә Яр Чаллы Югары мөселман мәдрәсәсе барлыкка килә. Әлмәттәге Р.Фәхретдин исемендәге ислам институты һәм Азнакайдагы мәдрәсә нигезендә Әлмәт мөселман урта белем бирү мәдрәсәсе барлыкка килә.

ТР МДН тарафыннан Казандагы «Мөхәммәдия», «Ислам дине кабул ителүгә 1000 ел» исемендәге, Түбән Камадагы «Рисалә», Буа һәм Норлат мәдрәсәләре үзләренең статусларына туры киләләр һәм үзгәртүдә мохтаҗлык юк дип табыла. Калган мәдрәсәләр башлангыч дини белем бирү мәктәпләре булып калалар һәм махсус лицензия

алмыйча гына якшәмбе мәктәпләре булып эшләүләрен дәвам итәләр. Бу уку йортларының типларын ачыкларга мөмкинлек бирә. Татарстанда 3 төрдәге уку йортлары: мәчетләр янында башлангыч мәктәп, урта (Яр Чаллыдагы, «Ак мәчет» мәдрәсәсе, Буа мәдрәсәсе, Әлмәттә Р.Фәхретдин мәдрәсәсе, Түбән Камадагы «Рисалә», Норлат мәдрәсәсе) һәм югары мәдрәсә «Мөхәммәдия», «Ислам дине кабул ителүгә 1000 ел» исемендәге мәдрәсә. Шул вакытта Россия ислам университеты формалаша башлый.

Татарстанда Югары мөселман уку йортының кирәклеге турындагы фикер 90 нчы еллар башында ук барлыкка килә. Татар лингвисты, мөселман җәмгыяте әгъзасы Вәлиәхмәт Содур Тәтештә Ислам Университеты оештырырга тырышып карый. Профессор У.Фәтхуллин тырышлыгы белән ачылган «Әл-Фатыйх» институты берничә ел эшли. Монда ислам дине буенча белгечләр әзерләргә тырышалар. Факультет деканы Госман хәзрәт Исхаков, укытучы мөгаллимнәре Фәрит хәзрәт Салман, Габделхак хәзрәт Саматов һ.б. була.

1998 елда Россиядә беренчеләрдән булып Югары һөнәри ислам уку йорты буларак Россия ислам университеты ачыла.

РИУның төп бурычы хәзерге көндә мөселман интеллигенциясе тәрбияләү, ислам теологиясе буенча белгечләр, югары квалификацияле тарих, хокук, тел, ислам иктисады буенча белгечләр әзерләү.

2007 елда Россия ислам университеты эшчәнлеге Россиядәге башка ислам уку йортлары арасында уңай билгеләнә һәм РФ мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан аттестацияләнә.

2009 елдан РИУ Дөнья ислам университетлары (FUIM) составына керә. 2010 елның 10 мартында РИУ юридик рәвештә ике уку йортына бүленә. Россия Ислам институты (РИИ) дәүләт мәгарифе стандартлары нигезендә (Теология), ә Казан ислам университеты дәүләт стандартлары белән каралмаган дини уку программасы нигезендә эшли башлый.

Бүгенге көндә РИИда Россиянең 30 төбәгеннән, шулай ук БДБ илләреннән килеп, 600 шәкерт белем ала. РИИ югары һәм урта һөнәри мөселман уку йортлары өчен методик һәм методологик үзәк булып тора. Теология факультеты «Теология», «Ислам», «Журналистика», «Лингвистика», «Ислам икътисады» кебек юнәлешләрне берләштерә. РИИ шәкертләре укуны тәмамлагач Россиянең күп мәчетләрендә имам-хатыйб булып хезмәт итәләр. Россия һәм БДБ илләрендә югары һәм урта һөнәри ислам уку йортларында укыталар, дини үзәкләрдә, дәүләт эшләрендә, гыйльми һәм эксперт оешмаларында эшлиләр.

2003 елдан ТР МДН җитәкчелеге тарафыннан оештырылган Коръән хафизлар (Коръәнне яттан белүче) әзерли торган уникаль үзәк эшли, РИУ структурасына керә.

Күп еллар укыту һәм системалы рәвештә кадрлар әзерләү белән беррәттән, республиканың һәр мәхәлләсендә эшләгән муллаларның дини белемнәрен күтәрү проблемасы көнүзәктә тора. 1998 елдан Яр Чаллыдагы «Ак мәчет» янында имамнарның белемен күтәрү курслары эшли.

2004 елны МДН приказы белән монда имамнарның белемен камилләштерү институты эшли башлый. 250 имам Татарстанның төрле җирләреннән килеп белемнәрен күтәрәләр. 2011 елда ТР мөселманнарының 5 нче чираттан тыш уздырылган съездының карары белән Казанда РИУ каршында имамнарның белемен күтәрү үзәге ачыла.

Бүгенге көндә «Мөхәммәдия» югары уку йортында дини һәм мәгариф оешмаларына белгечләр, шулай ук татар һәм гарәп телләре буенча тәрҗемәчеләр әзерләнә. Көндезге укуга 9,11 нче сыйныфны тәмамлаган егет-кызларны кабул итәләр. Укырга кабул итү имтихан нәтиҗәләре буенча. Көндезге бүлектә мәдрәсә шәкертләре 5 ел укыйлар. Беренче ике курста кызлар һәм егетләр аерым укыйлар. Кызларга 1 курста «Хатын-кыз исламда» дигән махсус курс укытыла. Монда хатын-кызларның тәртипләре, киеме, гаилә тормышында тоткан урыны һәм балаларда ислам рухын тәрбияләү мәсьәләләре буенча белем бирелә. Аларга нигездә Татарстан укытучылары, шулай ук гарәп илләренннән килгән мөгаллимнәр (Иордания, Египет, Судан, Сирия, Ливан) белем бирәләр.

Укыту программасында ислам нигезләре, мәдәният һәм башка фәннәр бар. «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе, 100 еллар элек кебек, татар мөселман зыялыларын үстерүче, тәрбияләүче белем учагы булып кала бирә.



*Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкертләре*

## 1.7. Татар педагогикасы өлкәсендә фәнни эзләнүләр

1990–2000 еллар – татар педагогикасы фәнендә милли күтәренкелек, укыту һәм тәрбия проблемаларын милли күзлектән чыгып өйрәнү чоры. Туган телдә белем һәм тәрбия бирү, татар телен һәм татар телендә укыту – бу чорның асылын билгеләүче төп үзенчәлекләр. Татар педагогик фикере үсешендәге әлеге юнәлешләр, әлбәттә, фәнни тикшеренүләрдә дә шактый киң чагылыш таба.

Фәнни эзләнүләрдә аеруча киң үсеш алган юнәлешләрнең берсе – халык педагогикасы, этнопедагогика мәсьәләләре. Тәрбия өлкәсендәге милли кыйммәтләрне кире кагу белән билгеләнгән совет чорында татар халкының күп гасырлар дәвамында туплап, буыннан-буынга тапшырылып килгән бай мирасы дәвамчылык чылбырыннан төшеп кала, бары тик бик аз өлеше генә фольклор үрнәкләре буларак тел-әдәбият дәресләрендә өйрәнелә. Әмма аларны гомумән укыту-тәрбия барышында файдалану мөмкинлеге түбән була. Татар мәктәпләрендә белем алмаган укучылар милли кыйммәтләр белән танышу мөмкинлегеннән мәхрүм ителә. Совет чорында милли тәрбия нигездә гаиләдә алып барыла. XX гасыр ахырында, милли үзаң күтәрелү белән белән бәйле рәвештә, бу юнәлешкә игътибар арта, халык педагогикасының милли тәрбия бирүдә иң нәтиҗәле чараларның берсе икәнлеге галимнәр тарафыннан раслана[165]. Халык педагогикасының төп өлешләреннән берсе булган халык авыз иҗаты әсәрләрен укыту-тәрбия барышында файдалануга зуррак әһәмият бирелә, аларның акыл, әхлак, физик, хезмәт тәрбиясендәге рольләре билгеләнә.

Әхлак тәрбиясе – яшь буынны тәрбияләүдә иң мөһим факторларның берсе. Бу фикер татар галимнәренең хезмәтләрендә дә чагылыш таба. «Гасырлар дәвамында тупланып, буыннан-буынга бирелеп килгән гомумкешелек сыйфатларын бер-беребезгә карата булган мөнәсәбәтләрдә, көндәлек гамәлләребездә кулланышка кертми торып, прогресска ирешеп булмый», – дип яза В.Казыйханов әхлак тәрбиясенең әһәмиятен ассызыклап[166]. Әдәплелек тәрбияләү татар

---

[165] Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 1997. – 175 б.; Җәләлиев Ш.Ш. Милли тәрбия нигезләре (исламдагы һәм татар халык педагогикасындагы рухи-әхлакый потенциал – милли тәрбиянең нигезе). – Казан: Алма-Лит, 2003. – 174 б. һ.б.

[166] Казыйханов В. Әхлаклы булу – сәламәт яшәү рәвеше ул // Фахретдиновские чтения. – Н.Новгород: Медина, 2009. – 18 б.

педагоглары тарафыннан укыту-тәрбиядә төп кыйммәтләрнең берсе буларак тәкъдим ителә[167].

Халыкның гореф-гадәтләрен һәм традицияләрен, бәйрәм һәм йолаларын өйрәнү, торгызу аша милләтебезнең рухи-әхлакый идеалларын, яшәү фәлсәфәсен чагылдыру омтылышы – бу чорның үзенчәлекләреннән берсе. Яшь буынга милли йолалар һәм гореф-гадәтләр, халык традицияләре нигезендә тәрбия бирү мәсьәләләре күп кенә тикшеренүләрнең үзәгендә тора[168]. Мәктәп укучылары өчен язылган методик әсбапларда нәсел-нәсәпне, тамырларны, шәҗәрәне өйрәнү мөһимлегенә басым ясала[169].

Татар халкының агрономик, метеорологик, астрономик белемнәрен, аларның тарихын өйрәнү генә түгел, мөмкин булган кадәр аларны укытуда файдалану кирәклеге дә ассызыклана[170]. Бу чорда төрле предметларны укытуда халык тәҗрибәсенә таянуның нәтиҗәлелеге раслана[171]. «Татар халык педагогикасы» махсус предмет буларак югары уку йортларында өйрәнелә башлый, дәреслекләр һәм уку кулланмалары языла[172].

XX гасырның 90 нчы елларында татар мәгарифе тарихын өйрәнү, педагогик мирасны барлау һәм өйрәнү мәсьәләләре татар педагогикасы фәнендә иң актуаль юнәлешләрнең берсенә әверелә. 90 нчы еллар – татар педагогик фикере үсешендә гасырлар дәвамында тупланып килгән милли-мәдәни һәм мәгариф өлкәсендәге мирасны бар-

---

[167] Низамов А.М. Әдәплелек дәресләре программасы: 5–11 сыйныфлар. – Казан: Мәгариф, 1995. – 23 б.; Низамов А.М. Әдәплелек кагыйдәләре. Укучылар, педагоглар һәм эти-әниләр өчен кулланма. – Казан: Мастер-Лайн, 1999. – 38 б. һ.б.

[168] Низамов Р.А. Халык педагогикасы – тәрбия нигезе // Мәгариф. – 1992. – № 9. –.5 б.

[169] Биктимирова Т.Ә. Минем шәҗәрәм... – Казан: Мәгариф, 1999. – 32 б.; Ислаев Ф.Г. Шәҗәрәдә – ил тарихы // Мәгариф. – 2007. – № 9. – 65–66 б. һ.б.

[170] Беркутов В. Развитие математического образования у булгаро-татар. – Казань: Дом печати, 1997. – 175 с.

[171] Сабирова Ф. Ай булмаса, йолдыз бар: Методик кулланма. – Яр Чаллы, 1995. – 68 б., Сабирова Ф. Идел суы илле батман (Математика дәресләрендә фольклор әсәрләрен файдалану) // Мәгариф. – 1997. – № 5. – 63–65 б.; Хәлиуллин Р. Химия дәресләрендә халык авыз иҗаты // Мәгариф. – 1996. – № 7. – 40–42 б.; Хөсәенов Җ. Халык белемнәрен экологик мәдәният тәрбияләүдә файдалану // Фән һәм мәктәп. – 2002. – № 4. – 28–29 б. һ.б.

[172] Шәймәрданов Р.Х. Татар халык педагогикасы: Уку ярдәмлеге. – Алабуга, 1994. – 22 б.; Шәймәрданов Р.Х., Сибгатуллин Р.Г., Сибгатуллина Ә.Т. Татар халык педагогикасы. – Яр Чаллы: КамАЗ, 1997. – 137 б.

лау һәм өйрәнүгә игътибар арту, моңарчы өйрәнелмәгән, совет чорында онытылуга дучар ителгән шәхесләр, аларның педагогик хезмәтләрен кире кайтару, яңача, яңа күзлектән чыгып өйрәнү, фикерләү чоры буларак билгеле.

Бик борынгы заманнарга барып тоташкан мирасыбыз – төрки чорлардан ук билгеле ядкарьләребезне, Урта гасырлар, XIII–XX гасырлар башында иҗат ителгән әдәби әсәрләрне җентекләп өйрәнү һәм аларның тәрбияви кыйммәтләрен билгеләүгә багышланган фәнни хезмәтләр барлыкка килә. Әлеге чорда урта гасырларда иҗат иткән төрки-татар әдипләренең әсәрләре әдәбият фәне күзлегеннән чыгып кына түгел, педагогик фикер чыганагы буларак та тирәнтен өйрәнелә, шуның нәтиҗәсе булып, гыйльми хезмәтләр, диссертацияләр языла, шул заманнарда татарларда мәгариф һәм педагогик фикер үсешенең төп тенденцияләре билгеләнә. Бу юнәлеш буенча эшләгән галимнәрдән Р.Ш. Маликов, А.Мөхәммәтшин һ.б.ны атарга мөмкин[173].

Татар мәгарифе тарихының иң мөһим һәм иң зур өлешләреннән берсе – бик борынгы чорларда ук барлыкка килгән һәм зур тарихка ия булган дини белем һәм тәрбия системасы. Халыкка гыйлем таратуда төп рольне башкарган, гасырлар дәвамында милләтнең рухи лидерлары булган, аның мәдәни һәм милли кыйммәтләрен саклап килгән дин эшлекләре, мөгаллимнәр һәм мөдәррисләрнең эшчәнлеген фәнни нигездә өйрәнү әлеге чор татар педагогик фикере үсешендәге төп юнәлешләрнең берсе. Бу чорда татарларда мәктәп-мәдрәсәләр эшчәнлекләрен яктырткан фәнни хезмәтләр языла[174], җәдитчелек проблемасы иҗтимагый һәм педагогик фикер үсешендә мөһим урын тоткан күренеш буларак өйрәнелә, җәдитчеләрнең бай мирасы

---

[173] Маликов Р.Ш. Педагогическая мысль Ю.Баласагуни. – Казань: КГПУ, 1999. – 80 с.; Маликов Р.Ш. Педагогические идеи булгарского поэта Кул Гали. – Казань: КГПУ, 1999. – 112 с.; Малик Р. Гуманист педагог Мухаммадьяр. – Казань, 1999; Мухаметшин А.Г. История становления и развития педагогической мысли в Волжской Булгарии (VIII–XIV вв.). – Казань: Изд-во КГУ, 2005. – 115 с.; Маликов Р.Ш. Становление и развитие тюрко-татарской гуманистической педагогической мысли Средневековья: автореф. дис. … докт. пед. наук. – Казань, 2000; Мухаметшин А. Г. Педагогическая мысль булгар-татар в Казанском крае: VIII – начало XX в.. – М.: НИИ школьных технологий, 2006. – 232 с.; Мухаметшин А. Г. Идейно-политические основы развития педагогической мысли булгар-татар в средние века (XV–XVI вв.). – Набережные Челны: НГПИ, 2008. – 82 с. һ.б.

[174] Амирханов Р.У. Система конфессионального образования у татар // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: История и современность. – Казань: Мастер-Лайн, 2002. – С. 140–157.

яктыртыла[175]. Шул ук вакытта совет чорында тискәре яктан гына тасвирланган кадимчелек юнәлешенең нигезләре яңа күзлектән чыгып өйрәнелә, аның уңышлы яклары, татар мәгарифе һәм педагогик фикере үсешендәге урыны билгеләнә[176].

Бу елларда мәгариф системасы һәрьяклап, комплекслы рәвештә өйрәнелә. Гасырлар дәвамында яшәп килгән, татар халкын аң-белемле итүдә зур роль башкарган мәктәп-мәдрәсәләр тарихы, алардагы укыту һәм тәрбия эшенең куелышы (эчтәлеге), дәреслек һәм методик әсбаплар, аерым педагогларның тормышы һәм эшчәнлеге тикшерелә, яктыртыла[177]. Озак еллар дәвамында танылмаган, күрелмәгән (күрергә теләнмәгән), бары тик совет хөкүмәте һәм компартия эшчәнлеге буларак карап киленгән сәхифәләр – татарларның башка төрки халыкларга аң-белем таратудагы хезмәтләрен (мәктәпләр ачу, белем бирү, дәреслекләр төзү һ.б.) яктырту – бу чорда татар педагогикасындагы иң әһәмиятле юнәлешләрнең берсенә әверелә[178]. Татар педагогикасы тарихын, аның төрле этапларын, үсеш үзенчәлекләрен күрсәткән хезмәтләрдән Я.И.Ханбиков, З.Т.Шәрәфетдинов, Ә.Н.Хуҗиәхмәтов, Р.Х.Шәймәрданов һ.б. галимнәрнең китапларын атарга мөмкин[179].

---

[175] Мухаметшин Р.М. Система образования у татар в начале XX века: состояние и проблемы // Медресе «Мухаммадия»: история и современность. – Казань: Иман, 2003. – С. 37–49; Юзеев А.Н. Татарская религиозно-реформаторская мысль. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – С. 76–77.

[176] Мухаметзянова Д.С. Кадимистская система образования в историческом и педагогическом контекстах. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2008. – 216 с.

[177] Гимазова Р.А. Просветительская деятельность Нигматуллиных-Буби. – Казань: Печатный Двор, 2004. – 220 с.; Махмутова А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – 254 с.

[178] Биктимирова Т.Ә. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. – Казан: Печатный двор, 2002. – 140 б.; Биктимирова Т.Ә. Урта Азия республикалары мәгарифен оештыруда татар хатын-кызларының булышлыгы // Тюрки Волжско-Уральского региона. – Берлин, 2006. – 63–66 б.

[179] Ханбиков Я.И., Шарафутдинов З.Т. История педагогики Татарстана. – Казань: КГПУ, 1998. – 306 с.; Шарафутдинов З.Т. Педагогическое пространство татарского народа. – Казань: КГПУ, 2000. – 180 с.; Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Мәгърифәт йолдызлыгы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 287 б.; Шәймәрданов Р.Х., Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Татар милли педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б. һ.б.



*Ә.Хуҗиәхмәтов*



*Р.Шәймәрданов*

Күпсанлы тикшеренүләр нәтиҗәсендә татар мәгарифе үсешендә эз калдырган, моңарчы исемнәре билгеле булмаган яки аз билгеле булган педагогларның эшчәнлеге барлана. Шактый гына татар дин эшлеклеләренең, мәдрәсә мөгаллимнәренең педагогик тәҗрибәсе, совет чорында җәмгыятькә зыян сала дип табылган рухани мирасы, фәнни китаплары (рисалә-трактатлары) һәм дәреслекләре барлана, өйрәнелә, фәнни әйләнешкә кертелә, укыту-тәрбия барышында файдалану мөмкинлеге билгеләнә[180]. Билгеле шәхесләр белән беррәттән, моңарчы аз билгеле булган яисә бөтенләй югалуга дучар булган, хезмәтләре юк ителгән педагогларга багышланган хезмәтләр языла, аларның тормышына һәм эшчәнлегенә җентекле анализ ясала. Бу җәһәттән, ТФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Милли мәгариф тарихы һәм теориясе үзәгендә әзерләнгән ике томлык «Татар педагогик фикере антологиясе»нең[181] әһәмияте зур. Анда борынгы төрки чордан алып бүгенге көннәргә кадәр татар мәга-

[180] Бигиев Муса. Избранные труды. В двух томах. Т. 1 / Сост. А.Г.Хайрутдинов – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 336 с.; Бубый Г. Истибдад белән гыйлем // Гасылар авазы = Эхо веков. – 2001. – № 3 / 4. – 196–201 б.; Гимазова Р.А. Проветительская деятельность Нигматуллиных-Буби. – Казань: Печатный двор, 2004. – 220 с.; Габәши Х. Мөфассал тарихе кауме төрки // Мирас. – 1994. – № 3. – 106–107 б.; Камалов Т. Зыя Камали. – Казан: Иман, 1997. – 53 б.; Мәрҗани Ш. Мөстәфад ел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар / Төз. Ә.Хәйри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 б.; Мортазина Л.Р. Татар авыллары мәгарифе: Бәхтияр әл-Мәмдәли һәм Бәхтияровлар нәселе. – Казан: Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2016. – 92 б. һ.б.

[181] Татар педагогик фикере антологиясе. Ике томда / Ред. Ф.М. Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. 1 т. (борынгы төрки чор – XX гасыр башы). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 407 б.; 2 т. (XX гасыр – XXI гасыр башы). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 486 б.




рифе үсеше тарихы барланган, педагогик фикер тарихының үзенчәлекләре һәм төп юнәлешләре билгеләнгән. Бу – соңгы чорда дөнья күргән, татар педагогик фикерен үсештә һәм бербөтен итеп күзалларга мөмкинлек бирүче мөһим хезмәтләрнең берсе.

XX гасыр ахыры – дини белем һәм тәрбия өлкәсендә зур алгарыш чоры. Педагогик фикер үсешендә дә дини тәрбия мәсьәләләре алгы планга чыга. Бу чорда татар галимнәренең хезмәтләрендә исламның әхлакый кыйммәтләренә игътибар бирелә, яшь буынны әлеге кыйммәтләр нигезендә тәрбияләү мөмкинлекләре билгеләнә. Бу юнәлеш бигрәк тә Ш.Җәләлиев, В.Казыйханов, Җ.Фазлыев хезмәтләрендә киң чагылыш таба[182].

1990–2005 елларда татар педагогикасы үсешендә шактый киң чагылыш тапкан проблемаларның тагын берсе – гуманлаштыру, гуманитарлаштыру, ягъни шәхескә, аның рухи дөньясына мөрәҗәгать итү. Бу нисбәттән Г.В.Мөхәммәтҗанова, Җ.Г.Нигъмәтов хезмәтләрен атау уңышлы булыр[183]. Гомумкешелек туплаган традицияләргә гуманистик караш формалаштыруда милли хәзинәләрнең ролен билгеләп, Җ.Г.Нигъмәтов: «балаларда гуманлы мөнәсәбәтләр формалаштыру аларны чын халык гуманистик традицияләренә


*Ш.Җәләлиев*

[182] Фазлыев Җ. Урта мәктәпләр өчен әхлак дәресләре укыту буенча ярдәмлек. – Казан: Иман, 2001. – 37 б.; Фазлыев Җ. Җәлил хәзрәт дәресләре. – Казан: Идел-Пресс, 2006. – 189 б.; Казыйханов В. Иман дәресләре. – Яр Чаллы, 1997. – 80 б.

[183] Нигъмәтов Җ.Г. Этнопедагогика: халыкчанлык һәм гуманлылык. – Казан: Мәгариф, 2002. – 159 б.; Нигматов З.Г. Гуманистические традиции педагогики. – Казань: ТаРИХ, 2003. – 271 с.; Мухаметзянова Г.В. Гуманизация и гуманитаризация средней и высшей технической школы. – Казань: ИСПО РАО, 1996. – 328 с. һ.б.

актив катнаштырудан башка мөмкин түгел. Традицияләр – тәрбия процессында гуманизм принцибын тормышка ашыруның мөһим чарасы, балаларның гуманлыгын формалаштыруда зур әһәмияткә ия. Коллективта гуманлы трдицияләр никадәр нык һәм киң җәелсә, аның әгъзаларына да шулкадәр тизрәк гуманлы тәртип гадәтләре формалаша, тәрбия процессы да уңышлы бара», – дип яза[184]. Өлкәннәргә, хатын-кызга ихтирам, балаларга ярдәм итү, башкаларга карата кайгыртучан караш тәрбияләү, киң күңеллелек, кунакчыллык кебек борынгыдан килгән милли кыйммәтләр бүгенге көндә гуманлылык тәрбияләүдә төп чаралар буларак карала[185].

Соңгы чорда дөнья күләмендә күзәтелгән экологик проблемалар тәрбия өлкәсендә дә табигатьне саклау, аңа сакчыл караш булдыруга игътибарны юнәлтү мөһимлеген китереп чыгара. Бу фикерләр Россиядә, шулай ук аның төбәкләрендә экологик тәрбияне оештыру зарурлыгына китерә. Татарстан табигатен, аның чисталыгын саклау мәсьәләләре фәнни эзләнүләрдә иң актуаль темаларның берсенә әверелә[186]. Бу проблеманы өйрәнгән И.Т.Гайсин фикеренчә, укучыларны әхлак таләпләрен белергә, табигатькә хөрмәт белән карарга өйрәтү мөһим; экологик юнәлешне галим-биологларның биографияләренә кагылышлы материаллар аша алып барырга мөмкин[187].

Милли проблемалар белән беррәттән, 1990–2005 елларда татар педагогик фикере үсешендә Россиядә мәгариф үсешен билгеләгән гомуми тенденцияләр, яңа педагогик технологияләр һәм аларны уку-укыту процессында куллану мәсьәләләре дә чагылыш таба. Бу төрле предметларны укытуда компьютер технологияләрен куллану, үстерелешле укыту һ.б да аеруча ачык күренә. Татар балаларына ана телен өйрәтүдә, мәсәлән, Ә.З.Рәхимовның иҗади үсеш технологиясен кулллануның укучының үзүсешен тәэмин итүе, коммуникатив сәләтен үстерергә ярдәм итүе раслана[188].

---

184 Нигъмәтов Җ.Г. Этнопедагогика: халыкчанлык һәм гуманлылык. – Казан: Мәгариф, 2002. – 3, 73 б.

185 Шунда ук. – 73 б.

186 Гайсин И.Т. Экология һәм әхлак // Мәгариф. – 1994. – № 6. – 35–37 б.; Гайсин И.Т. Эколого-нравственное воспитание учащихся в процессе изучения естественнонаучных дисциплин: дис. ... канд. пед. наук. – Казань: 1995. – 223 с.; Гайсин И.Т., Хусаинов З.А., Галимов Ш.Ш. География и экология Республики Татарстан. – Казань: КГПУ, 2003. – 204 с.

187 Гайсин И.Т. Экология һәм әхлак // Мәгариф. – 1994. – № 6. – 36 б.

188 Җамалетдинова З. Иҗади үсеш технологиясе // Мәгариф. – 2003. – № 8. – 56–57 б.

Гомумән алганда, бу чорда татар педагогикасы фәнендә төп эзләнүләр укыту-тәрбиядә милли үзенчәлекләрне, милли кыйммәтләрне куллану, бер үк вакытта дөньякүләм педагогик киңлеккә юнәлеш алу белән билгеләнә.

## 2. Хәзерге чорда милли мәгариф (2005 елдан соң)

Татар мәгарифе Россия халыклары милли мәгарифе белән тыгыз бәйләнгән һәм бер үк хокукый нигездә үсеш ала. Хәзерге вакытта Россиядә милли мәгариф проблемасы педагоглар җәмәгатьчелеге тарафыннан актив рәвештә тикшерелә.

РФ милли мәгариф сәясәте проблемаларын чишү хәзерге милли мәгариф учреждениеләре эшчәнлегенә анализ белән дә тыгыз бәйләнгән. Бу тәҗрибәне гомумиләштерү күпмәдәниятле җәмгыятьтә милли мәгарифне үстерүнең оптималь юлларын эзләү өчен кирәк. Беренче чиратта, анализ милли мәгарифнең бөтен үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирәчәк. Икенчедән, милли мәгариф учреждениеләренең статусын билгеләүче хокукый норматив документлар булмаган шартларда, галимнәрнең милли мәктәпләрнең төрләрен билгеләүне законлаштыру буенча тәкъдимнәрен күзалларга мөмкин булачак.

Россия халыкларының милли мәгарифенә бердәм һәм системалаштырылган фикер булмавы милли мәгарифне оештыру эшендә дә күренә. Хәзерге көнгә кадәр законда гына түгел, теориядә дә милли мәгариф учреждениеләрен билгеләүче бердәм критерийлар юк. Мәсәлән, Л.Г.Лазарева[189] хезмәтендә милли мәгариф учреждениеләренә классификация ясау өчен аларның милли составы тәкъдим ителә:

– моноэтник составлы (бер милләт балалары 70%тан күбрәк);
– составында 40–70% бер милләт балалары булган полиэтник;

[189] Актуальные проблемы развития национальных образовательных учреждений коренных малочисленных народов Ханты-Мансийского автономного округа / Под ред. Л.Г.Лазаревой. – Ханты-Мансийск: ГУО. Комитет по делам малочисленных народов Севера администрации ХМАО, 1996. – С. 21–28.

– составында бер милләт тә өстенлек алмаган полиэтник мәктәпләр.

Уку-укыту процессын алып бару өчен автор һәр группа мәктәп өчен аерым методология эшләргә тәкъдим итә.

Г.Н.Волков[190] тәкъдим иткән милли мәгариф учреждениеләре классификациясенең нигезендә укыту теле һәм программаларның эчтәлеге ята. Автор тәкъдим иткән 7 тип милли мәктәп татар милли мәгарифендә бар.

1. Бөтен предметлар туган телдә укытылган мәктәпләр (Татарстан һәм Башкорстан).

2. 8 нче сыйныфка кадәр туган телдә укыткан мәктәпләр (Чувашстан һәм Ульяновск өлкәсе).

3. Башлангыч сыйныфка кадәр туган телдә укытучы мәктәпләр (Европа өлешендә урнашкан милли мәктәпләр).

4. 1–2 нче сыйныфларда туган телдә укучы мәктәпләр (Мордовия).

5. Туган телне предмет буларак укытучы рус телендә эшләүче мәктәпләр (күпчелек төбәкләр).

6. Туган тел факультатив рәвештә укытылган шәһәр һәм поселок мәктәпләре (күпчелек төбәкләр).

7. Туган тел укыту-тәрбия эшендә кулланылмый диярлек бермилләтле (рус булмаган) мәктәпләр (бик күп республикалардан читтә яшәүче милләтләр мәктәпләре).

Мәсәлән, Новосибирск өлкә татар үзәге, башка татар оешмалары белән бергә татар мәдәниятен саклау һәм үстерү максатын куя, ләкин аны үтәү милли мәгарифне үстерми һәм телне өйрәнми мөмкин түгел. Үзәк мәгълүматлары буенча Новосибирск татар яшьләре туган телләрендә авырлык белән сөйләшә, үз мәдәниятен, татар телендә укый-яза белми, шуңа күрә Казан һәм Тубыл югары уку йортларында татарча укый алмый[191].

---

[190] Волков Г.Н. Основные пути развития национальной школы и ее современные проблемы // Проблемы двуязычая в национальной школе. – Ижевск: Удмуртия, 1989. – С. 33–34.

[191] Тихомирова Р.Ш. Роль Новосибирского областного Татарского культурного центра в деле сохранения и развития национального образования // Актуальные вопросы национального образования: поиски, проблемы, решения: Тезисы докладов и тематические материалы V традиционной ежегодной научно-практической конференции «Культура и образование национальных обществ Сибири». – Новосибирск, 2002. – С. 23–25.

Хәзерге заман милли мәгарифендәге педагогик концепцияләргә С.Л.Зубарева[192], Л.Ю.Пичкуренко[193] ясаган анализ нигезендә, хәзер укыту процессында милли мәктәптә 3 төп юнәлеш барлыкка килде дияргә мөмкин: яңарыш (И.Г.Гончаров[194], Е.П.Белозерцев[195], В.Ганичев[196]; поликультуралы (Д.Бэнкс[197], Г.Д.Дмитриев[198], О.В.Гукаленко[199]); методологик (Е.В.Бондаревская[200]).

Бу юнәлешләр бер-берсенә каршы килмиләр, бер-берсенә өстәмә булып торалар. Аларны үсеш этаплары дип карап була. Һәр концепция бер-берсенә нигезләнә һәм үсеш бирә. Милли мәктәпкә булган бу карашлар киләчәк XXI гасыр мәктәбенең моделен күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Яңарыш концепциясе XIX–XX гасыр педагогикасына нигезләнә һәм халыкның күпгасырлы тәрбия тәҗрибәсен, мәдәниятен исәпкә ала, халык педагогикасы һәм дин нигезләрен куллана.

Поликультуралы мәгариф халыклар арасында үзара бәйләнешне күз алдында тота һәм үзара аңлашып яшәү һәм теләктәшлек хисләре тәрбияли. Ул төрле мәдәниятләрнең үзара бәйләнешенә, мәдәни кыйммәтләрне үзләштерүгә һәм башка мәдәни кыйммәтләрне кабул итүне тәрбияләүгә нигезләнгән. Россия башка күп илләр кебек күп-

---

[192] Зубарева С.Л. Развитие образования народов Севера в Ханты-Мансийском автономном округе (1990-е гг. – начало XXI века). – Сургут: Изд-во СГПИ, 2003. – С. 32–34.

[193] Пичкуренко Л.Ю. Развитие педагогической мысли в России и Германии в девятнадцатом-двадцатом веках в аспекте проблемы национального образования: дис. ... канд. пед. наук. – Саратов, 2001. – С. 145.

[194] Гончаров Н.К. Педагогическая система К.Д.Ушинского. – М., 1974.

[195] Белозерцев Е. П. О национально-государственном образовании в России // Педагогика. – 1998. – № 3. – С. 30–35.

[196] Ганичев В.Н. Не быть иностранцами «посреди своей Родины» // Народное образование. – 1996. – № 6.

[197] Бэнкс Д. Мультикультурное образование: цели и измерения // Новые ценности образования. – 1996. – № 4.

[198] Дмитриев Г.Д. Многокультурность как дидактический принцип // Педагогика. – 2000. – № 10.

[199] Гукаленко О.В. Теоретико-методологические основы педагогической поддержки и защиты учащихся-мигрантов в поликультурном образовательном пространстве. – Тирасполь, 2000.

[200] Бондаревская Е.В. Теория и практика личностно-ориентированного образования. – Ростов-на-Дону, 2000.

милләтле җәмгыятьне берләштерә, шуңа күрә илне саклау өчен халыкларның толерантлы яшәешен тәэмин итәргә кирәк.

Методологик юнәлеш, янарыш юнәлешеннән аермалы буларак, мәдәни мирасны гына өйрәнми, уку процессында мәдәнияткә үсеш бирү юлларын да күрсәтә. Мондый тәрбия уку процессы белән бербөтен процесс булып бара. Поликультуралы мәгарифтән аермалы буларак, методологик юнәлешнең нигезен бердәм гуманитар мохит тәшкил итә. Уку процессында гуманитар дисциплиналар төрле мәдәният мохитен тудыралар.

Хәзерге заманда Россиядә яңарыш тибындагы милли мәктәпләр күп таралган. Поликультуралы мәгариф узган гасырның 80 нче елларында Көнбатыш Европа илләрендә барлыкка килә. Соңгы вакыттагы Россиядәге үзгәрешләрдән соң, поликультуралы мәгариф безнең илебездә дә үсеш алды[201]. Әлегә ул методологик юнәлеш буларак, теоретик нигезләрне билгеләү юнәлешендә тормышка ашырыла.

Шулай итеп, Россиядә соңгы елларда милли мәгарифнең теоретик нигезләре барлыкка килде һәм бу юнәлештә практик эш башланды. 1990–2007 елларда Татарстанда түбәндәге практик эшләр эшләнде:

1) икетеллелек һәм күпмәдәниятлелек шартларында гуманитар белемнең эчтәлеге булдырылды;

2) Республика милли мәгарифенең норматив-хокукый нигезләре эшләнде;

3) гомумроссия белем стандартларының федераль һәм төбәк компонентларына кергән гуманитар предметларның эчтәлеге берберсенә яраклаштырылды;

4) һәркемгә туган телдә түләүсез белем бирү дәүләт гарантияләрен тәэмин итү буенча оештыру – идарә механизмнары булдырылды;

5) милли мәгариф кадрлары әзерләү, квалификацияләрен күтәрү системалары оештырылды.

Шулай да, федераль кануннарның үзгәрүе кайбер яңа проблемаларны тудырды. 2007 елның 1 декабрендә 309-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә укыту программаларындагы милли-төбәк компоненты гамәлдән чыгарылды. Мәгариф белән идарәнең региональ органнарының уку планнары, төбәкләрнең программаларын

---

[201] Лотфуллин М.В. Россия шартларында милли мәгарифнең үсеш юнәлешләре // Чын мирас. – 2013. – № 8. – 26–29 б.

һәм дәреслекләрен әзерләү һәм бастырып чыгару вәкаләтләре юкка чыгарылды. 309-ФЗ законы белән мәгариф учреждениеләре эшчәнлегенә дә, аерым алганда, дәреслекләр сайлау һәм тәрбия эшен оештыруга, күп чикләүләр кертелде. Татарстанның укыту планнарыннан Татарстан тарихы, Татарстан географиясе кебек предметлар төшереп калдырылды. Ә бит укучыларны әхлаклы, патриотик рухлы итеп тәрбияләүдә, илнең булдыклы гражданы итеп формалаштыруда бу фәннәрнең әһәмияте гаять зур һәм мөһим. 15 ел дәвамында татар халкы һәм Татарстан тарихы аерым предмет буларак укытылса, соңгы елларда укыту программаларында аны өйрәнүгә сәгатьләр саны кыскартылды һәм ул Россия тарихы кысаларында төбәк компоненты дәрәҗәсендә генә укытыла башлады. Яңа стандартларда төбәк, милли тарихлар да өйрәнелергә тиеш дип язылган, әмма ул мәҗбүри итеп куелмаган, һәм аны өйрәнүнең юллары күрсәтелмәгән. Берничә ел дәвамында (2005–2007) ике телдә (татар һәм рус) бердәм республика имтиханын бирү каралган әлеге фән бүгенге көндә хәтта бердәм дәүләт имтиханнарының аерым сорауларында да чагылыш тапмый. Бу милли тарихны өйрәнүне икенче планга куюны аңлата.

Бүгенге көндә татар халкы һәм Татарстан тарихы курсы буенча шактый зур тәҗрибә тупланган. Заманча тарих концепцияләре һәм теорияләренә нигезләнгән, фәнни кулланышка яңа тарихи чыганаклар кергән дәреслекләр һәм методик әсбаплар чыгарылган (Солтанбеков Б.Ф., Иванов А.А., Галләмова Ә.Г., Гыйләҗев И.А., Исхаков Д.М., Заһидуллин И.К., Хуҗин Ф.Ш., Гибатдинов М.М., Кәбирова А.Ш. һ.б.).

2014 елдан тарих курсына тарихи-мәдәни стандарт кертелә. Анда ил халкының күпмилләтле һәм күпдинле булуына басым ясала, аларның бай рухи һәм матди кыйммәтләре, тарихы булуы ассызыклана. Тарихи-мәдәни стандарт концепциясе Россиядә чыгарыла торган бөтен дәреслекләргә шул яңа стандарт эчендә эшләү чикләрен билгеле. Яңа стандартны эшләүдә Татарстан галимнәре актив катнаша. Төп басым федераль дәреслекләрдә булган берьяклы карашны үзгәртүгә һәм объектив тарихны язуга юнәлдерелә, ягъни федераль дәрәҗәдә тарих укытуны үзгәртергә омтылыш ясала. Нәтиҗәдә Россиядә чыгарыла торган федераль дәреслекләрдә «татар-монгол изүе» төшенчәсе (хәзер ул рәсми рәвештә бу чорда рус кенәзлекләренең Алтын Урда ханнарына бәйлелеге дип алмаш-

тырылды) юкка чыга. Тарих укыту сәяси, хәрби, икътисади, сугышлар тарихыннан күбрәк мәдәният тарихына күчерелә.

Бүгенге көндә Татарстан республикасында Россия Федерациясенең тарихи-мәдәни стандарты нигезендә, татар халкы тарихын өйрәтү буенча концепция төзелде. Татар халкы һәм Татарстан тарихы буенча электрон кушымта, электрон атлас, аерым сайт материалларыннан торган укыту-методик комплект эшләнде. Хәзерге вакытта республика мәктәпләренең 1–4 нче сыйныфлары өчен «Татарстан мирасы»[202], 5–6 нчы сыйныф укучыларына борынгы заманнардан XVI гасыр ахырына кадәрге чорны алган «Татарстан һәм татар халкы тарихы» дигән уку кулланмасы[203] әзерләп чыгарылды. Әсбаплар рус һәм татар телләрендә бастырылган.

5–11 нче сыйныфларда Татар халкы һәм Татарстан тарихы курсы бүген Россия һәм гомуми тарих хисабына унар сәгать белән чикләнә. Социаль-гуманитар профильле сыйныфларда исә ул аерым фән буларак өйрәнелә ала. Шулай ук төп курсларга өстәмә рәвештә электив курс буларак укытылу мөмкинлеге бар (мәсәлән, «Күпмилләтле Россия – күпмилләтле Татарстан», «Тарихи-мәдәни мирас: Борынгы Болгар шәһәре һәм Зөя утрау-шәһәрчеге», «Шәһәр (район, авыл) тарихы»). Бай мирасы булган татар халкы тарихының этномәдәни эчтәлеккә генә кайтып калуы җәмгатьчелекнең һәм укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерә алмый. Соңгы вакытта уздырылган Татарстан һәм татар халкы буенча республика олимпиадалары (2015 елдан) нәтиҗәләре, укучыларның милли тарих буенча белемнәренең түбән дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Бу әлеге предметның уку планында булмавы белән аңлатыла.

---

[202] Татарстан мирасы. 1 сыйныф: Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Төз. М.М. Гибатдинов, Л.Р. Мортазина. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2016. – 80 б.; Татарстан мирасы. 2 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Төз. М.М. Гибатдинов, Л.Р. Мортазина. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2016. – 80 б.; Татарстан мирасы. 3 сыйныф: татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Төз. М.М. Гибатдинов, Л.Р. Мортазина. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2016. – 112 б.

[203] Татарстан һәм татар халкы тарихы борынгы заманнардан XVI гасыр ахырына кадәр. 5–6 сыйныфлар: Татар телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы / Ф.Ш. Хуҗин, В.И. Пискарев, А.Р. Мөхәммәдиев, И.М. Миргалиев, М.М. Гибатдинов. – Казан: Татар балалар нәшрияты, 2016. – 128 б.










*Татар халкы һәм Татарстан тарихыннан милли-төбәк компонентлы яңа дәресләкләр. 2005–2012 еллар*













*Яңа буын дәреслекләре*

309-ФЗ законы нигезендә дәреслекләр исемлеген төзү федераль үзәккә бирелде. Хәзер Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән яки рөхсәт бирелгән дәреслекләр генә кулланылырга мөмкин.

Укыту-тәрбия процессында Федераль исемлеккә кертелгән нәшриятлар чыгарган методик әсбаплар гына кулланыла ала. Татар теле һәм әдәбияты дәреслекләренең Федераль исемлеккә 5 елдан артык кертелми торуы Россия төбәкләрендә татар телен туган тел буларак укытуның мәктәп укыту планының төп өлешеннән төшеп калуына китерде.

309-ФЗ законы нигезендә укыту-тәрбия процессы укытуның федераль дәүләт стандартлары нигезендә оештырыла, бу стандартларны эшләү һәм раслау федерация хөкүмәтенә тапшырылган. Закон нигезендә стандартлар 10 елга бер үзгәртелергә мөмкин.

2009 елдан бирле белем бирүнең яңа федераль дәүләт стандартларын эшләү бара[204]. Стандарт белем үзләштерүгә, уку-укыту шартларына, тәрбия нәтиҗәләренә таләпләр булып кабул ителә. Элек эшләнгән стандартлардан аермалы буларак, яңа стандарт Европага ияреп, һәр белем циклы буенча компетенцияләр формасында бирелә. Бу компетенцияләр «Европа Советы һәм Парламенты тәкъдимнәрендә» (2006 ел, 18 декабрь, № 2006/692/ЕС) аңлатып бирелә. Аларны 2 төркемгә бүлеп була: гомуми (универсаль, төп, һөнәрдән тыш) һәм махсус (һөнәри). Гомуми төркемгә 8 төп компетенция керә, шулар арасында беренче урында туган тел белү компетенциясе тора. Еврокомиссия тәкъдимнәре буенча Болонья процессында катнашучы илләрдә балалар бакчасыннан алып, югары белемнән соң укуга кадәр туган телдә аралаша алу иң мөһим һәм беренче компетенция дип санала. Россиядә яңа стандартта туган тел белү компетенциясе дәүләт теле буларак рус телен белү компетенциясенә алыштырылган.

Шулай да белем бирүнең федераль дәүләт стандартлары (БФДС) нигезендә барлык Россия гражданнарының телләрен һәм мәдәниятен саклауны тәэмин итү татар педагогларының беренче

---

[204] Постановление Правительства Российской Федерации от 24 февраля 2009 г. N 142 «Об утверждении Правил разработки и утверждения федеральных государственных образовательных стандартов» (Собрание законодательства Российской Федерации, 2009, N 9, ст. 1110). Утратило силу с 1 сентября 2013 г.

бурычы булып тора. Татарстанда тупланган тәҗрибә бу мөһим эштә ярдәм итә ала.

Белемнең федераль дәүләт стандартлары нигезендә төзелгән үрнәк программалар туган тел һәм әдәбият укытуда ирешелгән нәтиҗәләрне бөтен Россия укучыларына җиткерергә тиеш.

БФДС кысаларында эшләнгән белем бирүнең үрнәк программалары туган тел һәм әдәбият укытуда ирешелгән дәрәҗәдә булырга һәм әлеге предметларны Россиядәге барлык татар укучыларына укытуны тәэмин итәргә тиеш.

Халыкларның үзенчәлеген саклауда һәм кешеләрнең тыныч яшәешен тәэмин итүдә телләрнең әһәмияте бик зур. Алар тотрыклы үсешне тәэмин итү һәм глобаль һәм урындагы мәнфәгатьләрне гармонияләштерү юлында стратегик фактор булып торалар. ЮНЕСКОның мәдәни күптөрлелек турындагы гомуми декларациясендә билгеләнеп кителгәнчә, мәдәни күптөрлелек телләрнең күп төрлелеге белән бәйләнгән. Шуңа күрә үзеңнең телеңне куллануга, шул исәптән мәгарифтә дә, берүк вакытта гомумдәүләт телен һәм халыкара телләрне үзләштерүгә, доминант тел ияләрен башка милли телләрне, халыкара телләрне өйрәнүгә этәрүгә юнәлдерелгән тел сәясәтен үстерү, алга этәрү бик мөһим. Глобализация заманында барлык телләргә дөньяда үз урынын табарга аңлы рәвештә үстерелүче күптеллелек кенә мөмкинлек бирә ала.

Мәгариф системасында тел хокуклары үз эченә азчылык телләренә өйрәтүне: милли азчылык әгъзаларын һәм башка ул телне өйрәнергә теләүчеләрне; милли азчылык вәкилләрен туган телдә укытуны ала. Сөйләм телен белүне гаиләдә тәэмин итеп булса да, язма һәм әдәби телне белү укыту оешмаларының актив эшчәнлеген таләп итә. Аның өстенә өлкән кешеләр махсус программаларда укырга теләргә мөмкин.

Икенчедән, азчылык теленә азчылыктан булмаган кешеләрне дә өйрәтү азчылык белән күпчелек арасында аңлашуга бигеле бер өлеш кертергә мөмкин. Күптән түгел Европа Советы мәдәни аралашу, аңлашу һәм толерантлык чарасы буларак бердән күбрәк тел белүнең әһәмиятен таныды.

Өченчедән, тел дәресләре тел өйрәнүнең һәм шәхеснең үзбилгеләнүен тәэмин итүче элемент булып торса да, тел уку процессының зуррак өлеше туган телдә укытылган очракта гына тулысынча үзләштерелергә мөмкин.

Дүртенчедән, тикшерүләр күрсәткәнчә, үз телен өйдә өйрәнүче һәм әлегә күпчелек телен яки рәсми телне өйрәнмәгән милли азчылык вәкилләренә билгеле бер күләмдә туган телдә уку белем күтәрүгә ярдәм итә.

Уку программалары составындагы база уку планнарының Россия составындагы республика мәктәпләре өчен дә варианты булу бик мөһим принципиаль мәсьәлә. Бу юнәлештә Татарстан Республикасында түбәндәге эшләр эшләнә.

ТР Дәүләт Советы Россия Дәүләт Думасына 309-ФЗ законына Россия субъектлары, мәгариф идарәсе органнарына туган телдә һәм туган тел укытуның үрнәк программалары эшләү хокукын бирүче үзгәрешләр кертү буенча закон чыгару инициативасы белән чыкты.

ТР Хөкүмәте карары белән федераль дәүләт белем стандартларын эшләү һәм тормышка ашыру буенча комиссия төзелде. Комиссиянең эшче төркеме стандартларның проектын тикшерүдә актив катнаша. Татарстанның катгый таләбе белән төп белем бирү программасының мәҗбүри өлешенә 3 сәгать күләмендә туган тел укыту кертелде.

Россия гражданины тәрбияләү шартларында милли-төбәк белеменең эчтәлеген саклап калу поликультуралы мәгариф шартларында гына мөмкин. ТР мәгариф системасы өчен дәреслекләр һәм методик кулланмалар хәзерләү буенча Россия Федерациясенең пилот проектында катнаша. Поликультуралы мәгариф концепциясе функциональ икетеллелек һәм күптеллеккә нигезләнгән. Башлангыч мәктәптә күпчелек фәннәр туган телдә укытыла. Өлкән сыйныфларда профильле укыту инглиз, рус һәм татар телләрендә алып барылырга мөмкин. Башлангыч сыйныфлар һәм балалар бакчалары өчен рус һәм татар телендә дәреслек комплектлары хәзерләнеп, экспериментта катнашучы мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына җибәрелде. Укыту-методик комплектларның эчтәлеге балаларны үз халкы рухында, Татарстан һәм Россия халыкларының тарихи-мәдәни мирасы, гомумкешелек рухи байлыклары нигезендә тәрбияләүгә юнәлдерелгән һәм БФДСна туры килә. Экспериментта катнашучы педагоглар Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтында белем күтәрү курслары узды[205].

---

[205] Лотфуллин М.В. Поликультурное образование как условие сохранения родных языков в рамках ФГОС // Казанский федералист. – Казань, 2012. – № 1–2. – С. 210–214.

БФДС, рус телендә генә бирелгән бердәм дәүләт имтиханнары татар милли мәгарифенең рус мәгарифе белән конкурентлыгын тагын да катлауландырды. Шул шартларда да яшәп калу өчен Татарстан чит илләрнең алдынгы педагогик технологияләрен кертү юлы белән дә бара. Мисал итеп «Киләчәк» – 2010–2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясе кысаларында «Educare International Consultancy» Сингапур компаниясе белән берлектә алып барылган «ТРда укыту сыйфатын камилләштерү» проектын, икенче төрле әйткәндә, «Сингапур проекты»н китереп була[206]. Шулай ук «Education First» платформасында эшләнгән татар телен дистанцион өйрәнү буенча «Ана теле» программасы да бу юнәлешкә керә[207].

Татар мәктәпләренең дәрәҗәсен күтәрү максаты белән Татарстанның район үзәкләрендә үз эченә балалар бакчаларын, музыка мәктәпләрен һәм урта белем бирү мәктәбен алган милли мәгариф үзәкләре төзелә башлады. Шулай ук мәгариф өлкәсендә татар теленең ролен күтәрү максатыннан татар теле буенча Халыкара олимпиада, татар теле укытучыларының Бөтенроссия конкурслары, укучылар өчен татар телендә бик күп төрле конференцияләр, конкурслар, чаралар, шул исәптән Татарстаннан башка төбәкләрдә яшәүче татар балалары өчен җәйге ял лагерьлары оештырыла. Талантлы татар яшьләрен берләштерүгә һәм тәрбияләүгә «Сәләт» яшьләр оешмасы зур өлеш кертә[208].

Югары уку йортларында татар телендә укытучылар хәзерләү өчен федераль хөкүмәт тарафыннан бюджет урыннары бирелмәү сәбәпле, ике телле укытучылар Татарстан хөкүмәте исәбенә әзерләнә. Шуңа да карамастан, татар телендә уку хәтта Татарстанда да елдан-ел кими бара.

2016 елда ТР Министрлар Кабинеты карары нигезендә «2030 елга кадәр Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү»[209] һәм «Татар теле һәм әдәбиятын укыту» концепцияләре кабул ителде[210]. «Милли мәгарифне үстерү» концепциясе республиканың

---

[206] http://mon.tatarstan.ru/rus/kilechek.htm

[207] http://mon.tatarstan.ru/ana_tele.htm

[208] http://selet.biz/tat/

[209] Постановление Кабинета Министров Республики Татарстан № 570 от 19.08.2016 (http://irort.ru/files/tatar/2.pdf).

[210] http://irort.ru/node/476?page=1 ; irort.ru/files/30.11.2016/1.docx

конкурентлык мөмкинлекләрендә һәм кешелек капиталы үсешендә мәгарифне төп фактор итеп билгели торган Татарстан Республикасының 2030 елга кадәр социаль-икътисади үсеш стратегиясен үтәү максатыннан эшләнде.

Милли мәгарифнең алга таба үсеше социомәдәни үсеш юнәлешләрен исәпкә ала һәм түбәндәге чаралар башкаруны күз алдында тота:

1. Милли мәгариф белән идарә итү системасының нәтиҗәлелеген арттыру түбәндәгеләрне үз эченә ала:

– милли мәгариф үсешенең хәзерге торышына һәм перспективаларына (киләчәгенә) өзлексез системалы анализ ясау һәм бәяләү, алга таба камилләштерү максаты белән идарә итү карарлары кабул итү һәм методик киңәшләр формалаштыру;

– милли мәгарифне популярлаштыру, туган телдә балалар тәрбияләгән гаиләнең уңай имиджын булдыру;




*Татар теле һәм әдәбияты буенча халыкара олимпиада җиңүчеләре: Япониядән Накамура Мидзуки һәм Сабадан Ризәлә Йосыпова. 2017 ел*

– милли мәгарифнең норматив-хокукый тәэмин ителешен камилләштерү;

– милли мәгарифне үстерү мәсьәләләрен хәл итү буенча федераль дәүләт хакимият органнары, федераль фәнни һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек итү;

– милли мәгарифне үстерү буенча белем бирү оешмалары һәм муниципаль берәмлекләр эшчәнлеген бәяләү системаларын камилләштерү;

– милли мәгарифнең сыйфатын бәйсез бәяләүне тәэмин итү; белем бирү оешмалары белән охшаш социомәдәни бурычларны үти торган оешмалар белән үзара актив хезмәттәшлек итү.

2. Белем бирү оешмалары челтәре (мәктәпкәчә, гомуми белем, һөнәри, өстәмә белем бирү системасы) үсеше түбәндәгеләрне күз алдында тота:

– муниципаль районнарда, шәһәр округларында милли белем бирү оешмалары, сыйныфлары, төркемнәре челтәрен саклап калу өчен уңайлы шартлар тудыру;

– белем бирү оешмалары, шул исәптән этномәдәни компонентлы (рус, татар, чуваш, удмурт, мари, мордва, башкорт) инновацион оешмалар (белем бирү үзәкләре, махсус мәктәпләр һәм сәләтле балалар өчен интернат-мәктәпләр) челтәрен үстерү;

– белем бирү программаларын, педагогик хезмәткәрләрне һөнәри яктан үстерүне бергә тормышка ашыру өчен, милли белем бирү оешмаларының хезмәттәшлек челтәре моделен төзү;

– алдынгы педагогик тәҗрибәне, белем бирү технологияләрен сынап карау һәм кулланылышка кертү өчен, инновацион, тәҗрибә (эксперименталь), ресурс мәйданчыклары булдыру эшен башкару, шулай ук, заманча мәгълүмати элемтә (коммуникацион) технологияләрне дә кулланып, этномәдәни белем бирү проектларын булдыру һәм тормышка ашыру.

3. Милли мәгариф эчтәлеген камилләштерү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

– мәктәпкәчә яшьтәге балаларны туган телгә таянып тәрбияләүче гаиләләргә методик киңәшләр әзерләү;



*Иннополис лицее укучылары*




*Халыкара яшьләр уку-укыту Сәләт форумы. 2016 ел*

– белем бирү программаларындагы этномәдәни өлешле фәннәрнең, курсларның эчтәлекләрен укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры китерү;

– укучыларда белем бирү программаларындагы этномәдәни өлешле фәннәргә кызыксыну уяту максатыннан, үз илебезнең һәм чит илнең нәтиҗәле белем бирү технологияләрен, ысулларын һәм алымнарын укыту-тәрбия процессына кертү;

– балаларның сәламәтләндерү-белем бирү үзәкләре (лагерьлар) базасында татар телендә ел буе белем һәм тәрбия бирү программалары булдыру;

– Россия Федерациясе субъектларының белем бирү оешмалары өчен татар теленнән нәтиҗәле белем бирү программалары һәм укыту материаллары эшләү;

– укучыларга туган телләрендә төп гомуми белем дәүләт йомгаклау аттестациясе тапшыру өчен оештыру-технологик шартларны камилләштерү;

– Татарстан Республикасы дәүләт телләрен белүче (халык белән турыдан-туры элемтәдә торучы) урта һөнәри һәм югары белемле кадрлар әзерләү программаларын камилләштерү;

– туган телләрне һәм туган телләрдә өйрәтүче укытучыларны әзерләү программаларын аларның эш үзенчәлекләрен исәпкә алып камилләштерү.

4. Милли мәгарифне ресурслар белән тәэмин итүне үстерү түбәндәгеләр аша тормышка ашырыла:

– Татарстан Республикасы территориясендә һәм Россия Федерациясе субъектларында татар телендә белем бирүче һәм татар телен өйрәтүче белем бирү оешмалары өчен педагогик һәм җитәкче кадрлар әзерләүне модернизацияләү (яңарту);

– милли мәгариф системасына, шул исәптән Татарстан Республикасыннан читтәге этномәдәни (татар) компонентлы белем бирү оешмаларын кирәкле кадрлар белән тәэмин итү өчен, кадрларны әзерләү һәм квалификация күтәрү системасын камилләштерү;

– милли мәгариф өлкәсендә гамәли һәм тирән нигезле эзләнүләрнең өстенлекле юнәлешләрен билгеләү, милли мәктәпнең теоретик нигезләрен формалаштыру, фәнни кадрлар әзерләүне камилләштерү;

– Татарстан Республикасының этномәдәни һәм региональ үзенчәлекләрен исәпкә алган дәреслекләр һәм укыту әсбаплары

әзерләүдә, экспертиза үткәрүдә, аларны сынап карауда, белем бирү процессына кертүдә катнашу;

– туган телдә һөнәри һәм югары белем бирүче оешмаларда табигать һәм гуманитар фәннәр укытуны ресурслар белән тәэмин итү;

– белем бирү оешмаларында белем бирү процессын мәгълүмати тәэмин итүдә ачык электрон ресурсларны үстерү;

– һөнәри берләшмәләрнең һәм туган тел укытучылары, фән укытучылары, милли белем бирү оешмалары җитәкчеләре берләшмәләренең эшләп торуына ярдәм итү, шул максаттан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре мөмкинлекләреннән дә файдалану.

Татар телен һәм татар әдәбиятын укыту концепциясе тел сәясәте һәм мәгариф өлкәсендә федераль һәм республика законнарына, гомумевропа стандартлары һәм тәкъдимнәренә туры китереп, 2030 елга кадәр Татарстан Республикасында милли мәгарифне үстерү концепциясен исәпкә алып әзерләнде.

Бүгенге көнгә Татарстан Республикасында туган телне һәм дәүләт телләрен саклау һәм үстерү өчен кирәкле норматив-хокукый база булдырылган, тиешле оештыру-идарә итү, фәнни-методик, кадрларга кагылышлы шартлар тудырылган. Кабул ителгән норматив документларга ярашлы рәвештә татар теле һәм татар әдәбияты гомуми белем бирү системасында туган тел һәм туган телдәге әдәбият һәм шулай ук дәүләт теле һәм чит телле әдәбият буларак мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү оешмаларының 1–11 нче сыйныфларында өч юнәлештә өйрәнелә:

– гомуми белемне татар телендә бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (татар укучылары өчен);

– гомуми белемне рус телендә бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (татар укучылары өчен);

– гомуми белемне рус телендә бирүче оешмаларда татар теле һәм татар әдәбияты (рус телле укучылар өчен).

Һәр юнәлеш буенча үрнәк эш программалары төзелгән, УМКлар эшләнгән; татар теле һәм татар әдәбияты укытучыларын әзерләү тормышка ашырыла; педагогларга өстәмә һөнәри белем бирү эше оештырылган.

Татар теле һәм татар әдәбиятын укытуның концептуаль нигезләрен яңарту гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү

стандартларының предмет өлкәләрен камилләштерү (модернизацияләү) кысаларында алып барыла һәм Россия Федерациясендә мәктәптә филологик белем бирүдә соңгы еллардагы үзгәрешләрне исәпкә ала. Әлеге Концепция нигезендә татар телен һәм татар әдәбиятын укыту ике юнәлештә гамәлгә ашырыла:

– туган тел буларак татар теле һәм туган телдәге әдәбият буларак татар әдәбияты (татар укучылары өчен);

– дәүләт теле буларак татар теле һәм чит телдәге әдәбият буларак татар әдәбияты (рус телле укучылар өчен).

Концепцияне тормышка ашыру белем бирү барышының барлык этапларында татар теле һәм татар әдәбиятын укытуның эчтәлеген камилләштерүгә, аны төбәк мәгарифенең аерылгысыз өлеше буларак карап, татар теле һәм татар әдәбиятын укытуның белем бирү, тәрбияви һәм үстереш потенциалын арттыруга юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы территориясендә татар теле һәм татар әдәбияты мәктәпкәчә белем бирү, гомуми белем бирү, урта һөнәри һәм югары белем бирү баскычларында өйрәнелә. Гамәлдәге хокук системасы һәм норматив актлар белән ярашлы рәвештә татар теле һәм татар әдәбияты гомуми белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларында билгеләнгән «Туган тел һәм Туган телдәге әдәбият» предметы кысаларында өйрәнелә һәм белем бирү программасында уку-укыту планының үзгәрешсез (инвариант) өлешенә кертелгән, республика укучыларының барысы өчен дә мәҗбүри булып санала.

Татар телен туган тел буларак укыту татар теленең саклануын һәм үсешен тәэмин итә, татар халкына аны функциональ куллану шартларын һәм мөмкинлеген тудыра, ил гражданнарының конституция нигезендә туган телдә белем алуга булган хокукын тәэмин итә. Туган тел буларак татар телен укыту туган телдә иркен сөйләшә һәм яза алуга, аны төп аралашу чарасы кебек кабул итүгә, милли әхлакый-этик нормаларны үзләштерүгә, туган телнең эстетик кыйммәтенә төшенүгә; татар теленең төзелеше, системасы хакындагы белемнәрне һәм аның кулланылыш кагыйдәләрен үзләштерүгә, шулай ук әлеге телдә аралашучы менталитетын формалаштыруга, милли-мәдәни үзбилгеләнүгә, телнең аралашу вазифасына таянып халыкның этник мәдәнияте турында белем алуга, татар әдәби сөйләм нормаларына өйрәтүгә юнәлтелгән.

Россия Федерациясенең этномәдәни татар компоненты булган субъектларында татар теле мәктәптә белем бирүнең барлык баскычларында, үрнәк төп белем бирү программаларына таянып, мөстәкыйль формалаштырыла торган эш программаларына нигезләнеп, гомуми белем бирү оешмаларының белем бирү программасына туры китереп туган тел буларак укытыла.

Дәүләт теле буларак татар теле укучыларда сөйләм эшчәнлегенең төп төрләрендә аралашу компетенцияләре формалаштыру, телдән һәм язма сөйләм культурасы нигезләрен үзләштерү, укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры китереп, аралашуның төрле очракларында татар телен куллану осталыгын арттыру һәм күнекмәләр булдыру, күпмәдәниятле җәмгыятьтә үзара татар телендә аңлашу мөмкинлеге формалаштыру максаты белән укытыла.

Татар әдәбияты гуманитар белем бирүдәге шәхеснең интеллектуаль һәм әхлакый-эстетик үсеш дәрәҗәсен билгеләүче төп предметлардан санала. Ул тормышны танып белү һәм чынбарлыкны кабат тергезү чараларының берсе булып тора – сәнгатьле тасвирлау алымнары ярдәмендә әдәби дөнья сурәте барлыкка китереп, ул аңа карата билгеле бер мөнәсәбәт тудыра; эмоциональ тәэсир итү көченә ия.

Әдәби белем бирү китап укуның һәм үзенең алга таба шәхсән үсеше өчен әдәбиятның әһәмиятен аңлаган, үз фикерен дәлилләргә сәләтле һәм аны телдән дә, язмача да тәгъбир итә белгән квалификацияле китап укучы тәрбияләү; тормышны һәм үз-үзен танып белү, кеше һәм җәмгыять мөнәсәбәтләрен килештерү чарасы буларак та яшь кешедә даими китап укуга ихтыяҗ формалаштыру белән бәйле.

Туган телдәге әдәбият буларак укытылганда, ул мөһим миллимәдәни кыйммәтләрне, фикер-карашларны, рухи-әхлакый күзаллауларны үзендә туплап, татар халкының тормыш фәлсәфәсен аңлау һәм үзләштерүгә, милли үзаң һәм үзбилгеләнү калыплашуга китерә, шулай ук гомумроссия гражданины буларак формалашуга да ярдәм итә. Аны өйрәнү эстетик зәвык, сәнгати фикерләү, әйләнә-тирә дөньяны эмоциональ-кыйммәти күрү, иҗади күзаллау үсешен тәэмин итәргә тиеш.





*Казан шәһәренең 4 нче интернат-гимназия укучылары дәрес вакытында*

Чит телдәге әдәбият буларак, ул татар халкының тарихи-мәдәни мирасы һәм рухи-эстетик кыйммәте кебек күзаллана, аны өйрәнү төрле этномәдәни традицияләрне чагылдыра торган әдәби әсәрләрне аңлау сәләтен үстерүгә юнәлтелгән. Классик һәм хәзерге татар әдәбиятының иң яхшы үрнәкләре, танылган язучыларның тормыш юлы һәм иҗаты турындагы материаллар, тарихи-әдәби барыш һәм татар әдәбиятының милли үзенчәлекләре белән таныштыру, башка милләт вәкилләренә толерантлык һәм ихтирамлы мөнәсәбәттәге, татар халкының тарихы, мәдәнияте, фәлсәфәсе хакында күзаллаулары булган, һәр яктан камил шәхес тәрбияләүгә ярдәм итә.

Бу Концепциянең максаты – татар теле һәм әдәбиятын укытуны дәүләт һәм җәмгыять куйган заман таләпләре белән тәңгәлләштереп, филологик һәм педагогик белем бирүгә яңача якын килү нигезендә камилләштерү.

Шушы рәвештә татар телен һәм әдәбиятын укытуның нәтиҗәлелеген арттыру өчен түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү күздә тотыла:

1) һәр юнәлеш һәм телне үзләштерү дәрәҗәсе өчен предметлар эчтәлегенең фундаменталь төшен, лексик-грамматик, коммуникатив нормаларын (минимумнарын), мәҗбүри, өстәмә һәм мөстәкыйль уку өчен тәкъдим ителәчәк әдәбият исемлекләрен эшләү;

2) яңа үрнәк эш программалары, укыту-методик комплектлары, тел компетенцияләрен бәяләү системасын әзерләү, сынап карау (апробацияләү) һәм кулланылышка кертү;

3) баланың яшенә һәм кызыксынуына, аның туган тел яки дәүләт телен үзләштерү дәрәҗәсенә туры килгән, барыннан да элек, телдән дөрес сөйләмгә алып чыга торган, аралашу компетенцияләрен формалаштыруны күздә тоткан нәтиҗәле технологияләрне гамәлгә кертү;

4) татар филологиясе өлкәсендә заман таләпләренә җавап бирә торган педагог-хезмәткәрләр һәм фәнни кадрлар әзерләү, яңадан әзерләү һәм белемнәрне күтәрү системасын камилләштерү;

5) татар телен һәм әдәбиятын укытуның сыйфатын күтәрү, методик яктан ныгыту, муниципаль һәм мәктәп эчендәге мониторинг ярдәмендә идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттыру;

6) татар телен һәм татар әдәбиятын укытуның норматив-хокукый нигезен камилләштерү;

7) Татарстан Республикасыннан читтәге белем бирү оешмаларына булышу һәм аларга методик ярдәм күрсәтү.




*Бишкекта Каюм Насыйри институтының белем бирү һәм мәдәният үзәге. 2015 ел*



*Астанада татар теле курсларын тәмамлаучылар беренче сертификат алдылар. 2016 ел*

Хәзерге вакытта башлангыч, төп һәм урта мәктәп өчен БФДС расланган. Туган тел һәм әдәбияты уку-укытуга таләпләр рус теле һәм әдәбияты белән бертигез куелган. Төп мәктәпне тәмамлаганда туган телләрдән дәүләт йомгаклау имтиханы каралган.

«Милли мәгарифне үстерү», тормышка ашыру буенча юл карталары эшләнде, дәүләт оешмаларының, фәнни даирәләрнең, галимнәрнең һәм педагогларның юл картасын үтәү буенча эшчәнлеген координацияләү өчен Мәгарифне үстерү институты каршында Милли мәгариф үзәге төзелде. Шул исәптән, Милли мәгариф үзәгендә «Татар теле һәм әдәбиятын укыту» концепциясе нигезендә татар телен дәүләт теле буларак укыту өчен башлангыч сыйныфлар өчен гомумевропа тел стандартларын кулланып укыту-методик комплектлар эшләнде. Хәзерге вакытта укытучыларны яңа методикага өйрәтү эше алып барыла[211].

Шулай итеп, татар халкын, Россия халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклап калу өчен Милли мәгариф учреждениеләре формасы ягыннан заманча модерн, эчтәлеге ягыннан милли булырга тиеш.

211 Лотфуллин М.В. Мәгариф системасында туган телләрне саклап калу юллары // Сб. докладов международной научно-практической конференции «Опыт организации высшего образования на татарском языке (1991–2016 годы)» г. Казань, 18 апреля 2017 г. – Казань: КГАСУ, 2017. – С. 39–44.

# ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

Абдрахманов М. Диалектик материализм. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 235 б.

Абдуллин Я.А. Милләт язмышы. – Казан: Фән, 1999. – 305 б.

Абдуллин Я.Г. Татарская просветительская мысль. – Казань: Иман, 2002. – 305 с.

Айдарова С.Х. К знаниям через игру. – Казань: ТГГИ, 1998. – 116 с.

Академический центр Татарии: 1920-е годы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 95 с.

Алексеев И., Бакиров Г., Бишипов М. Математика. Дәреслек. – Казан: Татгосиздат, 1933. – 287 б.

Алексеев И.А. Математика дәресләре. Партия мәктәбенә һәм татар коммунистик университетына хәзерләнүчеләр өчен. – Казан: Татгосиздат, 1930. – 20 б.

Алексеев И.А. Математика. Элементар курс. – Казан: Татгосиздат, 1931. – 55 б.

Алексеев И.А. Югары математика нигезләре. Укытучылар, читтән торып укучылар һәм югары математиканы үзлекләреннән өйрәнүчеләр өчен. – Казан: Татгосиздат, 1953. – 855 б.

Алтын кашык: Такмаклар, уеннар... / Төз. Р.Ягъфәров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1996. – 111 б.

Амирханов Р.У. Некоторые особенности развития народного образования у татар в дооктябрьский период // Народное просвещение у татар в дооктябрьский период. – Казань: ИЯЛИ им. Г.Ибрагимова, 1992. – С. 22–60.

Амирханов Р.У. Система конфессионального образования у татар // Ислам и мусульманская культура в Среднем Поволжье: История и современность. – Казань: Мастер-Лайн, 2002. – С. 140–157.

Антология педагогической мысли Белорусской ССР / Сост. Э.К.Дорошевич, М.С.Мятельский, П.С.Солнцев. – М.: Педагогика, 1986. – 468 с.

Антология педагогической мысли Древней Руси и Русского государства XIV–XVII вв. / Сост. С.Д.Бабишин, Б.Н.Митюров. – М.: Педагогика, 1985. – 363 с.

Арсланов М.С. Эшчеләр әлифбасы. Зурлар өчен. – М.: СССР халыкларының ҮН, 1928. – 72 б.

Арсланов М.С., Мөхәммәдев М. Крестьяннар өчен «Яңа авыл әлифбасы». – М.: СССР халыкларының ҮН, 1927. – 71 б.

Асадуллин А.Ш. Актуальные вопросы преподавания татарского языка в русскоязычной аудитории // Национальная школа и актуальные проблемы обучения. – Казань: Мастер Лайн, 2001. – С. 14–16.

Асмолов А.Г. О переходе на новую структуру исторического и обществоведческого образования // Преподавание истории в школе. – 1993. – № 4. – С. 45–46.

Ахтямова А.В. Преподавание на татарском языке и татарского языка в 1920-е гг. // Преподавание на татарском языке в системе среднего и высшего образования: история, современность и перспективы. – Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2015. – 58–67 с.

Әлмөхәммәтов М.И. Зурлар өчен математика. 2 кисәктә. – Казан: Татиздат, 1932. – 1 кис. – 114 б.; 2 кис. – 154 б.

Әлмөхәммәтов М.И. Сызма геометрия: югары уку йортлары өчен дәреслек. – Казан: Татиздат, 1932. – 163 б.

Әмирхан И. Татар фәлсәфәсе һәм милли мәгариф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 335 б.

Әмирхан Р.У. Иманга тугрылык. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 384 б.

Байки Г. 1 нче баскыч мәктәпләрдә иҗтимагыять укыту юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 168 б.

Балалар мәйданчыгы нәрсә һәм аны ничек төзергә? – М., 1926. – 24 б.

Балачак бәйрәмнәре (Тамаша үрнәкләре) / Төз. С.Сәүбанова. – Казан, 1999. – 58 б.

Бацын В.К., Кузьмин М.Н. Национальные проблемы образования в Российской Федерации // Школа и мир культуры этносов. Вып. 2. – М., 1995. – С. 5–30.

Бәдигов Х. Әлифба: Шәһәр һәм авыллардагы грамота мәктәпләре өчен. – Казан: Татгосиздат, 1935. – 72 б.

Бәдигов Х.Уку китабы. Грамота мәктәпләре өчен. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 98 б.

Бәдигый Т. Зурлар әлифбасына үрнәк. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1920. – 15 б.

Беркутов В. Развитие математического образования у булгаро-татар. – Казань: Дом печати, 1997. – 175 с.

Бигиев Муса. Избранные труды. В двух томах. Т. 1 / Сост. А.Г.Хайрутдинов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2005. – 336 с.

Биктимирова Т.А. Татар хатын-кызлары мәгърифәт юлында. – Казан: Печатный двор, 2002. – 140 б.

Биктимирова Т.Ә. Минем шәҗәрәм... – Казан: Мәгариф, 1999. – 32 б.

Биктимирова Т.Ә. Урта Азия республикалары мәгарифен оештыруда татар хатын-кызларының булышлыгы // Тюрки Волжско-Уральского региона. – Берлин, 2006. – 63–66 б.

Бондаревская Е.В. Теория и практика личностно-ориентированного образования. – Ростов-на-Дону: Издательство Ростовского педагогического университета, 2000. –352 с.

Валиди Дж. Очерк истории образованности и литературы татар. – Казань: Иман, 1998. – 157 с.

Валиев М.Х. Общее и особенное в образовательных доктринах России и Татарстана // Национальная школа и актуальные проблемы национального образования. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2001. – С. 8–11.

Вәлеева Ф.С. Халкына багышланган гомер: Мөхетдин Корбангалиевның татар телен укыту методик системасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 143 б.

Вәлитова К. Балалар бакчасында ничек эшләргә? – М., 1929. – 46 б.

Вәлиуллин Р. Татар мәктәп-мәдрәсәләре өчен гуманитар фәннәр буенча дәреслекләр (XIX йөз азагы – XX йөз башы). – Казан: Фән, 2004. – 220 б.

Гаврилюк В.В. Национальная культура и национальная школа // Образование в Сибири. – 1995. – № 1. – С. 62–67.

Гайнуллин Х. Җәмгыятьне өйрәнү. Беренче уку елы өчен эш китабы. – Казан: Татиздат, 1932. – 100 б.

Гайсин И.Т. Эколого-нравственное воспитание учащихся в процессе изучения естественнонаучных дисциплин: дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 1995. – 223 с.

Гайсин И.Т. Эколого-нравственное воспитание учащихся. – Казань: КГПУ, 1999. – 164 с.

Гайсин И.Т., Хусаинов З.А., Галимов Ш.Ш. География и экология Республики Татарстан. – Казань: КГПУ, 2003. – 204 с.

Гали Х. Мәктәпкәчә тәрбия яшендә баланың телен үстерү юллары. – Казан: Татиздат, 1929. – 68 б.

Галлямова А.Г. «Почему же бояться своего родного языка?» (Из стенограммы заседания бюро Татарского обкома КПСС 28 апреля 1958 г.) // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2013. – № 1/2. – С. 68–83.

Галлямова А.Г. Кризис национальной самоидентификации татар в 40–70-е гг. XX в. // Языки, духовная культура и история тюрков: традиции и современность (материалы Международной тюркологиче-

ской конференции, проходившей 9–13 июня 1992 г. в г. Казань). Т. 3. – М., 1997. – С. 96–98.

Гарипова З.Г. Культурно-просветительская работа в Татарии в годы I пятилетки. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1985. – 155 с.

Гатауллина М.Х. Ведущие тенденции развития татарской национальной школы (1985–2000 гг.). – Казань: Печатный двор, 2001. – 127 с.

Гибатдинов М.М. Преподавание истории татарского народа и Татарстана в общеобразовательной школе: история и современность. – Казань: Алма-Лит, 2003. – 160 с.

Гимазова Р.А. Просветительская деятельность Нигъматуллиных-Буби (конец XIX – начало XX вв.). – Казань: Печатный двор, 2004. – 220 с.

Гончаров Н.К. Педагогическая система К.Д.Ушинского. М., 1974. – 272 с.

Горохов В.М. Педагогика тарихыннан очерклар. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 124 б.

Горохов В.М. Реакционная школьная политика царизма в отношении татар Поволжья. – Казань: Татгосиздат, 1941. – 170 с.

Горохов В.М. Школьное образование среди татар Поволжья в XIX и в начале XX века. – Казань, 1947. – 50 с.

Государственные языки Республики Татарстан: множественность измерений. Сборник очерков / Под ред. Г.Ф. Габдрахмановой, Г.И. Макаровой. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ; Изд-во «Артифакт», 2014. – 236 с.

Государственные языки Республики Татарстан: множественность измерений. Монография / Под ред. Г.Ф.Габдрахмановой, Л.В.Сагитовой. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ; Изд-во «Артифакт», 2015. – 268 с.

Государственные языки Республики Татарстан: множественность измерений. Сборник очерков / Под ред. Г.Ф.Габдрахмановой, Г.И.Макаровой, А.Р.Мухаметзяновой. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2016. – 208 с.

Гыйззәтов К. Нәфасәт: кыскача нәфасәт тарихы. Нәфасәтнең нигез проблемалары: Югары уку йортлары өчен дәреслек. 1 кит. – Казан: Мәгариф, 2004. – 495 б.; 2 кит. – Казан: Мәгариф, 2006. – 479 б.

Гыйззәтов К. Философия: кыскача философия тарихы. Философиянең нигез проблемалары: Югары уку йортлары өчен дәреслек. 1 кит. – Казан: Мәгариф, 2002. – 448 б.; 2 кит. – Казан: Мәгариф, 2003. – 407 б.

Давлетшин Г.М. Волжская Булгария: духовная культура. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 177 с.

Давлетшин Г.М. Культура древних тюрков. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – 63 с.

Давлетшин Г.М. Очерки по истории духовной культуры предков татарского народа (истоки, становление и развитие). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2004. – 431 с.

Давлетшин Г.М., Хузин Ф.Ш. Булгарская цивилизация на Волге. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – 112 с.

Дистанов Г. Укый-яза белмәүчеләрне һәм аз белемлеләрне укытучылар өчен кулланма. – Казан: Татиздат, 1926. – 17 б.

Дистанов Г., Бурнаш В. Яңа ил (Аз белемле зурлар өчен эш китабы). – Казан: Татиздат, 1929. – 61 б.

Дистанов Г., Бурнаш В. Яңа ил (Зурлар әлифбасы). Авыл өчен. – Казан: Татиздат, 1930. – 95 б.

Днепров Э.Д. Четвертая школьная реформа в России. – М.: Интерпракс, 1994. – 241 с.

Документы актуальные и сейчас. О статусе татарского языка по документам 50-х гг. // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 1996. – №1/2. – С. 108–115.

Евграфова О.Г. Деятельность ТИУУ в годы Великой Отечественной войны 1941–1945 гг. // Казанский педагогический журнал. – 2010. – № 2. – С. 159–165.

Жирков Е.П. Как возродить национальную школу: Идеи и новые подходы. Концепция. Шаги Республики Саха (Якутия): Программа действий. Пути и механизмы реализации. – М.: Просвещение, 1998. – 238 с.

Җәләлиев Ш.Ш. Милли тәрбия нигезләре (исламдагы һәм татар халык педагогикасындагы рухи-әхлакый потенциал – милли тәрбиянең нигезе). – Казан: Алма-Лит, 2003. – 174 б.

Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 1997. – 175 б.

Загидуллин И. Исламские институты в Российской империи. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2007. – 415 б.

Закирова К.В., Кадыйрова Р.Ә. Әхлак нигезе – матур гадәт (Гаиләдә һәм балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбияләү): Методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2004. – 383 б.

Зарипова А.М. Татар әдәбияты дәресләрендә тарихи эчтәлекле әсәрләр укыту методикасы: тарихы һәм үсеш баскычлары. – Казан: Алма-Лит, 2006. – 100 б.

Заһидуллина Д. Урта мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2000. – 334 б.

Зәйни Х. Мәктәп, балалар бакчасы һәм балалар мәйданы өчен уеннар. – Уфа, 1919. – 101 б.

Зәйни Х., Исхаков Ф. Крестьян әлифбасы. – М.: СССР халыклары ҮН, 1928. – 71 б.

Зәкиев М.З. Милли телне саклау – милләтне саклау ул // Татар телендә югары белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар). – Казан: КДАТУ, 2017. – 33–36 б.

Зурлар әлифбасы (шәһәр өчен). – Казан: Шәһәр культпоход штабы нәшр., 1929. – 16 б.

Ибраһимов Г. Татар телен ничек укытырга: телемезнең методикасы хакында бер тәҗрибә. – Казан: Сабах, 1916. – 90 б.

Ибраһимов Ф. Белем әлифбадан башлана: татарча грамотага өйрәтү методикасы тарихы һәм әлифбалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1973. – 335 б.

Износков И. Об образовании инородцев и о миссии в Казанской епархии. – М., 1909. – 121 с.

Ислаев Ф. Батырша восстаниесе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 126 б.

Ислаев Ф.Г. Батырша. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 62 с.

Ислам в СССР. Особенности процесса секуляции в республиках Советского Востока. – М., 1983. – 173 с.

Исламов Ф. Татар әдәбиятын өйрәнү процессында интернациналь тәрбия мәсьәләләре // Вопросы обучения и воспитания в татарской школе. – Казань, 1975. – С. 192–205.

Исламов Ф. Татар әдәбиятын укытканда интернациональ тәрбия (5–8 класслар). – Казан, 1968. – 176 б.

Исламов Ф.Ф. Мәгърифәт, әдәбият һәм тарих сукмаклары буйлап. – Казан: Печатный двор, 2002. – 280 б.

Исмаил бей Гаспринский. Россия и Восток. – Казань: Фонд Җиен; Татар. кн. изд-во, 1993. – 132 с.

Исмәгыйль бәк Гаспринский. – Казан: Алма-Лит, 2004. – 78 б.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности. – Казань: Рухият, 2002. – 552 с.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. II. Волжская Булгария и Великая Степь. – Казань: РухИЛ, 2006. – 960 с.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. III. Улус Джучи (Золотая Орда). XIII – середина XV в. – Казань: Институт истории АН РТ, 2009. – 1056 с.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. IV. Татарские государства XV–XVIII вв. – Казань: Институт истории АН РТ, 2014. – 1080 с.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. V. Татарский народ в составе Российского государства (вторая половина XVI – XVIII вв.). – Казань: Институт истории АН РТ, 2014. – 1032 с.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. VI. Формирование татарской нации. XIX – начало XX в.– Казань: Институт истории АН РТ, 2013. – 1172 с.

История татар с древнейших времен: в семи томах. Т. VII. Татары и Татарстан в XX – начале XXI в. – Казань: Институт истории АН РТ, 2013. – 1008 с.

Исхаков Р.Р. Миссионерство и мусульмане Волго-Камья (последняя треть XVIII – начало XX в.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. – 222 с.

Казаков И. Җәмгыятьне өйрәнү методлары. – Казан: Татиздат, 1926. – 43 б.

Казанская татарская учительская школа 1876–1917 гг.: Сборник документов и материалов / Отв. сост. Л.В.Горохова; сост. Н.С.Горицкая, Н.А.Шарангина; под общ. ред. Д.И.Ибрагимова; отв. ред. Д.Р.Шарафутдинов. – Казань: Гасыр, 2005. – 256 с.

Казыйханов В., Шәрипов Ә. Әхлак белеме. – Яр Чаллы: ИНПО, 1997. – 104 б.

Казыйханов В. Иман дәресләре. – Яр Чаллы, 1997. – 80 б.

Камалов Т. Зыя Камали. – Казан: Иман, 1997. – 53 б.

Камалова З.А. Югары уку йортларында татар телендә укыту – телне саклап калуның төп шарты һәм мөмкинлеге // Татар телендә югары белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар). – Казан: КДАТУ, 2017. – 69–74 б.

Каримуллин Ә.Г. Безнең кардәшлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 335 б.

Кашапова М.Ф. Дидактические условия организации словарной работы по татарскому языку с детьми старшего дошкольного и младшего школьного возраста: дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 2005. – 268 с.

КГПИ / Сост. А.Л.Литвин, отв. ред. М.З.Закиев. – Казань, 1970. – 27 с. (КГПИ – Казанский государственный педагогический институт. – *прим. ред.*).

Кириллова З.Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20–30 нчы еллар). – Казан: Мастер Лайн, 2000. – 208 б.

Кириллова З.Н. XX гасыр башында керәшеннәр // Татар халкының педагогик фикерен һәм мәгариф тарихын өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре. – Казан: ТР ФА Ш.Мәрҗани ис. Тарих институты, 2011. – 250–258 б.

Коблов Я. Конфессиональные школы казанских татар. – Казань: Центр. тип., 1916. – 119 с.

Коблов Я. Мечты татар-магометан о национальной общеобразовательной школе. – Казань: Типо-лит. Имп. ун-та, 1908. – 20 с.

Корбангали М. Олылар өчен рәсемле татар әлифбасы. – Казан: Милләт, 1920. – 46 б.

Корбангали М. Олыларны укырга-язарга өйрәтү юллары һәм дәрес бирү үрнәкләре. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1921. – 43 б.

Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкалар өчен (техникум, рабфак, ВУЗ һәм ВТУЗлар өчен). – Казан: Татгосиздат, 1934. – 253 б.

Корбангалиев М. Татар теле дәреслеге. Татарлардан башкаларга татар телен читтән торып өйрәнү өчен. 1 кис. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 244 б.

Корбангалиев М. Укырга-язарга өйрәтү методикасы. – Казан: Татгосиздат, 1940. – 151 б.

Корбангалиев М., Бәдигый Х. Крестьян әлифбасы (зурлар өчен). – М., 1925. – 48 б.

Корнеева М.С. Очерки по истории общественного дошкольного воспитания в ТАССР (1917–1941 гг.).: автореф. дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 1960. – 20 с.

Краткая учебная грамматика татарского языка. – СПб., 1862. – 95 с.

Кукляшев С.Б. Словарь к Татарской хрестоматии, составленный С.Кукляшевым. – Казань: Тип. Казан. ун-та, 1859. – 104 с.

Культурная революция в Татарии (1917–1937 гг). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1986. – 304 с.

Культурное строительство в Татарии 1941–1970. Документы и материалы. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1976. – 519 с.

Куманев В.А. Социализм и всенародная грамотность. – М.: Наука, 1967. – 327 с.

Курбатов Х. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960. –131 б.

Күкләшев С.Б. Диване хикәяте татар = Татарская хрестоматия, составленная Салих-Джаном Кукляшевым. – Казань: Тип. Казан. ун-та, 1859. – 124 с.

Күльбиков З. Зурлар мәктәбе өчен әлифба. – Уфа: Башк. дәүл. нәшр., 1935. – 75 б.

Лотфуллин М., Гурьянова Р. Развитие национальной школы как общемировая тенденция // Татарстан. – 1996. – № 6. – С. 13–17.

Лотфуллин М.В. Мәгариф системасында туган телләрне саклап калу юллары// Сб. докладов международной научно-практической конференции «Опыт организации высшего образования на татарском языке (1991–2016 годы)» (Казань, 18 апреля 2017 г.). – Казань: КГАСУ, 2017. – С. 39–44.

Лотфуллин М.В. Поликультурное образование как условие сохранения родных языков в рамках ФГОС // Казанский федералист. – Казань, 2012. – № 1–2. – С. 210–214.

Максудов Г. Туры сызыклы тригонометрия (Өчпочмаклар белеме). – Казан: Татиздат, 1926. – 342 б.

Максудов Н. Автомобильләр (Шоферлар хәзерләү курсларында укыту өчен ярдәмлек китап). – Казан: Татгосиздат, 1936. – 312 б.

Максудов Н. Авыл хуҗалыгы машиналары: вузлар һәм техникумнар өчен уку китабы. – Казан: Татгосиздат, 1932. – 191 б.

Маликов Р.Ш. Педагогическая мысль Ю.Баласагуни. – Казань: КГПУ, 1999. – 80 с.

Маликов Р.Ш. Педагогические идеи булгарского поэта Кул Гали. – Казань: КГПУ, 1999. – 112 с.

Маликов Р.Ш. Становление и развитие тюрко-татарской гуманистической педагогической мысли Средневековья: автореф. дис. … докт. пед. наук. – Казань, 2000. – 40 с.

Маликов Р.Ш. Тюрко-татарская гуманистическая педагогическая мысль Средневековья. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1999. – 304 с.

Малов Е. Мухаммеданский букварь (миссионерско-критический очерк). – Казань, 1894. – 114 с.

Мардашова Р.С. Становление и развитие дошкольного образования в Татарстане (1872–1941). – Казань: КГПУ, 2004. – 272 с.

Марджани о татарской элите (1789–1889) / Пер. со старотат. и примеч. А.Н.Юзеева и И.Ф.Гимадеева; [отв. ред. И.Л.Алексеев]. – М.: Изд. дом Марджани, 2009. – 128 с.

Материалы Всероссийской научно-практической конференции «Реализация национально-регионального компонента исторического образования в национальных республиках Поволжья и Приуралья:

проблемы и перспективы». – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2003.

Махмудов М.М. Практическое руководство к изучению татарского языка, составленное старшим учителем Казанской гимназии Махмудовым. – Казань, 1857. – 255 с.

Махмутов М.И. Вопросы организации проблемного обучения (Методическое пособие). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1972. – 57 с.

Махмутов М.И. Некоторые вопросы развития татарской школы // Вопросы обучения и воспитания в татарской школе. – Казань, 1975. – С. 19–20.

Махмутова А. Становление светского образования у татар (Борьба вокруг школьного вопроса. 1861–1917). – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1982. – 96 с.

Махмутова А.Х. Лишь тебе, народ, служенье! История татарского просветительства в судьбах династии Нигматуллиных-Буби. – Казань: Магариф, 2003. – 453 с.

Махмутова А.Х. Пора и нам зажечь зарю свободы! (Джадидизм и женское движение). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2006. – 254 с.

Мәдрәсәләрдә китап киштәсе: мәшһүр мәгърифәт үзәкләре тарихыннан / Төз. Р.Мәһдиев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 238 б.

Мәктәпкәчә тәрбия: Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү. – Казан: Школа, 1998. – 15 б.

Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 415 б.

Мәрҗани Ш. Назурат ал-хакк фи фардият ал-аша ва ан лям ягиб-ш-шафак. – Казань: Тип. ун-та, 1870. – 164 с.

Мәхмүтов М.И. Мәктәптә мөстәкыйльлек тәрбияләү (Укучыларның танып-белү активлыгын һәм мөстәкыйльлеген укутуны тормыш белән бәйләү нигезендә үстерү). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – 172 б.

Мәхмүтов М.И. Мәктәптә проблемалы укытуны оештыру. Укытучылар өчен дидактик ярдәмлек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 232 б.

Мец А. Мусульманский ренессанс. – М.: Наука, 1973. – 473 с.

Милләт аналары: тарихи-документаль һәм биографик җыентык / Төз.-авт. А.Х.Мәхмүтова. – Казан: Җыен, 2012. – 560 б.

Мингазов Р. Становление и развитие системы естественнонаучного образования в татарской национальной педагогике. Научно-методическое пособие для учителей, аспирантов и исследователей. Кн.1. – Казань: Дом печати, 2001. – 194 с.

Миңлекәй С. Балалар өчен җырлы уеннар. – Казан: Татиздат, 1925. – 48 б.

Морозов С. Школа Башкортостана: на пути к национальному возрождению // Народное образование. – 1994. – № 4. – С. 84–95.

Мортазина Л. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында татарларның Төркестанда һәм казах далаларында мәгърифәтчелек эшчәнлеге // Историческая этнология. – 2017. – Т.2, № 1.

Мортазина Л. Мәрьям Ялымованың педагогик эшчәнлеге // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2010. – №3/4. – 191–195 б.

Мортазина Л.Р. Татар авыллары мәгарифе: Бәхтияр әл-Мәмдәли һәм Бәхтияровлар нәселе. – Казан: Ш. Мәрҗани ис. Тарих институты, 2016. – 92 б.

Мортазина Л.Р. Татар педагогик фикерен өйрәнүнең теоретик һәм методологик нигезләре («Татар педагогик фикере антологиясе»н төзү тәҗрибәсе нигезендә) // Tatarica. – 2014. – № 2. – 209–222 б.

Мөбарәкҗанов Г.М. Математика тамгалары һәм терминнары, барлыкка килү тарихы. – Казан: Фән, 2004. – 246 б.

Мөхәммәдев М., Арсланов Ш., Шамов А. Безнең ил СССҖ. Аз укыйяза белүчеләр мәктәпләре өчен беренче уку китабы. – М.: СССР халыклары ҮН, 1926. – 72 б.

Мөхәммәдев М.Н. Эшчеләр әлифбасы. – М., 1924. – 80 б.

Мөштәри М. Авылда ясleләр. – Казан: Татиздат, 1930. – 85 б.

Муртазина Л.Р. Династия Рафиковых. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – 55 с.

Муртазина Л.Р. Педагогический анализ деятельности ликбезов (на примере Республики Татарстан). – Казань: Печатный двор, 2002. – 136 с.

Муртазина Л.Р. Сравнительный анализ основных концепций реформирования образования в РТ // Сборник материалов итоговых конференций Центра истории и теории национального образования 2004–2005 гг. – Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2006. – С. 53–62.

Мухаметзянова Г.В. Гуманизация и гуманитаризация средней и высшей технической школы. – Казань: ИСПО РАО, 1996. – 328 с.

Мухаметзянова Д.С. Кадимисткая система образования в историческом и педагогическом контекстах. – Казань: Институт истории АН РТ, 2008. – 216 с.

Мухаметшин А.Г. Идейно-политические основы развития педагогической мысли булгар-татар в средние века (XV–XVI вв.). – Набережные Челны: НГПИ, 2008. – 82 с.

Мухаметшин А.Г. История становления и развития педагогической мысли в Волжской Булгарии (VIII–XIV вв.). – Казань: Изд-во КГУ, 2005. – 115 с.

Мухаметшин А.Г. Педагогическая мысль булгар-татар в Казанском крае: VIII – начало XX в. – М.: НИИ школьных технологий, 2006. – 232 с.

Мухаметшин Р.М. Система образования у татар в начале XX века: состояние и проблемы // Медресе «Мухаммадия»: история и современность. – Казань: Иман, 2003. – С. 37–49.

Мухарямова Л.М., Моренко И.Б., Петрова Р.Г., Салахатдинова Л.Н. Проблема доступности высшего образования для учащихся национальных школ: этносоциальные аспекты // Социологические исследования. – 2004. – № 3. – С. 58–66.

Надир Давлет. Исмаил Гаспринский / [Пер. с тур. яз. Б.Ногманова]. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – 63 с.

Нам жить и помнить. Татарская АССР в годы Великой Отечественной войны (1941–1945 гг.) / А.Ш.Кабирова, Е.Г.Кривоножкина, А.С.Бушуев; Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ. – Казань: Фолиант, 2016. – 248 с.

Насретдинова Д.М. Туркистоннинг маданий ҳаётида татар-бошқирд аёлларининг тутган ўрни (XIX аср охири – XX асрнинг биринчи чораги). Тарих ф. дисс. автореф. – Тошкент, 2011. – 29 б.

Насыйри К. Ләһҗаи татари. I-II т. – Казан: Ун-т тип., 1895. – 96 б.

Насыйри К. Нәмүнә, яки Әнмүзәҗ. – Казан: Ун-т тип., 1891. – 184 б.

Насыйри К. Татарча-русча лөгать китабы. – Казан: Ун-т тип., Амашев нәшр., 1878. – 120 б.

Национальная доктрина развития образовательно-воспитательных систем в Республике Татарстан. – Казань, 1999. – 63 с.

Национальная школа сибирских татар. Хрестоматия. Т. 3. – Тюмень: Вектор Бук, 2005. – 244 с.

Нигматов З.Г. Гуманистические традиции педагогики. – Казань: ТаРИХ, 2003. – 271 с.

Нигъмәтов Җ.Г. Этнопедагогика: халыкчанлык һәм гуманлылык. – Казан: Мәгариф, 2002. – 159 б.

Нигъмәтуллин З.Х. Аналитик геометрия. ВУЗ һәм ВТУЗлар өчен дәреслек. 1 кис. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 265 б.

Низамов А.М. Милли мәктәп: тәрбия нигезләре. – Казан: Мәгариф, 2005. – 334 б.

Никаноров В.А. Русский язык для татар. Рабочая книга для комвузов, совпартшкол, рабфаков, техникумов и курсов для взрослых. – Казань: Татиздат, 1931. – 224 с.

О стратегии развития исторического и обществоведческого образования в общеобразовательных учреждениях // Преподавание истории в школе. – 1995. – № 3. – С. 53–55.

Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре / Төз., кереш сүз һәм искәрмәләр авторы М.Гайнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 278 б.

Панькин А.Б. Образование для калмыков: (Истоки, реалии, перспективы). – Элиста: Калмыцкий государственный университет, 1997. – 220 с.

Рахимкулова М. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. – Оренбург: Яна Вакыт, 1997. – 254 с.

Садыкова Р.К. Роль татарских меценатов второй половины XIX – начала XX века в развитии национального образования г. Симбирска // Симбирский научный вестник. – 2016. – № 1 (23). – С. 180–188.

Салехова Н.Х., Максимова А.К., Харисова Ч.М. Интенсивное обучение татарскому языку. – Казань: Магариф, 1993. – 128 с.

Салихова Н. Мәктәпкәчә тәрбия йортларында җанлы сүз. – Казан: Татгосиздат, 1934. – 65 б.

Саматова Ч. Имперская власть и татарская школа во второй половине XIX – начале XX века (по материалам Казанского учебного округа). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2013. – 239 с.

Саттаров Ш. Кызылармеец әлифбасы. – М.: Дәүл. хәрби нәшр.,1925. – 64 б.

Сафиуллина К.З. Укучыларга патриотик тәрбия бирү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 88 б.

Сафиуллина Ф.С. Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре. – Казан: Хәтер, 2001. – 43 б.

Сибәгатов Р.Г. Башкортстан татарлары. Тел, тарих, мәдәният мәсьәләләре. – Казан: Мәгариф, 2002. – 190 б.

Сукунов Х.Х., Величук А.П. Разработка типовой модели национальной школы (для школ Северного Кавказа) // Педагогика. – 1997. – № 4. – С. 37–44.

Сулейманова Л.Ш. Создание и развитие национальных школ в Башкортостане в послеоктябрьский период. – Уфа: Башкирский государственный университет, 1996. –78 с.

Сыченкова А., Козлова О. «В отношении коренизации вуза сделан значительный шаг вперед»: политика коренизации в вузах ТАССР в

годы первых пятилеток // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2016. – № 3/4. – С. 91–97.

Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 2. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 471 б.

Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 1 т. (борынгы төрки чор – XX гасыр башы) / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2014. – 407 б.

Татар педагогик фикере антологиясе: ике томда. 2 т. (XX гасыр – XXI гасыр башы) / Ред. Ф.М.Солтанов, М.М.Гибатдинов, Л.Р.Мортазина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2016. – 486 б.

Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т. 1. – Казан: ТЭИ, 2008. – 720 б.

Татарские интеллектуалы: исторические портреты / Сост. Р.М.Мухаметшин. – Казань: Магариф, 2005. – 271 с.

Татарстан АССР тарихы. 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 588 б.

Татарстан Республикасында тел сәясәте. Документлар һәм материаллар (20–30 нчы еллар). – Казан: Мәгариф, 1998. – 207 б.

Терегулов Ә.Г. Гигиена (Хыйфзе сиххәт): Тәрбия-тәгълим техникумнары, гомуми урта мәктәпләр өчен дәреслек итеп төзелде. – Казан: Татар. матб. нәшр. комб., 1926. – 328 б.

Терегулов Ә.Г. Гигиена (Макушин, Крафт һ.б. буенча). – Казан: Татиздат, 1928. – 292 б.

Тирән тамырлы Түнтәрем / Төз. Р.Ш.Зарипов. – Казан: Школа, 2008. – 827 б.

Туктамышов Н.К. Билингвизм в современном мире // Татар телендә югары белем бирүне оештыру тәҗрибәсе (1991–2016 еллар). – Казан: КДАТУ, 2017. – 44–49 б.

Тутаев М.З. Октябрь и просвещение. – Казань, 1970. – 444 с.

Тутаев М.З. Развитие народного образования в Татарии (1917–1940 гг.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1975. – 204 с.

Фазлыев Җ. Җәлил хәзрәт дәресләре. – Казан: Идел-Пресс, 2006. – 189 б.

Фасеев К. Вспоминая прошедшее. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1999. – 116 с.

Фасхутдинова Е.Н. Учительство Казанской губернии / ТАССР в 1918 – начале 1930-х годов (по архивным документам): дис. ... канд. ист. наук. – Казань, 2008. – 193 с.

Фахрутдинов Р.Г. Фахрутдинов Р.Р. История татарского народа. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2015. – 407 с.

Фәйзи Г., Сафин М., Сәгъди Җ. Кыскача биология. Югары мәктәп һәм күтәренке типтагы техникумнар өчен. – Казан: Татиздат, 1932.

Фәтхуллин В.Ш. Татар булыйк, дөя булмыйк // Мәшһүр татар галимнәре. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2011. – 406–408 б.

Фәтхуллин В.Ш., Шакирҗанов Р.Ә., Нарбеков А.И. Татар телендә югары белем бирү концепциясен төзү юлында // Языковая ситуация в Республике Татарстан: состояние и перспективы. Ч. 2. – Казань, 1999. – 9–11 б.

Фәхреддинев Р. Болгар һәм Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – 287 б.

Хакимова Р.Ш. Борьба татарской партийной организации за ликвидацию неграмотности среди населения // Борьба КПСС за развитие народного образования и культуры. – Казань: М-во просвещения РСФСР, 1972. – С. 3–30.

Хальфин И. Азбука и грамматика татарскаго языка с правилами арабскаго чтения, преподаваемыя в Императорской Казанской гимназии. – Казань: Тип. Казан. ун-та, 1809. – 168 с.

Хальфин И. Букварь этимологии и лексики татарского языка. – Казань, 1804.

Хальфин И. Любопытные соображения И.Хальфина к просвещению татар. – Казань, 1819.

Хальфин С. Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочиненная казанских гимназий учителем и Адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфиным, и татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях, рассмотренная и одобренная. – М.: Имп. Московский ун-т, 1778. – 52 с.

Ханбиков Я.И. Из истории педагогической мысли татарского народа. – Казань: Таткнигоиздат, 1967. – 232 с.

Ханбиков Я.И. История педагогики татарского народа. – Казань: КГПИ, 1975. – 162 с.

Ханбиков Я.И. Основные направления в развитии педагогической мысли татарского народа в XI–XX вв.: автореф. дис. ... докт. пед.наук. – М., 1968. – 27 с.

Ханбиков Я.И., Шарафутдинов З.Т. История педагогики Татарстана. – Казань: КГПУ, 1998. – 306 с.

Хаплехамитов Р.Б. Национальная интеллигенция и проблемы образования (1944–1960 гг.) // Казанский педагогический журнал. – 2006. – № 5. – С. 49–53.

Харлампович К. Казанские новокрещенские школы (к истории христианизации инородцев Казанской епархии в XVIII в). – Казань: Казан. Император. ун-т, 1905. – 91 с.

Хәйри Ә.Н. Ш.Мәрҗанинең «Мөстәфаде-л-әхбар... китабы» // Шиһабетдин Мәрҗани: Мирасы һәм хәзерге заман. Мәкаләләр җыентыгы. – Казан: Алма-Лит, 2008. – 178–199 б.

Хәким Р. Татар рухы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 392 б.

Хәмидуллин Л. Иганәче Хөсәенов байларның варислары // Гасырлар авазы = Эхо веков. – 2009. – № 1. – 198–205 б.

Хисаметдинова Г.С. Этнообразовательная политика советского государства в 1920–1960-е гг. и состояние национальных школ сибирских татар // Сибирский сборник. – Казань: ЯЗ, 2011. – С. 90–106.

Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогика: педагогик уку йортлары, көллиятләр, гимназияләр, лицейлар өчен уку әсбабы. – Казан: Матбугат йорты, 1998. – 503 б.

XX йөз башында татар әдәбияты / Г.Хәлит, Х.Хисмәтуллин, Б.Гыйззәт. – Казан: Матур әдәбият редакциясе, 1954. – 386 б.

Һадиуллин И.Г. Хәзерге мәктәпкәчә тәрбия системасында милли-мәдәни юнәлеш // Мәктәпкәчә тәрбия: Балаларны милли-мәдәни рухта тәрбияләү. – Казан: Школа, 1998. – 5–10 б.

Шаехова Р.К. Играя – учимся творить. – Казань: ИССО РАО, 1997. – 40 с.

Шаехова Р.К. Педагогические условия и критерии развития творческих способностей дошкольников в игровой деятельности: автореф. дис. ... канд. пед. наук. – Казань, 1999. – 24 с.

Шакиров Р.В. Казанская педагогическая школа во второй половине XX века. – Казань: Матбугат йорты, 1999. – 528 с.

Шамсутдинов Д.З. Татарская национальная школа ТАССР в конце 1950-х – 1970-е гг.: дис. … канд. ист. наук. – Казань, 2014. – 208 с.

Шамсутдинов Д.З., Шайдуллин Р.В. Особенности развития татарской национальной школы в ТАССР в 50–60-е годы XX века // Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. – 2012. – Т. 154, кн. 3. – С. 98–103.

Шамсутдинов Д.З., Шайдуллин Р.В. Татарская национальная школа в СССР в конце 1950-х – начале 1960-х гг. // Симбирский научный вестник. – 2012. – № 1 (7). – С. 87–92.

Шарафутдинов З.Т. Педагогическое пространство татарского народа. – Казань: КГПУ, 2000. – 180 с.

Шарафутдинов З.Т., Ханбиков Я.И. История педагогики Татарстана. – Казань: КГПУ, 1998. – 307 с.

Шәехова Р.К. Иҗади уеннан – укуга. – Казан, Школа, 1999. – 91 б.

Шәймәрданов Р., Хуҗиәхмәтов Ә. Татар милли педагогикасы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.

Шәймәрданов Р.Х., Сибгатуллин Р.Г., Сибгатуллина Ә.Т. Татар халык педагогикасы. – Яр Чаллы: КамАЗ, 1997. – 137 б.

Шәкүрова М.М. Татар телен укыту методикасының фәнни мирасы (XVIII гасыр ахыры – XX гасыр). – Казан: Ихлас, 2012. – 143 б.

Шәмсетдинова Р.Р. Габдулла Сабир улы Ибраһимов-Шнаси – танылган галим һәм терминолог (тууына 125 ел тулуга багышлана) // Татар халкының педагогик фикерен өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре. – Казан: ТФАнең Ш. Мәрҗани исем. Тарих институты, 2011. – 245–249 б.

Шәрәфетдинов С., Нигмәти Г., Мөхәмәтов М. Җәмгыятьне өйрәнү. – М.: Госиздат, 1925. – 152 б.

Шәрәфетдинов С., Нигмәти Г., Мөхәмәтов М. Җәмгыятьне өйрәнү. – Казан: Татиздат, 1928. – 120 б.

Шнаси Г. Мохтасар химия. 1 кис. – Казан: Юл, 1910. – 172 б.; 2 кис. – Оренбург: Вакыт, 1912. – 106 б.

Шнаси Г., Мөштәри Х. Физика. Рабфаклар, II баскыч мәктәпләр, техникумнар һәм партия мәктәпләре өчен дәреслек: Үзлегеннән укучылар өчен ярдәмлек. 1 кис. Механика, сыеклык, газлар. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1929. – 168 б.; 2 кис. Молекулалар гипотезасы, җылылык, магнетизм, электрик. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1929. – 248 б.; 3 кис. Тавыш, яктылык, гомумән тирбәнү хәрәкәте һәм радио. – Казан: Татар дәүл. нәшр., 1929. – 208 б.

Югары уку йортларында татарча укыту мәсьәләләре. – Казан, 1998.

Юзеев А.Н. Просветительская мысль татарского народа (XIX – нач. XX вв.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 2014. – 415 с.

Юзеев А.Н. Татарская религиозно-реформаторская мысль. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. – 287 с.

Языковая политика в Республике Татарстан: Документы и материалы: 20–30-е гг. // Татарстан Республикасында тел сәясәте: Документлар һәм материаллар: 20–30 нчы еллар / Төз. З.Г.Гарипова, Ф.Ф.Исламов, К.М.Миннуллин. – Казань: Магариф, 1998. – 207 с.

Ялалов Ф. Гимназическое образование народов России. – Казань: Магариф, 2002. – 247 с.

# ИСТОРИЯ ТАТАРСКОЙ ПЕДАГОГИЧЕСКОЙ МЫСЛИ

В монографии показаны основные этапы формирования и развития татарской педагогической мысли, проведен анализ системы образования у татар, начиная с древности и вплоть до начала XXI в.

В книге рассматриваются основные формы и методы получения образования у татар в тот или иной исторический период, исследуются вопросы преемственности и традиций, а также в тесной связи с исторической эпохой освещаются и анализируются образовательные реформы, оказавшие самое значимое влияние на развитие системы образования татарского народа. Кроме этого, раскрывается и показывается вклад знаменательных личностей, сыгравших важную роль в истории татарской педагогической мысли.

Авторами монографии рассматриваются ключевые для системы образования татар законодательные акты, раскрываются их цели и задачи, анализируется их реализация, выявляются результаты и последствия этих законов и постановлений для национальной образовательной политики. В монографии выявляется широкий круг проблем, связанный с прошлым и современным состоянием системы образования татарской нации. Осмысление этих вопросов и задач, безусловно, позволит лучше понять и спрогнозировать будущее состояние просвещения и образования, объяснить многие явления педагогической действительности.

Данное исследование станет полезным учителям, преподавателям педагогических вузов и колледжей, аспирантам, студентам, а также всем, кто интересуется проблемами образования и педагогики.

# THE HISTORY OF TATAR EDUCATIONAL THOUGHT

This book shows a main periods and directions of developments of Tatar Educational Thought and practice from the early time till the present days.

Authors analyzed traditional approaches to the education and upbringing cultivated in Tatar society through the generations. The general trend in Tatar educational system and main educational reforms of each of historical periods (Early Medieval, Medieval, Early Modern and Modern) studied, with the detailed analyses of the writings of Tatar educators, textbooks authors, educational policymakers and experts; the official documents and the legislations and legislative projects in the field of Tatar education also examined. The Tatar folklore and writings of Tatar poets, writers and Islamic theologians and mystics (Sufis) is also significant sources of Tatar Educational Thought (especially for Early Medieval and Medieval time) and they was also scrutinized by authors. Using the wide range of the historical and educational sources, authors analyzed not only quantitative and qualitative development and changes in the system of education, but pay rather more attention to the development and changes of the Educational Ideals of Tatar society, main values and Ethos of the Tatar school in historical prospective. In special chapter the official educational policy toward the Tatars, which existed in Russian empire and Soviet Union analyzed, as well as the response of Tatar community and educators to official policy of the state (such as Christianization, Rusification etc.).

The last chapters gives an general overview of modern development of Tatar system of education and Didactics in Tatarstan Republic and introduced you a contemporary educational discourses in Tatar society, with the variety of ideas, theories and concepts of the future development of Tatar education.

**История татарской педагогической мысли**

*На татарском языке*

**Татар педагогик фикере тарихы**

*Монография*

Компьютерга салучы – *Л.М.Җиһангәрәева*
Техник редакторлар – *Р.Р.Абызова, А.Ә.Зиннәтуллина*

Оригинал-макет ТФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институтында хәзерләнде
420111, Казан ш., Батурин ур., 7

Басарга кул куелды 24.07.2017  Кәгазь форматы 70×100 $^{1}/_{16}$
Шартлы басма табагы 19,25   Тиражы 350 данә

Басылды ТФА Ш.Мәрҗани исем. Тарих институтының
күбәйткеч үзәгендә
Тел. (843) 292 18 09, 250 99 50

Сайт
Института истории
Академии наук РТ
Татаровед.рф